ISSN 0206–4189
Индекс 73210

12+

# КАЗАН УТЛАРЫ

6.2015



№6 (1112) 2015

# БУ САНДА:



**Лирон ХӘМИДУЛЛИН,**
**Булат ХӘМИДУЛЛИН**
**«Җиңүләр җиңел бирелмәде»**

«1939 елның августына әйләнеп кайтыйк. Шул айның 23ендә фашистик Германия белән СССР арасында «дуслык» килешүе төзелә. Тарихта ул килешү бу илләрнең шул вакыттагы Тышкы эшләр министрлары И.Риббентроп белән В.М.Молотов исемнәренә бәйле рәвештә «Молотов-Риббентроп пакты» дип тә йөртелә. 1941 елгы сугыш башланган көннән соң ук диярлек Совет илендә бу килешү-пактны бик сирәк искә алдылар. Ә аның яшерен, күрше илләрне бүлешүгә багышланган пункт-параграфын искә алу гомумән дә тыела иде».

155

# КИЛӘСЕ САНДА:

**Рәгать ХӨСӘЕНОВ**
*(Лениногорск муниципаль районы башлыгы)*
**«Лениногорскига – 60 ел»**

«Лениногорск — Татарстан нефтенең туган җире. Шәһәрнең барлыкка килүе, үсүе Шөгер, Ромашкино нефть ятмалары ачылу белән бәйле. Быел Лениногорск шәһәренең — 60, «Лениногорскнефть» идарәсенең 70 еллыгын бәйрәм итәчәкбез».



*«Казан утлары» журналының киләсе саны шушы вакыйгага багышлана. Анда шәһәрнең, районның елъязмасын яктыртачакбыз, атаклы кешеләре, аларның данлы эшләре турында сөйләячәкбез, шушы туфракта туган, шушында яшәп иҗат итүче каләм ияләренең иҗат үрнәкләрен тәкъдим итәчәкбез.*

www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Марсель ГАЛИЕВ. Су каргышы. *Шигырьләр.* ....3
Әнәс ХӘСӘНОВ. Бәхет кайда оя кора. *Роман.* ....9
Лена ШАГЫЙРЬҖАН. Туган телең ул бит — могҗиза. *Шигырьләр.* ....81
Шамил ХӘНИФОВ. Кеше булып калырга. *Әдәби-документаль бәян.* ....86
Мөхәммәт МИРЗА. Кысыр Гариф. *Поэма-кыйсса.* ....123

*100нче бит:* Факил САФИН. Сугыш сөреме җанда утыра. ....100

**СӘНГАТЬ**

Югары сәнгатькә юл *(Казан дәүләт консерваториясе ректоры Рубин АБДУЛЛИН белән Илфак ИБРАҺИМОВ әңгәмәсе).* ....142

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Фәрит ХАТИПОВ. Галимнең әдәби-теоретик фикер дөньясы *(Гали Халитнең тууына 100 ел).* ....146
Рифат СВЕРИГИН. Остаз күрсәткән юлдан. ....148

**ХӘТЕР**

Әлфия ШАМОВА. Сезнең язмыш сугыш уты белән үрелгән. ....151
Лирон ХӘМИДУЛЛИН, Булат ХӘМИДУЛЛИН. Җиңүләр җиңел бирелмәде. *Тарихи-публицистик язма.* ....155

**УКУЧЫ СҮЗЕ**

Әсма КАШАПОВА. «Казан утлары» яктысы. ....163

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Рәдиф ГАТАШ. Бәшири «мырау»лап кына язганмы? ....166
Фәйрүзә МӨСЛИМОВА. Сурәтләрдә – тарих... ....170

**ШАЯН СӘХИФӘ**

Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ....172

**АК ҖИЛКӘН**

Гадел КУТУЙ. Рөстәм маҗаралары. ....175
Руфинә ГАБДРАХМАНОВА, Алсу САЛАХОВА. *Шигырьләр.* ....179
Айгөл АБДРАХМАНОВА. Чана кайда?! *Хикәя.* ....180
Хикәя яза аласызмы? *(Динәрә ГЫЙЛЬФАНОВА, Илфат ӘХМӘДУЛЛИН, Рәзинә ӘХМӘДУЛЛИНА).* ....183
«Танымыш» дәресе. ....187

«Казан утлары» архивыннан. *Сәхифәне Равил ФӘЙЗУЛЛИН әзерләде.* ....140, 164
Мәкаль өмәсе. ....189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары — 222-09-83 (өст. 1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст. 1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст. 1267).*
✆: **Факс** — (843) *222-09-83 (өст. 1612).*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 28.05.2015, график буенча 28.05.2015.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-1536. Тираж 4004.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2015 ел



Марсель
Галиев

# СУ КАРГЫШЫ

## Бәгырь авазы

Җилкенсәк тә, җиңелсәк тә, җигелсәк тә —
Барыберме сезгә?
Безгә барыберме?!
Хан китсә дә, Кан китсә дә, Дан китсә дә —
Барыберме сезгә?
Безгә барыберме?!

Тиенсәк тә, тилерсәк тә, тибелсәк тә —
Барыберме сезгә?
Безгә барыберме?!
Көн китсә дә, Дин китсә дә, Ден китсә дә —
Барыберме сезгә?
Безгә барыберме?!

Сөелсәк тә, сөрелсәк тә, сибелсәк тә —
Барыберме сезгә?
Безгә барыберме?!
Җир китсә дә, Ил китсә дә, Тел китсә дә —
Барыберме сезгә?
Безгә барыберме?!

Учарланып, юашланган учакларның
Чал көлендә бөгәрләнеп калырбызмы?
Ут хәтере сүнсә әгәр, су хәтере кала —
С у с ү р ә с е н аңлап, сабак алырбызмы?
Ходай биргән Милләт дигән тажны җуеп,
Киләчәккә гидай булып барырбызмы?!

Барыберме сезгә?
Безгә барыберме?!

Марсель ГАЛИЕВ (1946) — *Татарстанның халык язучысы; «Догалы еллар», «Рух», «Талисман» һ.б. исемдәге утыздан артык китап, алты томлык «Сайланма әсәрләр» авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Ханчишмә рухы

*Бала-сумы, Ана-сумы —*
*Үз ярына таман су.*
*Акмый калган сулар булса —*
*Ямансулап, талган су.*

Уемланып, алкаланып,
Уелланып аккан су.
Башкаланың Баш чишмәсе —
Үз кадерен тапкан су.

И Ханчишмә, тамчың саен
Кояш көлеп баккан су.
Идел-Йортны ут ялмагач,
Кан-яшь түгеп аккан су.
Ярасына, язмышына
Авыр туфрак япкан су.

Гасыр катламнары аша
Хәтер ярын каккан су.
Төн — уятып, көн — оялтып,
Чор күзенә баккан су.

Җан сулышын саклый белеп,
Җир астында чыдар су.
Елдырым-шам кылыч булып,
Ташлар ярып чыгар су!

## Су кыйссасы

*«Иман китереп, игелекле гамәл кылгучыларга чишмәләре агып торган җәннәтләр хозуры булачак, дип кешеләрдән сөенче ал...»*
Коръән. Бәкара сүрәсе, 25 аятьтән

Кизләү күзе тирәндә ачыла.

Тома караңгылыкта... җир җелеге аша чемердәп саркый да, каты токым уентыгында яралган су бөреләре нәзберек челтерәп ачыла, таҗлары киерелә башлый... Аннары... куәтләнеп, нәни тояклары белән тибенә-тибенә, туң-сыкылы ташларны чатнатып, катлы-катлы җир сүрүен умырып, ирек-иркенлек даулап, тәкатьсез үҗәтлек белән өскә, биеккә — яктыга таба юл яра.

Нинди омтылыш, нинди тыелгысыз дәрт бу?

Кайсы халыкның тәнен-җанын сугаруда аның саф тамчылы теләге?

Дөнья йөзендә тәкъдир ана рәхмәтле кыйбла юраганмы?

Юрамаган очракта да, су шаукымы чигенүне белми.

Туфани дәвер тавы — хәзерге Богылтау — җир күзәнәкләре аша Сабый су салкынын тоя, текә яры кизләү туасы бөек мизгелне тулгаксып көтә. Яшел үлән keләмендә күләгә сирпеп үскән сыгылма гөл-чәчәкләр с ө е н ч е алырга әзер...

Менә ул — илаһи мизгел!

Кинәт ургылып чыккан лайлалы ташкын, — йә Хода, нинди якты Җиһан! — искиткеч нурлылыктан коты алынуданмы, соклануданмы — чарпаланып, елтыр бөртекләргә таркала... Аннары... Болганчык төсеннән кыенсынып, үлән арасында оя ясарга җыенгандай, бер тәлгәшкә җыелып түгәрәкләнә дә... салмак кына тона, чистара, сафлана, җетеләнә башлый.

Тургайлы күк, тугайлы җир шаһит: кизләү-чишмә гомер буе шушылай аккандыр сыман. Ургылып чыккан төбендә — толымланып, үлән арасыннан, салмакланып, җем-җем тәнкәле, үтә күренмәле елан сыман ыспай бормалана-бормалана килә дә ул, сөзәк ярдагы Үги ана яфраклары астыннан челтер-чырыйлап, мәтәлә-мәтәлә төшеп, олы елгага — Казансу куенына назланып сыена.

Кизләүнең кендеге өзелми.

Тамыры, тирәндә тармакланып, олы дәрьялар хасиятенә тоташа. Шулай итеп, С у к ы й с с а с ы, С у с ү р ә с е язылa башлый.

Богылтауда Казан атлы ташкала, ханлык тотар Башкала нигезен салу дәвере килә. Эчке һәм тышкы кирмән диварлары төзелә. Манаралар калка. Азан моннары Күк гөмбәзен биегәйтә. Хан сарае түбәсендә җилфердәгән сары байракта канатлы елан, гайрәт чәчеп, очып китәр шикелле «бәргәләнә».

Олы Мөхәммәд хан кизләүнең кашагасын ак мәрмәрдән, сәнгати зәвык белән, нәкышләп, иң өскә ак лачын сурәтен уйдыртып эшләткәннән соң, Башкаланың баш кизләүе — Ханчишмә исемен ала.

Тәме — көмеш, җыры — көмеш, тәнгә сихәт бирмеш Ханчишмә халык телендә «Изге» дигән мәртәбәгә ирешә.

Әгәр су телен тоя алсак, «Әүвәлгенең дә әүвәлгесендә минем каршымда Атилла үзе тезләнде!» — дигән фалнамәгә төшенер идек. Әйе, Көн баешы илләренә үтеп барышлый, һун бабаларыбыз башлыгы — атаклы саргаскәр Атилла, Богылтауга тукталып, тирмәләр кордыргандыр. Җәнлекләр такырайткан бормалы сукмактан ул, кизләүгә төшеп, сусавын баскандыр да... Ерак юлга кузгалыр алдыннан, дымлы тире белән тышланган чүлмәкләргә су тутырып алырга боергандыр.

Мәшһүр шагыйребез Кол Гали ерак илләрдән — Шәрыктан килгән ашуглар белән сәяхәт кылып йөргәндә, кыргый куаклар күләгәсендәге бу кизләү янында тукталып истирәхәт кылмаган да, язылачак дастанына су тәменә тиң илһамлы сүзләр теләнә килмәгәндер димә:

*Гәүһәр таш ул, ләкин һәр таш гәүһәр булмас,*
*Тикмә кеше гәүһәр кадрен аңлый алмас*[1].

Болгарда яшәп алган чорында Идел-Чулманның бөдрә урманлы ярларыннан үз биләмәләрен карап йөргән Бату ханны да кизләү сукмагы үзенә тарткандыр. Теш камаштыргыч салкын суын татып карап, тәменнән мәмнүн булып калуын гел исенә төшергәндер әле...

Сөембикә-ханбикәнең дә соклангыч чибәрлеге Шәрык илләреннән сәүдә кәрваннары белән кайтартылган затлы ислемайлар хушлыгыннан гына түгел, ә без белгән Ханчишмә суының догалы тылсымы килешкәнгәдер бәлки...

Көнне сәламләп, кояш чыга. Ил яши. Тормыш кайный. Мәйданда фанфаралар яңгырый. Кирмән капкалары вәкарь белән ачыла да ябыла. Урам ташларын кытыклап, ат тояклары тупырдый. Һәммә тарафтан Казанга илчеләр, мосафирлар, сәүдәгәрләр, төрле һөнәр ияләре туктаусыз килә-китә тора.

...Елларга йомгакланып гасырлар уза. Ханчишмә, уйнап-көлеп ага да ага. Берни дә сизми әле, берни дә сизенми... Казан ханлыгының кояшы баю сәгате, тәкъдирнең үз ихтыярыннан тыш, инде билгеләнгән. Бәхеткә юралган ил нигезенә, менә ничә кабат, афәт яный. Мәскәү кенәзлеге монарчы күрелмәгән көч туплый, үз күршесендә имин дәүләт яшәп ятуын кичерә алмый (бу хасият аңа тумышыннан һәм гомерлеккә бирелгән).

Казан күген авыр болытлар баса, кирмәнне кара чиру уратып ала. Явыз Иван тәреле байраклар астында хәлиткеч һөҗүмгә күчә. Көчләр тигезсез. Ядгәр ханның утыз мең укчысына каршы йөз илле мең укчы куела. Әмма сугыш кануны катгый: көче азрак якны — аклый да, көче күбрәк якны хаклый да алмый. Аның өчен ике як та уртак фаҗига корбаны...

Канкоеш сугыш берничә атнага сузыла.

Мәкерле алым куллану, җир астыннан казып килеп, кирмән диварын шартлату

[1] «Йосыф китабы»ннан

— Казаннық калканын ача. Коточкыч шартлау дулкынынннан җир тетри, диварлар актарылып калка, ташы-ташка аерылып, йөзтүбән ава. Әгәр Ханчишмәнең йөрәге булса, бу дәһшәтле мәлдә йөрәге ярылыр иде. Астан бәргән яман шартлау гарасатыннан бәллүр чишмә, өскә чөелеп, аягүрә баскан килеш киселә, җаны убыла.

Ишетүче булды микән Ханчишмәнең соңгы аһын?!

Кем ишетсен... Илләр көл ителгәндә, ирләр кол ителә... Казан күкрәгендә — канлы мәхшәр. Сугышмы бу — суешмы? Орышмы бу — кырышмы?! Йөзгә-йөз... Үчкә-үч... Көчкә-көч капма-каршы килә... Атыласы — атыла. Тураласы — турала. Сатыласы — сатыла... Адәм җаннарын рәхимсез кыя-кыя, кылыч йөзләре тупаслана. Кара-каршы очкан ук яңгыры, бәрелешеп, очкын чәчә. Сөңге очлары шартлап сына. Атлар, ахак кан кешнәп, күкрәгенә гөрселдәп ава. Байраклар таптала. Дуамал көч дуенында, утлы итәген бөтереп, Иблис бии, шаша, тантана итә. Иблис каһкаһәләп көлә...

Йөзенә кан чәчрәгән Кояш, бу вәхшилектән имәнеп, офык читенә хәлсез кырынайган.

... Сугышның да соңы була. Тынлыгы да шомлы була. Исән калган яугирләрнең чатнаган иренендә бары бер ыңгырашу өне: су... су... су...

Ханчишмә кабере өстенә эңгер караңгылыгы ишелә...

Су — тереклекнең бисмилласы.

Адәми зат Ана карынында су сүрүе эчендә ярала. Судан гына диярлек торган адәми зат үзе дә бит, үтәли күрә алсаң — тере су һәйкәле, тере су балбалы.

Милләт, төс-кыяфәт, холык-фигыль ягыннан төрле булсак та, без — кешеләр, бу җирдә Тәңре бар иткән уртаклыкка, с у  к а р д ә ш л е г е н ә  и я  и к ә н б е з...

Суга төкергән, димәк, үз-үзенә төкергән. Мондый бәндәне борынгылар җәзага тартканнар.

Кизләүгә кизәнгәннең заты корыр, дигәннәр кадимиләр. Шулайдыр! Ханчишмәне шартлатырга боерган рус кенәз-воеводаларының Казан-Мәскәү сугышыннан соң кичергән язмышы гыйбрәтле: аларның берсе дә мантымаган... Каланы яклаучыларны сусыз калдыру коткысы белән Ханчишмәнең төгәл урынын русның гаскәр башлыкларына күрсәткән сатлыкҗаннарның нәсел-нәсәбе дә, кинәнеп яшәргә дип, Мәскәү куенына күчкәч, эт тибенгесендә калып, гаип булып бетә.

Залимнәрнең залимлеге аңлашыла, әмма мондый хакыйкать бар бит әле:

*Җимергән як — бер гөнаһлы булса, җимерткән як — ун гөнаһлы.*

Нәләт корымы, аямыйча, ике якка да төшә.

Хәтеребезне яралап торган, әлеге тарихи шартлау гарасаты — дәһшәтле манзара, к и с ә т ү л е  я ң г ы р а у  б у л ы п, гасырлар аша һәр татарның үкенечле йөрәгенә сулык-сулык сугачак әле! Әмма халкыбызның тамак ялына, кесә малына ялманып яшәүче кушканга-куштан катлавы отыры калыная бара. Үз ихтыяры белән татарлыгын үзе буа барган әлеге хыянәтчел кавем — б у  я ң г ы р а у г а — с а ң г ы р а у шул инде, с а ң г ы р а у...

Су сүрәсен чем-кара Җир күге ала,
Су каргышы Җир өстендә сыктап кала...

## Казан нигезендә

Берни булмагандай, гасырларның
Дулкын-дулкын агылып барышы.
Берни, димә, яфрак өзелсә дә,
Сискәндерә моңсу кагынышы.

Кем ишетә: Җир өстендә түгел,
Җир астыннан килә су тавышы.
Җир бәгыреннән су сыктавы килә,

Хәтәр аның безгә кагылышы:
Су каргышы — Казан нигезендә,
Казан нигезендә — су каргышы...

Әллә шуңа чүгеп калганбызмы?
Күндәмлектән мәмнүн кешеләр без.
Башкалада кайчак башны чөйсәк,
«Кисекбаш»ны искә төшерәбез...
Ә хыялда... шундый адарынып,
Чама белми, ташып түгеләбез:
Хаҗи да без монда, казый да без,
Хуҗа да без монда,
түгел дә без...
Асыл холкын җуйган халык булып,
Бүтән телгә күчеп сүгенәбез.
И генә без, ахры, и генә... без...

Су каргышы төшә — йөзебезгә,
Су каргышы төшә — өнебезгә
Су каргышы төшә — төнебезгә,
Су каргышы төшә — көнебезгә...

Әй Ханчишмә! Суың шундый булган:
Җанга шифа, тереләрдән-тере!..
Раббы җирдә мең-мең кизләү ачкан,
Һәр кизләве Аның — бердәнбере!
(Саксыз кизәнденме — көт «әҗер»ен).

Терек суын җуйган халыкныңмы
Дәхеле бар гадел бәхетенә...
Ваемсызлык юшкыннарын кагып,
Тәвәккәллик чишмә ләхетенә...

Су каргышы төшә — буебызга,
Су каргышы төшә — уебызга,
Су каргышы төшә — телебезгә,
Су каргышы төшә — денебезгә.

## Имле дога кыла алсак

Су рәнҗеше... Су ләгънәте... Су каргышы...
Бу зынҗырдан безгә ничек арынырга?
Канга күчеп, күпме дәвер нәгърә орган
Бу гөнаһтан безгә ничек кагынырга?

Халык инде элеккеге халык түгел,
Тетрәп тормый фидаилар муллыгыннан.
Ә шулай да... дәрт җитәр бит, убылган су —
Ханчишмәне коткарырга коллыгыннан.

Изге суның мәрхәмәтен уяталсак,
Якты дөнья йөзләренә кайтаралсак,
Сәҗдә китеп, имле дога кыла алсак,
Башны чөеп, бөтен буйга калка алсак —

Көмеш шифа йөгермәсме тәнебезгә,
Раббы — нурын индермәсме кальбебезгә?..

Җир-суларның ярлыкавы мисалында
Бер яктыру балкып алыр Казанымда...

## Халык–дәрья ярыннан

Бер очынып, бер ачынып, бер ачылып,
Шуны әйтик догалы сүз азагында,
Юк чагында түгел әле, бар чагында:
«Чыбыркылыйк!» үзебезне кайчагында.

Идел-Урал, Җаек-Себер сыйган уртак
Дөньябызга кысыр ятьмә үрмик әле;
Хакыбызны, атыбызны, халкыбызны
Төрләндереп, телем-телем бүлмик әле!

Бу — минем җан, бу — минем тән, бу — минем кан —
Ничә бөртек татар яши җир йөзендә? —
Ниһаять, бер гадел санга килик әле!
Саекмыймы халык-дәрья Ил күзендә? —
Һәр тамчысын учта чөя белик әле;
Сыналганда кырыс язмыш бизмәнендә,
Үткен дала рухын җуя күрмик әле,
Чит кан кертеп, тере килеш үлмик әле!

Без бит атлы дәверләрнең каһарманы,
Күп кавемне кызыктырган кадер-данны
Хәтерсезлек каберенә күммик әле.

Үчләшсеннәр, көнләшсеннәр, үлчәшсеннәр —
Булганбыз ла! Булабыз да! Булачакбыз!
Мең елдан да т а т а р булып туачакбыз!

## Соңгы нота

Су сүрәсе... Меңьеллыклар аръягыннан
Килә — сәмави аң Җиһан ярларыннан.
Сеңә — кайнар тынлы һәрбер Сүзебезгә.
Санлаганнар өчен, сынмаганнар өчен
Тәфсиренең сере — Ана телебездә,
Иң борынгы бөек телебездә!

Тик үҗәт бер сорау һаман гаҗизләнә:
— Барыберме сезгә?
                    Барыберме безгә?!



Әнәс Хәсәнов

# БӘХЕТ КАЙДА ОЯ КОРА

РОМАН

*Тормышның максаты — бәхет...*
Теодор Драйзер

*Көпә-көндез ут элдереп кеше эзләгәнче, аны үзеңдә тап.*
А.Давидович

## Беренче кисәк

### I

Алар Тәнзилә белән һич көтмәгәндә, уйламаганда таныштылар. Салкынча бер көзге кичтә, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында мәшһүр җырчы концерты бара иде.

Равил Илһамның җырлавын бик ярата, аның концертларына бармый калмый, мөкиббән китеп тыңлый, учлары авыртканчы ихлас күңелдән кул чаба, җырчының кабат-кабат чыгуын таләп «афәрин» дип залны яңгырата иде. Менә бу кичне дә Равил күңеленең әллә кайсы төпкелләренә үтеп кергән моңга бирелеп, күршесендә утырган кызның кулын каты итеп кысканын сизми дә калды. Җибәрегез, зинһар, авырттырасыз ич, дип пышылдаган тавышка борылып караса, күрше кәнәфидә утырган алсу күлмәкле, дулкынлануы, ләззәт кичерүе йөзенә ташып чыккан чибәр кызның йомшак кулын чытырдатып кысқан икән ләбаса.

— Ай, зинһар, гафу итегез... гафу, — диде Равил, кыенсынып. — Җырга бирелеп онытылып киткәнмен. Мондый иркен сулыш, аһәнле, киң колачлы вокаль осталык аңа каян килә икән, ә?

— Әйе шул. Сокландыргыч. Үзем дә тәмам дөньямны онытканмын, күр инде, күр инде сезнең кәнәфигә авышып беткәнмен ич.

— Илһам җырлаганда, халкыбызның авыр тарихы, уй-хыялы моң булып агыла, күңелләрне әсир итә, — диде Равил урамга чыккач. Аннары карашы белән кызның озын куе керфекләре артына яшеренгән кара күзләрен, киң маңгаендагы карлыгач канатыдай сызылып киткән кашларын, грек кызларыныкына охшаган туры борынын, энҗедәй балкыган ап-ак тешләрен сыйпап узды.

Әнәс ХӘСӘНОВ (1935) – *шагыйрь, прозаик, тәрҗемәче. «Җырым – ал җилкән», «Коязлы яңгыр», «Әнис алмалар» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, ТР Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

— Минем өчен бүгенге кич икеләтә бәхетле, онытылмаслык кич булды, — дип өстәде.

— Дөрестән дә, концерт бик матур булды. Илһам җырлаганда, тормыш ваклыклары онытылып тора, хисләр өермәсе әллә нинди ераклыкларга алып китә. Сезнен дә шулаймы?

Егет белән кыз әллә кайчангы танышлар кебек, концерттан алган тәэсирләре рәхәтендә урам буйлап шактый озак йөрделәр. Кыз үзенең туңа башлаганын сизгәч кенә:

— Ярар, хушыгыз. Мин кайтып җиткәнмен икән, — дип туктап калды.

— Хушыгыз, хуш. Үзегезгә рәхмәт. Шундый матур концерттан соң сездәй чибәр кыз белән уртак хисләр бүлешү үзе бер бәйрәм.

— Сез әдәбиятчы, ахрысы. Сизелеп тора, — диде кыз, Равилнең балкып торган елмаюлы йөзенә карап.

— Әйе, мин педагогия институтында филфакта укыйм. Ә сез?

— Мин авиация институтында, КАИда. Соңгы курста.

— Мин дә быел бетерәм. Сез шәһәр кызымы?

— Шулай дисәң дә була. Авылда туганмын, җиде яшьтән әни Казанга алып килгән.

— Ә мин чын авыл егете. Әти-әни авылда яши.

— Ә минем әтине Себер якларына эшкә җибәргәннәр дә, ул шунда югалып калган.

— Алай икән... Була андый хәлләр. Карагыз әле, ярты шәһәрне әйләндек, ә исемегезне сорамадым.

— Тәнзилә мин. Күпләр Зилә дип кенә йөртәләр.

— Ә мин сезне тулы исемегез белән атап йөртермен, яме, Тәнзилә.

— Ярар, очрашсак. Ә сезнең исемегез ничек?

— Равил. Сезнең белән танышуыма бик шатмын, Тәнзилә. Театрларга, концертларга бергә йөрсәк иде, чакырсам, каршы килмәссезме?

— Күз күрер. Исән булыгыз.

Тәнзилә-Зилә баскыч буйлап ике катлы агач йортның өске катына күтәрелде дә, кулын изәп күздән югалды.

Равил трамвайга утырып тормады, тулай торакка җәяүләп кенә элдертте.

Күңеле күтәренке. Шулай булмыйча, нинди чибәр татар кызы елмаеп, кул биреп хушлашты. Күз күрер, диде, димәк, әле тагын очрашырга өмет бар. Равилне күпсанлы кибетләрнең аллы-гөлле неон утлары җемелдәшә-җемелдәшә озата кайтты. Аның каршысына очраган кешеләрнең барысын да кочасы, бүгенге шатлыгын уртаклашасы килә иде.

Тәнзилә кыстатып тормады, Равил чакырган спектакльләргә, концертларга, дискотекаларга бик теләп йөрде. Беркөнне әнисе белән дә таныштырды. Халидә апа Равилгә:

— Кая ашкына икән бу бала дип уйланып кала идем, синең янга икән, — диде сораулы карашы аша.

Аннары сүзен шәрехләп тә куйды:

— Тәнзиләне әйтүем... Ярар, шуны да онытмагыз: күз тиз төшкән җирдән күңел тиз кайта. Шулай булмасын, бу икегезгә дә кагыла.

Тәнзиләнең йөзенә күләгә кунды:

— Синең кешене беренче генә күрүең, әни, инде үгет-нәсыйхәт тә бирә башладың...

— Заманында без дә яшь идек, кызым. Яшьлек тиз уза. Халык юкка гына «кызлар үсә — гөл була, гөл яндымы — көл була», димәгән. Мин бит сезгә яхшылык кына телим.

Равил Халидә апага ихлас күңелдән рәхмәт әйтте. Аның үз әнисе дә һәрвакыт гел яхшылыкка, мәрхәмәтлелеккә, миһербанлыкка өйрәтте, Равилгә дә, энесе Рифатка да әтиләрен үрнәк итеп куйды.

***

Ильяс пәйгамбәр чыбыркысын шартлатып, бар җиһанны алтын кояш нурларына күмде. Шагыйрь әйтмешли, «март аеның нечкә билле җиле сузылып ятып җиргә» туйганчы кар ашады. Барча җан ияләрен дулкынландырган җир исе аңкытып апрель дә узып китте. Чәчәкле майның эссе бер көнендә Равил Тәнзиләсен су коенырга чакырды. Яшьләр үзәге каршындагы пляж кызлар, егетләр тавышыннан гөрләп тора иде. Әйтерсең лә бөтен шәһәр яшьләре шушында җыелган. Равил Тәнзиләсен купальниктан гына күргәч, таң калды. Тәнзиләнең йөзе генә түгел, ап-ак тәне, сыгылып торган зифа буе, нечкә биле, аккошныкыдай озын муены искиткеч гүзәл иде. Калку күкрәкләре аяк атлаган шәпкә сикереп куя. Озын аяклары Микеланджело сыннарыннан гына төшкән диярсең — төз, матур. Үз гүзәллеген үзе беләме икән ул, дип уйлап куйды егет. Әлбәттә, беләдер. Әнә ич тирә-яктан күпме егетләр, кызларның сокланып карап калганын ул күрә, сизә, шуңа күрә вак-вак атласа да, төз аяклары сыгылып-сыгылып ала.

Соклanudан авызын да ябарга оныткан Равил янына килеп җиткәч, Тәнзилә, елмаеп:

— Башта бераз кызынабызмы? — дип сорады, егетнең җавабын да көтеп тормыйча, зур сөлгесен ком өстенә җәйде дә сузылып ятты. — Әйдә, ят минем янга.

Ятты Равил. Тик... Нишлисең бит, яшь тәннең кайнарлыгын тыеп була димени? Әйләнеп ятып та карады, торып утырып та карады, аптырагач гәүдәсен кайнар ком белән күмәргә тотынды. Җитмәсә, алар янында тыз-быз йөрүчеләр ешайды. Күзләре чекерәйгән. Булмады, Равил сикереп торды да, мин коенып киләм, дип елга ягына йөгерде.

Ул урап килгәндә, Тәнзилә туп сугучы бер төркем егетләр, кызлар арасында чырык-чырык килеп уйнап йөри иде. Әле уртага чыга, әле читкә төшкән тупны алырга йөгерә, һаваны ярып кычкырып ала, шаркылдап көлә, шаяра. Равилнең читтән генә карап торганын күргәч:

— Равильчик, әйдә, кил монда, кушыл безгә, — диде. Ул арада туп Равил янына килеп төште. Ул аны бар көченә сугып читкә очырды да киемнәре янына китеп барды.

— Уф, арыдым, — дип, бераздан аның янына Тәнзилә дә килеп ятты. — Әйдә, коенабызмы?

Равил эндәшмәде.

— Әйдә, коенып киләбез, дим. Нишләп сөмсерең коелды әле? Әллә үпкәләдеңме?

— Мин сине кычыткан чыпчыгы дип белми идем.

Тәнзилә җавапка кесәгә кереп тормады, авызын турсайтып:

— Мин дә сине үпкәчән дип уйламый идем. Мин үпкәлисе урынга... Үзең мине алып килдең дә ташлап киттең. Кем шулай эшли инде?

Равил монысын болай ук тирәннән уйлап бетермәгән иде шул. Кызлар күңеле төпсез диңгез, каян белеп бетерәсең, ди.

— Әйдә, алайса, тагын коенып килик.

Балалар кебек чыр-чу килеп бер-берсенә су чәчрәтеп уйнап туйгач, янә сөлге өстенә килеп яттылар. Яннарыннан кыска гына буйлы бер кыз узып китте. Тәнзилә:

— Равил, әйт әле. Син минә егет кеше. Башта кызларның битенә игътибар итәсеңме, әллә аякларынамы? — дип сорады.

Равил гажәпкә калды:

— Син әллә мине «сердцеед» дип беләсеңме?

— Юк ла. Менә миңа чибәрем дисең бит.

— Аңладым. Кешенең йөзе матур, ә аяклары кәкре икән, соклана алмыйсыңдыр инде. Төз аяк, ямьсез йөз дә сокландырмыйдыр. Сөйкемлененң йә юләр, йә усал булуы да ихтимал ич әле. Андыйлардан ерак йөр дип тә әйтәләр бит.

Тәнзилә көлә башлады:

— Син әдәбиятчы гына түгел, философ та икәнсең. Кешегә эчке матурлык та кирәк дисең инде. Алайса, әйт әле, менә мин матурмы?

Равил үзләренең кайда икәнлеген дә онытып, Тәнзиләне үбә башлады:

— Син бөтен яктан да матур, Тәнзилә. Күз генә тимәсен. Йөзең дә, аякларың да. Һәм... Мин гел синең күзләреңә батып үләрмен ахрысы дип куркып йөрим...

— Син үзең дә төшеп калганнардан түгел, Равил. Дулкын-дулкын чәчләрең... Кызларныкыдай зур күзләрең. Кап-кара мыегың үзе генә ни тора.

***

Әй, ни-нәрсә икән ул мәхәббәт дигән илаһи хис! Йөрәгеңә канатын җилпедеме, бар дөнья гүзәллеккә чума, кешең очып кына йөри, табигать гел елмаеп тора, бакчалардагы агачлар, куаклар, үләннәр аңлатып бетерә алмаслык искиткеч сергә төренә, урамнар, йортлар сихри нурга күмелә. Бу изге хис күңелеңдә тамыр җәйдеме, моңа кадәр гап-гади булган нәрсәләр олы мәгънә ала, көләсе, җырлыйсы, мәңгелек күкләргә очасы, кешеләргә кочак-кочак йолдызлар өләшәсе килә. Кояш, ай якыная. Җаның-тәнең ихтыярсыз сөйгәнеңә ашкына, аның гүзәл елмаюыннан, кайнар сулышыннан изри.

Менә Равил дә шундый халәттә, җылы, матур язгы кичтә өзелеп сөйгән Тәнзиләсе белән Галиәсгар Камал театры янында тын гына балкып яткан күлгә, яр кырыенда шатланып-куанып йөзеп йөргән үрдәкләргә, йомшак йон йомгакларга охшаган нәни бәбкәләренә карап, назлы рәхәтлеккә талып басып тора. Сөйгәненең йомшак кулыннан аның йөрәгенә кайнар агым ага, мең төрле ислемайлардан тәмлерәк тән исе аңын томалый. Егетнең кулы сөйгәненең биленә ята, кыз аны йомшак кына читкә этәрә. Сизелер-сизелмәс бу хәрәкәт Равилнең хисен көчәйтеп кенә җибәрә — кыз әдәпне белә, әмма бераздан кул янә аның биленә ята. Бу юлы кыз да аны этәрми, киресенчә, гәүдәсе белән егеткә сыена төшә.

Бу мизгелдә Равил башына бер уй килә. Ничек ул бу гүзәллекне күрмичә, белмичә, татымыйча яши алды икән, ничек институтка укырга йөргән, ашаган-эчкән, йоклаган?

Ә реаль тормышның үз кануннары, ул сине мәхәббәт дулкынында тирбәләсең дип тормый, бик тиз үз эзенә төшерә. Узынма, янәсе. Әле хәзер дә кайнар хис кочагында изрәгән Равил кинәт сискәнеп китте, кемдер арттан килеп башын ике куллап кысып тотты.

— Җә, ярар, җибәрегез, биреләм. Болай барыбер таный алмыйм, — диде Равил.

— Рамил, син бит бу! Исәнмесез! Исәнме, Тәнзилә. Югалган кеше табылган икән.

Равил борылгач аптырап калды, бу кыз таныш түгел иде. Ул үзе дә уңайсызланып әле Равилгә, әле Тәнзиләгә карап алды. Равил дә сөйгәненә сораулы караш ташлады.

Тәнзиләнең йөзендә дә көтмәгәндә килеп туган хәлдән уңайсызлану галәмәте. Ләкин ул бик тиз гадәти тыныч хәленә әйләнеп кайтты:

— Таныш бул, дус кызым Гөлфия. Без урта мәктәптә бергә укыдык.

Аннары дустына карап әйтте:

— Гөлфия, мин сиңа Равил исемле егет белән таныштым дип әйткән идем бит. Менә ул шушы егет инде. Син Рамил дип ялгыш ишеткәнсең, ахры.

— Шулай булган икән шул, — диде Гөлфия. — Гафу итегез, Равил. Ярар, мин китим әле, эшләрем муеннан. Хушыгыз. — Кыз ничек кинәт килеп чыкса, шулай кинәт кенә китеп тә барды.

— Сәеррәк очрашу, — диде Равил Тәнзиләгә, — хәл-әхвәл дә сорашып тормады. Үзең дә унайсызландың кебек.

— Игътибар итмә, Равил. Шундый инде ул, дуамалрак. Шуңа күрә бик сирәк очрашабыз. Нинди матур кичнең ямен боза язды.

Равил күңелендә шик сыман нәрсә туган иде, шуны ачыклыйсы килде.

— Мин аның «югалган кеше табылган икән», диюен аңламадым, — диде.

— Син имтиханнар биреп йөргәндә, берара кузгә-башка күренми торган идең, хәтерлә әле. Гөлфия белән без шул чакта очрашкан идек. Шуны әйтүе булды, күрәсең.

Равил тагын нәрсәдер сорарга авызын ачкан иде, Тәнзилә сүз әйтергә ирек бирмәде, чиядәй иреннәре белән аның иреннәренә үрелде. Алар театрга керергә дип кузгалгач, Равилнең аягына эләккән буш консерв банкасы шалтыр-шолтыр килеп шактый тәгәрәп барды. Равил шундый чиста, матур ял урынын ник пычраталар икән, дип кәефсезләнсә дә, спектакль барышында моны тиз онытты.

Театрда «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле бара иде. Тамаша беткәннән соң Равил сөйгәненнән:

— Жә, ничек? Ошадымы? — дип сорады. Тәнзилә җавап бирергә ашыкмады. Аннары гына:

— Әллә тагы... Артистлар әйбәт уйный. Бигрәк тә Шәүкәт Биктимеров, Равил Шәрәфиев, Рәшидә Җиһаншина. Тик спектакльнең төп фикере нәрсәдә соң?

— Син аңламадыңмыни? Тамашачыда оптимизм, тормышка актив мөнәсәбәт уятуда дип беләм мин.

— Әлмәндәр карт сугышларда катнашкан, гомере буе тырышып хезмәт иткән. Янында улы, килене, оныгы, ә үзе ялгыз. Аны санга сукмыйлар. Бөрешеп беткән Хәмдебану карчык та аңламый үзен. Әле бакчада беркемгә кирәкмәгән дача йорты төзеп ята тагы. Гомере бетеп бара бит инде. Кемгә төзи? Акчалы эш эшләсә, әле бер хәл иде.

— Хикмәт тә шунда шул, Тәнзилә. Нәрсә генә эшләмәсен, ул җир йөзендә кешеләрне авырлыкларга бирешмәскә, мәлҗерәп калмаска өнди, юл күрсәтә, эз сала. Юлның башы — эз, дип юкка әйтмиләр бит.

***

Институт артта калды. Диплом кулда, тик ул зур шатлык китермәде. Үткән гасырның сиксәненче еллар ахыры, туксанынчы еллар башы хәвефле, болганчык булды. Дөньяның асты өскә килде. Үзгәртеп кору дип башланган эш ахыр чиктә кирегә мәтәлү, социализмнан капитализмга әйләнеп кайту булып чыкты. Равилгә укытучы булып эшләргә туры килмәде. Мондый шартларда кем сиңа эшкә юллама бирсен, кем кайгыртсын. Ул инде тулай тораклан берәүләрнең хосусый фатирына күчкән иде. Беркөнне ул Тәнзиләгә:

— Әйдә, сиңа торган җиремне күрсәтим әле. Кереп чыгыйк, — диде. — Дипломнарыбызны да юган юк. Мин шампанское да алып куйган идем.

Кыз берни әйтмәде, иңнәрен генә сикертеп куйды. Аның йөзе уйчан, игътибары таркау иде. Үзе әле бер ноктага карап уйга тала, әле уянып киткәндәй җанланып ала.

— Сиңа ни булды, Тәнзиләкәй? — диде Равил. — Бик борчылгансың димме, йөзеңә бәреп чыккан.

— Булуын берни дә булмады... Тик ничек әйтим икән... Мине кияүгә сорыйлар... шул гына.

Равилнең күзләре киң ачылды, тавышы калтыранып чыкты:

— Ничек инде?! Шул гына-а? Кем? Кайчан?

— Урта мәктәпне миннән алдарак бетергән бер егет... Рамил... Волгоградта хәрби училище тәмамлап ялга кайткан. Әти-әнисе мине сорарга килгән. Хат язгалап торган иде.

— Менә сиңа яңалык! Бу нәрсә була инде?

— Укыганда минем арттан йөргән иде. Таза тормышлы. Өч бүлмәле фатирда яшиләр. Теге чакта ук машиналары бар иде. Мин аның, борынын чөеп, берьюлы берничә кыз артыннан сөйрәлгәнен белә идем. Шуның әти-әнисе килгән.

— Ә мин? Ә син?

— Минме? Мин каршы, әни кыса. Мәхшәр, ил тикле ил җимерелде, ди. Дөрестән дә, бөтен халык байлыгы өлгер җитәкчеләр, олигарх дигән бәндәләр кулына күчте. Хәтта казылма байлыклар да. Телевизорны гына ач, сүз боткасы, бәхәс. Горбачёв белән Ельцин власть бүлә. Ә халык бөлгенлектә. Азык-төлек талонга калган иде, хәзер ул да юк. Булганына да бәяләр котырып үсә. Әни йокысыз калды.

— Ә мин? Мин дим, Тәнзилә?

— Син — укытучы, мин — инженер. Икебез дә эшсез. Әни бик борчыла. Тормышның рәте бетте, башлы-күзле булып куясыңмы әллә, ди.

— Менә сиңа мә!

— Аңлыйм мин аны. Ялгыз калгач, авырлыклар үзегенә үткән. Бернәрсәне дә әрәм-шәрәм итмә, сакчыл бул, дип гел колагыма тукып үстерде. Хәзер инде бигрәк тә. Кинәт кенә шундый көннәр килер дип кем уйлаган. Нишләргә дә белгән юк.

— Башка күсәк белән органдай булды бит бу, Тәнзилә.

— Менә шундый хәлләр. Авиация заводына эшкә урнашырмын дигән идем. Тик анда да хәл мөшкел. Дәүләт заказлары юк, диләр. Бөтен җирдәге кебек анда да инженер-техник хезмәткәрләрне, квалификацияле эшчеләрне кыскартып торалар икән. Бездә эшләре юк та юк инде аларның. Син әле, Равил, бәлкем авыл җирендә эш табарсың. Ә менә мин... мин...

— Авылда хәлләр тагы да мөшкелрәк.

— Алайса нишлибез соң? Мине әни бик аптырата.

— Берләшәбез дә уртак нигез корабыз, Тәнзилә. Дөнья актарылганда бер-беребезне югалтуыбыз бар. Аерылганны аю ашар, диләр. Мин берничә көн элек авылдаш егетне очраттым. Эшендә хезмәт хакы түләми башлагач, күрше республикаларга, өлкәләргә кача-поса гына азык-төлек чыгарып сата икән.

— Мондый кытлык заманында каян ала икән соң ул аны?

— Әшнәлек хөкем сөрә бит, Тәнзиләкәй. Таныш-белеш аша инде.

— Элеккечә әйтсәк, бу спекуляция бит. Шуңа кача-поса эшли микәнни?

— Безнең республикада азык-төлек арзанрак булганга, аны читкә чыгару тыела икән. Тотсалар, эш харап, ди. Тик ничек тә яшәргә кирәк лабаса. Безгә дә авылдашка иярергә кирәк. Икәүләп.

— Бу синең миңа өйләнергә теләвең, ягъни тәкъдим ясавың буламы инде?

Равил сөйгәненең кулларын үз кулларына алды:

— Мин сине беркемгә дә бирмим. Бик яратам мин сине, кадерлем. Чык миңа, гомергә бергә булыйк.

— Ярар, чыктым да ди. Шуннан?

— Башкалар нишли, без дә шуны эшләрбез.

Тәнзилә эче катканчы көлде, Равил хәтта аптырашта калды:

— Үзең ярар, дисең... үзең көләсең...

— Без гомер буе алыпсатар булып көн күребезме? Шуңа көләм, гафу ит.

— Гомер буе болай булмас, Тәнзилә. Бу авыр хәл вакытлыча гына, диләр ич. Хосусый милек, шәхси бизнес тормышны аякка бастырачак, диләр. Без дә аннан читтә калмабыз, югары белемебез бар, гарип-гораба түгел... Җә, ничек, чибәрем?

— Тиктомалдан гына... Әни ни дияр бит әле.

— Күндерербез, Тәнзилә, күндерербез. Җавабыңны әйт, кадерлем.

— Әйттем ич инде.

— Рәхмәт сиңа, гүзәлем. — Равил суыткычтан шампан шешәсе алды. — Әйдә, киләчәк бәхетле, рәхәт тормыш өчен күтәреп куйыйк әле!

Шампан шартлап бөкесе түшәмгә бәрелде. Тәнзилә сискәнеп Равилгә сыенды.

— Әйдә, синең гүзәллегең өчен!

Тагын бер-ике тосттан соң башым әйләнеп китте дип, Тәнзилә караватка барып ятты. Равил дә аның янына сузылды. Егетнең кочагы кайнар, иреннәре татлы иде. Шампан градусларына егетнең мәхәббәт уты да кушылгач, Тәнзилә изрәп, эреп төште. Равил каударланып аны чишендерә башлады...

Иртән алар Тәнзиләнең әнисе янына киттеләр. Күз төпләре каралып калган ана, кызына шелтәле караш ташлап:

— Кызым, кайларда йөрисең, ә? Мин төн буе ут йотып, нишләргә белми арлы-бирле сугылып чыктым. Оят түгелме? — дип каршылады.

Тәнзилә әнисен кысып кочаклады да:

— Әни, әнкәем! Мин кияүгә чыктым. Менә ирем, Равил. Ачуланма инде... безгә бәхет кенә телә, — дип анасын өнсез калдырды. Халидә апа урындыкка сыгылып төште.

— Ничек инде? Рөхсәтсез... Син мине нинди хәлгә куйдың...

— Халидә апа, зинһар, ачуланмагыз. Мин бит Тәнзиләне бик яратам. Ул да, — диде Равил. — Без мәңге бергә булырга вәгъдә бирештек. Сезне дә ташламабыз. Фатихагызны бирегез инде.

Бүлмәдәге тынлык озакка сузылды. Әллә яшьләргә генә шулай тоелдымы? Бераздан аны әниләренең калтыранып чыккан тавышы бүлде:

— Әй, бу яшьлек юләрлеге... Миңа нишләргә кала соң? Ичмаса, туган-тумачаны гына булса да җыеп мәҗлес ясап алыйк.

— Кирәкми, әни, кирәкми. Вакыты андый түгел. Бурыч өстенә бурыч җыеп... Загска барып язылышабыз да бетте-китте.

— Равил, ә синең әти-әниең беләме соң? Алар ни дияр? Гаилә кору кеше гомерендә бер генә була торган җаваплы, шатлыклы, изге, күңелле вакыйга бит ул.

— Каршы килмәсләр, Халидә апа. Алар минем бик ипле кешеләр. Тәнзилә белән кайтып килербез, аңлатырбыз, — диде Равил.

— Әй, балалар, балалар... Инде шулай хәл иткәнсез икән, фатиха бирми нишлисең. Хәерле сәгатьтә булсын. Ходай Тәгалә шулай язгандыр, күрәсең.

Тәнзилә белән Равил әниләренә рәхмәт әйттеләр дә загска гариза бирергә чыгып киттеләр. Халидә апа мөлдерәп яшь тулган күзләре белән яшьләрне озатып калды.

***

... Язга чыктымы Рифатның күңеле сыерчык диярсең, очына башлый. Күптән түгел бөтенләй ялгыз калган әтисен, туганнарын, авылын, аның яшел чирәмле урамнарын, балачак дусларын сагына. Элегрәк яшьлектәнме, хәрби хезмәтенә бирелгәнлектәнме алай түгел иде. Тормыш кайда да бер инде бу илдә, дип фикер йөртте. Ә тора-бара туган ягын җирсенә башлады. Күз алдына урман юллары, чәчәкле аланнар, дус малайлар, алар үзләре генә белгән җиләклекләр, баланлыклар

килә дә баса, килә дә баса. Яшьлек дуслары хәзер кайда икән, исәннәрме икән? Жор сүзле, шаян табигатьле күрше Шәмсетдин бабай нихәл икән анда?

Бер елны, әле авылда мәктәптә укып йөргәндә, аларга утын кисәргә булышыйм дип кергәч, Рифат картның пычкы тоткан кулына игътибар итте. Картның бармаклары һәркайсы ничектер аерым-аерым, тырпаеп тора иде.

— Бабай, кулыңа ни булды? — диде Рифат, гаҗәпләнеп.

— Картая-картая сеңерләр дә бушый икән, улым, — диде бабай. — Ә күзе ашаганда күлмәк капламасына ябышып калган бәрәңге кисәгенә төшкәч, елмаеп карчыгын мактады. — Карчык шәп минем. Кайгыртучан. Менә бит, ашыйсы килсә дип, күлмәк капламасына да запаска бәрәңге салып куйган. — Аннары әллә шаярып, әллә чынлап әйтеп куйды. — Өйләнгәндә, улым, карап өйлән. Киленнең чибәрлегенә генә түгел, кешелегенә кара. Урынсыз терәлеп биленне сындырма. Минем карчык шикелле үзеңә птходяший булсын.

Картлар сүзен кар басмас, ди халык мәкале. Шәмсетдин бабайның гыйбрәтле сүзләрен Рифат бик еш искә төшерә. Нишлисең, аңа шулай туры килде, әлегә кадәр ялгыз йөри. Тәвәккәл түгел дияр идең, андый кеше прапорщик булып хезмәт итә аламыни? Икенче яктан карасаң, аның яшендәгеләр әллә кайчан гаилә корып ду китереп яшәп яталар. Алма пеш, авызыма төш дип тормыйлар. Шәһәрдә булсынмы, авылдамы, тормышта үз урыннарын тапканнар. Сүзнең чиге юк, уйның төбе юк. Көн-төн уйлана Рифат. Уйлары яшь юртак сыман әле тегендә, әле монда ташлана, баш мие кузәнәкләреннән йөрәккә күчә, аны тасырдата, йокыны качыра. Тормыш корып җибәрергә әллә кайчан вакыт инде вакытын, тик һаман шул «птходяший» кыз туры килмәдеме, әллә Рифат үзе бик сайландымы шунда. Абыйсы Равил, Казанга кайт кына, менә дигән кәләш табарбыз, дип күптәннән чакырып яза.

Ниһаять, Рифат бер фикергә килде, дөрестән дә, кайтсын әле ул, Татарстандагы тормышны үз күзе белән күреп килсен. Газеталар, телевидение, радио андагы хәлләрне әле тегеләй, әле болай тасвирлый. Бәлкем, ул үзе шикелле сазаеп баручы берәр чәчбикәне дә очратып куяр. Буйдак килеш күпме яшәргә мөмкин...

Казанда инде Рифат башында өр-яңа уйлар бөтерелә башлады. Әллә бөтенләйгә кайтып урнашыргамы? Дөрес, Чиләбедә дә ярыйсы гына, командирлары ярата үзен. Хезмәт хакы да зарланырлык түгел, бераз маясы да бар. Тик үз милләтебез кызлары күзгә ташланып тормый шул, ә башкалада алар, әлбәттә, күбрәк инде. Хәрби комиссариатта урын булмаса, башка эш табар. Абыйсы да ярдәм итәр. Әнә ул Казанда заманның ялына ябышып әйбәт кенә яшәп ята ич. Хатыннан да уңды бугай. Тәнзиләсе белән алны-ялны белмичә чабалар икән чабуын. Алмаш-тилмәш әле Төркиядән, әле Польшадан тауар ташып сатканнар, тормыш төбенә батмаганнар. Тора-бара тауарга Мәскәүгә, бүтән шәһәрләргә йөргәннәр, әле дә әнә хәтта Кытайга, Вьетнамга баралар икән. Эш урыннарында хезмәт хакы бирелмәгәч, бик күп халык шулай көн күрә, диләр. Нинди тауар үтемле, шуны белеп тору мөһим икән. Йөри, тырыша торгач, абыйларының эше җайга салынган, элегрәк бер кечкенә кибет кисәген дә арендага алганнар, аннары мең төрле авырлык белән аны үзләренеке иткәннәр.

Абыйсы туксанынчы еллар галәмәтләрен сөйләгәч, Рифат:

— Ә рэкет, криминал тенкәгезгә тимәдеме соң? Коррупция дигән нәрсә бөтен Россиядә котыра бит? — дип сорады.

— Әй, энекәш... Кемнең генә кесәсен калынайтмадык инде, — диде Равил. — Баштарак нәрсә икән соң ул коррупция, дип уйлый идем. Хәзер беләм, мең башлы елан икән ул. Дәүләт үзе үк — коррупционер. Күптән түгел дәүләт даруханәсенә кергән идем. Бер хезмәт ветераны, льготник ялына-ялына үзенә

тиешле даруны сорый. Юк, бетте, диләр. Әнә икенче бүлектә сатуда бар. Шуннан алыгыз, диләр.

Менә безгә генә кара. Барча салымнарны үз вакытында төгәл түләп барабыз. Ә аларны һаман үстерә торалар. Кибетне чиста тотабыз. Көнаралаш диярлек кызыл катыргылылар төрле тикшерү оешмаларыннан агыла. Янгыннан саклаунықыннан дисенме, санэпидстанция дисенме, «Водоканал»данмы, страховка оешмасыннанмы... Һи, аларның саны! Әле баштарак без сезнең «крыша» дип, бушка талап йөрүчеләр тенкәгә тиде. Нәрсә диләр бит: әнә күрше урамдагы кибетне яндырганнар, сезгә дә тия күрмәсеннәр, янәсе.

— Шуларга каршы юньле законнар юкмыни соң, ә?

— Ул законнарның кирәклеген һәркем белә. Үзәктә дә, урыннарда да. Сүз күп, нәтиҗә генә юк. Россия хәзер коррупция иң киң таралган илләрнең берсе. Бу бит әле безгә — вак эшмәкәрләргә кагылганы гына. Югарырак күтәрелгән саен, коррупция зурая, җәелә бара дип сөйлиләр бит. Анда миллионнар, миллиардлар үзләштереп яталар икән. Сум түгел, доллар белән.

— Ә авылда хәлләр ничек соң, абый?

— Авыл халкына кайчан гына җиңел булганы бар, энекәш?! Кырмыска шикелле көне-төне хезмәт, хезмәт. Һәркем хәл кадәри тырыша. Бәрәңгесен, яшелчәсен утырта, билен бишкә бөгеп мал карый. Карт-корыга аеруча авыр. Җегәрлеген җуйган кул-аяктан ни көтәсең?!

— Колхозларны таратып, җирне пайга бүлделәр ләбаса. Авыл кешесе җиргә үзе хуҗа булды. Эшлә, файдасын күр.

Равил кулын селтәп куйды:

— Биш-алты гектар җиреңне көрәк белән казып йөри алмыйсың бит инде. Һәр эштә техника кирәк, ягулык-майлау материаллары, ашлама. Барына да акча каян җиткерәсең. Бәяләре туктаусыз үсә бара.

— Аренда да гамәлдә түгелмени?

— Күрәм, хәрби хезмәттә син тормыштан шактый артта калгансың, энекәш. — Равил үпкәләтмим тагы дигән уй белән энесенең йөзенә карап алды. Юк, Рифатның йөзендә чынлап кызыксыну ярылып ята иде.

— Гамәлдә лә. Тик халык аннан да мантый алмый. Арендаторлар аренда хакына, печән-салам, дүрт-биш центнер ашлык ала, дип сөйлиләр. Тик, әйтик, ул ашлыкны игә китергәнче, ризык иткәнче күпме җәфа чигәсең бар бит әле. Заманында КПСС политбюро әгъзасы Яковлев дигән бәндәнең авыл хуҗалыгы турында әйткән сүзләрен белмисеңдер инде?

— Юк. Аны бит үзгәртеп кору дигән мәсхәрәнең «архитекторы» диләр иде. Юньле сүзе булмагандыр.

— Шул-шул. Бу хәлендә авыл хуҗалыгы «чёрная дыра», имеш. Безнеңчә «кара упкын» була инде. Ул акчаны суырып кына ята, нәтиҗәсе генә юк, янәсе. Шуңа күрә колхоз, совхозларны бетерергә кирәк. Чит илләрдәгечә авылны фермерлык нигезендә корырга кирәк. Бүгенге шартларда батканы тормыш төбенә батсын, калкып чыга алганы, яши алса, яшәсен, янәсе.

— Авыл җирендә дә кешеләр яши ләбаса. Алар нишләр дип уйламадылар микәнни?

— Яковлев карашы ялгыш иде ул, энекәш. Беләсеңме, безнең республика җитәкчеләре ул авыр чакта нәрсә дигән иде. Әгәр без авыл хуҗалыгын үз хәлен үзе күрсен дип, аңа ярдәм итмәсәк, аны ташласак, авыл үзенә бикләнәчәк. Андагы халык тырышыр-тырмашыр, үз тамагын үзе ничек тә туйдырыр, ә менә шәһәр өчен азык-төлек җитештерә алмас. Ул чакта шәһәр халкы нишләр? Менә ни өчен без авыл хуҗалыгына республика бюджетының дүрттән берен юллыйбыз. Ашлама алсыннар, шунсыз иген игү әхлаксызлык ул. Авылларда

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ

юллар төзиячәкбез, газ кертәчәкбез. Шәһәрдә дә, авылда да үзебезнең кешеләр яши бит, диделәр.

— Дөресе шул.

— Килеп туган хәлне, проблемаларны кешечә хәл итү, халыкның тормыш дәрәҗәсен кайгырту менә шулай булырга тиеш ул. Татарстандагыча. Тузган торакны бетерү программасы үзе генә ни тора!

— Шәймиевләр теге Яковлевлардан акыллырак булып чыкты алайса.

— Минтимер Шәрипович авыл хуҗалыгын белә ул. Мелиорация министры булып озак еллар эшләгән бит. Әтисе дә егерме биш ел колхоз рәисе булып хезмәт иткән. Авылда да, шәһәрдә дә өзеклек булмады бездә. Бер мәлне мәскәүлеләр дә азык-төлекне Казаннан ташыды әле.

— Татарстанда фермерлар бармы соң?

— Хәзер бар. Аның өчен башта мая тупларга кирәк иде.

— Алайса, хәзер тормыш авылда да үзгәрә төшкәндер инде. Шулаймы, абый?

— Әле генә шуны сөйләп тордым ич. Авылга хәзер газ керә, юллар төзелә. Тик менә эшсезлек бар. Бигрәк тә яшьләргә авыр. Алар хәзер карашын шәһәргә төби... Тукта әле, Рифат, син һаман авыл да авыл, дисең. Әллә шунда кайтып төпләнергә җыенасыңмы?

Рифат тиз генә җавап бирмәде. Аннары үзалдына гына сөйләнгәндәй фикерен уртаклаша башлады.

— Мин шәһәрдә чыдый алмый башладым, абый. Әллә гел хәрби хезмәттә булгангамы, әллә туйдырдымы шунда. Шәһәр миңа казарманы хәтерләтә. Тимер ишекләр, әллә нинди йозаклар, видеокамералар. Урамда да, кибеттә дә. Сез менә кемнәр белән аралашасыз. Дус-ишләрегез бармы?

Равилнең чибәр йөзенә күләгә йөгерде:

— Заманы шундый, энем. Яңача яши башлау җинел түгел икән ул.

— Әйе, армиядә дә җинел түгел.

— Ишетәбез. Дедовщина дигән нәрсә теңкәгезгә тия, диләр. Дөресме?

— Армия җәмгыятьнең көзгесе ул, абый. Мондый тормышта анлы дисциплинага ирешү шактый кыен.

— Әйе, яңа шартларга күчү, аңны үзгәртү кайда да авырлык белән барадыр, күрәсең. Хәзер әнә авылда яңа алпавытлар аякка басып килә. Әнә анда Балык Бистәсе районында асыл егетләр көн-төн хезмәт итеп, аена бары сигез-тугыз мең акча ала икән. Анда да арендаторлар ае-ае белән шул акча исәбенә кыйммәтрәк бәягә колбаса, атланмай, ярма кебек нәрсәләр сатып яталар ди. Авыл халкы чыдый, карышып нәрсә эшли ала соң? Син авыл ягына карама инде.

— Кайтып бераз торып килим әле. Әтине дә бик сагындым. Анда күз күрер. Кайда да кул кушырып утырып булмый.

— Ярар, авыл тормышын үз күзең белән күреп кил, алайса. Ә син, Тәнзилә, әтигә күчтәнәч җибәр.

Тәнзилә Рифатка бер кап чәй, тартмалы чәкчәк тоттырды. Равил азсынып:

— Син нәрсә инде? Кайчан тагын мөмкинлек чыгар әле, күбрәк бир — җимешен, лимонын куй, — диде.

Хатынының җавабы әзер иде:

— Авыл кибетләренең шәһәрнекеннән ким ягы юк, диләр ич. — Равилнең чырае сытылды. Син кайчан шулай саранланып киттең әле, димәкче булган иде, Рифат алдында тыелып калды.

— Шулайдыр ул, акчаң булса, — дип кенә куйды.

Алар әле кыз белән егет чакта ук ниндидер сүз уңаеннан Тәнзилә:

— Авыл кешесе бер банка кайнатмага да бик шат, — дигән иде.

***

Сагынылган, бик сагынылган икән шул. Рифат озаклап-озаклап авыл урамнарын, тыкрыкларын карап йөрде, очраган карты-яше белән сөйләшеп, хәл-әхвәлләрен сорашты. Зиратка барып әнисе, Шәмсетдин бабай кабере янында белгән догаларын укыды. Беркөнне аның үсмер чакта чикләвек, җиләк, балан, миләш җыеп йөргән урманга барасы килде. Ябалдашларын җәеп горурланып утырган хуш исле юкәләрне таныды Рифат, таныды. Әнә алар янында гына миләш агачлары кукыраеп утыра. Куе яфраклар арасыннан яшь каеннарның аклы-каралы кәүсәләре балкып тора. Җирне ямь-яшел хәтфә келәм каплаган, чәчәкләр балкый. Аларны ярышып үбә-үбә нечкә билле бал кортлары безелди, күбәләкләр бөтерелә. Әйтерсең лә табигать балаларының зурысы-кечесе киерелә-талпына күккә, кояшка омтыла. Борынны кытыклап җир исе, үлән, чәчәк исе аңкый. Меңләгән бөҗәк үз эше белән мәшгуль. Бөтен урманны яңгыратып кошлар концерт куя.

Күнеле күтәренке чакта Рифат еш кына Фәтхерахман Әхмәдиевнең «Мәңге яшисе килә» дигән җырын җырлап йөри иде. Менә әле дә ул шул җырны көйли башлады. Композитор да табигатькә сокланып язгандыр бу җырны, мөгаен, шулайдыр, дип уйлады егет.

Көннәрнең берендә Рифат Актайның бормалы-бормалы ярлары буйлап малай чакта дуслары белән ду килеп су коенган урынга барып чыкты. Монда алар комда кызынып, очсыз-кырыйсыз зәңгәр күккә карап еш кына хыял диңгезенә чума иде. Кем очучы була, кем космонавт, инженер, укытучы, колхоз рәисе... Биредә әле дә күп нәрсә элеккечә, комлык та, читтәрәк шактый куе, биек булып үскән әрекмәннәр дә, колак төбендә безелдәп йөргән төклетуралар да. Хәер, үзгәреш тә бар икән, елга саеккан, Йомры тау юкка чыккан, юл салганда аның балчыгын техника белән ташып бетерделәр дигәннәр иде, дөрес икән.

Рифат бала чактагы кебек әрекмәннәр арасына керде дә комга сузылып ятты. Тәненә рәхәт җылылык таралды. Нәкъ элеккечә зәңгәр күкне чуарлаган мамык болытлар каядыр агалар да агалар. Чиелдәп акчарлаклар килеп чыга, кинәт кенә суга томырыла. Томшыкларында нәни маймычлар тыпрпылдый.

Әнә үги ана яфрагына чикерткә килеп төште. Ул уңайлап урнашып ике аягын бөкте дә аркасын кашый башлады. Туктап ял итә дә кашый, ял итә дә кашый. Рифатка бу кызык тоелды, тотмакчы булып кулын сузган иде, чикерткә читкә атылды. Менә бит, шушы нәни генә җан иясенең дә яшисе килә, дип уйлап ятканда, ул уң кулының чәнти бармагына нәрсәдер кагылганын сизде. Әллә кәлтә микән? Рифат бу җан иясен куркытмас өчен башын чак кына борып кулына күз салды да кычкырып көлүдән көчкә тыелып калды. Аның бармак тырнагын соргылт үрдәк бәбкәсе чукый иде. Үрдәк бәбкәсе! Башын әле бер, әле икенче якка кыегайтып, нәни күзләрен йома-йома чукый да чукый. Рифат башын бераз калкытып бәбкәгә текәлде. Ә тегенең бернидә эше юк, һаман чукуын белде.

— Әй, сабый, бармакны нәрсә дип белдең соң? — дип уйлап куйды Рифат. — Анда нәрсә таптың? Әллә шулай дөнья белән танышып йөрүеңме? Тукта әле, ул монда ялгызы гына ничек килеп чыккан соң? Юк, бәбкә ялгыз түгел, әнкәсе якында гына: тирә-якны күзәтә икән. Ул Рифатны абайлап, күрәсең, бакылдап бәбкәләрен үз янына чакырды. Бәбкә әнисе тавышын ишеткәч, «пелт» иттереп кәкәйләп алды да әрекмәннәр арасына кереп югалды.

Рифатның башыннан кайнар уй йөгереп узды. Бу әллә кайчан борынлап, әле генә үзенә юл тапкан күптәнге уй иде. «Шушы матур дөньяга туып, шунда, авылның яшел чирәмендә аунап, Актайның шифалы, тәмле суын эчеп үскән туган җиреңнән башка ничек яшәргә мөмкин? Юк, ни булса шул, ул авылда

калачак! Тәвәккәллим, тәвәккәллек ярты бәхет дип юкка гына әйтмиләрдер. Димәк, Чиләбегә барып, эштән китәргә кирәк. Баста!»

Мондый карарга килгәч, аңа рәхәт булып китте, күңеле дә тынычлана төште. Авыл дигәндә, Равил абыйсы кара буяуны куерткан икән. Телевидение, радио эшләп тора, кибетләр бар. Берничә гаилә шәһәрдән кайтып йорт күтәргән, гөрләп яшәп яталар. Юләр, ник мин моңа башта ук игътибар итмәдем икән, дип Рифат үзен битәрләп тә алды.

Кинәт кыр ягыннан исеп куйган җылы шаян җил Актай маймычларын шатландырып су өстен шадралатты да Рифатны битеннән сыйпап каядыр китеп барды. Әйтерсең лә бала чагындагы кебек әнисе сыйпап иркәләде.

***

Мәҗмәр урта мәктәбендә укыганда, җәйге матур көннәрнең берсендә малайлар, кызлар Актайның Чулманга койган урынына су коенырга барганнар иде. Монда су да җылы, аулаграк та иде. Кызлар гадәттәгечә читтәрәк чыр-чу килде — егет кәмәшләре комачау итмәсен, янәсе. Итмәс алар, бар. Бастырып килеп тә җиттеләр, кызларны чырылдатып шаярта да башладылар. Бигрәк тә Рәкыйп. Әле Наиләнең, әле Рәшидәнең лифчигына сузыла. «Матур урыннарын» кояш та күрсен, янәсе. Рифатның ачуы чыкты, аның яшертен генә Рәшидәгә күз салып йөргәнен Рәкыйп белә ләбаса. Рәшидә үзе дә ник аңа ирек бирә, ник яңагына кундырмый! Ә теге юньсез тәки теләгенә ирешкән икән.

— Нишлисең син, оятсыз!

Рифат Рәшидә тавышына борылып карады да катып калды. Күзләре ирексездән кызның ап-ак күкрәкләренә, чиядәй ал ими очларына төште. Яшьлек яшьлек шул, бу гүзәл күренеш үсмер егетнең хәтеренә мәңгегә сеңеп калды, әледән-әле күз алдына килеп, күңелен кытыклап, ымсындырып торды, хәтта төшенә дә кергәләде. Күз бәрәңгедә дә бар бит ул, күңеле белән күрде, күрәсең. Җаен туры китереп, ул Рәкыйпкә:

— Рәшидәгә бәйләнмә, — диде.

— Шаярам гына ич мин. Юләр сатма инде, — диде тегесе.

Армия хезмәтенә алынгач, Рәкыйпнең һаман Рәшидә тирәсендә бөтерелүен ишеткәч, Рифатның чын-чынлап кәефе китте. Алай гынамы, шушы хәбәр аны хәрби хезмәткә калырга этәрде дә инде. Теге чакта Рәкыйпнең яңагына берне менеп төшәсе булган икән дип үкенеп тә алгалады. Хәер, тора-бара ачуы басылды, йөрәген талкып торган югалту хисе генә утырып калды. Рәшидәнең Казанда кияүгә чыгуын белгәч, әлеге хис бүселеп-бүселеп өскә калкып чыккалады.

Соңрак Рифат Рәкыйпкә карата ниндидер рәхмәткә тартым хис тә тоя башлады. Солдат хезмәтенең читен чакларында гүзәл күкрәк алмаларыннан көмеш тамчылар тамып торган теге мизгел күз алдына килеп, аны дәртләндереп җибәрә иде. Сары чәчләре кыеклап маңгаена төшеп торган Рәкыйпне дә күрәсе, рәхәтләнеп сөйләшеп утырасы килгән чаклар шактый булды. Их, кызлар, егетләр, сез хәзер кайларда йөрисез, ниләр майтарасыз икән?

Хөрмәтле укучым!

Син бу дөньяда могҗиза булуына ышанасыңмы? Бар ул, бар! Рифат туган авылы урамыннан әнә шундый сагынычлы уйларга батып атлаган бер мәлдә каршына килеп чыккан кешене син кем дияр идең? Әйе, ул Рәшидә, Рәшидә үзе иде. Моны могҗиза дими ни дисең!

Чигәләренә сизелер-сизелмәс кенә бәс куна башлаган куе чәчләре элеккечә калын, матур итеп толымлап үрелгән. Ике каш арасына нечкә генә матур бер сызык менеп утырган икән. Киеме дә килешле. Ап-ак кофтасы тулы яңакларына

аксыл төс сипкән, бу аны яшәртеп җибәргән. Күкрәк алмалары тагын да калкурак булып кабарып тора. Сокланып туймаслык.

— Рәшидә! Рәшидәкәй! Синме бу, ә? Менә ичмаса очрашу! Руслар ничек диләр әле? Сколько лет, сколько зим! Исәнме? Күнелем юкка гына авылга тартмаган икән.

— Исәнме, Рифат. Син кунакка кайткан дигәннәр иде шул. Абау, үзгәргәнсен. Озаккамы?

Рәшидә энҗедәй ап-ак тешләрен күрсәтеп, элеккечә, әллә кайчандагыча матур итеп елмайды. Бу елмаю аның төпсез зәп-зәңгәр күзләрендә туып, алсу иреннәре почмагына үрмәләп, көндез кояш, төнен ай үбеп иркәләгән нәни генә бит чокырчыкларына кереп эреде. Кап-кара каш, ап-ак йөз. Шушы капма-каршы төсләр Рәшиданең чибәрлеген бермә-бер арттыра иде. Кашы янына кайчандыр кунып калган нәни генә яра эзе дә ачык йөзенә үзенә бер төрле матурлык биреп тора.

Рәшиданең кулын кысып исәнләшкәндә, анын кайнарлыгыннан Рифат калтыранып китте. Моны сиздермәс өчен сораулар тезә башлады:

— Тормышлар ничек? Кемнәрен бар? Ирең кем? Рәкыйп авылдаш түгеллеген ишеткән идем.

— Ул мине алырга бик теләгән иде. Мин риза булмагач, Мәскәү тирәсендә яшәүче бер кызга өйләнеп китеп югалды. Үпкәләде инде, үпкәләде.

— Алай икән. Сабакташлар белән аралашасыңмы? Кайларда көн күрәләр?

— Аралашмыйм диярлек. Таралышып беттек, авылда беребез дә калмады. Казанда Наиләне, Рузалияне, Ленарны сирәк кенә очраткалыйм. Дөньяның асты өскә килде бит, барыбыздан да чабыш аты ясады.

— Шулай шул. Ирең белән кайттыңмы? Ул безнең яктан түгелме?

— И юк. Ирем Буа ягыннан иде.

— Иде, дисең. Әллә юләрләнеп аерылдыгызмы? Шундый чибәр хатынны ничек ташларга мөмкин?

Рәшиданең йөзенә күләгә йөгерде. Ул зират өстендәге ялгыз болытка күз салып алды.

— Юк, юл һәлакәтенә юлыгып вафат булды ул. Бик тә яхшы күнелле, инсафлы егет иде. Уңган, кулы теләсә нинди эшкә ятып тора иде. Әрәм булды. Матур гына тормыш корып йөри идек... Ә үзең ничек яшисең соң? Кайларда? Синең читтә икәнеңне ишетеп белә идем.

— Чиләбедә яшәп ятам. Армиядә хезмәт срогын тутыргач, командование прапорщик булып калырга тәкъдим итте. Калдым. Прапорщиклар мәктәбен бетердем. Еллар йөгереп кенә узды. Менә хәзер күңел туган якларга тарта. Әнисез калганыбызга да шактый инде. Ни кызганыч, бәхилләшеп кала алмадым. Хәрби хезмәт бит, учениедә идек. Ник кайтмыйсың дип хатлар яза иде, мәрхүмәм... Аннары инде бер ияләшкән урынны ташлап китәсе дә килмәгәндер. Дөньялар әнә ничек актарылды бит. Кайтып нишлисең дип тә бик озак уйландым. Командирлар белән дә мөнәсәбәтем әйбәт.

— Ә гаиләң?

Рифат бу сорауны көткән иде. Авылда очраган һәр кеше хәл-әхвәлне сораугa гаиләң тормышы белән кызыксына башлый. Рифатның моңа бераз кәефе дә киткәләде. Уйлый торгач аңлады Рифат, балигъ булган кешенең тормышы гаиләдә уза лабаса. Кеше ике яшәми, Ходай биргән гомерне ирең, хатының, балаларың белән тату, матур, тигез итеп уздырырга кирәк шул. Тәмен, ямен табып. Халыкның иң изге теләкләренең берсе, ул да булса исән-сау, имин, тигезлектә яшәү лабаса.

— Гаиләм юк минем. Әле дә өйләнмәгән. Баштарак хезмәт белән мавыгып

шактый еллар уздырдым. Аннары карыйм, минем яшьтәге кызлар инде кияүгә чыгып, балалар үстереп яталар.

— Чиләбедә татарлар күп диләр ич. Берәр татар кызы таба алмадыңмыни?

— Димләп тә карадылар, каравын. Күнеленә ятмаган кеше белән ничек тормыш корасың. Йә, ярар. Син дә үзең турында сөйлә инде.

— Мин Казанда педучилищеда укыдым. Шунда булачак ирем белән таныштым. Ул үлеп гашыйк булды. Көләч егет минем дә күнел түренә кереп утырды. Укып бетердек кенә, дөнья үзгәрде дә куйды. Мин балалар бакчасына эшкә кердем. Мәсгут шофёр булып эшли башлады. Училищеда укыганда ук права алган иде. Өйләнешеп кеше почмакларында яшәдек. Бик авыр чакларда берәр авыл җиренә китик, эш табылыр әле дип, теңкәсенә тидем. Хәзер үкенәм. Бишкә ярылам, сөеклем, барыбер сине, туачак балаларыбызны бәхетле итәм, дия иде. Көне-төне эшләде, төзелешкә дә йөрде, йөк тә бушатты. Иске генә машина алып аны аякка бастырды, йокыларын калдырып, таксист булып йөрде.

— Унган егет булган инде, алайса. Сине дә бик яраткан, күрәсең.

— Үлеп, дим ич. Тора-бара Ходай безне дә кеше белән тигезләде, иске булса да фатирлы булдык. Өстәвенә Мәсгуткә бер танышы Әтнәбайда җире белән йорт сатучы бар, арзанга гына сата икән, дип коткы салган. Әйдә, барып карыйк әле, ди. Сатучы олы яшьтәге бер әби булып чыкты. Кызы үзен Казанга кыстый икән. Сатмыйк, үзебезгә кирәге чыгар, дип әйтеп тә караган. Тегесе җир эшеннән гарык булдым, борылып та карыйсым килми, сат, дип каты торган. Риза булдым инде, нишлим соң, үземнең рәт бетте, ди. Бакча эшенә күптән ярамыйм инде. Җире шәп, кара туфрак. Алыгыз, балалар, ди. Үкенмәссез, үзебезнең мөселман кешесе генә булсын дип теләгән идем, менә Ходай сезгә язган икән, ди.

— Шулай итеп, сез дачалы да булдыгыз инде,

— Дача дип... Йорты шактый тузган иде. Төзәтәсен төзәтеп, җәйләрне шунда уздыра башладык. Бәрәңгесе, яшелчәсе дә ярап куйды. Ял көннәрендә кайтабыз, көне буе бакчада эшлибез. Ял итәбез, имеш. Дөрес, йортыбыз Камадан ерак түгел. Су кереп, рәхәтләнеп кызынып яткан чаклар да булды. Сирәк кенә. Шулай тормышны җайга салабыз дип кенә торганда, Мәсгутем гүр иясе булды... Менә шундый хәлләр, Рифат. Инде менә мин дә йорт-җирне сатарга кирәк дип торам. Бәясен дә түләп бетермәгән бит әле. Ялгызыма бик авырга туры килә.

— Ярдәм итәрлек кешең юкмыни соң?

— Юк шул. Улымны да күтәрәсе бар... Биш яшендә генә бит әле. Ул кул астына кергәнче әле, ай-һай.

— Олырагы юкмыни?

— Башта, тормышның рәтсез чагында бала табасым килмәде. Мәсгут ни ялынды, тап, үстерербез, кеше таба бит әле, дип үгетләде. Киреләндем... Аннары таптым, көнкүреш көйләнә генә дигәндә... Мәсгутем...

Рәшидә күзенә мөлдерәп тулган яшьләрен кулъяулыгы белән сөртеп, туктап калды. Рифат аны тынычландырырга кереште:

— Ярар, Рәшидәкәй, тынычлан. Дөнья тигез генә булмый шул. Минем әти, җан биргәнгә җүн бирә, ди. Улың кайда соң әле?

— Әнә йөгереп кайтып килә. Балык жене кагылды үзенә. Иптәш малайларына ияреп Актайга балык тотарга киткән иде.

— Кечкенә күренә бит. Ничек аны су янына җибәрәсең соң?

— Актай бик саеккан хәзер. Чыпчык тезеннән генә калган.

Ул арада малай сулышы кабып, йөгереп килеп житте. Рифатка күз ташлап алгач:

— Әни, без Наил белән спорить иттек, — диде. — Менә бу балыкны ул алабуга, ди. Мин окунь, дим. Кто прав?

— Икегез дә, улым. Окунь — русча, алабуга — татарча.

— Ә-ә... — Малай борынын тартып куйды, озын козырёклы кепкасын салып, тирләрен сөртте. Аннары әнисе янындагы чит ирдән әллә кайчангы танышыдай сорап куйды:

— Абый, син тәмәке тартасыңмы?

— Так точно! Булгалый шул, энем. Ник сорыйсың?

— Тәмәке исе килә ич.

— Ну, гафу ит инде.

— Нәрсә ул «гафу»?

— «Извини» дигән сүз.

— Тартмасаң, извиню. Тартма син. Зарар була.

— Есть! Син әйткәч, тартмам.

— Ә синең машинаң бармы?

— Юк шул.

— Һи, йөртә дә белмисеңме?

— Анысын беләм.

— Мин белмим әле. — Малай көрсенеп куйды. — Үскәч шофёр булам мин. Әнине йөртәм.

— Абый, ә син боксёр түгелме?

— Бераз гына.

— Пирчәткән дә бармы?

— Бар.

— Ә син мине бокска өйрәтерсеңме?

— Өйрәнәсең киләмени?

— Килә шул... Ишегалдына чыгам гына, Гриша килеп житә. Жә акча, жә конфет сорый. Бирмәсәң, суга.

— Ә син?

— Ул көчлерәк. Бокска өйрәнсәм, кирәген бирер идем.

— Начар малай икән ул. Әниең рөхсәт итсә, мин сина пирчәткә бүләк итәрмен. Кечкенә боксчыларныкын.

— О-о! Рәхмәт. Честно?

— Так точно!

— Молодец! Я побежал. Скажу Наилю, что оба мы правы.

Малай үкчәләрен ялтыратып кабат елгага йөгерде. Олылар елмаеп карап калдылар.

— Егетнең исеме ничек соң?

— Эмир. Әтисез үсә менә. Борчылып та куям.

— Шәп исем. Жисеменә туры килгән булырга тиеш. Сөйләшүенә карап әйтүем. Кайсы айда туды?

— Августта.

— Әйтәм бит. Арыслан, димәк. Чәче әтисенекедер, синең — кап-кара, аныкы — күксел. Сез кайчан китәсез?

— Иртәгә. Сеңлемнең хәлен белергә генә кайткан идек. Моннан туп-туры Әтнабайга. Ә син?

— Мин торам әле. Әтинең дә ялгызын калдырасы килми. Абый белән сөйләшеп, Казанга алып китеп булмасмы дип йөрим. Бәлки, үзем...

Рифат сүзен әйтеп бетермәде. Күрәсең, уйларының очына чыгасы бар иде.

Рәшидә кайнар кулын сузды:

— Ярар, Рифат, без киттек. Жыенасы да бар. Сау бул. Бер күрешү — бер гомер, диләр. Яшьлеккә кайткандай булдым.

— Рәшидә, син миңа Казан адресыңны бирмәссенме? Кем белә, бәлкем, очрашып куярбыз.

Рәшидә гаҗәпләнмәде. Рифат синә нәрсәгә инде ул дигәнне көткән иде.

— Азинода торабыз. Рәхим ит. Беркөн генә әле Мәҗмәрдә бездән алдарак укыган Нариман килеп чыккан иде. — Рифатның йөзеннән күләгә йөгереп узгангамыдыр, өстәп куйды. — Хатыны белән. — Без яхшы ният белән ишек каккан кешене генә ачык йөз белән каршылыйбыз. Тол хатын бусагасына кемнәр генә килеп кагылмый. Ярар, хуш иттек. — Рәшидә адресын әйтте, аннары улын чакырып алды.

— Хуш, хуш, Рәшидәкәй! Син дә сау бул, балыкчы. Ә пирчәткә миннән, яме.

— Ярар, рәхмәт. Абый, син миңа исемеңне әйтмәдең.

— Рифат абый мин. Синекен белдем — Эмир.

— Хуш Рифат абый.

Батып барган кояшның алсу нурларына коенып тыкрыкка кереп баручы Рәшидәне, аның әледән-әле борылып кул изәгән улын Рифат җылы карашы белән озатып калды.

***

Рифат абыйларының ишек төймәсенә басканда, инде күптән караңгы төшкән иде. Коридордан Тәнзиләнең төксе тавышы яңгырады:

— Кем бар анда?

— Мин әле бу, Тәнзилә.

Тәнзилә әллә ничә йозакны шалтыр-шолтыр китереп ачты.

— Исәнмесез, Тәнзилә. Мин йөрим әле.

Тәнзилә әле генә кибеткә чыгып кергән кешегә әйткәндәй, илтифатсыз гына:

— Нишләп йөрисең, ә? — диде. — Шулай соң...

Мондый тәкаллефсез каршы алуга Рифатның кәефе китсә дә, үзен тыеп калды.

— Менә шәһәргә килеп урнашырга дип йөрим әле. Абый кайда соң? Өйдә юкмы әллә?

— Өйдә мин, өйдә, Рифат. — Ванна бүлмәсеннән кызарып-бүртенеп Равил килеп чыкты. — Менә шәп булган. Ниһаять, хәл иткәнсең икән. Эш муеннан. Син миңа бик кирәк, энекәш, бик кирәк. Әйдә, Тәнзилә, чәй куй. Рифат юлдан арып килгәндер. Душта юынып чыгар.

Тәнзилә дәшми-нитми кухняга кереп китте.

— Нәрсә булган аңарга? — диде Рифат.

— Натурасы шундый инде аның. Игътибар итмә. Беренче күрүең түгел ләбаса. Йә, нихәлләр бар. Авыл ничек яши?

— Башта әти нихәл дип сора. Сәлам әйтте. Ник тавышы-тыны юк, ди.

— Бар андый гаеп, бар. Крутимся, как белка в колесе. Кайтып киләм генә диюем була, тагын тормыш басып ала. Күчтәнәчләрне ошаттымы соң?

— Әйе. Рәхмәт әйтте.

— Абый, син безнең урмандагы теге тарихи аланны хәтерлисеңме икән?

— Анда аланнар шактый иде.

— Теге чикләвеккә бай аланны әйтүем.

— Ә-ә... Хәтергә төште, төште. — Егетләр көлешеп алдылар. Хәзер, әлбәттә, көлке, ә теге чакта утырып еларлык иде. Авыл баласы, бигрәк тә малайлар, урман-кырсыз яши аламы соң. Равилгә ул чакта унөч, Рифатка ун гына яшь иде. Август аеның матур бер көнендә иптәш малайлары белән чикләвеккә бардылар. Шактый җыйгач, кояш нурына чумып утырган бер аланда ял итәргә тукталдылар. Кем нәрсә алып килгән, шуны чыгарды, тамак ялгап алдылар. Бары — бергә,

югы — уртак. Рифат алданрак торып, якындагы колмак каплаган куаклар янына килде. Аларда сап-сары булып өлгергән чикләвек тәлгәшләрен күргәч:

— Абый, малайлар, бәгырьләрем! Килегез әле, килегез! Монда чикләвек оясы икән, дөнья хәтле! — дип кычкырды.

Арганнарын да онытып, барысы да куакларга ябырылды. Шатыр-шотыр китереп, ах-ух итеп җыя да башладылар. Шул мәлне Таһир ачыргаланып кычкырып җибәрде дә ачыклыкка чыгып тәгәрәп китте:

— Малайлар, үләм! Уф, үләм!

— Нәрсә булды? Әллә елан чактымы? — дип барысы да Таһир янына йөгереп килде. Ул арада үрле-кырлы сикереп, үрсәләнеп Равил дә үләндә ауный башлады:

— Үтерәләр, качыгыз, кач!

— Шөпшәләр, шөпшәләр!

Инде Кәрип тә бөтерелә иде. Кинәт Рифатның да битенә зур гына шөпшә килеп кунды да үзәккә үтәрлек итеп тешләп тә алды. Рифат аны бәреп төшерүгә булды, икенчесе муенына килеп ябышты.

Малайлар кайсы кая чәчелде. Ләкин куактагы ояларыннан кузгатылган шөпшәләр биетүләрен белделәр. Явызлар кием аша да тешли ала икән. Малайларның битләре, куллары, маңгайлары, хәтта йомшак урыннары да кызарып, шешеп, кабарып чыккан иде. Һөҗүм басылгач, бәхәс купты.

— Рифат аркасында гына булды бу хәл. Ул әйтмәгән булса, без шөпшә оясы янына бармаган булыр идек, — диде кайсыдыр.

— Нәбинең иренен карагыз әле. Сыерныкы белән бер. Ояны син кузгаттыңмы? — диде Равил. Аның үзенең дә бер күзе томаланып бара иде.

— Мин түгел. Аны Таһир кузгаткандыр. Иң элек ул үрсәләнә башлады:

— Колмак арасыннан күрмәгәнмендер инде.

— Һай, биеттеләр дә соң!

Малайлар шау-гөр килеп гаепне Рифатка сылтадылар. Хәер, үпкәләре озакка китмәде. Таһир капчыгын аланда ташлап калдырган булган икән. Аны алып килергә батырчылык итүче табылмагач, капчыкны Рифат барып алып иясенә бирде. Шул көннән башлап малайларның Рифатка ихтирамы бермә-бер артты.

— Әйе, һич онытылмаслык хәл булды ул.

— Мин шул аланга да барып чыктым.

— Мин генә бушый алмыйм. Ярар, нишләп озакладылар соң әле бу? — диде Равил, аннары кухня ягына карап алды. — Тәнзилә! Буласыңмы инде, юкмы? — дип кычкырды.

— Өлгерерсез! — Кухнядан чынаяк тавышлары ишетелә башлады.

— Син, Рифат, иртәгә иртән үк эшкә тотын. Минем күрәсе кешеләрем бар, шулар белән йөрермен. Кибеткә күз-колак булырсың. Аннары торыр урыныңны кайгыртырбыз.

— Юк, абый. Мин монда кучәргә дип килмәдем.

Равилнең йөзендә артык дәрәҗәдә гаҗәпләнү, аптырау чагылды:

— Соң әле генә эшкә урнашам дидең ләбаса.

— Хәләл җефетең нишләп йөрисең дигәч, юри генә әйттем. Мин киңәшергә дип кенә килдем. Чиләбегә кайтып, эштән чыгарга да авылда төпләнергә уйлыйм. Берәр эш башлап җибәрергә кирәк булыр. Терлек-туар симертүме шунда, үрчетергәмедер... Әнә ич телевизордан күрсәтеп торалар, кем кошчылык белән шөгыльләнә, кем терлек фермасы тота.

— Оһо, син зурдан кубарга исәплисең икән. Ә сәмән?

— Шул-шул. Бераз запасым бар-барын. Житмәсә нишләрмен, дим.

— Әтинең бераз ЭНЗЫсы юкмы икән соң?

— Каян килсен?! Ярар, берәр жае табылыр. Әти иждивениесендә ятмассың ич инде. — Равил кухня ишегенә карап алды. — Кая югалды соң бу? — дип чыраен сытты.

Рифат аның тезенә кагылды:

— Абый, син чәчәгенә алданып, чәнечкегә кадалгансың бугай, — дип куйды. Аннары абыйсының йөзе агарып китүен күргәч: — Эчмәгән чәй түгел. Ник борчыласың, ә? — диде. — Мин кафега кереп тамакны туйдырган идем инде. Күрәм, сезнең тагын яңа җиһазларыгыз арткан. Бу ак күнле гарнитурыгыз кыйммәттер, ә?

— Кырык мең.

Тәнзилә ирләрне кухняга чакырды. Өстәл өстендә печенье, булка, шикәрдән кала башка ризык күрмәгәч, Равилнең тавышында канәгатьсезлек яңгырады:

— Син нишләп кайнар ризык хәзерләмәдең, ә? — диде. — Берәр төрле ботка пешерсәң дә начар булмас иде.

— Кайчан өлгерим? Мин дә арып кайттым лабаса. — Тәнзиләнең иреннәре аска салынды.

— Колбаса, сыр турап куй. Май чыгар. Без энекәш белән берәр рюмка да күтәреп куярбыз, дим.

— Сәүдәгәр кеше хәмерне авызына да китерми, диләр ич. Әллә Казанда алай ук түгелме?

— Әйтмә, Рифат. Безнекенең шул инде аның. Жае туры килсә, авызы шапылдап кына тора. — Тәнзилә Рифатның сүзен җөпләргә кирәк тапты.

— Юкка борчылмагыз әле, зинһар. Мин эчмим.

— Очрашу хөрмәтенә дәме? Алай булмый ич инде.

— Ярар, чәегез өчен рәхмәт. Мин китим әле, — дип Рифат урыныннан кузгалды.

— Кунарга калмыйсыңмыни? — Равил соравын Рифатка бирде, ә үзе карашы белән хатынына текәлде. Тегесе аны-моны дәшмәде, чынаяклар җыештыруын белде.

— Юк-юк, сезне борчып тормыйм инде. Сез эшегезгә бик иртә чыгып китәсездер. Ял итегез, мин дә кунак йортына кайтып аякларымны сузыйм.

— Ярар, алайса, энем. Син әйткән мәсьәлә турында уйлашырбыз, яме.

— Рәхмәт. Хушыгыз. Мин кагылырмын әле. Кибетегезгә диюем.

Рифат киткәч, Тәнзилә ире янына килеп утырды, нәзакәтле итеп чәчләрен таратып җибәргәч, кулларын Равилнең тезләренә куйды.

— Нәрсә уйга калдың, Равил?

— Дөньяда яшәүнең кызыгы бармы икән дип уйланып утырам. Булса, нәрсәдә?

— Син әле дә шуны белмисеңме?

— Белсәң, әйт.

— Кесәдә акчаң күп булса, әтәчкә атланып та очып була, дигәннең мәгънәсен ничек аңлыйсың?

— Син бөтен нәрсәне акчага кайтарып калдырасың алайса.

— Акча патшаны да җиңгән ди.

— Кешенең ашказаны ике түгел ләбаса. Ул берьюлы ике костюм, ике пальто да киеп йөрми, ике машинада да йөри алмый. Ә шулай да яшәүнең кызыгы бар дип уйлыйм мин. Тик байлык җыюда түгел. Башкаларга кирәген булуда, аларның рәхмәтен ишетүдә. Нәфесеңне тыя белүдә. Кешелекле булуда. Дөрес, кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен дип юкка гына әйтмиләрдер. Мин менә шулай уйлыйм.

Тәнзилә йөзен чытты:

— Син тагын фәлсәфәгә керештен, Равил. Ник сон кешеләр эткәләшәләр, төрткәләшәләр, кансызланалар, бер-берсенә аяк чалалар, ә?

— Әйе, андыйлар да бар.

— Купчелек. Акыл сатканчы син куршеләргә генә кара. Әнә Фердинанд коттедж сала башлаган. Министрлар кабинетында дусты бар икән. Ярдәм итә, ди. Ә син нәфес, нәфес, кешелек...

— Тәнзилә, менә бу дурт булмәле квартира сина житмимени? Коттеджда нишләмәк буласын? Фердинандларнын өч баласы усеп килә. Ә безнен?

— Тагын шул иске балык башы... Таба алмагач нишлим сон? — Тәнзилә елый ук башлады. — Минем әрнуле йөрәгемә тоз сибәсен. Балага узгач, аны төшерергә үзен дә каршы килмәден ич. Дөрес, тормышыбызнын ин авыр чагы иде. Ә хәзер мине гаеплисен.

— Гаепләмим. Суз унаеннан гына әйтуем. Әйдә алайса, тәрбиягә бирәр бала алыйк. Үзенә ирмәк, юаныч булыр иде.

— Хәзер! Шул гына житмәгән ие.

— Инде туганнар, дуслар белән дә аралашмый башладык. Акча, акча дип...

Тәнзилә торып басты, биленә таянып, тагын каршы төште:

— Кемен бар сон синен? Килеп карадылар бит инде. Бөтенесенен уенда ярдәм сорау. Әнә энен дә. Тормышыбыздан көнләшә кеше. Безгә дә берни дә куктән төшмәде. Алны-ялны белми йөгердек. Әле дә шулай!

— Саранныҥ сарае салкын була, ди халык. Моллюсклар шикелле кабыкка кереп бикләнәбез тугелме?

— Бикләнмә! Ник бикләнәсен?.. Кеше ирләре...

— Менә тагын... Әй! — Равил кулын селтәп урамга чыгып китте. Юк, аңлата алмый хатынына уз уйларын, уз теләкләрен. Әле беркөн генә корбан чалып, Коръән укытыйк дигән иде, ник әйткәненә укенде.

***

Рифатнын карарын Газыйм абзый хуплап каршылады. Кайтып уз көтуен тапса, адашкан малныҥ гаебе юк дип, улынын монача тормышын узенчә бәяләде. «Хәзер өрәнгедә өрек устерә торган чак, сон булса да, ун булсын, әйдә кайт», — диде. Контрактнын срогы да килеп житкән иде, Рифат аны янартып тормады, тормышынын шактый зур өлешенә нокта куеп, Казанга кайтып төште.

Аны кургәч, Тәнзилә тетрәнеп китте. Тәки кайтырга ризалаткан икән, дип ул Равилен гаепләде. Кайда торыр бу, кайда эшләр? Сагыз булып безгә ябышыр микән? Юк инде. Тәнзилә мона юл куймаячак. Йомшак уләнне кырмыска ашый. Тәнзилә әле уз туганнарын да өнәп бетерми. Энисенен дә тел төбендә бергәләп яшәу теләге сизелә, тик Тәнзилә тынычлык ярата. Тормышлары рәтләнеп киткәч, аларны әллә нинди ерак туганнары да килеп таба. Кайсына акчалата ярдәм кирәк, кайсынын баласын вузга кертергә, кайсын шифаханәгә салырга. Хәзер бит һәрнәрсә акча исәбенә эшләнә. Акча — ул узе закон, дип уйлый Зилә. Ишек какканнын һәркайсына ярдәм кулы сузсан, ыштансыз калырсын, көймән бик тиз комга терәлер. Һәр кош уз оясын узе кора.

— Бу чемоданнар settle сездә калып торсын әле, Тәнзилә, — диде Рифат. — Абый кайда сон? Өйдә юк мәллә?

— Юк шул, Мәскәудә иде. Ник берәр кунакханәгә тукталмадын сон? Менә бит, ә! Минем дә анын янына жыенып йөрүем иде. — Зилә турыдан бәрде.

— Борчылма, Зилә. Мин сездә чемоданнарымны гына калдырып торам. Кунакханәдә тукталдым, барасы урыннарым да бар, кунарга кайтмам.

— Ярар, алайса... Гаеп итмә инде. Кстати, Рәшидә исемле хатын синең кемең ул? — Зилә кызыксынулы карашын Рифатның йөзенә төбәде. Адресыбызны ничек тапкандыр.

— Син аны каян беләсен?

— Әле берничә көн элек кенә ул хатын сине сорап килгән иде. Улы белән. Шундый усал, тере малай. Һаман нииндидер пирчәткә дип тәкрарлады.

— Кит аннан. Ул безнең авыл кызы. Бергә укыган идек. — Рифатның йөзенә алсулык йөгерде. — Йомышы төшкәндер. Авылдашлар бит.

— Белмим. Бәлки. Аның белән Равил сөйләште.

— Алай икән. Абый берни дә әйтмәдемени? Бу тол хатын нәрсә эзләп йөри икән димәдеме?

— Юк шул.

— Ярар, мин китим әле. Син кайчан юлга чыгасың сон?

— Кая?

— Мәскәүгә, диден ич.

— Ә... Иртәгә инде. Иртүк.

— Ярар, хәерле юл сиңа. Хуш. Чемоданнарны сез кайткач килеп алырмын. Менә бу кечкенәсен генә алыйм да.

Рәшидә сине сорап килде, дигәч, Рифатның иңендә канат үскәндәй булды. Кайнарланган йөзен җилгә каршы куеп, ул урам буйлап китте. Башында уй өермәсе бөтерелә иде. Барып карасын әле ул. Алай дисән, уйлары һаман теге чакта әйтелгән тол хатын бусагасына кем генә килеп кагылмый дигән сүзләргә барып төртелә дә, күнелдәге омтылышларны тышаулап ала. Килеп йөрүчеләр шулай күп булды микәнни? Һаман уй да уй.

Һәй, Рифатның йөрәген ул чибәр аңлый калса! Юкны бушка авыштырып йөрмә, Рифат. Һәр кош үз оясын үзе кора. Син дә шулай ит инде, дисә. Сиртмәле койрыкларың булмый калмагандыр, син шуларны кара инде, дисә. Икенче яктан, аңа да бер ялгызына җинел түгелдер, үзе шулай диде ич. Бер канат белән генә очып булмый лабаса.

Ленин бакчасында шактый уйланып утыргач, Рифат бер карарга килде.

— Син нинди прапорщик буласың инде, йә! — дип үзен-үзе битәрләп ташлады. — Хәрби, имеш. Ник кайттың соң? Яшәешеңне төптән үзгәртәм дип түгелме? Нәрсә җебеп калдың әле. Рәшидә эзләгән икән, димәк, кирәген чыккандыр. Бар, тап, күр, адресын беләсең. Теләгеңне әйтеп кара.

Һе, баруын барырсың да, нишләп йөрисең дисә. Янында берәр мыеклыны очрата калсаң, ни диярсең, ә? Менә тагын шик. Ярар, хәерле булсын.

Тукай мәйданында автобуска керәм дип торганда, Рифат кинәт туктап калды, Кабан күле ягыннан мәһабәт Мәрҗани мәчете манарасыннан моңлы, аһәңле азан яңгырый башлады:

— Аллаһы әкбәр! Аллаһы әкбәр! Аллаһы әкбәр!.. Әшһәдү әннә Мөхәммәд рәсүллуллаһ!.. Лә илаһә иллəл-лаһ!

Бу минутта Рифат янында басып торган кешеләргә карата үзенә бер төрле җылылык, якынлык тойды, күнеленнән аларга бәхет-сәгадәт, саулык-сәламәтлек, иминлек теләде. Аның дулкынланган йөзендә елмаю уйный иде. Казан Казан шул инде!

Электр кыңгыравы төймәсенә басканда, ул кулларының калтыравын тойды. Әчтән таныш тавыш яңгырагач, Рифат мөмкин кадәр тыныч булырга тырышты:

— Мин әле бу... Рәшидә, мин әле бу, — дип аваз салды.

Ишек ачылып китте. Анда матур чәчәкле халат кигән Рәшидә пәйда булды.

— Мин бу, Рәшидә, мин. Керергә мөмкинме?

— Рифат! Синме бу? Сөбханалла! Әйдә, кер, кер!

Рифат бусагага абынмас өчен, аягын югарырак күтәреп эчкә атлады. Абынмады, шөкер.

— Әллә Себер ягыннан да жылы җилләр исә башладымы? — Рәшидә дулкынлануын яшерер өчен, элгечләргә эленгән киемнәрне төзәткәләргә кереште. Ярый әле бүлмәдән улы килеп чыкты.

— Әни, безгә кем килде?

— Менә Рифат абыең иң. Таныйсыңмы, улым? — диде әнисе. Аның зәңгәр күзләрендә очкыннар кабынган, яңаклары алсуланган, кызыл иреннәре тагын да кызыллана төшкән иде.

— Мин әле бу, егет! Эмир исемле бит әле син, әйеме?

— Так точно! Ә мин сине беләм. Авылда очрашкан идек.

— Син тагын да үсеп киткәнсең димме, Эмир. Менә сиңа бокс пирчәткәләре.

— Менә, улым, пирчәткәле дә булдың, — диде Рәшидә. — Авылда очраган абый бирәм, диде бит. Ул абый кайда соң? — дип теңкәмә тигән иде. — Аннары Рифатка борылды. — Рәхмәт инде сиңа, Рифат.

Рифат кулындагы конфет, чәй тартмалары тулы пакетны Рәшидәгә тоттырды. Хатын инде тынычлана төшкән иде.

— Әйдә, әйдә, түрдән уз, ник ишек төбендә басып торабыз соң әле, — дип ул кунакны бүлмәгә чакырды.

— Менә шушында улым белән икәүләп ду килеп дөнья куып ятабыз. Уз инде, уз.

Рифат залга узуга, дивардагы ир кеше рәсеменә игътибар итте. Аннан елмаеп һәм бер үк вакытта гаҗәпләнгән төсле чибәр генә ир карап тора иде. Секунды белән Рифатның миен, монда килеп зур ялгыш ясадым ахрысы, дигән уй чәнчеп узды. Бер караганда, ул һичнинди начар ният белән йөрми ләбаса. Рифатның карашын тоткан Рәшидә, аны тынычландырырга теләгәндәй:

— Безне әтиебез Мәсгут шулай күзәтеп тора, — диде. Ләкин бу Рифатны тынычландыру түгел, киресенчә, шөбһәгә төшерү булып чыкты:

— Житмәсә, мин борчып йөрим!

— Юк, юк, Рифат, борчымыйсың. Утыр, утыр. Килүеңә, кучтәначләреңә рәхмәт. Хәзер чәй эчәрбез. Сез сөйләшә торыгыз, — дип Рәшидә кухняга кереп китте.

Эмир кунак абыйсы каршына килеп басты, иснәнеп:

— Абый, син хәзер тәмәке тартмыйсыңмы? — диде.

— Так точно! Ташладым. Зарар була, диден бит.

Малайга җавап ошады, ул Рифатның ике тезе арасына кереп, нечкә генә кулларын аның иңбашына куйды, аннары Рифатның күзләренә, кууе кашларына, яңакларына озак карап торды да:

— Син минем әтием буласыңмы? — дип сорады. — Бүтән малайларның әтиләре бар, ә минем юк.

Балаларга гына хас самими сораудан Рифат тетрәнеп китте. Аның өске ирене өстенә тир бөртекләре бәреп чыкты, шактый вакыт ни әйтергә дә белми торгач:

— Ә син, Эмир, минем әти булуымны телисеңме соң? — диде.

Малай аның муенына сарылды:

— Әйе, Рифат абый. Ишегалдындагы малайлар әтиләре белән чаңгы шуалар, уйныйлар, балыкка баралар. Ә мин... Пирчәткәләрне мин иртәгә үк аларга күрсәтәм. Ярыймы?

— Ярый, ярый... Син менә, Эмир, әти буласыңмы, диден. Мин бик тә булыр идем. Тик әниең ни дияр бит әле...

Рифат Эмирны тезләре белән кысып, башыннан сыйпады. Малай аның кочагына кысылганнан кысыла барды. Шулвакыт кухнядан Рәшидә килеп чыкты. Улының Рифат белән кочаклашып торганын күргәч, йөзендә гадәттән тыш гаҗәпләнү чагылды. Рифат та бик нык каушады. Ул Эмирны кочагыннан аерырга теләде, тик малай аңа чатырдап ябышкан иде. Рифат, гафу үтенгәндәй, килеп чыккан хәлне аңлатырга дип торып басты:

— Рәшидәкәй... ни бит... Менә ничек килеп чыкты... Без Эмир белән аталы-уллы булырга килештек. Син үзең... каршы килмәсәң... Мин бу хакта гомерем буе хыялландым, Рәшидә...

Көтелмәгән бу хәлдән ахыр чиктә аптыраган, гаҗәпләнгән, дулкынланган Рәшидә:

— Әй... бу ирләрне... — дип кенә әйтә алды.

Аның күзләреннән эре-эре яшь тамчылары идәнгә, келәмгә коела башлады.

Эмир, Рифаттан ычкынып, әнисен кочаклады:

— Әнием, ник елыйсың, ә? — диде ул. — Елама, сине якларга хәзер без икәү булдык. Рифат абый да, мин дә.

— Улым, әле кичә генә миңа үзең ела, дидең ич. Бүген елама, дисең.

Рифатның сораулы карашын күргәч, Рәшидә аңлатып бирде:

— Кичә улым балалар бакчасыннан кайтканда ярды да салды. Әни, ела, ди. Ник мин еларга тиеш, улым, дим. Мин синең белән бүтән йокламыйм, ди. Сүз тыңламаганда, үз янымда йоклатмаганда, ул елап җинә иде. Мин кызыксына калдым, ник минем белән йокламыйсың соң, дим. Өйләнәм дә Динә белән йоклый башлыйм, ди. Улым өйләнеп куйса, нишләрмен дип борчылуым әле.

Эмир әнисен тынычландырырга кереште:

— Борчылма, әни. Өйләнмим мин. Ул бит кичә иде.

— Нишләп инде? Нәрсә булды?

— Динә риза түгел. Башта риза, диде. Риза дип пәп итеп тә алган иде.

— Чыннан да, бик житди икән хәлләрегез.

Олылар, елмаешып, башыннан сыйпагач, Эмир күптәнге теләген белдерде:

— Рифат абый, иртәгә бакчага мине син илтерсең, яме. Малайлар күрсеннәр әле. Пирчәткәләрне мин анда да алып барам, ярыймы?

— Алар синеке бит, акыллым. Телисең икән, алып бар, — диде Рифат. — Үзең хуҗа.

— Ә мин сиңа әти-абый диярмен.

— Шулай булсынмы, Рәшидә? — Рифат әле икеләнә иде.

— Шулай хәл иттегез ич инде. Мин каршы килә алмыйм.

Җавап Рифатны күкләргә күтәрде.

— Рәхмәт, кадерлем.

***

Равил хатыны белән сөйләшкән саен, үзен бер уч тоз ашагандай хис итә, аны һаман бер уй җәфалый. Башына кайчан кереп утыргандыр, ул моны хәтерләми. Ни хикмәт, аңа үзенең дә, Тәнзиләсенең дә ике йөзе бар сыман тоела. Тышкысы — җәндагы үзгәрешләрне, эч пошуны башкаларга күрсәтмәскә, сиздермәскә тырышу. Гаиләдә бары да ал да гөл, имеш. Икенчесе, ныклап эчкә яшерелгәне — үзләрен бәйләп торган җепләрнең сүсәргәнен сизеп тә шуны танырга теләмәүләреме, туры әйтергә батырлыклары житмәүме шунда. Боларның кайсы хак, әллә икесе дәме, Алла белсен. Алар сөйләшеп утырганда иң мөһиме әйтелми кала бугай. Равил сизә: андый чакта икесенең дә күңелендә юшкын

сыман канәгатьсезлек куерып кала. Әйтерсең лә араларында күзгә күренми генә салкын таш дивар үсә, тормышларының нигезен астыртын гына какшата.

Ярдәм кулы сузучылары булмаса да, алар шактый житешле тормыш кордылар. Менә дигән квартиралары дисеңме, шәп машиналары дисеңме, итальян мебель, зиннәтле савыт-саба, кеше күзе төшәрлек кием-салым. Әмма, әмма... Акчасыз юл такыр, акча акылыңны алыр дигән гыйбарәнең соңгы өлешен истән чыгарганнармы әллә? Халык әйтсә, хак әйтә. Акча бар, ә шатлыгы кайда? Баштарак алар карамый калган яңа спектакль, концертлар сирәк иде. Иптәшләре, юлдашлары белән дә, үзләре генә дә чыгып йөгерәләр иде. Эшләренә зарар иткән чаклары да булгалады. Ә тора-бара... Әнә беркөн генә Төркиягә тауарга баргаләп йөргән Саимә шалтыратып, София Ротару концертына чакырды. Барырга җыенсалар да, Тәнзиләләр концертка эләкмәделәр.

— Ник килмәдегез? Билетлар чүт кенә янмый калды бит? — дип Саимә иртәгесен шелтә белдерде. — Сез мал дип үләсез инде. Юк нәрсәгез юк лабаса.

Бусы да көнләшә бугай, дип уйлап куйды Тәнзилә. Торна йомырка салганда, карганың арты ертыла, диләр. Саимәнең эшләре бик гөрләми шул.

— Кинәт кенә килеп чыккан эшне хәл кылдык без ул көнне, — диде Тәнзилә. — Чыпчыкны бер кулдан ычкындырсаң, янадан тота алмыйсың аны.

Концертка бардылар алар баруын, беркөнне, бардылар. Шәһәрне тутырган «татарча солянка» игъланнарын күргәч, Равил кызыксына калды. «Солянка» дигәч, моның тозы бардыр дип уйлады. Сирәк кенә эләккән буш вакытларында телевизорга төртелеп утыра-утыра кеше арасына чыгуны онытып та барабыз лабаса. Барыйк әле. Тәнзиләсе күлмәкләрен, балдакларын, алкаларын, түшенә эләсе кулоннарын сайлый-сайлый, чәчләрен ясый-ясый чүт кенә соңга калмадылар.

Баштагы елларда спектакль, концерттан күңелләре хушланып, яктырып, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә сайрашып кайталар иде. Бу юлы исә җырчыларның ярым шәрә чыгуларыннан, «фанерага» җырлауларыннанмы, шулар тирәсендә болганучы «поддержка» төркемнәреннәнме күңелләрендә ризасызлык калды.

Алып баручыларның чинап-чинап алуларына, башкаручыларның һәркайсын «иң яхшы», «иң яраткан», «иң популяр», «менә хәзер сезнең кумирыгыз үзе чыга», дип урынлы-урынсыз мактауларына ачулары кузгалды, кәефләре бозылды. Җитмәсә, Равилнең икенче ягына күзен-башын юмарт майлаган бер чая хатын туры килде. Тончыктырырлык итеп хушбуй сипкән, колакларына кул учы хәтле алтын алкалар таккан. Борын яфрагында бриллиант җемелди. Үзе әледән-әле Равилнең йә җилкәсенә, йә тезенә кагылып гайбәт сипте:

— Мин бу җырчыны беләм, фатиры юк!

— Менә бусы бер хәерче ие, хәзер әнә ничек киенә...

— Бусы хатынын аерган, хәзер бик каты эчә икән...

Тәнзиләнең чын ачулары чыкты, курчак хатынның авызына бәрерлек булды. Терсәге белән Равилгә төртеп:

— Ник шуны туктатмыйсың, ә? Авызын ябарлык итеп әйт үзенә, — дип кайнар ысылдады.

Равил җилкәләрен җыерып, бер дә юкка башыңны катырма әле, дигәч, Тәнзилә фырт итеп читкәрәк борылып утырды. Юлда алар троллейбус тәрәзәсеннән урамга карап сөйләшми кайттылар. Җитмәсә «бөке»гә эләгеп, троллейбус акрын сөйрәлде. Машина куеп торырга урын булмавы, шәһәр транспорты белән йөрүләре болай да кәефләрен бозган иде. Биш йөз сумны суга салдык дип уйлады Тәнзилә.

Икенче көнне аларда бик күңелсез сөйләшү булды.

— Кара әле, Равил, — дип сүз кузгатты Тәнзилә, иренә озаклап карап

торгач. — Син көзгегә күз салганың бармы, ә? Маңгаең ничек кинәеп килә бит. Ха-ха-ха... Пеләшең беләң тоташып бара. Әле кайчан гына чәчең куп-куе, кап-кара ие. Халыкның акыллы чәч килделе-киттеле башта тормый дияе дөрес микән әллә?

— Син акыллы баш чәчне яратмый дигәнне дә онытма. — Равил шаян тонда сөйләшүне дәвам итәргә уйлады. Һәм ялгышты. — Тәнзилә, ә син үзең хәзер миңа беләсеңме нәрсәне хәтерләтәсең? Кулларың белән бөеренә таянганда, ике тоткалы кувшинны! Бүлтәеп чыккан корсагың нәкъ кувшин корсагы. Кая китте синең зифа буйларың...

Суы артыкка китсә, кечкенә инеш тә буаны ерып чыга. Икенче иягенә суккалап массаж ясап утырган Тәнзиләнең талагы ташып, буяулы матур күзләре түгәрәкләнде, зәңгәр очкыннар чәчрәтте. Зәңгәрле-яшелле тавышлар чыгарып, ул тотлыгы-тотлыга:

— Ә син... нәкъ рахитик... авыл гыйбады! Ир, имеш! — дип ярсып китте. — Кеше ирләре хатыннарыннан көлми. Ә син! Хәчтерүш, мин булмасам, ниләр кырыр идең? Утырыр идең капкагыз төбендә бүрәнә өстендә! Әтиең шикелле.

Равил һич тә мондый реакция көтмәгән иде. Еракка китте Зилә, еракка. Үзе башлаган сүздән үзе үк ямьсез нәтиҗә ясады. Шулай итеп гаилә бәхетенең тагын бер зур канаты каерылды. Әти-әнисенә теш тидергәнне ир заты күтәрә аламы соң:

— Ә син мин булмасам, таракан баскан черек өегездә коргаксып яткан булыр идең! Ярар, барысын да әйтеп тормыйм инде!

Аның бу сүзләре калай түбәгә яуган боз кебек яңгырады. Хәер, боз ява да эреп бетә. Ә сүз йөрәккә салкын гына бөркеп калмый, озакка тамыр җибәрә.

— Таракан?! Коргаксып?!.

Зилә тагын нәрсәләрдер кычкырып калды, Равил ишекне дөпелдәтеп япты да урамга чыгып китте. Үзен кая куярга белми шактый йөргәч, ресторанга барып керде. Халык әйтсә, хак әйтә: тыштагы буранга чыдап була, өйдәге буранга чыдап кара. Ресторанда шактый эчте, әмма исермәде. Тирән уйларына батып утырганда, аның янына сап-сары чәчле, алсу йөзле, зәп-зәңгәр күзле чибәр генә бер кыз килеп утырды. Карап торган, күрәсең.

— Күрәм, сезгә нидер булган, ахрысы, — диде чибәркәй, чиядәй иреннәрен ялмаштыра-ялмаштыра. Аның шулай әллә кайчангы танышыдай сүз катуы Равилне уйларыннан айнытты. Каян гына очрап торалар соң шундый чибәр кызлар минем юлымда? Менә тагын берсе, дип уйлап куйды.

— Сез күрәзәчеме әллә, чибәр туташ? Әйе, хатыным белән бик каты сүзгә килдек әле.

— Шулайдыр, шулайдыр. Моның эшендәме, гаиләсендәме бер-бер хәл булгандыр, дигән идем. — Гүзәл кыз керфекләрен кыштырдатып, тагын нәрсәдер әйтергә теләгән иде, Равил бүлдерде:

— Менә сез дә ялгыз. Сезнең дә күңел китек инде, алайса. Шулаймы?

— Шулай...

— Чибәрләргә дә яшәү җиңел түгелмени?

— Һәй, әйттегез! Киресенчә. Чибәр дип кем генә килеп бәйләнми. Һәрберсенең уенда бер генә нәрсә...

— Аңладым, гаиләгез юк, алайса.

— Бар иде... Ир дигәнем көнләшеп тенкәмә тиде. Кул күтәрде. Ә мин аңа турылыклы идем. Кул уйната башлагач, тоттым да хыянәт иттем. Шуның белән вәссәлам.

— Кайчаннан бирле сөйләшеп утырабыз, ә исемегезне белмим. Мин — Равил.

— Элеонора.

— Исемегез дә бик матур икән. Әйдәгез, танышу хөрмәтенә берәрне күтәрик әле.

Кыз кыстатып тормады. Равил рюмкаларга янә хәмер койды. Була бит шундый вакытлар: үз хәлеңне иң якын туганыңа да сөйләмисең, һәм кайвакыт кинәт кенә ачылып китәсең дә гомереңдә беренче очраган кешегә бөтен күңелеңне бушатасың. Хәмер тәэсиреннәнме, әллә чыннан да күңелләге буа ерылып киткәнгәме, Равил янында сүзен хуплап утырган гүзәл кызга үз хәлен сөйләп бирде. Кыз озын нечкә бармаклары белән аны битеннән сыйпап да алгалады. Равил аны озата китте һәм бу төнне өенә кайтмады...

Тау башыннан кубып аска тәгәрәгән ташның төшкән саен тизлеге арта бара. Менә Равил дә Элеонора белән яшерен-батырын гына бер ялгыз карчык фатирында очрашып йөри башлады. Ә күптән түгел генә...

***

Дон-дон... Доң-дон... Доң-доң... Бу ни бу? Кем шулай буш мичкәгә бәрә? Башны яра бит бу... Равил һич аңлый алмый ята. Кайда соң әле ул? Житмәсә укшыта... Уф! Әллә нинди исләр тагын... Каян килә? Торып утырмакчы булган иде, башына күсәк белән ордылар. Күз алдында тагын әллә нинди җеннәр биеп йөри башлады. Ул янә диванга ауды. Бераздан аңына килде бугай, тагын торырга талпынды. Бу юлы да күсәк башын янгыратты, тик егылмады. Күзе дивардагы тонык кына янып торган лампочкага төште. Миеннән кайнар уй йөгереп узды: нинди кирпечләр соң анда? Кая килеп эләккән ул? Утыра-утыра тирә-ягына карарлык хәлгә килде. Әһә, әнә аның машинасы. Тукта! Кем әле ул аның машинасы янында ята? Ниндидер хатын-кыз... Өстендә сәдәпләре каптырылмаган кофта. Тәнзиләме? Ботын-чатын аерып болай ятмас аның хатыны. Ул түгел. Йоклыймы соң ул, юкмы? Равил уятырга теләп, хатынга кагылган иде, йөрәге жу итте. Аның тәне сап-салкын иде. Күзләре ачык. Ис аннан килә икән, ул коскан, тырпайган күкрәкләре буялып беткән.

Чү! Бу Элеонора ич! Ул, ул! Равилнең бөтен гәүдәсе жыерылып килде, тәненә салкын тир бәреп чыкты. Йа, Хода! Ничек булды соң әле бу! Ничек?

Равил көч-хәл белән торып басты, башы әйләнеп чүт кенә егылмыйча калды. Ул әкренләп чуалган уйларын тәртипкә китерергә керешә. Әйе, әйе, Элеонора белән алар кичә гаражга килделәр. Бикләнделәр, шәп итеп коньяк эчтеләр. Кызны ул кыстап-кыстап эчерде, эчкәч, син батыррак буласың, оялмыйсың, диде. Менә хәзер сөяркәсе гараж идәнендә аунап ята. Нәрсә булды икән соң аңарга? Беренче генә лаякыл эчүләре түгел ләбаса! Хәзер нишләргә инде?

Бу сорау миенә шырпы кебек кадалды. Коточкыч бәла, фаҗига бит бу! Аһ! Ул янә ятагына ауды. Моның өчен ул, ул җаваплы. Димәк, дөньясы җимерелде, кара көннәр килде. Болай да Тәнзиләсе белән аралары күптәннән салкынайган иде, ул Равилне кичермәячәк. Хәзер инде барысы да чәлпәрәмә киләчәк.

Болай күпме ятарга мөмкин? Торырга, чыгарга, нидер кылырга кирәк ләбаса. Тик нәрсәдән башларга? Нәрсәдән?

Аяк астында буш шешәләр тәгәрәде. Равил чайкала-чайкала ишеккә юнәлде. Саф һава аның сулышына бәрде, айнытып җибәрде. Һәм хәтерендә берәм-берәм кичәге хәлләр борынлый башлады. Алар машина төтененә тончыкканнар ич. Элеонора нәфесле зат, шуна күрә төн урталарына кадәр калдылар. Равил хәмер парларыннан сыекланган баштан сөяркәсе тунмасын дип машинасын кабызган, күрәсең. Монысын ул үзе хәтерләми. Болай булга-ач! Эх, Тәнзиләсе аны гомердә дә гафу итмәячәк. Бетте, бары да бетте...

Әллә каян гына кечкенә болыт килеп чыкты да күк йөзен каплап алды,

чиләкләп янгыр коя башлады. Равил моны сизмәде, урам буйлап китеп барды. Ул әле кая барасын да белми иде.

Алпан-тилпән бара-бара ул милиция формасы кигән егетләрне абайлап алды. Ә-ә, ана бит башта милициягә барып, хәлне сөйләргә кирәк. Бина ишеген ачып керүгә, аның каршында дежур лейтенант калыкты:

— Гражданин, сез кем буласыз? Ни йомыш?

Аннары Равилнең өс-башын күздән кичергәч:

— Бу кыяфәттә ничек килергә уйладыгыз? Барыгыз, кайтып торыгыз, — дип ишеккә күрсәтте.

— Миңа ни булган? — диде Равил, кулын селтәп. — Миңа сезнең начальник кирәк. — Кинәт аны очкылык тота башлады.

— Сез айнып та җитмәгәнсез, фу-у! — лейтенант йөзен читкә борды. — Кайтып йоклагыз. Аннары килерсез!

Шул чакта яннарына бер капитан килеп басты:

— Нинди тавыш бу? — Аннары Равилгә төбәбрәк карагач, аптыраштa калды.

— Абау... Равил, син түгелме соң бу? Мондый кыяфәттә ничек килергә булдың? Что стряслось, парень? Үзеңнән хәмер, төтен исе аңкып тора.

Равил күтәрелеп карады. Аның каршында күптәнге танышы, ГАИ инспекторы Әгъзам Ихсанов басып тора иде.

— Авариягә очрамагансыңдыр бит?

— Әгъзам Вәлиевич, синмени әле бу? Авария дисеңме? Әйе, әйе, авария... Аварияиең дә нинди генә әле. Ә син монда нишләп йөрисең? Әллә үзең дә...

— Соң, эш урыным шушы бит инде.

— Ә-ә, ГАИ мени бу? Уф, Алла... Иш янына куш.

Әгъзам Исхаков, башын чайкый-чайкый, Равилне бер бүлмәгә алып керде. Чәйнеккә су агызып утка тоташтырды:

— Тукта әле, болай булмый... Чәй эчеп ал, аннары сөйләрсең.

Кайнар чәй авызын өтеп алса да, Равил моны сизмәде. Аның маңгаеннан аккан тиргә, йотлыга-йотлыга эчкәненә карап торгач, Әгъзам соравын кабатлады:

— Җә, ни булды? Машинаңны кайда калдырдың?

— Машинанымы? Машина исән лә ул... Гаражда. Ә менә аның янында мәет ята. Элеонора.

Равилнең сүзләрен Әгъзам исе китеп тыңлап торды. Чыннан да, Равил башына төшкән фаҗига коточкыч иде.

— Ә Тәнзиләң моны беләме соң? Аның каршына ничек килеп басасың инде? Аның характеры унга түгел, сулга ясалган резьбә дигән идең ич.

— Юк, белми әле. Ул Мәскәүгә эш белән киткән иде. Бүген кич кенә кайтырга тиеш.

— Алай икән... Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә, ди халык. Дөньяны онытып йөргәнсең шул. Ай-яй-яй...

— Әгъзам Вәлиевич! Киңәш бир. Нишлим? Минем бит милициянең тикшерү бүлегенә баруым иде.

— Нинди генә киңәш бирим икән инде. Милициягә бару дөрес булыр. Алар инде аннары үзләре карар... Бу кыяфәтеңдә урамда йөрмә инде. Әйдә, үзем илтеп куям.

— Әй-й, хикмәт кыяфәттәмени-и! Бөтен тормыш чәлпәрәмә килде бит. Кеше арасында мәсхәрә. Дус бар, дошман бар. Уф-ф!

— Да-а, сине бит утыртып куюлары да ихтимал.

— Шулайга ук китәр микәнни? Мин үтермәдем бит ул кызны! — Равилнең

башы салынып төште. — Төтенгә буылыпмы, косыгына тончыгыпмы үлгән бит ул. — Үзем ничек исән калганмын әле. Әгъзам Вәлиевич, әйдә, гаражга барыйк әле. Үз күзең белән күргәч, бәлкем, берәр яхшы киңәш бирерсең, ә?

Әгъзам үзе дә аптырашта иде. Зур бәлагә тарган танышына ярдәм кирәген ул аңлый. Тик ничек ярдәм итәргә соң? Гаражга мәет янына барып ни кырасың?

— Равил, мин сине теләсәң кая илтеп куя алам. Тик гаражына түгел. Минем анда күренеп йөрүнең бер кирәге юк. Тикшерү эшләре башлангач, анда син нишләп йөрдең диюләре ихтимал. Минем дә хатын бар бит. Аның да шиккә калуы мөмкин, — диде.

— Анысы да дөрес. Әйдә алайса... милициягә. Әллә башта өйгә кагылыйм микән? Тәнзиләгә записка язып калдырырга дим... Мине бит алып калулары бар.

Юлда ул күңеленнән Тәнзиләсе белән сөйләшеп барды. Әгәр дә аралары бозылмаса, Равил шушы фаҗигагә юлыккан булыр идеме! Әчелешләре кайчан, ничек көчәеп китте соң аларның? Ике арада пыскып яткан утлы күмер Мәскәүдән теге Сәлим дигән адәм килгәч ныклап кабынып китте дисәң, аннан алда да кискен бәрелешләр булмады түгел...

***

Әйе, беркөнне Равил кибетләренә кайтып кергәч, эчке аулак бүлмәдә бер ят иргә юлыкты. Ул Тәнзилә белән көлешә-көлешә, авызын авызга куеп сөйләшеп тора иде. Тәнзилә:

— Равил, таныш булыгыз, менә Мәскәүдән Сәлим килгән. Безгә тәкъдиме бар, — дип торып басты.

— Мин Сәлим Мифтахов булам, бизнесмен, — диде киң иренле, җәенке борынлы ир, юеш кулын сузып. Зилә белән шуны уйлашып утырабыз әле. Сез монда нигездә чүпрәк-чапрак сату белән мавыгасыз икән. Ә мин сезне Мәскәүдәге оптовый базадан ашамлыклар белән тәэмин итеп тора алам. Транспорт үземнеке, чыгымнарын түләрсез.

— Моның өчен безнең кибет кысан бит.

— Кысылырсыз, кием-салымны киметерсез. Халык бит свежий азык-төлекне урып ала. Җә, ничек?

— Уйларга кирәк. Тиктомалдан гына эшләнә торган эш түгел.

Сүзгә катнашырга талпынып торган Тәнзилә:

— Тәвәккәллик, Равил. Файдалы тәкъдим ич, — диде.

— Азык-төлекнең срогы тиз чыга, Тәнзилә. Шуны да онытма син.

— Анысын хәл итү юлларын үзем өйрәтермен, — диде юеш кул иясе.

— Суыткычлар кирәк булачак. Аларны монда кая куярбыз?

— Ярар, уйлашыгыз. Бик керемле эш. Мин киттем. — Сәлим ишеккә борылды.

— Уйлашырбыз. Визиткагызны калдырыгыз әле.

— Мин аны Тәнзиләгә бирдем инде. Сау булыгыз.

Чокырлы ияге бүлтәеп торган бу кеше Равилгә күп ягы белән ошамады. Туктаусыз сагыз чәйнәве беләнме, йонтәс кашлары беләнме, шул кашлар астындагы уйнап торган күзләре беләнме. Җәенке борыны тагы! Йөзенә күз ташлауга, Равил бу бәндә кашларын йолкып, әллә кырып йөри микән, дип уйлап алган иде. Кәефе китүен ул хатыныннан яшерә алмады.

— Менә шундый шома затлар сине кайдан килеп таба соң, ә? — диде ул Тәнзиләгә. — Теге юлы да берәү селәгәен агызып утыра иде...

Тәнзилә сүзне уенга борды:

— Син, Равил, матур, хуш исле чәчәкләрне яратасыңмы, юкмы?

— Яратсам...

— Аларны бит син генә түгел, бүтәннәр дә ярата. Әйт әле, мин матурмы?

— Тәнзилә! Мең кат әйткәнем бар! Син матур, син чибәр.

— Шулай булгач! Матурга кеше күзе төшми буламы инде. Моның өчен мине гаепләргә кирәкмени? Минем бер гаебем дә юк лабаса.

— Матур дип синең янга теләсә кем килеп йөрсенмени?

— Яныма кермәгез, йөрмәгез, дип кычкырып торыйммыни инде мин. Равил, Равильчик, җә инде, җә. Әллә бер дә юкка көнләшәсең инде? Син матур, шуңа күрә яратам, дип миңа өйләнден. Хәзер матурлыгым гаеп саналамыни?

Менә сөйләш син хатын-кыз белән!

«Красота правит миром», дип ничек өстәмәде әле. Равил кулын селтәп, сату залына чыгып китте.

...Бераз вакыт узгач, алар, Мифтахов тәкъдимен файдалы, кабул итәрлек дип таптылар. Мәскәүнең бер күпләп сату базарыннан Тәнзиләләр кибетенә товар килә башлады.

***

Фаҗигале үлем белән тәмамланган эш тирәсендә вакыйгалар куерганнан куерды. Равилнең кешелеге бетте. Йөрәген савып, миен суырып торган ачы кайгыдан, зур сынаулар көтүдән җаны гаҗиз иде. Йөрешләре үзгәрде, муены бөгелеп төште. Теге бәхетсез көнне Элеонораны моргка озатуга, аны тикшерү комитетына алып килделәр, көн буена җентекләп сорау алдылар. Шәһәрдән читкә чыгып йөрүне тыйган кәгазьгә кул куйдырдылар. Протоколга имза салганнан соң, тикшерүченең: «Әлегә кайтып торыгыз», — дигәнен ул аңламады. Иректә калуы аңына барып җиткәч тә күзләрен челт-челт йомгалап урыныннан кузгалмады. Тикшерүче Ризван Харисович Әшрәпов кабат:

— Әлегә китә аласыз, — дигәч кенә дөньяга әйләнеп кайтты.

— Сез читкә чыгып йөрү тыела, дисез. Минем эшем сәүдә белән бәйле бит. Чит шәһәрләргә барасым бар иде. Нишләрмен икән соң? — диде.

Тикшерүче — аксыл чырайлы, җитди, сөзүчән карашы белән үзегенә үтә торган егет гаҗәпкә калды.

— Равил Газыймович! Алайса, бераз сабыр итегез. Сез нинди бәлагә юлыкканыгызны аңлап бетермисезме әллә? — диде. — Тикшерү башлана гына бит әле. Эшләрегезне куеп торырга туры килер.

— Мин үзем дә чүт исән калдым лабаса. Әйттем бит инде. Элеонора сыман буылып ятканмын. Әлегә хәтле рәтләнә алмыйм.

— Ул хатынны ник гаражыгызга алып бардыгыз? Ник бикләндегез? Ник машинагызны кабыздыгыз? Гаражны төтен басачагын кем белми инде.

Равилнең маңгае тагын тиргә чыланды, башы күкрәгенә сыгылып төште.

— Үзе шалтыратты бит ул. Үлеп сагындым, диде. Мин үзебез барып йөри торган фатир хуҗасына шалтыратып карадым, өйдә туры килмәде. Элеонорага әйткән дә идем, башка көнгә калдырыйк дип, тыңламады. Бүген үк, хәзер үк очрашыйк, диде. Бик темпераментлы иде ул.

— Шуннан гаражыгызга алып киттегез инде?

— Бәхетсезлеккә каршы.

— Ә ни өчен аның квартирасына бармадыгыз?

— Мин анда бер генә бардым. Кеше күзенә күренеп йөрисем килмәде. Аннары, аның квартирасында эчемлек юклыгын белә идем. Медсестраның хезмәт хакы күпме икәнен үзегез дә беләсездер. Ә безнең гаражда сатарга дигән бер-ике әрҗә эчемлек саклана. Гараж гына түгел, склад та ул безнең. Бардыгыз, күрдегез, тикшердегез ич инде.

— Гаражыгызга еш йөрдегезме? Анын белән диюем?

— Юк. Вакытлыча йөри торган квартирага барырга мөмкинлек булмаганда гына.

— Аңлашылды. Ә диванны анда кайчан илткән идегез?

— Ике-өч ел элек. Дачалары булганнар искергән әйберләрен шунда ташый. Безнең дача юк. Яңа мебель алгач, ул диванны ташларга җәлләдем дә гаражга илтеп куйдым. Арып кайткан чакларда ял итеп алырга әйбәт иде.

Равил, башын иеп, йөрәген талкыган соравын бирергә батырчылык итте:

— Ризван Харисович, минем хәл шулай бик өметсез дип уйлыйсызмы?

— Тикшерү дәвам итә. Кан составын, эчемлекнең сыйфатын тикшерергә кирәк. Сез анда бушаткан шешәләрдәге бармак эзләре шактый икән. Кирәгегез чыгуга без сезне повестка җибәреп чакыртып алырбыз. Әлегә барыгыз, кайтып торыгыз.

«Кайтып торыгыз». Тик кая кайтасы? Бу хәлләр фаш булгач, Тәнзилә ике генә сүз әйтте: күземә күренмә! Равил инде ничә көннәр дус-ишләрендә кунып йөри. Хәзер кайтмый да булмас, повестканы квартираңа җибәрербез, диделәр бит. Күрше-тирә күзенә чалынмыйм дип, Равил караңгы капкач кына кайтты. Ярый әле Тәнзилә өйдә юк иде. Ул үзе белән алып кайткан ризыкларын капкалап кабинеттагы диванга барып ауды. Бик тырышып йокыга китәргә маташты, тик йокы алмады. Бераздан хатынының кайтып керүен, бүлмә ишеген ачып карагач: «Кабахәт! Кабахәт, кабахәт!» — дип тиргәвен ишетте, йоклаганга салышты.

Шулай берничә көн йөргәннән соң, Тәнзилә ишекне бәреп керде дә:

— Син чыгып китәсеңме, юкмы?! Әллә милиция чакырганны көтәсеңме? — дип акырды. — Гаражыңа олак! Шунда рәхәтлек тапкансың бит!

Равил үзен мөмкин хәтле тыныч тотарга тырышып:

— Вакыты җиткәч китәрмен, — диде. — Син акырма әле. Квартираның яртысы минеке, хакым бар.

Тәнзилә «лып» итеп урындыкка утырды:

— Оятсыз, жир бит! Әллә монда яшәмәкче буласыңмы, ә? Бар, фахишән квартирасыз булмагандыр, шунда олак! Наследствосы сиңа булыр!

— Син, Тәнзилә, бик чәпчемә, — диде Равил. — Әйтсәм әйтим инде. Син мине бозау дип уйладың бугай. Мәскәүдә дә, монда да йөргән нәстәң барын беләм. Беренче укны син аттың. Барын да сөйлимме?

Тәнзиләнең нидер әйтергә теләгән авызы ачык килеш калды. Күзләре акайды, матур йөзен аклы-кызыллы тимгелләр басты.

— Миңа кадәр йөргән егетеңә: «Рамил, кадерлем, любимый мой, прости. Я глубоко ошиблась, пожалуйста, прости меня», — дип инәлеп язган хатыңны кая кыстырып куйганыңны хәтерлисеңме?

Тәнзилә сикереп торып арлы-биреле сугыла башлады:

— Ялган! Ялган! Не было такого! Ничего не было!

— Ялган, имеш. — Равил шкафтагы китапларның берсеннән эре-эре хәрефләр белән язылган дәфтәр битен йолкып алды.

— Ә менә бу нәрсә?

— Какая низость! Как ты мог?! — Ярсуын авызлыклый алмаганда, Тәнзилә русчага күчә иде. Ул кинәт очынып килеп ире кулыннан хатны йолкып алды да теткәләп ташлады.

— Мин соң аңладым шул. Ул егеткә син минем белән хыянәт иткәнсең, аннары аның белән миңа! Хатыңны ертып, дәлилне юк иттем дип уйлыйсыңмы әллә? Юкка! Мин аның копиясен алган идем инде. Син, Тәнзилә, артык чәбәләнмә! Так что мы с тобой квиты. Шунысы гаҗәп: мин бик яратышып өйләнештек дип уйлый идем.

— Кем белән яшәгәнмен мин! Кем белән яшәгәнмен! — Тәнзилә бүлмә

ишеген бәреп чыгып китте дә серванттагы бәллүр вазаларны идәнгә бәрә башлады. Равил залга чыкты, исән калган сервизларны хатынына берәм-берәм бирә торды, Тәнзилә исә аларны кыруын белде. Бу мизгелдә аның миендә бер уй бөтерелә иде: «Нинди хәлгә төштем мин! Нинди хәлгә!»

***

Тикшерү эшләре дәвам итте. Беркөнне Тәнзиләгә дә повестка китереп бирделәр. Тикшерүче кабинеты ишеген ачканда, Тәнзиләнең тез буыннары калтырый иде, ярый әле керүенә урын тәкъдим иттеләр.

— Утырыгыз, Тәнзилә Әхмәтовна, — диде чәче агарып килә торган кырык-кырык бишләр тирәсендәге тикшерүче. Мин Ризван Харис улы Әшрәпов булам. Гаиләгездә килеп чыккан хәлнең сезнең өчен никадәр авыр икәнен аңлыйм. Ләкин барын да ачыкларга тиешмен. Вазифам шундый. Сез минем сорауларга җавап бирергә әзерме?

— Яшермим, Ризван Харисович, сезнең тирәләргә кабат аяк басарга Ходай язмасын, дип килдем. Тик нишләмәк кирәк? Сорагыз.

— Ярый, алайса, рәхмәт. Әйтегез әле, сез квартирагызда спиртлы эчемлекләр тотасызмы?

— Аз-маз бар инде ул. Сату-алу эшендә кирәге чыккан чаклар була. Кибеттәгесен әйтеп торасы да юк. — Тәнзилә тир бәреп чыккан маңгаен, кызарып киткән яңакларын хуш исле кульяулыгы белән сөрткәләп алды.

— Нинди эчемлекләр инде ул?

— Аракысы да бар... Коньягы да. Шәраблар — агы, кызылы...

— Ә гаражыгызда эчемлекләр сакламыйсызмы?

— Бу сәер сорау, Ризван Харисович. Безнең гараж берьюлы склад булып та хезмәт итә. Зур ул безнең. Эчемлекләр аның махсус бүлегендә тора. Хәер, мин үзем гаражда бик сирәк булам.

— Соңгы тапкыр кайчанрак булдыгыз?

— Ел, ел ярым чамасы элегрәктер, мөгаен. Товарны ирем Равил илтте, алып кайтты. Эчемлекләрне дә...

— Квартирагызданмы?

— Монысын төгәл әйтә алмыйм. Бәлкем, кибеттән дә алган чагы булгандыр.

— Тәнзилә Әхмәтовна, мин моны ни өчен сорыйм. Теге фаҗига көнендә, төнендә дисәк, дөресрәк булыр, бушаган эчемлек шешәләрендә сезнең бармак эзләре дә ярылып ята. Моны ничек аңлатыр идегез?

— Иптәш следователь, бу бик гади аңлатыла. Мин бит хатын-кыз. Өйдәге мебельне, сервант, гарнитурларны тузаннан даими тазартып торам лабаса. Шешәләрне дә...

— Ә кибеттәгеләрен?

Аларын да. Гаҗәпләнерлек урын юк монда.

— Бар шул, Тәнзилә Әхмәтовна. Бер шешәдәге эчемлек составында моңа кадәр күренмәгән бик көчле синтетик наркотик булганлыгы ачыкланды. Ул анда каян килде икән соң?

Моны ишеткәч, Тәнзиләнең йөрәге урынынннан купты, иреннәре калтырый башлады. Ярый әле шул мизгелдә өстәлдәге телефон телгә килде. Тикшерүче сөйләшкән арада Тәнзилә үзен кулга алып өлгерде.

— Нинди оятсыз, әшәке җан! Әле наркотик та кулланып йөргән икән, — диде ул аягүрә басып. — Димәк, теге кабахәт хатынны исертеп, йоклатып мәсхәрә иткән инде, алайса! Явыз! Үз башына булган икән.

— Сез ирегезне тиргисез инде?

— Кемне булсын тагын!

— Утырыгыз, утырыгыз, Тәнзилә Әхмәтовна. Менә су, эчегез. Тынычланыгыз. — Тикшерүче Тәнзиләнең йотлыга-йотлыга су эчкәнен карап торды. — Эш сез әйткәннән катлаулырак шул, — дип сорау алуын дәвам итте. — Хикмәт шунда: үлгән хатын канында да, ирегез канында да шул наркотик барлыгы беленде. Бу ничек була соң инде? Ирегез үз эчемлегенә дә наркотик салган буламыни?

— Белмим, белмим, Ризван Харисович. Моны сез анын үзеннән сорагыз.

— Сорадык, сорадык. Гомеремдә дә андый нәрсәне кулыма алганым юк, ди.

— Акланыр өчен ул ни әйтмәс.

— Эш әйтүдә генә түгел шул, Тәнзилә Әхмәтовна.

— Тагын нәрсәдә соң?

— Наркотикны ирегез салган булса, аны үзе эчәмени инде. Аннары кулындамы, киемендәме, машинадамы, табыннарындамы, гомумән, шул тирәдә азмы-күпме эзе калыр иде. Криминалистлар җентекләп тикшерде, һичнинди эзе табылмады. Ул салмаган аны.

— Алайса, кем? Ул каян килгән?

— Менә без шуны ачыкларга телибез дә шул.

— Сез миннән шикләнмисездер бит?

— Моның өчен безнең дәлилләребез юк. Без әлегә тикшерү белән мәшгуль.

— Тикшерегез. Ләкин минем монда бер гаебем дә юк, Аллага шөкер. Мин Равилнең өстемнән фахишәләр белән йөргәнен белгән булсам, андый нәрсәләр белән маташмас идем. Башына шешәсе белән томырган булыр идем.

Тикшерүче көлеп куйды:

— Һәм бик нык ялгышыр идегез. Җә, ярар. Менә шушында кул куегыз да киттек, Тәнзилә Әхмәтовна.

— Кая?

— Сезгә, Тәнзилә ханым, сезгә. Гафу үтенәм, вазифам буенча без сезнең квартирагызда, кибетегездә тикшерү ясарга тиешбез. Менә ордер.

— Кирәк икән, тикшерәсез инде. — Тәнзилә тыныч калырга тырышып шулай диде диюен, әмма чигәләрендәге кан тамырларының бүртеп бик еш тибә башлаганын абайлады.

Ярты сәгатьтән тикшерүче, берничә криминалист бүлмәләрдәге мебельне, шкафлардагы сервизларны, савыт-сабаны, кием-салымны әллә ничә төрле аппаратлар, пумалалар белән тикшереп чыктылар. Тәнзиләне иң гарьләндергәне шул булды: понятойлар итеп аларның күршеләре чакырылган иде. Шулай ук җентекләп кибеттә дә тикшерү эшләре уздырылды. Алдан ук әйтеп куйыйк, наркотик эзе беркайда да табылмады. Исән калган бәллүр вазадан гараж ачкычлары килеп чыккач, тикшерүче белән криминалист бер-берсенә мәгънәле итеп карашып алдылар.

***

Тикшерүче Әшрәпов Равилне кабат чакыртып алды.

— Монда бер табышмак килеп туды бит әле, Равил Газыймович, — диде ул. — Соңгы вакытта Мәскәүдә дә берничә кеше шундый ук наркотик белән агуланып, хастаханәгә эләккән икән. Алар да сезнеке кебек коньяк эчкәннәр. Сезгә ничек килеп керде икән соң ул? Сез аны Мәскәүдән алабыз дигән идегезме әле?

— Әйе, Черкизов базарыннан Сәлим Мифтахов дигән кеше арзангарак китерә. Мин моның берәр хикмәте бардыр инде дигән идем, бик теләсәң, әйдә күбрәк түлә дип көлде. Мин шуны шәйләдем: Черкизов базарына аны Грузиядән күпләп китерүчеләр бар, күрәсең.

— Алай икән. Димәк, кемнәрдер идән астыннан гына эш йөртү җаен тапкан. Югыйсә бәяне төшермәс иде. Сезгә аны Сәлим Мифтахов китерә, дидегез. Соңгы партияне кайчанрак китерде?

— Хәтерләмим инде.

— Накладнойларны, сертификат кәгазьләрен алып килегез, дигән идем.

— Менә, рәхим итегез.

Ризван Әшрәпов, кәгазьләрне кат-кат карап чыккач:

— Болардан эчемлекләрнең күптән китерелгәне күренә, — диде. — Ә агулану очраклары яңа гына булды. Агулы шешәләр сезгә кайчан килеп эләкте икән соң? Хатыныгыз мин инде гаражга ел ярымнар тирәсе барганым юк, ди.

— Юк, ул авыр әрҗәләр күтәреп йөрми. Мин югында аңа барырга туры килсә дә, безнең гаражлар сак астында бит. Тикшереп була.

— Тикшердек, Равил Газыймович, тикшердек. Охрана ирләре соңгы вакытта бернинди чит машина килгәне булмады, диделәр. Шулай итеп, ул наркотиклы шешәләр сезгә элек китерелгәннәре арасында да булган күрәсең, дигән нәтиҗә ясыйсы кала. Ә аларның Грузиядән Мәскәүгә килү юлын тикшерү эше бара инде. Бер ачыкланыр әле. Бүгенгә хушыгыз.

Берничә көннән Равил тагын повестка алды. Тикшерүче бүлмәсенә беренче керүе булмаса да, аның тез буыннары калтырый, күз кабагы тартыша иде.

— Равил Газыймович, тикшерү нәтиҗәсендә хатыныгызның да, үзегезнең дә наркотикка катнашыгыз юклыгы беленде. Кызганыч, сез эчкән эчемлеккә аның ничек эләгүен ачыклап булмады. Димәк, бу мәсьәләдә җаваплылык сезнең өстән төшә. Үлгән кыз квартирасында да шикле нәрсә табылмады.

— Анда да тикшердегезмени?

Следователь сорауны җавапсыз калдырды.

— Сүз унаеннан әйтим әле, — диде Равил. — Әти-әнием күрше шәһәрдә яши, туганнарым да бар, дигән иде. Аларга хәбәр итәсе иде. Күмү чыгымнарын мин үз өстемә алам, шуны да аларга җиткерәсе иде.

— Хәбәр бирелде инде. Ә чыгымнарга килгәндә, бу чыннан да кешелекле адым булыр. Ә менә гаражыгызда кешенең төтенгә тончыгып үлүенә килсәк, монда тикшерәсе дә тикшерәсе әле...

— Аңлыйм, Ризван Харисович. Мәет — факт. Тик моның ничек килеп чыкканын һич кенә дә аңлата алмыйм. Мин машинаны кабызганымны хәтерләмим.

— Нәрсә генә хәтерлисез соң сез?

— Элеонора белән шактый күп эчтек...

— Анысы билгеле. Гаражыгыз төнгә таба салкынайды, шулаймы?

— Гараж гараж инде.

— Җә, җә?

— Ничек дип әйтим. Сез ир кеше, чамалыйсыз ич инде.

— Сөештегез дип белик.

— Әйе... Аннары мин йоклап киткәнмен. Озак йокланылган. Шундый кайнар кыз белән кайнар кичтән соң... ир кеше ләбаса. Уянып китсәм, ул үлеп ята. Башым ярылырлык булып авырта. Бөтен гәүдәм дер-дер калтырый. Үзем ничек исән калганмын, белмим. Үлсәм, яхшырак булыр иде.

Тикшерүче Равилне кешечә кызганды бугай, графиннан су салып бирде.

— Ярар, тынычланыгыз, Равил Газыймович. Хәвеф агач башыннан түгел, кеше башыннан йөри. Әйтегез әле, машина ачкычын кая куйган идегез?

— Сумкада иде. Һәрвакыттагыча. Без гаражга җәяү генә бардык, ерак ара түгел бит. Кибеткә кереп кабымлыклар алдык әле.

— Тикшерү барышында сез ул ачкычны озак эзләдегез, тик таба алмадыгыз, шулай бит.

— Әйе, эзләмәгән жир калмады.

— Табылган ул.

Равил урыныннан сикереп торды:

— Каян? Кем тапкан? Төшереп калдырганмынмыни?

Тикшерүче Равилгә утырырга кушты да әйтергәме-юкмы дип икеләнеп торды, күрәсең, бераздан сүзе Равилгә нинди тәэсир ясар икән дип йөзенә текәлде. Аннары:

— Морг хезмәткәрләре тапкан, — диде. — Кызның учында. Ул аны шул тикле кысып тоткан, учына катып калган бармаклары арасыннан көчкә-көчкә аерып алганнар. Ә сумкагызда аның бармак эзләре ярылып ята.

Бу хәбәрдән Равилнең башы әйләнеп китте, күз аллары караңгыланды. Ул куллары белән урындыкка ябышты, башында уйлар өере йөгереп узды. «Элеонорага ачкыч нәрсәгә кирәк булган, ул ник аны уятмаган, әллә уята алмадымы икән? Әллә туңа башлап, машинаны үзе кабыздымы икән? Бу хакта тикшерүче ни уйлый икән?»

— Сез, Равил Газыймович, аның торып йөргәнен хәтерләмисезме?

— Юк. Әйтәм ич тирән йокыга талганмын.

— Ачкыч аның учына үзе кереп утырмагандыр ич.

— Алайса, мин йоклагач, Элеонора машинаны кабызып маташкан микәнни?

— Әллә сүндерепме? Сез кайчанрак йокыга киттегез икән? Вакытны хәтерли алмыйсызмы? Чама белән булса да диюем. Бу бик мөһим нәрсә.

— Гаражда кунып калып булмый ич. Шуңа күрә мин сәгатькә күз салгаладым. Бик каты йокы килә башлагач, сәгать унберенче яртыларда кайтырга кирәк дигән уйга килгәнемне хәтерлим. Шуннан соң йоклап киткәнмен, күрәсең.

— Алай икән. Экспертиза ачыклады, Элеонорагыз сәгать өчләрдә әле исән булган. Сез йокыга китәр алдыннан ул сезнең яныгызда идеме, әллә юкмы?

— Иптәш следователь, мондый детальләр нәрсәгә инде, ә? Болай да җаным кыйнала...

— Сез сорауга җавап бирегез.

— Янымда иде. Кочаклап яткан иде.

— Ә сез уянганда?

— Ул машина янында ята иде. Өстенә кофта кигән иде. Сәдәпләре каптырылмаган иде. Карагыз әле, бу ничек була соң әле? Элеонора торып йөрде микәнни?

Тикшерүченең аксыл йөзе бераз алланып китте. Ул, саран гына елмаеп:

— Менә күрдегезме? Үзегез үк бик мөһим нәтиҗәгә килдегез, — диде. — Ә үзегез «детальләр», дисез. Үлгәнен белгәч, аңа кагылмадыгызмы? Урыныннан күчермәдегезме?

— И-и, кая инде ул, Ризван Харисович. Ул чактагы хәлемне белсә, бер Алла гына беләдер. Йөрәгем ярыла дип торам. Үзем дә чүт кенә үлемнән калдым лабаса.

— Әйтегез әле, хатыныгызның правасы бармы? Ул машина йөртә беләме?

— Барын бар. Тик ул рульгә утырмый дисәң дә була. Курка ул.

— Равил Газыймович, машинагызның запас ачкычы бармы? Аның кайда икәнен әйтә аласызмы?

— Алам, ник алмаска. Өйдә ул, залдагы гарнитурда ватылмый калган бәллүр ваза эчендә булырга тиеш.

— Сөяркәгез көндәлек алып барган икән. Анда Изергил дигән исем очрый. Кем ул?

— Көндәлек алып барганын белми идем. Конспиратор, имеш. Ә Изергил дип без сәгатьләп очрашып йөргән фатир хуҗасын атый идек. Горькийның бер әсәрендәге карчык исеме.

— Алайса сез Данко буласыз инде.

— Элеонора мине шулай дип атый иде.

— Көндәлегеннән күренә, ул сезне бик яраткан икән. Ә сез?

— Андый назлы хатынны яратмый мөмкин түгел. Мин көне-төне аны уйлап йөри башлаган идем инде.

Тикшерүче торып басты:

— Аңлашылды. Ярар, бүгенгә җитеп торыр. Кирәк булуга чакыртып алырмын. Хушыгыз.

— Ризван Харисович, чакыра калсагыз, повестканы сез мин вакытлыча тора торган адреска җибәрегез инде. Мин үз квартирамнан киттем бит.

— Алай икән. Менә протоколга имза салганда, яңа адресыгызны үз кулыгыз белән язып калдырыгыз.

***

Рифат ишекне шактый озак шакыды, әллә ялгыштыммы икән дип шиккә дә калды. Кабат-кабат шакыгач кына хәзер-хәзер дигән тавыш ишетелде. Тавыш абыйсыныкы иде. Энесен күргәч, Равил кызарып китте. Кочаклашып күрештеләр. Караңгы, кысан гына бүлмәгә узгач, Рифат мондагы җиһазның шактый тузганлыгына, дивардагы төсләре әллә кайчан тоныкланган картинага игътибар итте. Урындыклар, сервант урыны-урыны белән кыршылып, тәрәзә төпләре тапланып беткән иде.

— Каян эзләп таптың, энекәш? — диде Равил. — Кеше күзенә күренмәс өчен менә шушында бикләнеп диярлек ятам әле.

— Әй, абый. Телевизордан безнеке шикелле фамилияле берәүнең бәлагә юлыкканын ишеткәч, Рәшидә, абый түгелме икән, бар, тап, алып кил әле дип чыгарып җибәрде. Кибетегезгә кергән идем, сатучы кыз ул бит гаражда булган хәлдән соң Вишневский урамындагы «Ял» кунакханәсе урнашкан йорттагы квартирага чыккан икән, диде. Менә килеп таптым. Соңгы минутка хәтле ул бәхетсез кеше син түгелдер дип уйлаган идем. Син икәнсең. Әйдә әле, безгә китик. Бу бәладән котылу юллары юк түгелдер. Дөнья бетмәгән, уртага салып киңәшик.

— Юк, энем. Бу турыда сөйләшәсем дә килми, гафу ит. Беркая да бармыйм. Әлегә адым да атлыйсым килми. Оят. Тәнзилә белән танышкач, түбәмә кояш чыкты, айның кирәге калмады дип ихлас күңелдән яратып йөргәннәрдән баш тарттым да менә хәзер үкенеп бетә алмыйм. Беләсең ич, классташым Нәҗияне, аннары төркемдәшем Сәрияне әйтүем. Хәзер эш узган инде...

— Сирәк кенә очрашсак та, гаиләгездәге татулыкның чамалыгын белә идем. Шул инде ул, песи белән уйнасаң, тырналмый калмыйсың. Син бик нык тырналгансың шул. Түзәргә туры килә. Өмет бер дә юкмыни соң? Шуны гына әйт әле. Ничек ярдәм итим?

— Булыр кебек. Сүзең өчен рәхмәт. Тикшерүче кеше объектив күренә.

— Үзең ничек уйлыйсың соң?

— Детальләрен сөйләп тормыйм инде. Гаебем бар, тик әхлакый, мораль яктан гына. Аның өчен утыртып куймаслар дип өметләнәм. Өметсез шайтан, ди.

***

Ике көн дә үтмәде, Ризван Әшрәпов Равилне тагын чакыртып алды. Кабинетында кырык биш-илле яшьләрдәге ир белән хатын утыра иде. Икесенең дә йөзе сулган, хатынның күзләре тирәнгә батып кергән иде.

— Равил Газыймович, мин сезне менә Элеонораның әти-әнисе Булат

Абдуллович, Сәгыйдә Ибраһимовна белән очрашырга чакырдым, — диде Әшрәпов. — Ә бу Равил Әкбәров була.

Моны ишеткәч, коточкыч кайгыдан гаҗиз калган ата-ана Равилгә текәлде.

— Ә-ә, шушымыни инде ул, — диде ир.

Хатыны торып басты, аның иреннәре тартышты, йөзе газаплы чалшайды, тамак төбеннән гырылдаган тавыш килде, тик бер генә сүз дә чыкмады. Булат Абдуллович хатынын акрын гына урынына утыртты, кулларыннан сыйпады:

— Сәгыйдә, зинһар, тынычлан.

Бүлмәдә тынлык урнашты.

Бәхетсез ата-ананы күргәч, Равил коелып төште, йөрәге өшеде. Әйтерсең лә аны күкрәгенә хәтле җиргә күмеп куйдылар. Башын чүкеч белән төяләрмени, чигә тамырлары бүртеп чыкты, йөзе комач төсенә керде. Ризван Әшрәпов үзе дә шактый каушаган иде, сулы стаканны читкәрәк этте, карандаш, ручка тулы приборын, алдындагы папкаларны кабат-кабат рәтләде. Киеренке тынлык озакка сузылды. Бераздан Равил торып баскан иде, чүт егылып китмәде.

— Булат Абдуллович, Сәгыйдә апа... сезнең каршыгызда, — дип сүз башлаган иде, гыжылдап кына чыккан үз тавышын үзе танымады, туктап торды. Аннары кипшегән иреннәрен ялап алды да сүзен дәвам итте. — Сезнең каршыгызда ... менә шулай басып тормас өчен, ун гомерем булса, унысын да бирер идем. Сезгә дә бит авыр, аңлый күрегез, миңа да... Аяк астыннан чыккан фаҗига булды ул. Зинһар өчен, гафу итә күрегез.

— Аяк астыннандыр шул. Әйе. Йөгәнсез, әхлаксыз булсаң, кайчан да бер килеп чыга шул ул. Сез бит ир затыннан, гаиләле кеше дә икәнсез. Җаваплылык кайда соң сезнең? — диде ата.

— Без бер-беребезгә ияләшеп өлгергән идек инде. Аны югалту миңа да бик авыр. Башыма сыймый, ничек шулай килеп чыкты.

— Авырдыр шул, авырдыр. Үз-үзеңне тыя белмәсәң. Мин кызыбызны да гаепсез дия алмыйм. Ике чабата — бер кием... Бөтен бәлаләрнең башы тотнаксызлыкта. Ул да тотнаксыз, җилбәзәк булды. Унынчы класстан ук иркен яши башлады. Өченче курстан институтны ташлады. Кияүгә чыкты, аерылды... Икенчесен тапты... аерылды. Вольному воля, имеш. Һәм менә нәтиҗәсе.

— Булат Абдуллович, икебездә дә гаеп бар. Сез хаклы, миндә күбрәктер дә әле. Хәзер нишләргә генә кала соң... Минем бер тәкъдимем бар. Элеонораны Ульяновскига алып китү, күмү, истәлек ташы, чардуган кую чыгымнарын үзем түлим әле, ә?

Ризван Харисович та сүзгә кушылды:

— Риза булыгыз, Булат Абдуллович. Равил Газыймович моны күптән әйткән иде инде.

Булат Абдуллович шактый дәшми торгач, теш арасыннан гына кысып чыгарды:

— Ярар соң... Сәгыйдә, син нәрсә дисең?

Хатын ләм-мим сүз әйтми һаман бер ноктага карап утыра бирде.

— Булат Абуллович, беренче очрашуда мин сезгә әйткән идем, — диде Әшрәпов. — Сез Равил Газыймовичны җавапка тартырга сорап прокуратурага гариза яза аласыз. Вазифам буенча мин сезгә шуны әйтергә тиеш. Ләкин тикшеренүләр нәтиҗәсендә, әхлакый якны исәпкә алмаганда, монда җинаять эше күренми. Мин юристлар белән дә киңәштем. Кызыгыз машинаны үзе кабызган булган бит. Бу мәсьәләне үзегез хәл итегез.

— И, Ризван Харисович. Фаҗига, фаҗига инде ул. Әмма хәзер гаеп эзләүдән, фаҗига өстенә фаҗига ясаудан ни файда. Кызыбызны кайтарып булмый лабаса.

Менә Сәгыйдә апагызга, аның хәленә карагыз. Телдән калды бит. Равилнең дә ата-анасы бардыр.

— Ихтыярыгыз, Булат Абдуллович. Алайса, җинаять эше ачудан баш тартабыз дигән гариза калдыра аласыз.

— Ярар, калдырырбыз... Ә бу хәлләр Равилгә зур сабак булсын.

...Икенче көнне Равил, күз яшьләренә буыла-буыла, Элеонораны соңгы юлга озатып калды.

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

Күктәге аксыл болытлар, бер карасаң, әле биниһая зур коточкыч җанвар, әле елан, әле сарык бәрәне, әле аккош рәвешенә кереп, буталыпмы буталалар. Кояш нуры төшкән урыннары кан саркып торган җәрәхәтләрне хәтерләтә. Икенче карауда тау-тау булып өеләләр дә җир өстенә соры күләгәләрен сибәләр.

Равил бакчада утыра-утыра да якындагы супермаркетка юнәлә. Шунысы әйбәт: кибетнең икенче катында яхшы кафе бар. Анда төрле-төрле ризык хәзерләнә. Равил өчен иң кулае — өчпочмак, пәрәмәч, сумса. Күрше өстәлләр тирәсендәге тамак туйдыручыларның әңгәмәсенә колак салып ашап ала. Уртадагы өстәлләр тирәсенә утыруның сәбәбе шунда: күршеңдә кеше күп була. Ә Равилгә бүген шул кирәк. Күңел ачлыгыннан аптыраганга, шыксыз, эчпошыргыч ялгызлык җанын ашаганга күрә, ул кеше арасында булырга омтыла. Элеккеге танышлары тора-бара күренмәс булды. Үзе дә алар белән аралашуны өнәми, чөнки ул гаиләләрдә бәхет, тынычлык хөкем сөрә. Балалары гөр килә, эти-әниләре, әби-бабалары шулар белән «мәтәүләнә». Ә Равил көнне үткәрә алмый, төннәр аның өчен бигрәк тә газаплы, йокысыз ауный, күзе таң алдыннан гына йомыла. Төш күрсә, алары да ниндидер соры, күңелсез йә газаплы була. Аннан соң башы чатнап уяна.

Равил, тамагына капкалап алгач, павильоннар каршындагы урындыкка барып утыра, газета укый, ыгы-зыгы килеп йөрүчеләрне күзәтә. Башында һаман бер уй бөтерелә. Кешеләрне нинди пружина йөртә икән? Нишләп бу дөнья шулай бимазалы икән? Кыска гына гомерендә кеше нишләп әллә нинди авырлыкларга дучар икән?

Заманында ул М.Горькийның бер әсәрендә кешеләр тормышын балыкларныкы белән чагыштыруны укып гаҗәпләнгән иде. Бу җан ияләренең бар мәшәкате — тамак туйдыру, вакыты җиткәч, яңа буын булдыру. Шунын белән вәссәлам. Тыныч кына яши бир. Равил башта шулай уйлаган иде. Тора-бара бөек язучының төп фикеренә төшенеп бетмәгәнен аңлады. Кем-кем, М.Горький кешеләр арасындагы тигезсезлекне, гаделсезлекне дошман иткән акыл иясе булган лабаса. Ерткыч балыклар да бар бит әле. Аларның исә бар максаты — тота алганны, көче җиткәнне кабып йоту. Үзеннән зуррак исә аның үзен дә тотып ашый. Кайда инде монда гаделлек? Җәмгыять тормышы балыкларныкыннан нәрсәсе белән аерыла соң? Берәүләр кешенекен, дәүләтнекен урлый, башкалар өлешен үзләштерә, хәрәмли, җинаять кыла, хәтта кеше үтерә. Икенчеләр — корбаннар — билен бишкә бөгә, тир түгеп хуҗасын баета. Моның ахыры бармы соң? Булырга тиеш бит ул. Шулай уйланып утыра-утыра кайвакыт Равил йокыга тала.

Беркөнне ул төш күрде. Имеш, аны милиция егетләре алып китәргә килгән. Ул карыша, барысы да ачыкланып бетте бит инде, минем гаебем юк, дип тартыша. Ә аны әйдә-әйдә дип һаман төрткәлиләр... Бакса, чыннан да төрткәлиләр икән. Тиргә батып уянып китсә, каршында елмаеп бер ир басып тора иде.

— Равил, син бит бу? Нишләп йоклап утырасың? Кибеттә мал сайлый-сайлый әлсерәп беттеңме әллә? — Ир берьюлы әллә ничә сорау бирде. Равил

башта аптыраштa калды. Ирнең йөзенә, сөзәк маңгаен каплаган кара чәчләренә, бүселеп чыккан симез яңакларына текәлеп карап торгач кына хәтере кайтты.

— Син икәнсең әле, Энгельс... Милиция дип торам. Әйе, мин бу, утыра-утыра оеп киткәнмен.

— Жә, тормышлар ничек? Күптән күрешкән юк бит. Ябыгып, сулыгып калгансың димме. Алай да иске гадәт буенча Энгельс дип төрттерүне дә онытмагансың үзең, ә?

Әйе, институтта укыганда, Равилләр бу егетне, сакалы булмаса да йөзенең озынчалыгына ишарәләптер инде, Энгельс дип үртиләр иде. Беренче курста ук Роберт профсоюз комитеты активы булып йөрде. Өченче курстан аны комсомол өлкә комитетына инструктор итеп алдылар, тора-бара финанс-хуҗалык бүлеге мөдире итеп күтәрделәр. Елдан-ел өскә үрмәләп, ул хәтта Министрлар Кабинетының Эшләр идарәсе мөдире булуга иреште. Әмма кыек эшләре беленгәч, тиз генә тайды, югалып калмады, йонлы куллы әшнәләре ярдәме белән Мәскәү эшмәкәрләре ачкан супермаркетның управляющие булып төшемле эшкә урнашты. Равилнең Энгельс дип атавы шуларны искә төшерүе иде.

— Үпкәләмә тагы, — диде Равил. — Дусларча гына әйтүем. Мин монда еш булам. Дөнья куып китерә. Ярар, ә син нишләп йөрисең? Заманында Министрлар Кабинетыннан киткәнеңне ишеткән идем. Начальство янында эшләү җинел түгел диләр шул.

— Әйе, парень. Җитәкчеләрнең холкына ярамасаң, эшең хөртигә әйләнә. Әйе. Мин хәзер монда управляющий. Дөнья һаман үзгәреп тора. Халык тормыш авыр дип зарлана, ә үзе кибетләрдә тыз-быз йөгереп кенә йөри. Әнә кара әле теге парны. Ничек киенгәннәр! Димәк, рәтләре бар. Ә бездә мал тулып ята, хе-хе-хе.

— Дөнья үзгәрсә дә, син югалып калмагансың, молодец. Ә менә минем көймәм комга терәлде. Эшсез дә калдым, торыр урыным да юк, — диде Равил.

Тормышы чәлпәрәмә килгәннән бирле беркем белән дә иркенләп сөйләшмәгәнгә, тынлаучы табылгач, Равил кинәт кенә ачылып китте дә башыннан узган хәлләрне сөйләп бирде.

Робертның маңгаена җыерчыклар җыелды:

— Алайса, син кайда, нәрсә исәбенә яшисең соң?

— Миңа бурычлылар шактый иде. Сәүдә эшендә шулай инде ул. Шулардан әҗәтләрен алам. Вакытлыча берәр арзанрак фатир табасы булыр дип торам.

— Хатының белән араң бөтенләй өзелдемени соң?

— Окончательно һәм бесповоротно. Тиз пешкән җимеш тиз чери диләрме әле. Әллә ничек килеп чыкты безнең тормыш. Квартирабыз дүрт бүлмәле, шәп урында иде. Әнисе белән икәүләп син бит ир кеше, калдыр инде квартираны дип тәкрарлагач, чыгып киттем. Сатулашып, судлашып йөрүне җенем сөйми. Дөрес, үз өлешемне акчалата алдым алуын. Авырлык белән булса да квартиранықын да, кибетнекен дә. Машина баштан ук хатын исеменә алынган иде. Так что мин хәзер иректе гражданин. Синең, Роберт, дус-иш күптер инде. Бәлкем, берәр эш табып бирерсең, ә?

Башын чайкый-чайкый тыңлап торганнан соң, Роберт Равилнең йончыган йөзенә, каралып калган күз төпләренә текәлде:

— Син эчмисеңме?

— Эчсәм, мин шундый житеш тормыш корып җибәрә алыр идемме? Шундый елларда.

— Дөрес инде анысы. Эчкән кешедән рәтле эш көтмә. Син бер-ике атнадан минем янга кил әле. Бергәләп обмозгуем. Давай, башыңны имә, комсомол. Держи хвост трубой. Хуш, ну давай.

Нәкъ ике атнадан Равил чиста киенеп, кырынып, кешелеккә кия торган киемнәрен киеп, тагын супермаркетка юнәлде. Роберт урыныннан торып, кул биреп күреште, урындык тәкъдим итте. Тәрәзә пәрдәләрен ачыбрак куйды. Бүлмәгә иртәнге кояш нурлары үрмәләде. Робертның эшләре әйбәт бара икән, дип нәтиҗә ясады Равил, бүлмәне күздән кичергәч. Кая карама, чит ил җиһазы. Идәндәге зур яшел келәм үзе генә дә ни тора! Диварның яртысы зурлыгындагы телевизор, өстәлдә ап-ак ноутбук, әллә ничә телефон. Шуларның берсендәге кнопкага басып, Роберт кофе кертергә әмер бирде. Дулкынланып килгәнгә күрә, монда кергәндә Равил секретарь кызга игътибар итмәгән икән. Ул кыз килеп кергәч, телсез калды — кыз сөйләп бетерә алмаслык сөйкемле иде. Макияжны белеп кенә салган ак йөзе, биленә кадәр төшеп торган калын чәч толымы, нечкә биле, төз, тулы аяклары, вак-вак атлаганда сыгылып торган сыны күзнең явын алырлык иде.

Равилнең сокланулы карашын тотып алган Роберт кыз чыгып киткәч:

— Симпатяга бит ә, каһәр! Тик недотрога, җинеп кенә булмый үзен, — дип ычкындырды. — Югарыдагы берәү рәхәтен күрә. Бу да үз бәясен яхшы беләә. Ярар, моны лирическое отступление дип саныйк. Әйдә, кофега житеш. Бездә бер эш урыны бушарга тора. — Роберт җитди тонга күчте. Дөрес, әлләни күренекле эш түгел-түгелен. Синең дә сайлана торган чагың түгел. Икенче каттагы зур кием-салым залына сак эше тәкъдим итсәм, ничек карарсың?

— Директор итеп алмаячагың баштан ук билгеле иде инде...

— Башта ярап торыр, дус кеше. Аннары күз күрер. Сиңа хәзер «кара упкыннан» чыгу хәерле. Да, әйтергә онытып торам, сиңа урын бушатачак кеше тулай торакта яшәп ята. Мин әйтермен, ул чыгып китәр. Җә, ничек?

— Сайланып торыр чагың түгел, дип үзең әйттең ич. Чикләвек жыйганда җиләккә бармыйлар, ди халык.

— Килештек, алайса.

***

Бирим дигән колына чыгарып куяр юлына, диләрме әле. Бер айдан Равил бик зур супермаркет хезмәткәре булды. Робертның шәхси танышы булса да, сакчылар җитәкчесе аны читтән шактый вакыт күзәтеп йөрде. Эше авыр түгел, вазифасы сатып алучыларга, павильонга кереп-чыгып йөрүчеләргә күз-колак булып тору гына. Сатучылар күрмәгәндә кием-салымны кыстырып китмәсеннәр. Хәер, киемнәргә махсус сигнал төймәләре беркетелгән, түләмәгәннәр ишектән чыкканда, алар чыелдап тавыш бирә. Акчасын түләгәннәрдән кассирлар ул тауарның сигнал төймәләрен алып калалар, әйдә, китә бир, рәхәтен күр, рәхмәт.

Хезмәт хакы әлләни түгел, шулай да Равилгә ярап куйды. Шунысына аеруча шатланды: аңа тулай торактан үзенә генә кечкенә бер бүлмә бирделәр. Равил хәзер эштән кайта да рәхәтләнеп караватка ава. Көн буе аяк өстендә йөрү арыта шул. Аның каравы, маркет кафесында аны бушлай ашата башладылар. Равилгә, авылда үскән кешегә, берни түгел ич, нәрсә үтенсәләр, шуны эшли. Әрҗәләрен дә ташып куя, буш подносларны да җыеп ала. Тора-бара ул кафе хезмәткәрләренең якын кешесенә әверелде. Кайсы аңа Равил Газыймович ди, хатын-кызлар Равилчик дип тә җибәрәләр.

Бер ел чамасы шулай эшләгәч, Роберт аны үзенә чакырып алды да:

— Син ышанычны акладың, Равил, — диде. — Замечаниеем юк. Без сине үстерергә киңәштек.

Равил шатлыгын йөзенә чыгармады.

— Күрәм, кафеда син үз кеше булып киткәнсең. Бигрәк тә раздача кызлары ярата үзеңне. — Равилнең иреннәре агарып киткәнен күреп, Роберт елмаюын

яшерә алмады. Димәк, ул дөрес уйлый икән. Тәрәзәгә, аннан дивардагы картинага карап алгач:

— Әгәр без сине кафе мөдире итеп куйсак, моңа ничек карыйсың, — дип дәвам итте управляющий. — Ашханәгә халык агылып йөри. Күреп торасың, сәүдә шәп бара. Тәмле ризык пешерүнең файдасы зур. Әйдә, алын, дус кеше!

— Ә хәзерге мөдир китәмени?

— Җибәрәбез. — Роберт кеткелдәп көлеп куйды. — Керем читкә күп тая башлады. Мин аны кисәткәләдем. Төзәлгән була да, янә иске юлына төшә. Үзсүзләнә. Бу бигрәк тә Мәскәүдән хуҗалар килгәндә нык сизелә. Безнең бит Зияле буенда кунак йортыбыз бар. Аларны еш кына шунда урнаштырабыз да шунда сыйлыйбыз. Ну, мунча анда, шашлык, башкасы. Кыскасы, безгә анда ышанычлы үз кешебез кирәк. Килештекме?

Равилнең күз тирәләренә вак җыерчыклар өелде:

— Уйларга кирәк, уйларга...

— Нәрсә уйлап торырга? Яңа шартларда син үз бизнесыңны булдыра алгансың ич, моны гына булдырасың инде. Кул астындагыларны эшләтә генә бел. Дисциплина нык булсын. Урлашмасыннар, хәрәмләшмәсеннәр. Тагын бер-ике йомыш булыр. Аларны соңрак әйтермен. Кыскасы, сиңа яңа юл ачыла. Башкасы үзеңнән тора.

Тәкъдим көтмәгәндә ясалганга, Равилнең йөрәге урыныннан купкандай булды. Миеннән болай булгач, яшибез әле, дигән уй яктырып узды.

— Ярар, Роберт. Ышанычың өчен рәхмәт. Канатланып киткәндәй булдым. Кайчан керешергә?

— Иртәгә үк. Сузасы юк.

— Хуҗаларың белән килешенгәнме соң?

— Анысы минем эш. Ну, давай.

«Давай, давай». Яратмый шул сүзне Равил. Каян бөтен кеше теленә кереп оялады шул урыс сүзе. Менә Роберт та «хәерле сәгатьтә» диясе урынга «давай», ди. Хәзер «хуш» диясе урынга да «давай». «Вау» дигән инглиз сүзе дә урысы, татары теленә кырмавыктай ябышты. Татар кешесе «вау» диясе урында ник «абау» дими? Тьфу, валлаһи.

— Хәерле сәгатьтә дип, үзебезчә әйтик, Роберт.

— Ну, давай, алайса. Хәерле сәгатьтә.

***

Эшләр җайланды. Равил хәзер башын салып утырмый. Ашханә файда китерә, ит-сөт, он, яшелчә, җиләк-җимеш белән вакытында тәэмин итеп торсаң, эш тотрыклы бара. Пешекчеләр үз эшен белә. Равил әле күптән түгел генә училище бетергән ике яшь егетне дә эшкә алды. Егетләр уңган булып чыкты, кушканны тыңлыйлар, урлашмыйлар. Бу яктан Равил аларны баштан ук кисәтеп куйды, хезмәт хакыгызны күтәрә торырбыз, әмма кулыгыз кыекланса, үпкәләштән булмасын, диде. Кыскасы, ашханәдә тәртип, халык агылып йөри, ризыкны яратып ашый. Равил кайсы көнне тукланучылардан үзенең кемлеген сиздерми генә сораштырып ала: ризыктан канәгатьләрме, менюда тагын нәрсә күрергә телиләр...

Керем дә әйбәт. Равил Робертны аерым бүлмәдә кабул итә, алар дөнья хәлләрен сөйләшә-сөйләшә тәмләп ашыйлар, аз-маз утлы су да капкалыйлар. Дөрес, Равил ул мәсьәләдә бик сак, югыйсә... Аның күңелендә теге чактагы хәлләр таш булып ята. Ятарлык та шул.

Шулай хозурланып утырган бер көнне Равил дустына эч серен чиште.

— Роберт, минем сиңа тагын бер зур үтенечем бар бит әле, — диде. — Гомер буе тулай торакта яшәп булмый лабаса. Әллә берәр банктан кредит алып,

квартира төзеп керим микән? Арзанракка диюем. Сатып алсам, тагын да яхшырак булыр иде. Син ничек уйлыйсын?

— Синенчә үк уйлыйм. Бик мәслихәт.

— Кирәк тә бит. Банклар бик зур процент каералар икән шул.

— Анладым... Мин үзебезнен күптәнге таныш, әшнә банкир белән сөйләшермен. Бер булышырга дигәч, булышырга кирәк инде сиңа.

Роберт сүзендә торды. Равил күтәрерлек процент белән аңа кредит алып бирде. Равил хәзер алтмыш квадрат метрлы бер бүлмәле бик иркен фатирлы булды, аны өр-яңа җиһаз белән тутырып куйды. Җиһаз дигәндә хәзер аптырап йөрисе юк, ул кибетләрдә тулып ята, акчаң гына булсын. Хөррият! Кадак та таба алмыйча интегеп йөргән чаклар үтте шәт. Роберт белән дә мөнәсәбәтләр әйбәт, күз тия күрмәсен.

...Кайсы көннәрне Роберт аерым бүлмәгә бик кәттә киенгән, буянган-ясанган бер-ике яшь кыз белән килеп керә, аларны шәп итеп сыйлый. Андый чакта баштарак Роберт Равилгә чыгып торырга куша иде, тора-бара үзләре белән дә калдыра башлады. Кызлар еш алышынып торганга, Равил аларның исемнәрен дә белми кала. Хәер, эш исемдәмени. Галялар, Валялар, Розалар, Тосялар барысы да чаялар, сүзгә кесәгә кереп тормыйлар, ашап туйгач, анекдотлар сибәләр, аннары Роберт биргән машинага төялеп каядыр китеп тә баралар. Алардан соң бүлмәгә баш әйләндергеч хушбуй исләре генә тулып кала.

Беркөнне алардан соң бүлмәне җилләтим дип тәрәзәләрне ачып йөргәндә, теге кызларның берсе кабат әйләнеп керде. Равил башкалардан тыйнаклыгы, уйчанлыгы белән аерылып торган бу чибәр кызга башта ук игътибар иткән иде. Шомырттай чем-кара чәчләрен матур итеп, авыллагыча тасмалап үреп, иңнәренә салган бу кыз авызларын кече телләре күренгәнче ачып шаркылдаган иптәшләреннән пөхтәлеге, нindидер сәер монсулыгы белән аерылып тора иде. Керде дә:

— Равил абый, минем ридикюлем монда калмаганмы? — дип, өстәл асларын, кәнәфи артларын карады, урындыкларны эткәләп, Равил янына ук килеп басты. Гадәттә һәр кеше лифтта булсынмы, транспорттамы, янәшәсендәге кеше белән үзе дә сизмәстән билгеле бер ара тота, борынга-борын килеп терәлми. Ә бу кыз тыгыз күкрәк алмаларын китереп терәде дә, Равилнең күзләренә карап:

— Сез күрмәдегезме соң ул ридикюльне? — дип сорады.

Бу исерткеч якынлыктан Равилнең тез буыннары калтыранып китте. Аның бит күптәннән инде хатын-кыз назын, хатын-кызның кайнар сулышын да тойганы юк иде. Кулы үзеннән-үзе чибәр кызның нечкә биленә үрелде, ләкин ул ихтыяр көчен җыеп, тыелып кала алды, кагылмады. Ә бәлкем теге бәхетсезлек күмере баш миенең берәр почмагында әле дә пыскып ятканга шулай булгандыр.

— Юк шул, сеңлем, күземә чалынмады, — диде.

Кызның бал төсендәге күзеннән шаян очкын чәчрәгәндәй булды. Гаҗәпләнде дә бугай.

— Юк тек, юк. Ярар, алайса, — дип куйды. — Минем исемем бар, Равил абый. Тәскирә мин... Кызлар Тося дип йөртәләр.

— Син татар кызымыни әле? Белмәссең дә. Хәзер сезне аеру да кыен. Русча әйбәт сөйләшәсез, матур киенәсез.

— Ярар, мин киттем, алайса...

Тәскирә-Тося Равилнең тир бөртекләре бәреп чыккан киң маңгаена карап алгач, ничектер сәер елмаеп ишеккә юнәлде.

Һич көтмәгәндә килеп чыккан хәлдән, кызның кинәт кенә кереп, шулай сәер елмаеп китеп баруыннан аптыраган Равил бүлмә тәрәзәсен бер япты, бер ачты. Аннары кәнәфигә утыргач, хәлсезләнгән аякларын сузып, уйга калды:

нәрсә булды соң әле бу? Тәскирә исемле бу кыз үзе чая кебек тә күренә. Бер үк вакытта күз карашында әнә нинди тирән монсулык та сизелә. Елмаюы тагы... Әллә бу Равилне сынап карау булдымы?

***

Тикшерү эшләре тәмамлангач, Равил авылга әтисе янына кайтты. Карт килеп ирешкән хәбәрләрдән ачы кайгыга батып йөри иде. Шуна күрә улы күзенә күренүгә, каршына утыртты да:

— Ну, давай, сөйлә! Ил авызына кереп,ниләр кырыштырып җөрисең анда? — дип җимерелгән йөнтәс кашлары астыннан Равилгә текәлде.

Әтисенең кырыс тавышыннан Равилнең иннәре җыерылып килде. Картның таләпчән сорауларына ул җавап та хәзерләгән кебек иде, ә шулай да югалып калды. Урынлы-урынсыз:

— Менә бераз ял итеп алгач эшкә керәм, — дип куйды.

— Син, давай, боргаланма. Аяк-кулы сызламаган кешегә эш табылыр. Муены булганга камыт табыла, ди халык. Мин синнән аны сорамыйм. Тагын кайларда ишек бавы ишеп җөрисең? Кемнәр белән чәбәләнәсең хәзер? Әллә урамда ауныйсынмы? Телевизордан сукбайларны күрсәтеп кенә торалар анда.

— Әй, әти, син бигрәк инде... Әлегә кунакханәдә торып торам. Уңайлы фатир тапкач, шунда чыгармын. Баш исән булсын... Шөкер, котылып калдым... Әрәм булмам...

— «Торып торам»... «Әрәм булмам»... Баш исән булсын, шул! Ба-аш! Әгәренки ул җилкәндә булса-а... Их, улым, улым! Тәүфыйксызлыктан бәхет кача шул ул. Аннан инде фаҗигасе дә ерак йөрми. Сезнең хәлләрне телевизордан да сөйләгәннәр ди. Ун елга картайттың син мине. Әле ярый анагыз үлеп котылды, югыйсә акылдан язар иде.

Әтисенең сыкранулы сүзләреннән Равил тетрәнеп китте. Тикшерүчеләр алдында басып торуы бер хәл, кайгыдан җилкәләре салынып төшкән атаң каршына килеп басудан да авыррак тагын нәрсә бар икән?!

— Әти, зинһар, гафу ит... Зинһар, онытыйк инде.

— Онытырсың ди... Ул бәхетсез кызның да ата-анасы бардыр. Алар ни хәлдәдер... Балаң шулай фаҗигале үлеп китсен әле.

— Тикшерүче яхшы кеше булып чыкты. Төрле яктан килеп карагач, ул кызның үлеме үзенең саксызлыгыннан дип таптылар. Машинаны ул үзе кабызган дигән нәтиҗәгә килделәр. Төп гаеп миндә түгел, диделәр.

— Шуннан сиңа рәхмәт әйттеләр инде...

— Гомерлек сабак булды инде бу миңа, әти. Илдә тормыш әнә ничек үзгәрде. Аның читенә кагылганымны сизми дә калдым.

— «Сизми дә калдым». Шул-шул. Сүз уңаеннан шуны да сорыйм әле. Ул давыллы җылларда халык Казан урамнарын тутырып азатлык таләп итеп җөргәндә, син кайда булдың?

— Тамак кайгыртып йөрдем... Миннән көрәшче чыкмады инде.

— Күренеп тора. Әх! Гаиләсендә тәртип булдыра алмаган кеше башына ил кайгысы төшәме соң?

— Эчеп йөрмәдем ләбаса... Хатыннан уңмадым, анысы хак.

— «Сизми дә калдым»... «Хатыннан уңмадым». Ирләр сүземе инде бу. Уңмаганның угы да кыек оча, ди. Барысына да үзең гаепле. Чөнки гаилә тормышына да җинел карагансың. Җаның борчылмыймы? Буйдак тормышың озакка барырмы? Берәр уең бармы?

Бу сорауларны да Равил көткән иде. Ә шулай да туп-туры, күзенә карап бирелгән сораудан йөрәге тагын кысылып куйды.

— Әй, эти, уйсыз кеше бар микән ул?

— Сон?

— Уйлыйм да очына чыга алмыйм. Уйлар чәбәләнә. Әллә ничек кенә кителде китте минем бәхет.

— Ә мин нәрсә дим соң? Шуны әйтеп торам лабаса. Кеше алдында мәсхәрәгә калдың. Шушы яшеңдә... бер ялгызың. Ни хатының, ни балаң. Белем алдың, кирәген тапмадың. Эшеңнең рәте булмады. Сәүдәгәр, имеш. Сезнең сәүдә сәүдәмени инде ул.

— Алайса нәрсә соң ул?

— Безнең татар халкы гомер-гомергә сәүдәгә маһир булган. Әллә кайларга барып җиткән. Дөнья гизгән. Төрле-төрле халыкларга аралашырга юл салган. Күкрәк көчен түккән, юмарт, ярдәмчел булган, рәхмәт ишеткән. Ә сез?

— Мин дә нәкъ шулай көч түктем. Әнә нинди җитеш тормыш корып җибәргән идем.

— Әй, мал тапканчы акыл тапкан булсаң... Ник җимерелде соң ул? Гаиләң кайда? Җылы куышың кайда?

— Кайда дип... Тормыш син дигәнчә генә тәгәрәми икән.Ниләр буласын алдан кем генә белә икән? Хатынымның җиңел акыллылыгын, акча колы буласын?

— Җитәкләшеп җөргәндә нәрсә карадың соң? Башлы-күзле булганчы?

— Артык яраттым мин аны. Сукыр булганмын. Матурлыкка кызыгып, курчак уены уйнаганмын мин.

— Гаилә тормышы ул яратам, яратам дип күкләр гизү, кочаклашып түшәктә яту гына түгел. Ул да кешедән хезмәт сорый. Җан хезмәте. Җаның булса.

— Син дә «хезмәт», «җан» дисең... Китаптагыча.

— Шулай булмыйча. Гаиләдә бер-береңне ихтирам итү, җул куя белү, хатыныңның, иреңнең җитешмәгән җакларына күз җома белү кирәк. Гаилә бәхете — бер-береңнең холкын аңлау. Законлы аерылышып беттегезме соң инде?

— Анысы аның бик тиз эшләнә икән. Өч мәртәбә талак дип кычкырган шикелле генә.

— Һәй, әйттең сүз. Талак дип кычкырган заманнарда никахлы гаиләләр мең кат ныграк булган. Сезнеке ише түгел. Хатыныңда да гаеп зур. Акча колы дисең. Моны син башта күрмәдеңмени? Җәлт итеп өйләнеп куйдың, җәлт итеп җалгыз калдың. Яшәү тәме, яме кайда соң сезнең... Җә, ярар инде. Узган эшкә салават.

Газыйм бабай торып басты да дивар янындагы сандык янына китте. Ачты, актарынып бер төргәк алып Равилнең тезенә салды.

— Мә, беренче мәлгә ярап торыр.

— Нәрсә бу, эти? — Равил әтисенә сораулы карашын төбәде.

— Акча, акча.

Равилнең күзеннән яшьләр чәчрәде. Әтисе аны һаман бала итеп күрә ләбаса.

— Юк, юк, эткәй. Мин мохтаҗ түгел. Рәхмәт. — Равил әтисен кочагына кысты.

...Бу көннәрдән соң инде шактый вакыт узды. Равилнең эшләре җайланып китте. Әтисе белән очрашуы искә төшкән саен, аның йөрәге әле дә тыпырчына башлый. Утызны узган булсак та, без ата-анага һаман да бала, ә ник шулай каты күңелле булабыз икән соң, дип уйлый ул. Дөнья куам дип шул тикле гамьсез, мәгънәсез булырга ярыймыни соң!

***

Йа Хода, минә язмыш Рәшидәгә дә елмайды. Рифат үзе дә бик шат иде, ихлас күңел белән эшкә керешә: тиз арада кирәк-ярак табып квартираны ремонтлап куйды. Буйыйсын буяды, кагасын какты, агартасын агартты. Ишекләрне алыштырды. Тәрәзә рамнары хәзер әнә ничек ялт итеп, көлеп тора.

Рәшидәнең тагын бер шатлыгы артты. Беркөнне алар автобуска утырып, Әтнәбайга бардылар. Рифат йорт нигезләрен каккалап-суккалап карагач:

— Шактый ук тузган икән шул, — диде.

— Әйттем ич, сатасы гына бар аны. Заманында безгә ярап торды торуын. Бәясен дә түләп бетерергә кирәк әле дигән идем. Хәзер күп калмады инде, — диде Рәшидә. Рифат кискен каршы килде:

— Юк-юк, Рәшидәкәй. Сатмыйбыз. Үзем түләп бетерәм. Әлегә сипләп торырбыз. Аннары яңасын салырбыз. Мин менә эшкә урнашыйм йә үз эшемне башлап җибәрим. Бераз запасым да бар дигән идем ич.

— Күз генә тимәсен минем бүгенге бәхетемә, — дип хатынын кочаклап, үбеп алды.

— Шәһәр кешеләренең шул булыр инде аларның... Яннарында балалары йөргәнгә дә, күршеләре килеп кергәнгә дә карап тормаслар, сөешерләр... — Шулай дия-дия елмаеп, капкадан күрше хатын Нәкыя килеп керде. — Исән-сау гына йөрисезме? Әллә Галиябану әби дә кайтканмы дип торам. Ирем Гариф абыйң Казанда күчтәнәч кертеп чыккан иде. Бик сагынам, бер кайтып килермен әле дигән. Йә, Рәшидә, бу синең яңа хәләл җефетең буламы инде? — Нәкыя хуҗаларга сүз кыстырырга да ирек бирмичә үзенекен тезде. — Әйдә, әйдә, төкле аягың белән... Таза, матур күренәсең, кем дип әйтик?

— Рифат булам мин...

— Рифат? Рифат... Мәрхүм Мәсгутне алыштырырлык булгач, шәп егеттерсең, шәт. Рәшидә алай-болай гына кеше белән тормыш кормас. Менә Эмир улыма да әти булган. Шулаймы, улым?

— Так точно! — Эмир күзенә төшкән пилоткасын рәтләбрәк куйды да чыбык белән кычыткан кыйнавын дәвам итте.

— Син бигрәк инде, Нәкыя апа. — Рәшидә күршесе сүзләреннән уңайсызланып калды. — Йә, ярар, ничек яшисез? Саулык-сәламәтлекме?

— Ходайга шөкер. Кара әле, ә! Минем шул булыр инде, тел бистәсенең. Чәйгә чакырырга дип керүем иде ләбаса. Әйдәгез, самавырым кайнап кына чыккан иде. Әйдәгез, әйдә... — Хатын хуҗаларны куыра башлады. — Чәйнек чәе түгел ул, самавыр чәе.

Рифат белән Рәшидә икәүләп рәхмәт әйтә-әйтә баш тартмакчылар иде дә, күрше хатын кырт кисте:

— Юк, кирәксез, бетте-китте. Свежий йомырка тәбәсеннән Эмир улым да баш тартмас. Шулаймы, улым!

— Так точно!

— Менә күрдегезме? Әфисәр улыгыз нәрсә диде...

— Апа, мин әфисәр түгел, прапорщик.

— Алайса, бигрәк тә. Киттек. Сөбханалла, ничек үсеп киткәнсең син, улым. Әфисәр дип торам бит.

Коймаклап, каймаклап тирләп-пешеп чәй эчеп чыкканда, Рифатның битләре балкып тора иде. Ул хатынының кулларын учына алды да, тәэсирләнеп:

— Мондый кешеләр булганда халкыбыз яши әле, Рәшидәкәй! Шулаймы? — диде.

Рәшидә җавап урынына башын иренең иңенә салды.

***

Зияле елгасының тәбәнәк яры буендагы урманлыкка житкәч Роберт:

— Менә ул ожмах почмагы шушы була инде, — диде. — Анын йөзендә зур канәгатьлек хисе ярылып ята иде. — Урман, елга, балык, бал... Жанын ни тели, шул бар монда. Әнә, таш койма эчендә, агачлар уртасындагы бинаны күрәсенме? Хәзер инде анын хужасы син булырсын. — Равилнен гажәпләнгән йөзенә күз салгач, ул хахылдап көлеп жибәрде. — Ха-ха-ха! Аптырама, дус кеше. Кирәге чыкканда гына мин сина монда алданрак килеп, кунаклар каршылау хәстәрен күрергә әйткәләрмен. Ну, саунасын, шашлыгын, ухасын анда... Әйдә, бүгеннән башлап хужалык белән таныша башла.

Биек таш койма янына килеп житкәч, Роберт БМВсын сүндереп куйды, күкрәген киереп, рәхәтләнеп хуш исле урман һавасын сулады. Аннары капкадагы кнопкага басты. Биек тимер капка ачылып китте. Анда камуфляж костюм кигән пәһлевандай эре сөякле ике егет пәйда булды. Роберт аларга:

— Машинаны гаражга кертеп куегыз, — дип әмер бирде.

Тегеләр баш иеп кенә исәнләштеләр, ләм-мим сүз әйтми әмерне үтәргә керештеләр. Равил болар әллә авызларына сумала капканнар микән дип уйлап куйды.

Робертка ияреп капкадан кергәч, ул шаккатты. Асфальт жәелгән юллар сулап себерелгән, кая карама, клумбалар, аларда дистәләрчә төрледән-төрле хуш исле чәчәкләр, гөлләр. Кошлар хоры яңгырап тора. Үрмәле үсемлекләр каплаган беседкалар янында ымсындыргыч гүзәл сыннар... Мәрмәр баскычлар буйлап юан-юан наратлардан салынган, сагыз исе аңкып торган кунак йорты эченә кергәч, Равил соклануын яшерә алмады. Менә кайда икән ул байлык.

Читтән әлләни зур күренмәгән иде, эче нинди иркен икән! Зур зал, бик зур кухня, ашханә, бильярд бүлмәсе, әллә ничә йокы бүлмәсе. Кая карама, алтын йөгертелгән бәллүр люстралар, чит илләрдән кайтартылган зиннәтле мебель. Сауна янында гына зур бассейн. Монда да кыйммәтле жиһаз тутырылган бүлмәләр. Буфетларда, суыткычларда шыплап тутырылган кыйммәтле эчемлекләр. Бөтен жирдә көзге, көзге, алар янында төрле-төрле ап-ак сөлгеләр, халатлар, аяк киемнәре. Юыну бүлмәләрендә ике-өч кеше сыярлык джакузилар, ванналар, келәмнәр.

— Син, Равил, кайда нәрсә барын хәтеренә сендер, — диде Роберт. — Кунаклар килгәндә бернинди тоткарлык та булмасын. Зияледә дә безнең мунча бар. Суга ләүкәдән генә сикерәсе. Кстати, себеркеләрне пешекли беләсенме? Дөрес пешекләмәсән, яфраклары коела да бетә, белеп тор. Безгә аларны мәтрүшкәләр, тагын әллә нинди хуш исле үләннәр, юкә чәчәкләре кыстырып чуваш хатыннары бәйләп килә. Себеркеләрне пешекләргә алардан өйрәнеп кал. Алар аны башта киндер тукымага төреп жылы суда йомшатып пешеклиләр. Кыскасы, син хәзер минем уң кулым. Иялэш!

Үз өстенә яңа вазифа йөкләнүдән гажиз калган Равил, ниһаять, сорау бирде:

— Ничек була соң инде бу? Шул тикле жаваплы эш дисен... Ә кем монда чын хужа? Ул кайда? Кунакларга хезмәтне кемнәр күрсәтә? Син шуны әйт әле?

— Вакыты житкәч, үзен күрерсен... Ялгыз булмассын... Хужа дисен, хәзер барысына да үзен хужа дип әйттем ич. Элеккесен кудым, кулы кыек иде.

— Алай икән-ән. Кунаклар килгәндә ризыкны каян аласыз?

— Хи-хи-хи... Соң барысы да үз кулында лабаса. Кафе мөдире синме, түгелме? Башынны эшләт инде, йә!

Шәһәргә Равил тирән уйга бирелеп кайтты. Бер яктан тормышында шундый киң иркенлек вәгъдә иткән яналыкка гел шатланасы гына иде дә бит, юк,

аның күнелендә шик уянды. Роберт кафенын, менә бу серле кунак йортынын элеккеге хуҗасын кудым, ди. Болай булса, ул үзе дә тулысы белән аның хөкеме астына килеп эләгә түгелме соң? Аның сынавын үти алмаса... Һай, бу тормыш дигәнең... Бер яктан рәтләнеп китсә, икенче яктан...

***

Берничә көн узды. Равил шактый тынычландым гына дигәндә, Роберт аны кабинетына чакырып алды.

— Иртәгә үзәктән зур начальниклар килә. Безнең бер министр аларны озатып йөри. Күргәч, танырсың. Мин дә барам, — диде ул. — Син бүген кичтән үк тегендә кит. Бөтен кирәк-ярак анда бар. Мунча ягып, бассейн суын яхшылап җылытып куегыз. Сиңа ярдәмгә кешеләр китте инде, пешекче, мунчачы. Кстати, каравылчыны кисәтеп куй, этен бәйдән ычкындыра күрмәсен. Кавказ овчаркасын күрдең бит, ул бүредән дә болайрак. Ну, давай.

Икенче көнне кунаклардан берничә сәгать алда Роберт үзе килеп төште. Сауналарны, буфетларны тикшереп чыкты, шулпага дигән чөгә балыкларын иснәп-иснәп карады. Импортный эчемлекләрне аш бүлмәсенә, сауналның ял бүлмәләренә үзе кертеп тезде. Өстәл өсләрен ак, кызыл шәрабләрнең, югары градуслы «юбилейный»ларның иң сыйфатлылары белән тутырды. Равилнең бу сухой, полусухойлар нәрсәгә инде диюенә, шулай кирәк, шулай тиешле дип кенә куйды.

Менә кунаклар да килеп җитте. Равил шундук таныды, аларны Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министры озата килгән иде. Кунакларны күргәч, Равил елмаюын яшерә алмады. Тегеләрне әйтерсең лә махсус сайлап җибәргәннәр, берсе, муен төере уйнаклап торганы, кипкән балык шикелле ябык, иреннәре алга чыккан очлы авызлы, башы пеләш бер адәм иде. Бу кеше нәкъ тукран икән, дип уйлап куйды Равил. Икенчесе кысык күзле, чиртсәң кан атылып чыгардай кып-кызыл йөзле, былкылдап, ишелергә торган зур корсаклы, кара куе чәчле, тукмак борынлы иде. Кунакларны иелә-бөгелә каршылагач, Роберт аларга табигать почмакларын күрсәтеп йөрде, җаен табып Равил белән таныштырды. Юан кунак баш иеп алды. Ә «тукран» очлы иреннәрен тагын да алга сузды:

— Очень приятно.

Равил сискәнеп китүен сизми дә калды, «тукранның» тавышы бас һәм көчле иде. Гөбедән чыккан диярсең...

Кунаклар җиңелчә генә балык шулпасы ашап алгач, саунага кереп чабынып чыгарга теләделәр. Роберт Равилгә дә керергә кушты, үзе дә чишенеп ташлады. Равил кыймыйча маташты, минем монда плавкием юк ич дип, баш тартып карады. Роберт:

— Әнә, шкафтан җаның нинди тели, ал, — дип «хуҗаны» ризалашырга мәҗбүр итте.

Үзенең нәрсәгә кирәклеген Равил хуш исләр аңкып торган саунага кергәч кенә белде. Роберт кунакларның әле берсен, әле икенчесен ике себерке белән кычкырта-кычкырта чаба иде. Чаба-чаба да өсләренә салкын су сибеп җибәрә. Тегеләр «ляпота» дип изрәп ятканда, тагын пешекли башлый. Үзе Равилгә борылып күз кысып ала.

Кунаклар арып, хәлсезләнеп, һәркайсы сауна янындагы бүлмәләргә кереп яткач, Роберт Равилгә:

— Дус кеше, моннан соң кунакларны чабу синең өскә төшә, — дип яңа вазифасын аңлатып бирде.

Хәер, Равил мона үзе дә төшенеп килә иде. Әйе, бу дөньяда тәбедәге сыр

гына бушлай була шул. Ул арада Роберт дивардагы бер кнопкага басты. Ишектә өч кыз пәйда булды. Роберт аларга башы белән генә ым какты, кызлар кунаклар янына кереп киттеләр.

— Чабынганнан соң массаж кирәк. — Равилнең гаҗәпләнү билгеләре чыккан йөзенә күз ташлагач, Роберт аңлатып бирүне кирәк тапты. Күрше бүлмәләрдән шешә бөкеләре атылганы, кызларның шаркылдап көлүләре ишетелә башлагач, Роберт, әйдә чыгыйк, дип ишарә ясады.

Зияленең бу почмакларында балык тоту тыела икән. Гади халык бу тирәгә килә калса, тынынны кысарлык штраф салына. Ә аксөякләргә ярый. Алар бит балыкны кызык өчен генә тота. Ике-өч чөгәдән, сазаннан, алабугадан ил байлыгы кимимени? Аның каравы, кунаклар нинди зур канәгатьлек, рәхәтлек хисе кичерә, тәм-том салып кыздырылган балыкны ашаганда, бер-берсенә ничек итеп оста каптырганны, шундый зур балыкны көчкә-көчкә тартып чыгарганны сөйли-сөйли кыйммәтле шәрабны авызга коя. Аларны тыңлаганда, Равилнең чын ачуы чыга, тик ул аны баса белә. Ачуланырсың да шул, әлеге балыкчылар кармакка суалчан, мормышка, опарыш дигән нәрсәләрне үзләре кидерергә җирәнәләр. Бу эшне әле берсе, әле икенчесе янына йөгереп йөри-йөри Равил эшли. Капкан балыкны кармактан алу да Равилгә йөкләнә, тегеләрнең кулларын пычратасы килми. Ашагач та кунак балыкчылар кулларын кат-кат сабынлап юалар, балык исен яратмыйлар, янәсе. Мондый чакта Равилнең күңелендә бу тормыш хуҗаларын берәр атна терлек фермасында эшләтәсе иде дигән үчле теләк уяна. Әй, белсеннәр, татысыннар иде ит-сөтнең чын бәясен!

***

Беркөнне Рифат телевизор караган җиреннән сикереп торды да ишегалдына хатыны янына йөгереп чыкты.

— Рәшидәкәй, алтыным, таптым, таптым! — дип аны кочып әйләндерә башлады.

— Уф, кысма, эчемне авырттырасың ич! Нәрсә таптың? Әллә алтын таптыңмы? — Рәшидә көлә-көлә ире кочагыннан ычкынды.

— Никак нет! Үзебезгә эш таптым! Сиңа да, миңа да!

— Минем эшем бар ич. Нәрсә, балалар бакчасын ташлыйммыни?

— Юк, ташламыйсың! Тик бүтән балалар карыйбыз. Икәүләп. Күрдәк бәбкәләрен.

— Нәрсә? Нинди күрдәк? Ул нинди җанвар тагы?

— Индоутка. Күркә белән үрдәк кушылмасы. Татарча күрдәк буладыр инде ул. Телевизордан шуны сөйләделәр. Бик үрчемле икән. Ите холестеринсыз да, тәмле дә икән.

— И хыялый. Аны каян аласың? Кайда, ничек үстерәсең, карыйсың?

— Башта менә шушы сарайда. Аннары фермада. Инкубатор да төзербез, тәҗрибә туплый-туплый яңа эш башларбыз. Йә, ничек?

— Ә аларны каян алабыз?

— Телевизордан адресын да әйттеләр. Мин язып алдым. Үрчетергә берәр дистә сатып алабыз да чынлап торып керешәбез. Бик файдалы эш дип кызыксындырып аңлаттылар.

— Ярар, Рифат. Инде хәзер барын да ашыкмыйча гына янадан сөйләп, аңлатып бир әле.

Рифат хатынының һәрнәрсәне төптән уйлап эш иткәненә кабат инанды. Авыл хуҗалыгына караган бер фәнни-тикшеренү институты хезмәткәрләренең күркә белән үрдәк кушылмасы булдыру проблемасын уңышлы хәл итүләре турында чыгышын тыңлавын сөйләп бирде.

— Институт институт бит инде ул, — диде Рәшидә. — Ә без кем?

— Безме? Без институт чишкән фәнни мәсьәләне тормышка ашыручылар булырбыз. Күнелем сизә, Рәшидә, бик файдалы, кызыклы эш булачак бу.

Рифат канатланып эшкә кереште. Эмир да әти-абыйсына булышып йөрде. Алар иң элек искергән терлек абзары нигезен, стеналарын балчык измәсе белән сылап, шәпләп жылыттылар. Түшәменә такта кадаклап, идәнгә иске линолеум жәйделәр, коры печән тараттылар. Ут та уздыргач, сарай эче ямьләнеп китте. Кошларга ашатырга шактый гына ашлык сатып алгач, Рифат юлга чыгып китте. Ике-өч көннән Рәшидә тәрәзәдән йортлары каршына «Газель» машинасы килеп туктаганын күрде. Аның кабинасыннан авызы колагына житкән Рифат сикереп төште дә әржәгә менеп китте. Рәшидә чыкканда, ире кулларына ике кәржин тотып капкадан кереп килә иде инде.

— Кунакларны каршы ал, Рәшидәкәй, — диде ул. — Менә ул безнең байлыгыбыз. Син ләгәннәргә су сал, ә син, Эмир улым, ашарларына ашлык куй. Ял итсеннәр, ашасыннар. Арганнардыр, мескеннәрем. Ерак юл бит.

Рәшидә белән улы кушканнарны үтәргә йөгерделәр, Рифат кәржиннәрдәге кошларны сарайда ирекккә чыгарды. Алларына су, ашлык куйгач, бер ата, ике ана күрдәк, унлап бәбкә кыстатып маташмадылар. Хужалар, болай булгач, эш пешә, дип елмаешып карап тордылар.

— Кара әле, Рифат, син юлга чыкканда, бисмилланы әйткән идеңме? — диде Рәшидә.

— Так точно! А как же!

Соры йонлы, әрсез, нәни бәбкәләр Эмирга тиз ияләште. Эмир үзе дә аларны бик яратты, ашарларына үзе салды, суны үзе әчерде. Күрдәкләр талымсыз булып чыкты, ашлыкны да, Эмир тураклап салган үләнне, хәтта кычытканны да тәмләп ашадылар. Бәбкәләр күзгә күренеп үсте, көз житкәндә инде әти-әниләрен куып життеләр. Моңа Рифатның кош азыгын төрләләндереп, баланслап торуы да ярдәм итте. Салкыннар башланыр алдыннан кошларны төнгә жылы сарайга кертә башладылар.

Октябрь урталарында салкынча иртәдә Рифат тышка чыккан иде, ишегалдында яткан өч күрдәкне күргәч аптырап калды. Кошлар аякларына баса алмыйча ятып кына тора иде. Нәрсә булган икән боларга, дип аптырады ул. Рифат институт хезмәткәренең күрдәкнең аяклары йомшак була, салкыннан саклый күрегез, югыйсә аяксыз калулары бар, дип кисәткәнен оныткан иде. Бу хәл гаиләгә сабак булды. Рифат улы белән капкаларны яхшылап ябылырлык итеп кыстылар, тишек-пошык калмадымы икән дип нигезләрне кабат тикшереп чыктылар. Кошларга ризык та, яктылык та үз вакытында бирелде, аслары тиешенчә чистартылды. Нәтижә озак көттермәде, март аенда ук күрдәкләр йомырка сала башлады. Шулай итеп эш жайга китте. Хәзер инде аны тагын да киңәйтү, кечкенә генә булса да ферма, инкубатор төзү турында уйларга вакыт житте.

***

Беркөнне Рифат азык-төлек кибетеннән чыккан гына иде, аның юлына майланып беткән чәчләре иңбашына ук төшеп сыланган, кыска сары керфекле егерме сигез-утыз тирәләрдәге бер ир заты аркылы төште. Нечкә ireннәре арасыннан вак тешләре күнел кайтаргыч булып күзгә бәрелеп тора, озын борыны зәп-зәңгәр. Кем булыр бу? Моңа тикле күзгә-башка күренгән кеше түгел кебек. Зәңгәр борын Рифатның каршысына килеп басты.

— Син тукта әле! Сүз бар. Син Рифат буласың бугай.

— «Син» түгел, «сез». Тәрбияле кеше «сез» дип эндәшә. Бигрәк тә таныш түгел кешегә.

— Хәзер танышабыз анысы. Миңа Марс, диләр. Менә күрше авылдан.

— Греклар сугыш алласына Марс, диләр.

— Алай икән. — Ир заты вак тешләрен ыржайтып хихылдап алды. — Сугыш дигән нәрсә безгә таныш ул, таныш.

Рифатның борын яфраклары тетрәнеп китте. Ачуы чыкканда, аның гел шулай борын яфраклары тартыша.

— Сез нишләп минем юлга аркылы төштегез әле? Жә, ни йомыш?

— Менә нәрсә, тәти егет! Күрәм, син, Рәшидә атлы хатын тирәсендә чуаласың. Шулаймы?

— Шулай да булсын ди. Шуннан.

— Утырган да шуган. Ычкын син моннан, югыйсә...

— Нәрсә, нәрсә? — Бу затның тупаслыгыннан ачуы ныклап кабара баруын сизеп, Рифат үзен-үзе тынычрак тотарга тырышты. — Югыйсә нәрсә була?

— Әйтү шушы — ычкын. Менә бер ел инде мин аңа күз салып йөрим. Ә син...

— Рәшидә минем хатыным. Сиңа күңел дигән нәрсәңне авызлыкларга туры килер, — диде Рифат тегенең сүзен бүлдереп.

— Хатының? Эшләр шулай тирәнгә киттемени инде? Хәер, безгә шулай да ярап торыр. Аерырга туры килмәгәе. Бәлки аерырсың. — Зәңгәр борынның күзләре мыскыллы ялтырады.

— Хәзер! Алайса, мин дә әйтим инде. Монда эзең булмасын. Рәшидә монда бәйләнчекләр бар, дигән иде шул. Син шуларның берсе инде алайса.

— Ярар, мин уступчивый. Эшең рәтләнеп барганга охшый. Син безгә ай саен өлеш чыгарып торырсың. Хатының шунда гына үзеңә калыр.

Сүзенең җитдилеген раслар өчендер, күрәсең, зәңгәр борын кинәт кенә бармакларына әллә нинди бишни бизәкләр кадалган пычрак тырнаклы кулы белән Рифатны изүеннән эләктереп алды:

— Шуны да кисәтеп куям: телеңне тыя бел. Синең ишеләрнең арт сабакларын күп укыткан инде без!

— Шаштыңмы әллә, ахмак! Кагыласы булма! — Рифат адәмнең кулын бәреп төшерде. — Рәшидәне уеңнан чыгар. Ир хатынына бәйләнеп йөрү законга сыймый торган ахмаклык. «Өлеш» дисең тагын... Күрсәтермен мин сиңа өлешне! Ахмак!

— Кемнең ахмаклыгын соңрак белербез! — дип Марс кычкырып калды.

Рәшидә ирен елмаеп каршы алды:

— Озакладың, Рифат, аш суына. Менә кулыма күз сал әле.

Рифат хатынының кабарып чыккан бармакларын күргәч аптырап китте:

— Пешердең мәллә? Ни булды?

— Такта ышкылап маташкан идем. Сиңа ярдәм булсын дип.

— Патша кызының мамык тотса да кулы кабара, диләрме әле. — Ир сөйгәненең кулын әйләндереп-әйләндереп карады да җитди тонга күчте:

— Ирләр эшенә кагылма дип мең кат әйттем ләбаса, Рәшидә. Хатын-кыз эше дә җитәрлек бит сиңа.

— Һи, таптың патша кызы. Бер үзеңә сиңа да җинел түгел бит. Ярдәм итәсем килгән ие.

Рифат хатынының кулын сыйпаштырып, биленнән кочып алды.

— Синең хәзер ирең бар, матурым. Ялгыз чагында эшләгән ир-ат эшләрен ташла инде, кадерлем. — Син авылыбыздагы безнең күрше Шәмсетдин бабайны хәтерлисеңме?

— Әйе.

— Бервакыт ул бабай миңа гомер онытмаслык гыйбрәтле хикәя сөйләгән иде. Менә тыңла әле. Бер ялгыз адәм дөнья күңелсез дип үзен кая куярга белми йөри икән. Жанына урын таба алмый инде бу. Көннәрдән бер көнне Ходайдан сорарга итә. И Ходаем, сиңа зур бер гозерем бар, ди. Күрәм, дәүләте зур булганнар бал-майда йөзә, бернигә эче пошмый. Кодрәтең киң, син мине күп акчалы итсәң ие. Мәчет юлыннан кайтмас ием, мохтажларга ярдәм кулы сузар ием. Ярар, ди Ходай. Карап карарбыз.

Менә бу бәндәнең көнкүреше рәтләнә, байый, күңеле урынына утыра. Әмма ләкин бер заман вәгъдәләрен оныта бу, тагын күңелсезләнә, зарлана башлый. Гомерем узып бара, ә эч пошуга тәкать тотып булмый. И Ходаем, ярдәм ит, ди. Әнә кешеләрнең сөекле, күндәм хатыннары бар. Алар итәк тутырып бала таба. Ә мин моңлы-зарлы бер ялгызым. Син миңа тәрбияле, чибәр генә, минем сүздән чыкмый торган хатын багышласаң ие.

Ходай Тәгалә моны тыңлап-тыңлап тора да ачуы чыга.

— Юк инде, — ди Ходай. — Мин уңган-булган адәмне генә хатынлы итәм. Ә син уңмаган, буш куык, әрәмтамак. Ни эшләргә, ни эзләнергә теләгең юк. Эч поша, дип кул кушырып утырасың. Күңелең тарткан, күңеленә яткан хатын-кыз — ул синең ярты җаның, беләсең килсә. Үзең тап. Тап та кадерен бел, ди. Аңлый алсаң, аңла: җиргә утырып утын кисмиләр, ди.

Рифат елмаеп тыңлап торган хатынының башын күкрәгенә кысты.

— Ә мин таптым! Менә дигән алтын куллы, алтын холыклы хатынымны таптым!

***

Гаражга барасы исенә килүгә, Тәнзиләнең йөрәге жу итә, аягы тартмый. Ире аны теге уйнаш кыз белән шунда мәсхәрәгә калдырды бит. Сатарга да бүтәнне алырга дигән уйга килгән иде, тик сатлык гаражлар шәһәр читендә генә булып чыкты. Ә аларныкы, юк ла, аның үзенеке — бик якында, унай җирдә. Андый зур гараж-складны каян табасың әле. Нишлисең, башыңа төшкәч, шул җирәнгеч гаражга барырга туры килә. Әле товар илтергә, әле алырга. Права юнәтеп дөрес эшләде. Хәзер ул рульгә үзе ябыша да чаба, ябыша да чаба. Равилдән соң эше дә бермә-бер артты. Баштарак машинасын төнгә ишек алдында гына калдыра иде, тик көннәрнең берендә эшкә барырга чыккач шаккатты. Көпчәкләр урынында машина астына кирпечләр генә кыстырылган иде. Ә гаражда машинаң сак астында тора. Тик Тәнзилә күренүгә, бозау хәтле этен ияртеп, яшел күзләрен ялтыратып, куллары һәрвакыт машина маена баткан сакчы Алик килеп җитә. Сораша, киңәш биргән, ярдәм иткән була. Тәнзилә күзләрен яратмый шуның. Күргән саен бу яшел күзләр мәченеке шикелле караңгыда да ялтырый микән, дип уйлап ала. Эте тагын, котны алып өрә дә өрә. Тәнзиләнең сыны катып куркып калуын күргәч, Алик гыргылдап көлә генә:

— Курыкма, матур апа, курыкма. Мин булганда...

Курыкмассың, беркөнне усал эт Тәнзиләнең күлмәк итәген умырып алды. Этен ачуланасы урынга Алик, эре сары тешләрен ыржайтып:

— Ай-яй, матур апа, синең аякларың да бик матур икән, — диде. — Син болай ит әле. Киләсе юлы эткә бирәр тәмле әйбер алып кил. Минем Чикотило ит ярата. Шуннан соң ул сине үз итә башлар. Миңа да бәлки өлеш чыгарырсың, ә? Ха-ха-ха...

Ничек кенә ачуы килмәсен, Тәнзилә Алик сүзенә колак салмый булдыра алмады, селәгәйләре агып торган явыз эткә пәрәмәчләр китерде.

— Мә, тынычландыр, өрмәсен, — дип, пәрәмәчләр төргәген эт хуҗасына тоттырды. Алик төргәкне ачып, пәрәмәчләрне иснәп телен шартлатты:

— Це-це-це! Исе дә исе! Кулың алтын икән. Әрәм булып йөрисең шунда. — Күзләрен майландырып, бер пәрәмәчне ике генә капты да, чап-чап чәйнәп, төргәкне Тәнзиләгә кайтарып бирде:

— Син, матур апай, боларны эткә үзең бир. Тәмле ис сизеп әнә ничек биеп тора. Сине шулай истә калдырсын. Шуннан соң өрмәс ул.

Тәнзилә Алик әйткәнчә итте. Чикотило пәрәмәчләрне капты да йотты, капты да йотты. Шуннан соң Тәнзилә калдык-постык ит кисәкләрен, сөяк-мазарны ташламады, эткә алып килә башлады. Эт ияләште, хуҗасы да Тәнзилә күренүгә ялт итеп пәйда була, вак-төяк эшкә булыша, машинаны алып чыга, кертеп куя. Тәнзилә баш тартыр иде, тик капкадан кергәндә инде ике тапкыр машина ишеген кырдырды, кешечә керергә-чыгарга тәки өйрәнә алмады. Беркөнне Алик карап торды-торды да:

— Син, матур апай, этне генә түгел, мине дә үзенә ияләштерден, — диде. — Тик аны төрле-төрле ризык белән сыйлыйсың, ә миңа шымытыр. Минем бүген рәтем юк, ә тамак кипте. Ә?

Тәнзилә аны гына аңлый торган кеше. Юл йөреп, сату-алу эшендә кеше каешлана шул.

— Мә инде, мә. Тамагыңны чылат алайса, — дип ул Аликка ике йөзлек тоттырды.

Тегесе алдын-артын белмичә, якындагы «Магнит»ка чапты.

«Юләр, — дип карап калды Тәнзилә. — Нишләп кайбер ирләр шул әче суга мөкиббән китә икән. Менә моның куллары алтын бит. Күренеп тора. Гараж кооперативында машина хуҗалары аның тирәсендә бөтерелеп кенә йөри».

Ул машинаның теләсә кайсы детален сүтеп ала да: «Это безгә нипочём», — дип, авыз эченнән генә җыр көйли-көйли рәтләп тә бирә.

Беркөнне Тәнзилә гаҗәпсенә калды. Аликның ял көне икән, кырынып-чистарынып килгән. Буй-буй чалбарын үтүкләгән, яңа күлмәк кигән. Ул көнне үч иткәндәй Тәнзиләнең машинасы кәҗәләнде. Кабынмый гына бит. Хатынның чиләнгәнен күргәч, Алик ярдәмгә килде. Чишенеп ташлады да машинаның Тәнзилә белмәгән әллә кайсы урыннарын актарды, «свеча» дигәннәрен борып алды, кайсын кырды, кайсын бензин белән юды. «Тойота» гөрләп эшли башлады. Тәнзилә Аликның күзгә бәрелеп торган мускулларына сокланып карап-карап алганын сиздермәскә тырышса да, ир моны сизде. Эш беткәч, кулларын озаклап сабынлап юды да, кинәт кенә Тәнзиләне биленнән кочаклап:

— Ай-яй, матур апа, синең билләрең нинди йомшак икән! — диде.

Тәнзилә мондый оятсызлыктан тетрәнеп, тыны кысылып, Аликның яңагына чалтыратып җибәрде:

— Нишлисең син... хулиган! Кара син моны, ә! Кычкырам бит! Җибәр!

Алик кулларын ычкындырды. Аның күзләреннән ачулы очкыннар чәчри иде. Беравык Тәнзиләгә карап торгач, бер генә сүз әйтте:

— Зря! — Аннан тиз-тиз атлап китеп барды.

Машинаны майлап, хатын-кызны җайлап торырга кирәк, дип юкка гына әйтмиләрдер шул. Импортный машина булса да, «Тойота»ның да үз вакытында маен алыштырып, тузанын суырттырып, юып торырга кирәк. Тәнзилә пычрак машинада йөрергә яратмый. Ә машина безнең табигать шартларында пычранырга гына тора. Ю да ю гына. Пычрак янгырлы көннәрдә гаражга кайтып төшкәндә, Тәнзилә аптырашта кала. Ничек кенә уңайсыз булмасын, аңа тагын шул сакта торучы ирләргә ялынырга кала. Шул исәптән теге Аликка да. Дөнья бит бу!

***

Рифат эшләрен бетереп саф һавага чыкты, үпкәсен тутырып, киерелеп сулыш алды. Анын йөзендә елмаю уйный иде. Эшләре жай гына бара, күрдәкләр йомырканы күп сала, талымсызлар, ашатып-эчертеп, асларын чистартып торсаң, Алла бирсә, файдасы да тияр. Бәбкәләрен сорап кына торалар. Авыл халкы яңача тормышка ияләшеп килә. Эш болай барса, алган кредитның шактый өлешен түләргә мөмкинлек туа. Ярдәмче егетләргә, кызларга да хезмәт хакын арттырырга була. Акчаны ул «конверт» белән түгел, тиешенчә түли. Шуңа күрә инкубаторга, бәбкәләрне тәрбияләргә, сугым эшләренә алынырга теләүчеләр бетми. Киләләр, сорашалар, әлегә эш юк шул, менә бераздан эшләр киңәергә тора, шунда сезне истә тотарбыз дисәң дә кәефләре китә. Тик нишлисең, «Москва не сразу строилась».

Кайтып житкәндә, Рифат капка төбендә бер карчыкны шәйләп алды. Кем булыр икән бу? Күрше-күлән өйгә кермичә, капка янында ялгыз утырмас. Әллә берәрсе читтән килдеме икән? Якыная төшкәч, Рифат бу әбине таныды, авызы ерылды:

— Галиябану апай, син бит бу! Сөбханалла! Нишләп монда утырасың, өйгә кермичә, ә? Рәшидә өйдәдер бит?

— Менә хәл алып утырам әле, кем, Рифат. Карт кешенең хәле минуты белән үзгәрә дә куя. Авылымны күреп килим дип батыраеп автобуста килгән ием... Бөтен сөякләрем тарала дип торам.

— Арыттымыни?

Карчык тирән тын алып, дәвам итте:

— Авылыбыз шоферы Сәфәргали булганда, юл йөрү рәхәт иде. Әйе... Бу кара адәм бигрәк дорфа икән. Әле уңга, әле сулга чайкап, элдерә генә. Әйтеп тә карадык, утын ташымыйсың лабаса, саграк кылан дип. Әйе... Тәки үзенекен итте.

— Шулайрак диләр шул... Ярар, әйдә, керик. Чәй эчеп, ятып торырсың, әйдә, әйдә.

Рифат карчыкны житәкләп өйләренә алып керде. Рәшидә дә үз әнисен күргәндәй шатланды. Тәмләп чәй эчкәч, карчык черем итеп алды. Аннары:

— Сез инде, оланнар, бу карчык нишләп йөри икән, дип уйлыйсыздыр, — диде. — Әллә ни эшләрем юк ла. Эшлисе эшләр эшләнгән инде. Пенсия алдым да авылга кайтып килим әле, минәйтәм. Үземнекеләрне көчкә ризалаттым. Исән чагымда карт-корыны да күрим әле, дим. Житмештән соң һәр көнең Ходай бүләге ләбаса.

— Күрәм, синең күнел авылга береккән шул, Галиябану апа. — Рәшидә карчыкның хәленә төшенгән иде.

— Ничек берекмәсен соң ул, кызым?! Авыл бит ул, авы-ыл. Туган-үскән, күкрәк сөтенне имезеп, газиз балалар үстергән авы-ыл.

— Галиябану апа, шәһәрдә дә начар түгел ләбаса. Беләбез, урының жылы, кызың «әни» дип кенә тора. Әллә иптәше корыракмы?

Карчыкның йөзендәге жыерчыклары куера төште. Бераз дәшми торгач:

— Коры дип... Гөнаһысына керәсем килми, миңа тел-теш тидергәне юк. Бүлмәм жылы, якты, ризык мул... Әмма... Ильяска мин әллә бар, әллә юк. Исәнме, әби, хуш, әби.

— Шешә белән дус мәллә?

— Капкалап куя. Тавыш чыгармый... Юк. Тик карт кеше жаны жылы сүзгә, жылы мөгамәләгә, хәленә керүгә мохтаж. Уй-зарыңны уртаклашуга...

— Ә Рузалиян?

— Рузалияме? Эш инде анарга, эш. Исәнлеге дә чамалы гына бит. Тормыш

хатын-кызга шәһәрдә дә җиңел түгел. Рузалия көне-төне чаба. Уллары Рөстәмне укытырга кирәк. Түләп укыталар. Акча, акча... Әй, күңелемне чиштегез, оланнар, зарланып утырган шикелле булып чыкты. Бүгенгемә шөкер, киләчәкта ни язгандыр. — Карчык сөякләрен шыгырдатып торып басты. — Мин якындагы ялан-кырга барып килим әле. Шунда үстек, шунда бил бөктек. Аннары кичке автобус белән кайтып китәрмен.

— Кырга дисеңме? — Рәшидә сәерсенебрәк иренә күз ташлады. — Бик аргансың ич, Галиябану апа. Кырга барам дисең тагы. Юк, без сине җибәрмибез, кунарга каласын.

— Туган-үскән җиргә аяк баскач, хәл дә кереп китте әле.

Сүзгә Рифат та кушылды:

— Алайса без болай итик, Галиябану апа. Әйдә, чыгып утыр машинага. Рәшидә, син дә. Урман-кыр тирәсендә күптән булганың юк. Күңел ачып кайтырбыз.

Галиябану әби рәхәтләнеп машинага кереп утырды. Кырда тезләнеп дога укырга кереште. Рифат белән Рәшидә аңа комачауламас өчен читкә киттеләр. Әйләнеп килгәндә карчык тезләнгән килеш урганнан калган кыска камылларны кулы белән сыйпап утыра иде.

— Әй, бәгырьләрем, бәгырьләрем. Бөтен көчегезне башакка сарыф итеп, инде кыш көтеп утырасызмы? Кешеләр дә шулай мәңгелек хезмәттә, сезнең шикелле. Мине, мине хәтерлисезме соң? Хәйдәрем белән шушында, сезнең янда тәүге тапкыр серләшеп, кочагыбыз җылысыннан эреп басып торганыбызны онытмадыгызмы? Ул чакта без тасырдап, янып торган яшьләр идек шул.

Галиябану әбинең җыерчык баскан йөзеннән яшь ага иде. Моны күргәч, яшьләр икесе дә карчык янына тезләнделәр, аның сөяккә генә калган аркасыннан сөйделәр. Бераз сүзсез торгач, Рәшидә:

— Бик сагынасыңмыни соң, Галиябану апа? — диде.

— Сагынмаган кая ул... сагынмаган кая. Сагынасыңмы дип сорыйлар, сагынмаган кая ул, дигән җырны кем чыгарды икән? Бигрәк тә җанга үтәрлек итеп әйткән бит... Туган-үскән җиргә йөрәк береккән бит, йөрәк.

Бу көн Рәшидәнең дә, Рифатның да күңелен кузгатып җибәрде. Рәшидә төн уртасында:

— Рифат, тоеп торам, уйланасың да уйланасың. Әйт әле, башыңда нинди уйлар йөри? — дип сорады.

— Туган якны җирсеңү дигән нәрсәне мин үзем дә нык татыган идем.

— Шулай дип фаразлаган идем. Риза булыр микән? Кызы, кияве ни дияр?

— Килештерербез. Безгә ул үз әниебез кебек инде диярбез. Дөресе дә шул: мин әнием белән яшәп кала алмадым. Рәшидәм, мине аңлавың өчен рәхмәт сиңа. Ходай сиңа олы җан биргән.

— Үзеңә рәхмәт. Рифат, син чын ир. Татарның менә дигән егете. Көтмәгәндә Ходай улым белән миңа нинди бәхет бирде. — Рәшидә иренең кочагына сыенды...

Күрше бүлмәдә йоклап яткан Эмир кычкырып җибәрде:

— Так точно!

Төш күреп ятуы икән.

Карчыкның кызы Рузалия бик озак тартышты: ничек инде, газиз әниеңне чит кешеләр алып китсен дә, үз кызы белән кияве шуңа риза булсынмы? Юк-юк, авыз да ачмагыз. Әни, син ник бер сүз дә дәшмисең?

Галиябану әби башын иеп торды-торды да сабыр гына фикерен әйтте:

— Салкын акыл белән уй йөртсәң, кызым, син хаклы, хаклы. Әмма ләкин йөрәк тә бар бит әле. Мин бит дөнья читенә китмим. Туган-үскән, гомерем

узган жиргә. Әтиегез зираты янына. Шәһәрдә дә, сезнең янда да әйбәт. Рәхмәт, тәрбиялисез. Тик таш белән сөйләшеп булмый бит. Ак булса да, таш бит ул.

— Рузалия, Ильяс, беләсезме, аның җаны авылга, җиргә береккән, — диде Рифат. — Беркөн кырда камылларны сыйпап, алар белән сөйләшеп утырганын күрсәгез иде сез аның. Бездә дә бөтен уңайлыклар бар. Риза булыгыз инде. Теләгән чагында монда да алып килербез. Аралашып торырбыз. Кунакка кайтырсыз. Сезнең нигезегез шунда ич.

Моңа кадәр маңгаен җыерып дәшми торган Ильяс сүзен кыска тотты:

— Барсын, Рузалия. Теләсә кайтыр. Аны бит куган кеше юк. Әби, ишеттеңме? Мин әйттем.

Шулай итеп, Рифат белән Рәшидә Галиябану әбине туган-үскән жиренә, төшләренә кереп сагындырган мәтрүшкәле урман-кырларына, иркен сулышлы авылына алып кайттылар.

***

Теге Марс дигән адәм без әле очрашырбыз дигән иде, сүзендә торган икән. Беркөнне Рифат каршында кабат пәйда булды ул. Бу юлы ике әшнәсен дә иярткән. Болары да моңа чаклы күренгән бәндәләр түгел иде. Бу бәндә белән йөргәч, кемлекләрен шәйләп була, дип уйлады Рифат.

— Күрәм, чакырылмаган кунаклар килгән икән. Йә, ни йомыш? — Рифат ныклы адымнар белән Марс каршына килеп басты. Ул арада тегеләрнең берсе — тырпаеп торган колак иясе Рифат артынарак шуды. Аның уң кулы кесәсендә иде.

— Безнең йомыш бер инде. Мин аны сиңа әйткән идем. — Марс чистартылмаган вак тешләренең казналарын күрсәтеп елмаеп маташты. — Син, егет, җә авылны ташлап китәсең, җә безгә ай саен өлеш түләп торасың, — дидем бит мин сиңа.

— Китмәсәм?

— Китмәсәң, җибәрәбез. Ну, ул чакны синең кабыргаларың сынык, башың ярылган була инде.

— Мине бик матур киләчәк көтә икән, алайса.

Ул арада Марсның шәүләседәй артта басып торган сакалбай чыгып басты. Рифат «сакал»ның иңбашларына игътибар итте. Аның гәүдәсе шешәгә охшаган иде.

— Өлешләп риза булмасаң, берьюлы түләрсең. Контрибуция! — дип, «шешә» кулындагы кастетын уйнатып алды.

— Контрибуция? Сүзе генә нинди! Егетләр, карагыз, бу ниятегез начар бетәчәк бит. Шуны уйладыгызмы, юкмы?

— Уйладык та менә сиңа шуны әйтергә дип килдек. Ризамы?

Армия хезмәтендә дә берәр катлаулы, киеренке хәл килеп туса, Рифат гәүдәсенең пружина кебек атылырга торганын тойды.

— Юк! Бу беркайчан да булмаячак!

— Алайса, егет, үзеңә үпкәләрсең.

— Мин үпкәләмәм. Ә менә сезгә үкенергә туры килмәсен. Алдан әйтеп куям. Шаярмагыз, мин — спорт мастеры! — Рифатның яңак сеңерләре уйный башлады.

— Хо-хо-хо!

— Хе-хе-хе!

— Хы-хы-хы! Куркыттың. Ә менә безнең Ратмир спирт мастеры.

Артта басып торган «спирт мастеры» кискен хәрәкәтләр вакыты җитте дип уйлады булса кирәк, кинәт кенә кесәсеннән пычак чыгарып, Рифат өстенә

ыргылды. Рифат тегеләр белән сөйләшкәндә, күз кырые белән генә аны да игътибарда тоткан иде. «Спирт мастеры»ның кизәнгән кулы астыннан читкә тайпылды да бар көченә тегенең касыгына типте. Теге «дык» итеп бөгелеп төште. Аннан өстенә сикергән Марсны тибеп очырды. «Шешә» бер секунд эчендә ике дустының ыңгырашып тәгәрәп китүен күргәч, җиргә береккәндәй өнсез калды.

— Йә, сине нишләтим, батыр?

— Яр-рар, ярар, — диде «шешә», — бетте, бетте...

Аның теше-тешкә тими, бөтен гәүдәсе калтырана иде.

— Мин Марс әйткәнгә генә килдем. Бер-р-гә үстек, бер-гә укыдык. Яшьтиләр...

— Бик яхшы укыгансыз икән. — Рифат ыңгырашып яткан «яшьтиләргә» карап алды да:

— Әйттем бит мин сезгә, мин спорт мастеры дип. Әйттем бит...

— Әйттең, әйттең...

— Әйдә, торгызыйк үзләрен, алдыгыздан артыгыз матур. Исемең ничек?

— Зоммер... Әй, Зариф ла. Егетләр Зоммер дип йөртәләр.

Рифат көлеп җибәрде:

— Зоммер? Их син, Зоммер. Яшьти әйтте дип җинаять юлына баскансың лабаса. Йә, боларны нишләтәбез?

Ул арада Марс телгә килде:

— Китәбез... без... китәбез...

— Иптәшегезне житәкләгез, аңа бик каты эләкте. Пычак белән уйнарга ярыймыни соң, ахмаклар. Кстати, пычагын үземдә калдырам. Эшнең дәвамы була калса, кирәге чыгуы бар.

— Рифат, дәвамы булмас, имансыз китим. Зинһар, зурга җибәрмә инде. Тюрагадан чыкканыма бер генә ел бит минем.

— Җибәрмәм. Егет сүзе. Тик бу җинаятьчел шөгылегезне ташлагыз сез.

— Ярар, ярар... Бетте, бетте. Пычакны бирмисеңмени?

— Юк..

Рифат пычакны кулъяулыгына төреп кесәсенә салды. «Спирт мастерын» җитәкләп, рэкетирлар авылларына титакладылар.

***

Чәчәкле май житте. Беркөнне Рәшидә иренә:

— Рифат, безнең әткәй нишләп ята икән анда? — диде. — Ялгызына бик читен бит инде аның. Монда алып киләсе иде, ә?

— Үземнең дә шуңа җаным кыйнала, Рәшидә. Әйтеп тә карадык бит. Теге чакта Равил, аннары мин. Юк, ди бит. Картайган көнемдә, кул-аягым йөргәндә, күзем күргәндә, нигеземнән кузгалмыйм, ди. Күрше-тирәм бик ярдәмчел, бик карыйлар, ди.

— Кунакка гына дип әйтеп карыйк. Ерак ара түгел. Ошатса, бәлкем, калыр.

— Шулай итеп карыйк әле, Рәшидә. Рәхмәт яхшы сүзеңә. Галиябану апага да иптәш булыр иде.

Газыйм бабай башта ике аяклап каршы торды.

— Бу яшемдә гомерем узган нигездән кузгалмыйм. Әниегез каберен ташлап, чит-жат җиргә аяк та атламыйм, әйтмәгез дә, — диде.

— Әти, ошатмасаң кайтарып куярбыз. Әйдә әле, безнең тормышны күреп китәрсең. Һич югында бер-ике атнага гына булса да, — дип Рифат картны шактый үгетләде.

— Шулай дисәң генә инде... Кара аны, озакка түгел... Ә кош-кортны, кәҗәләрне нишләтәбез?

— Күршеләргә әйтербез. Кирәк-яракны күпләп биреп калдырырбыз. Кәҗәләренне алар сава дисең ич. Ул арада гына күз-колак булып торырлар инде.

Газыйм бабайның кунакка җыенуын күршеләре хуплап каршылады:

— Борчылма, бабай. Синең яхшылыкларыңны без гомердә дә онытмаячакбыз. Бар-бар, көндәлек мәшәкатьләрдән бераз арынып тор, — диделәр.

— Ярар инде, алайса, рәхмәт. Мин озакламам, җәме. Исән-имин торыгыз, — дип карт машинага чыгып утырды.

Юлчылар кайтып житкәндә, Рәшидәнең гөбәдиясе пешеп өлгергән иде инде. Пилмәнен дә салып җибәрде. Галиябану апай, син карый тор инде, дип Рәшидә юлчыларны каршыларга ашыкты. Газыйм абзый әүвәл хуҗалыкны карап йөрде, канәгатьлек белән тамак кыргалап, болдырга күтәрелергә торганда ишектә Галиябану әби пәйда булды. Аны күргәч, Рифат белән Рәшидә бер-берсенә карап, елмаеп куйдылар. Карчык пөхтә итеп кешелеккә кия торган күлмәген кигән, шәл-яулыгын матур итеп иңенә салган иде.

— Әйдә, әйдә, Газыйм абзый, хуш киләсең, — диде ул. — Менә безнең тормышка күз салырсың. Улың белән киленеңә мин рәхмәт укып бетерә алмыйм. Мине үз әниләре сыман карыйлар.

— Шулай булырга тиеш, кем...

— Галиябану булам мин, Галиябану.

— Шулай булырга тиеш, Галиябану. Кемнеке — аныкы, ди халык. Минем балалар алар. Киленгә килгәндә, алар нәселе гомер-гомергә уңган, кешелекле, ярдәмчел булды.

Ашап-эчеп, ял итеп, намаз укып алгач, каралты-кураны, кече инкубаторны да карап чыгарга ниятләде. Андагы чебешләрне, сугымга хәзерләнгән, житлеккән күрдәкләрне, һәркайдагы чисталыкны ошатып:

— Кул куям мин моңа, кул куям, — дип канәгать калды. — Хәере белән булсын.

Галиябану карчыкны алыштырып куйдылармыни. Рәшидә каенатасының күңелен күрергә дип бирәр эшкә тотынса, карчык юк-юк, үзем-үзем, дип кунак тирәсендә бөтерелеп кенә йөрде. Тәһарәт алырга комганга җылы су тутырып, сөлгесен китереп куйды, ашарга утыргач, кыстый-кыстый сыйлады, балын-шикәрен, җиләк-җимешен аның алдынарак күчерде, чәен яңартып торды. Картның коймак яратканын белгәч, аны көн аралаш пешерде. Шулай ярты ай чамасы вакыт узды, карт китү хакында сүз күтәрмәде. Рәшидә дә, Рифат та аның Галиябану апалары белән еш кына капка төбендә сөйләшеп утыруына шатланып йөрделәр. Бәлки калырга риза булыр. Карт монда да тик тора белмәде, карчык белән бергә казык кагып, помидорларны күтәртеп бәйләделәр, аларның төпләрен йомшарттылар, кыярларга су сиптеләр, көлдән селте ясап, карлыганнарны бөҗәкләрдән тазарттылар. Көннәрнең берендә карт яшьләрне шаккатырып болай диде:

— Улым, син бу авылның мулласын алып кил әле, — диде. — Никах укырга диген. Без Галиябану апагыз белән кушылырга булдык. Аннары кайтып китәрбез, вакыт житте, булды.

— Менә сиңа яңалык! — диде Рифат. — Тиктомалдан гына дип әйтимме соң... Без бит инде син калырсың дип өметләнгән идек. Галиябану апага ияләшеп беткән идек. Үзе дә... Аннары, эти, аның бит үз кызы, үз гаиләсе бар. Алар нәрсә диярләр соң?

— Безнең яшьтә тиктомалдан эшләнә торган эш түгел бу, улым. Үз гаиләсе, дисең. Менә бит сезнең белән яшәргә ризалык биргәннәр.

— Галиябану апа, үзең ни дисең соң?

— Риза ул, Рәшидә кызым. Югыйсә мин сүз күтәреп торыр идемме... Мин бит аны җәһәннәмгә алып китмим. Теләгән чагында мондамы, Казангамы, кайтып җөрер. Икебезгә дә шулай яхшы булыр дип уйлаштык.

— Әти, без бит синең белән бергә яшәрбез, дип өметләнеп торган идек. Ничек була соң инде бу? — Рәшидә яшьләнгән күзләрен сөртә башлады. — Кушылыгыз, тик монда яшәгез.

— Галиябану, син нишләп авызыңа су капкан шикелле дәшми торасың? Әйт сүзеңне, — диде карт.

— Сез, балалар, каршы килмәгез әле. Ходай шулай язгандыр, — диде карчык. — Уйлаштык инде без. Төрле яктан уйлаштык. Безнең әти сөялә белгән егылмас дия иде. Янында сүз катарлык та кешең булмаганда ялгызыңа бик авыр ул, авыр. Особый ир-атка. Мин риза, савабы да булыр, иншалла.

— Кызың, кияվең каршы килсә?

— Аңлашырбыз. Без бит әле үз акылыбызда.

— Ярар инде, алайса. Нишләмәк кирәк... Кайчан телисез, шунда алып килербез, илтеп куярбыз. Ә кышын бездә яшәрсез. Безнең дә менә сезгә шундый шартыбыз бар, — диде Рифат. — Шулай бит, Рәшидә?

— Шулаен шулай да. Кеше ни дияр? Карт белән карчыкны сыйдырмаганнар икән диюләре мөмкин ләбаса.

— Дисәләр диярләр. Кызыл тел ни сөйләмәс, Рәшидә кызым. Гайбәтнең урыны чүплек башында, аңарга шаккатасы түгел.

Шулай итеп, кунакка гына килгән Газыйм бабай туган авылына карчыгын ияртеп кайтты. Дәлиле дә нык иде — Ходай Тәгалә безгә уртак ризык язгандыр.

***

Көннәрнең берендә Аликның нияте тәмам ачыкланды. Урамда аяк асты шактый тазарган, нәни күлдәвекләр пыяладай четердәп ватылган көз көне иде. Инде күпләр машиналарының көпчәкләрен кышкыга алыштырып бетергән иде. Тәнзилә дә кышныкын куйдыртырга ниятләде. Тик моны кем эшләр икән соң? Бәлки автосервиска барыргадыр? Гараждан чыгуга, күзе арткы көпчәккә төшкәч, эче жу итте, көпчәк шиңгән иде. Димәк, Тәнзилә аны тагын кайдадыр тишкән инде, шушында ук алыштырырга кирәк иде. Ичмаса, иртән үк эшлекле очрашулар билгеләнгән. Тагын шул каравылчы ирләргә ялынырга калды. Бүген, гөнаһ шомлыгына, тагын шул Алик дигәннәре тора икән. Кәҗәләнмәде тагын, җәйге дүрт көпчәкне дә җәт кенә салдырып, шипланганнарын җәт кенә куйды.

— Рәхмәт, ничә сум бирим?

Хатынның соравына каршы Алик, киерелеп торган иреннәрен колакларына кадәр җәеп, акчадан баш тартты:

— Бу юлы акча алмыйм.

— Аракым юк. Алып килгәч бирермен, алайса, — диде Тәнзилә.

— Аракы да алмыйм.

— Ничек? Бушка эшлисеңмени?

— Бушка дип. Юк, син миңа үзең кирәк.

Тәнзилә ачу белән Аликның йөзенә текәлде.

— Син миңа, матур апай, үзең кирәк. — Аликның шома күзләре ялт-йолт итте. — Үзең кирәк, үзең. Түләү натуралата.

Бу интим якынлыкка ишарә, чиксез йөгәнсезлек, оятсызлык иде. Бераз телсез калып торгач, Тәнзилә аңа килде:

— Ничек сиңа оят түгел! Кагыласы булма! Бу бит, бу бит җинаять! Башың

төрмәдән чыкмаячак бит синең, жир бит, — дип, ул ярсуына ирек бирде. Алик мыскыллы елмаеп тыңлап торгач:

— Зря ярсыйсың, матур апай, — диде. — Ташла әле син моны. Ә төрмә дигәндә анда мин түгел, үзеңнең утыруың мөмкин. Әйе, әйе. Әгәр шулай кәҗәләнеп торсаң!

Аликның бу сүзләре гараж стенасыннан кире кайтып, шомлы киноларда гына була торган кайтаваз булып яңгырады. Бу нинди көн булды соң, ә? Ниндидер йолкыш аңа, Тәнзиләгә, төрмә белән яный!

— Авызың ни сөйләгәнне колагың ишетәме соң синең?

— Бик тә ишетә, апаем. Алайса, әйтим инде. Теге уйнашчы кыз үлгән көннән алдарак син монда нинди машина бушатып йөрдең? Гаражыгызда кем белән үбешеп тордың, ә?

Тәнзиләнең башына күсәк белән суктылармыни, сыгылып төште. Буш банкалар тулы мичкә өстенә утырмаса, ул, мөгаен, идәнгә үк авар иде. Банкалар шыксыз тавыш чыгарып шыкырдады. Кайсыдыр ватылды да бугай. Тәнзилә аркасына кайнар тир бәреп чыкканын тойды, ә шулай да икенче мизгелдә үзен-үзе кулга алды.

— Син нәрсә лыгырдыйсың? Нишләп, ничек монда йөрим, — диде ул. — Мин ич ул көннәрдә Мәскәүдә идем.

— Мәскәүдә, Мәскәүдә... Яныгыздан мин кат-кат узып киттем. Мин Мәскәү номерларын бик яхшы беләм. Үзең Мәскәүдә. Ә монда синең өрәгең йөргән идемени? «Киногa» төшеп? — Аликның тавышы зәһәр яңгырады.

— Нинди кино? Син саташасыңмы әллә?

— Ярар, ярар, — диде Алик, тавышын акрынайтып. — Син бүген тәртәгә тибәсең. Ә иртәгә риза булырсың, иртәгә булмаса, берсекөнгә. Мин көтәрмен. Гаражларга килгән-киткәннең бөтенесе охрана видеотасмасына язылып бара. Ә теге көнгеләре миндә. Тикшерүчеләр сораганнар иде, без аларны боздык инде, дидем.

Тәнзиләнең бөтен гәүдәсе калтыр-колтыр килә башлады. Ул диванга сыгылып төште. Алик моны үзенчә аңлады, аның куллары житез генә хатынның итәк астына үрелде.

***

Беркөнне Равил урамда Саимәне очратты. Хәл-әхвәлне белешкәч, ул Равилнең калкып чыккан яңакларына карап:

— Син картая төшкәнсең, димме... Ничек яшисең, өйләнмәдеңме әле? — дип сорады.

— Тормыштан зарланмыйм ла, анысы, — диде Равил.

— Шулайдыр, бик ыспай күренәсең. Зиләңне сагынмыйсыңмы соң?

— Сагынып нишлисең... Икебез ягыннан да хата булды инде, булды. — Равил көрсенеп куйды.

— Беркөнне Зилә янына кергән идем әле. Сөйләшеп утырдык. Кайларда, ни эшләр бетереп йөри икән, ди. Ярый әле, утыртып куймадылар, ди. Әй, юләрләр, юләрләр сез.

— Ә үзенең хәле ничек? Эшләре әйбәт барамы?

— Эшем ару, ди. Тик әнисе бик борчый икән. Картайган, Тәнзилә янына күчәсе килә икән. Хәтере бик начарайган. Аны карарга калсам, миңа эшне ташларга туры киләчәк, ди Тәнзилә. Квартирын сатып, картлар йортына урнаштырмый булмас ахрысы, ди. Жә, ярар, хуш...

Шуннан бирле Равилнең миен бер уй чокый башлады. Саимәне әллә Тәнзилә жибәрдеме икән? Әллә барып өзелгәнне ялгап карарргамы? Көне белән күңеле

бар, сөйләш, ди, ул да түгел үзгәреп тә куя — йөрмә, бер киселгән икмәк ябышмый, ди. Шулай шактый ара изалангач, барырга, сүз катып карарга ниятләде. Куа икән кусын, нәрсә югалта соң ул? Югалтасын югалткан инде.

Таныш баскычлар буйлап менгәндә аның йөрәге күкрәгеннән чыгарлык булып тибә башлады. Кыңгырау төймәсенә басыйммы-юкмы дип шактый икеләнеп торды. Ул арада әчтән чыркылдап көлгән таныш тавыш яңгырады. Әйе, Зилә өйдә иде.

— Кем бар анда?

Равилнең теле аңкавына ябышты да куйды. Тотлыга-тотлыга көчкә генә:

— М-мин... әле бу... Равил, — дип әйтә алды.

Бикләр чалтыр-чолтыр килде, ишек яртылаш ачылды. Анда Тәнзилә пәйда булды. Аның йөзенә чиктән тыш гаҗәпләнү, аптырау билгеләре йөгерде. Хатын әле Равилгә, әле коридорга борылды, хәтта баскан урынында таптанып алды.

— И-и-сәнме, Тәнзилә? Керергә мөмкинме?

Тәнзилә артында, коридорның ары башында трусиктан гына бер ир заты калкып чыкты:

— Кем бар, матур апай? Вакытлы-вакытсыз кем йөри?

Йа, Ходаӧ! Бу теге гараж кооперативы каравылчысы Алик түгелме соң?

Әйе, ул кеше чыннан да Алик иде. Равил өнсез калды. Бу мизгел аңа үзе бер гомер булып тоелды. Ул ихтыярсыздан шаркылдап көлә башлады, аннары башын чайкый-чайкый, абына-сөртенә баскычтан аска ташланды. Борылып карамаса да, ул үзен тәрәзәдән озак күзәтеп калуларын баш чүмече белән тойды.

***

Равил бер мәлне массаж ясаучы кызлар арасында Тосяны — Тәскирәне күрде. Кыз үзе дә елмаеп аңа карап алды. Шуннан соң алар кунак йортында очрашканда,ерактан гына бер-берсен сәламләп йөри башладылар. Беркөнне саунада Равил ана сүз катырга да теләгән иде, кыз бармагын иреннәренә тидереп алды. Бу кисәтү иде. Монда хезмәт итүчеләргә авызларын йозакта тотарга әмер бирелгән. Официантлар, пешекчеләр чукрак-телсезләр шикелле, авызларыннан сүз чыкса да, «әйе», «юк»тан башканы белмиләр иде. Роберт Равилгә дә баштан ук биредә күргән-белгәненне шунда ук оныт, диде. Баштарак Равил мона артык игътибар итмәсә дә, тора-бара күңеленә шом керә башлады. Кая килеп эләкте соң ул? Дөрес, кафеда эш үз унаена тәгәри, Роберт та канәгать, чөнки килгән файданың үз өлешен төгәл алып бара. Тик аның кунак йортына кешеләр алып килүе ешайганнан ешая гына бара. Үзләре белән яшь кызлар алып килүчеләр дә бар. Эчәләр, шаулашалар, бәхәсләшәләр. Ярым шәрә килеш холда шахмат, карта уйныйлар, иртәнгә чаклы бильярд туныйлар. Үзәк кунаклары белән район башлыклары, төрле дәрәҗәдәге депутатлар, бизнесменнар, зур сәнәгать предприятиесе җитәкчеләре дә күренгәч, Равил бизнес белән хакимият йомгагы тыгызлана баруын, илдә коррупциянең тирәнәйгәннән тирәнәюен аңлады. Кунакларның кәефен күреп хәлдән тайган көннәрдә Равил үзенең кайчан, ничек мунчачы, арка юучыга әйләнеп калуы хакында уйлый башлады. Китәргә! Тик ничек? Бәлки, тотарга да Робертның үзенә турыдан-туры әйтергәдер. Исәнлегем какшый башлады дияргәдер. Равилнең бу ниятен Роберт чыраен җимереп каршылады.

— Ташла син бу уенны, — диде. — Жайланып киткән тормышыңнан туя башладың мәллә? Шуны бел, дус кеше: безнең арадан, безнең системадан чыгу керүгә караганда да катлаулырак.

Робертның күзләреннән усал дулкыннар сибелде. Шуңа күрә Равил әлегә сүз кузгатып тормаска булды. Ничек диде бит — чыгу керүдән дә авыррак, диде.

Әйе, бар икән хәлләр... Бермәл аның үзенә хәтле кафе мөдире булып эшләгән егетне очратуы хәтерендә янарды. Егетнең күз төпләре күгәргән, таякка таянып, бик нык аксап, көчкә-көчкә генә атлап бара иде. Равил аптырап:

— Сиңа ни булды? Авариягә очрадыңмы әллә? — дип сорады.

Егет нидер әйтмәкче иде, кире уйлады бугай:

— Әй, сорама! — дип кулын гына селтәде.

«Системадан чыгу керүгә караганда да катлаулырак» дигән сүз шушы буламы икән әллә? Йа Хода!

***

Тагын бер ел узды. Равил чын-чынлап кафедагы эштән китәргә кирәк дигән уйга килде. Хәер, кунак йортындагы вазифаларыннан баш тартса, аны болай да кафедан очырачакларын аңлый иде. Тик кая барачак соң ул? Аның кемгә кирәге бар? Энесе әнә үз урынын тапты. Үзе яраткан хатынга өйләнеп, күрдәк хуҗалыгы корып, матур гына тормыш итеп ята. Ә Равил үзе һаман юлда. Юлы нинди диген әле! Бу турыда уйлаганда, аның йөрәге дөп-дөп тибә башлый. Бу шайтан оясыннан ничек котылырга, ничек? Ниһаять, ул Роберт белән катгый сөйләшеп, араны өзәргә дигән нәтиҗәгә килде. Ни булса, шул булыр!

Бу уйга аны көннәрнең берендә Тәскирә белән кәтмәгәндә очрашып сөйләшү этәрде. Ул көнне Тәскирә буш иде. Бу чибәр татар кызын күргән саен, Равилнең йөрәге әрни иде. Кызның ялгыз гына ял бүлмәсенә кереп киткәнен күргәч, Равил аның артыннан атлады.

— Равил абый, кирәкми, чыгыгыз, зинһар, — диде кыз. — Күрсәләр, миңа волчий билет. Сезгә дә рәхмәт әйтмәсләр. Сез дә бит «обслуживающий персонал».

— Минем бернинди начар уем юк, сеңлем. Син шундый чибәр, чын татар кызы. Буең-сының димме, йөзең димме. Килмәгән җирең юк. Мин сине тәүге күрүемдә үк ошаткан идем. Чибәр син, бик чибәр...

— Равил абый, зинһар, чыгыгыз инде. Кызганыгыз, күрсәләр, эш харап.

— Тәскирә, сеңлем, бернинди начар ниятем юк, дим ич. Шуны гына әйтәсем килә. Кит син моннан, чык бу юлдан. Әрәм булма! Әти-әниең белсә, кара кайгыга төшәр!

Тәскирәнең күзеннән чәчрәп яшьләр чыкты:

— Әти-әнием юк минем, абый. Ятимә мин. Әби-бабай карамагында үстем, беркемем дә юк.

— Алай икән... Ничек мондый юлга бастың соң, сеңел?

— Тормыш бастырды, Равил абый. Ятимә тормышы. Ә син, син үзең, Равил абый? Ярар, мин ятимә кыз бала, ә син? Безнең аерма шунда гына: син ир кеше. Үзең монда нишләп йөрисең? Ә? Тап-таза ир! Кунакларның кыланмышларыннан еш кына йөзеңә ачу чыкканны мин күрәм бит.

Үтерде Тәскирә, үтерде. Дөреслекне ярды да салды. Чыдасаң чыда, чыдамасаң, әнә агач ботагына бау эл дә... Тьфү, тьфү. Юк инде, Тәскирә сеңлем, мин барам да Робертка барын да ачып салам!

Роберт аны ачулы каршылады:

— Кайчан да бер кыякларга йөргәнеңне күптән аңладым. Ярар, китәрсең. Кисәтеп куям — телеңне тыя бел.

— Могила!

— Кафедан да китәсеңне аңлыйсыңдыр инде. Шулай да яңа кеше тапканчы анда йөреп тор. Исәп-хисапны аның белән бергә ясарсыз. Син бит матди җаваплы кеше.

Равил гаҗәпкә калды:

— Мине алганда, бернинди актлар төзеп тормадык ич. Миннән алдагы мөдир китте дә барды.

— «Китте дә барды!» Кудым мин аны, кудым! Кудым! Ә син үзең китәсең.

— Шулай булгач?

— Раз на раз не приходится. Акт, опись белән хуҗалыкны тапшырырсың да дүрт ягың кыйбла.

Бу сөйләшүдән соң ике атналап вакыт узып китте, яңа кеше һаман күренмәде. Равил хуҗага янә телләген исенә төшерде. Роберт караңгы чыраен ачмыйча гына:

— Син эшләгән арада йөзләп тарелка ватылган... Өч йөзләп кашык югалган. Бәясен түләргә туры килер, — диде.

— Мин ватмадым, мин урламадым ич аларны, — диде Равил. — Списать итеп булмыймыни?

Роберт шактый озак дәшми торгач:

— Син яна шартларда яшәвеңне һаман аңламыйсың икән, — дип өстәде. — Хәзер үзмилек хөкем сөрә.

***

Кафе хезмәткәрләре белән җыелышып тиешле акчаны бухгалтериягә кертеп биргәч, Равил янә Роберт ишеген какты. Хуҗа тагын бер-ике атна көтәргә кушты. Шулай ай ярымнар вакыт узгач кына Роберт Равилне чакыртып алды да кафенең яңа мөдире белән таныштырды.

— Менә Михаил Сергеевич, бөтен тапшыру-кабул итү эшләрен җиренә житкереп эшләп бетерегез. Шуннан соң, Равил, китә аласың. Без монда фикер алыштык, сине тоткарларлык сәбәп күренми, диделәр. Ярар, барыгыз.

Михаил Сергеевич дигәннәре артык вак кеше булып чыкты, алыш-бирешне ике атнага сузды, һәрнәрсәне энәсеннән җебенә хәтле тикшереп бетергәч кенә обходной актка кул куярга мөмкинлек туды. Равил Роберттан кунак йортында калган вак-төяк әйберләрен алып кайтырга рөхсәт сорады. Роберт бар инде, бар, Тосяң белән хушлашып кайт, дип көлемсерәде. Аннары:

— Синең, Равил, үзенә хәтле эшләгән мөдирне очратканың булдымы? — дип сорады.

— Бер мәртәбә урамда очраткан идем. Артык сөйләшеп тормады, кулын селтәп, аксый-туксый тиз генә китү ягын карады.

— Алайса акыл кергән икән үзенә, — дип Роберт канәгатьләнеп калды.

Аннары урынлы-урынсыз тагын өстәп куйды. — Онытма, Равил. Авызың йозакта булсын.

Равилнең вак-төяк әйберләр салган сумкасын тикшергәннән соң, «сумала капкан егетләр» дәшми-нитми аны кунак йорты капкасыннан чыгарып җибәрделәр. Көтеп торган машина янына килеп житкәндә:

— Равил абый! Равил абый! — дип кычкырган тавышка борылып караса, үзенә таба йөгереп килгән Тәскирәне күреп алды. Кыз килеп тә житте, муенына да сарылды.

— Китәсеңмени, Равил абый?

— Китәм, китәм, сеңлем.

— Ә мин?! Мин нишлим? Ә?

Равил аптырап, ни әйтергә белми торды.

— Равил абый, алып кит син мине! Зинһар, алып кит! Мин сиңа гомеремә турылыклы хатын булырмын!

Тәскирәнең күз буяуларын юып аккан ачы яшьләре Равилнең йөрәген тетрәндерде. Ул кызны биленнән кочаклап алды:

— Алайса, әйдә, сеңлем, алла күз күрер.

***

Эш белән Казанга килгәч, Рифат абыйсының фатирына сугылды. Соңгы вакытларда эше күп булды, абыйсын да күптән күргәне юк иде инде. Подъезд ишегендәге кнопкаларга басарга гына торганда, ишек ачылып китте, аннан чыккан алтмыш-алтмыш биш яшьләрдәге хатын-кыз Рифатка чүт кенә килеп бәрелмәде:

— Гафу итегез, куркыттым бугай, — диде Рифат. — Равил Әкбәров шушы подъездда яши бит, әйеме? — Рифат хатынны тизрәк тынычландырырга теләде.

— Сез аның кеме буласыз? Күзгә-башка күренгән кеше түгелсез? — Хатынның уяулык күрсәтүе иде бугай.

— Энесе булам, энесе. Шикләнмәгез, — диде Рифат.

— Шикләнерсең шул, — дип хатын Рифатны баштанаяк күздән кичерде. — Телевизор ачсаң, туктаусыз сак, сизгер булыгыз, шикле кешеләрдән, шикле әйберләрдән сакланыгыз, дип тәкрарлап кына торалар. Транспортка утырсаң, тагын шул хәл.

— Сез хаклы, ханым, хаклы. Уяулык хәзер бик кирәк. — Рифат хатын сүзен җөпләде. — Өйдә микән, юк микән? Абыйны әйтәм.

— Өйдәдер, бу арада гел өйдә күренә. Өйләнергә дә йөри бугай әле.

Рифат ничек алай, каян беләсез, кайчан дип берьюлы әллә ничә сорау бирергә авызын ачкан иде дә моның урынсыз икәнен чамалап өлгерде. Чыннан да, күрше хатын аларга ничек җавап бирсен инде. Звонок төймәсенә басуга, эчтән Равилнең:

— Кем бар? — дигән тавышы ишетелде.

— Абый, мин бу, мин, Рифат. Ач әле.

— Һай, энекәш, син икәнсең! Кер, кер әйдә! — Равил ихлас шатланды. — Үзем дә сагынып тора идем. — Аннары бүлмә ягына борылды:

— Тәскирә, күрен әле, күрен. Энем белән таныштырыйм әле.

Ишектә өстенә озын матур бизәкле халат кигән, башына ап-ак яулык бәйләгән урта буйлы, күзгә бәрелеп торган чибәр йөзле, зифа гәүдәле кыз пәйда булды.

— Менә Тәскирә була бу. Роберт Зарипов хуҗалыгында бергә хезмәт иттек. Зияле буендагы кунак йортында. Ә бу энем Рифат, таныш булыгыз.

— Исәнмесез, Рифат абый. Хуш киләсез, әйдә узыгыз, уз. Гафу итегез, кулым камырлы. Равил абый, әйдә, кунакны залга чакыр. Мин пәрәмәчләрне пешереп бетерим дә чәй эчәрбез, — дип, Тәскирә янә кухняга юнәлде.

Кыз Равил абый дигәч, Рифатка сораулы караш ташлап алды. «Өйләнергә йөри... Равил абый...» Энесенең карашын тотып алган Равил:

— Менә шулай... Аңлатырмын. Әлегә үзем дә белеп бетермим, — дип куйды.

Рифатның тәҗрибәле күзе һәркайдагы чисталыкка, пөхтәлеккә игътибар итте. Хатын-кызның кулы тимәсә, почмакларга пәрәвез куна, плинтусларга тузан катламы җыелып ята. Ә монда барысы пөхтә, сөртелгән, ялт итеп тора. Рәшидә кебек Тәскирә дә уңган икән, дип уйлап куйды Рифат. Кызарып пешкән сусыл пәрәмәчләр янына катык куеп сыйлагач, аның йөзендә елмаю киңәйгәннән киңәйде. Кыз күрмәгән арада ул абыйсына баш бармагын күрсәтеп, хуплавын белдереп алды. Равилнең иңбашларын сикертеп куюын гына аңламады.

Тәскирә ирләрне сыйлаганнан соң кинәт кенә:

— Рифат абый, сез барыбер безнең мөнәсәбәтләрне Равил абыйдан сораячаксыз. Әйтегез әле үзенә, ун еллык яшь аермасы әлләни зур түгел ләбаса. Шулай бит? — диде. Аннары Равилгә борылды. — Равил абый, син энеңә

яшермичә барын да сөйләп бир. Мин чыкмыйм, икәвегезгә генә сөйләшергә унайрак булыр.

— Ах, син акыл иясе, — дип көлде Рифат. — Алайса, әйт әле, үзең ун яшь зур аерма түгел дисең. Үзең һаман Равил абый да, Равил абый?

— Шулай ияләшенгән инде.

— Ә мин ихтирамнан дип торам.

— Анысын ул үзе белә. Кыз бала үз язмышын ихлас күңелдән ихтирам итмәгән ир заты белән бәйли алмый дип беләм мин.

— Ун-унике еллык яшь арасы һич тә киртә түгел. Хәзер картаеп беткәннәр дә яшьләргә өйләнә, кияүгә чыга. Бу мәсьәләне үзегез хәл итәрсез дип уйлыйм. Ә мин сезгә исәнлек-саулык, бәхет телим.

— Ә бәхет нәрсә соң ул, Рифат абый?

Рифат кызның матур йөзенә шактый озак карап торды. Шагыйрь Мөхәммәт Садри бәхетне сөекле ярың булу дип анлата. Икенче бер шагыйрь, бәхет ул күп канатлы, шуның берсе — тәүфыйк, ди. Бу тирән фәлсәфи сорауга һәркемнең үз җавабы бардыр, күрәсең. Рифатның да бар, тик әлегә тикле беркемгә дә әйткәне юк иде.

— Бәхет ул, минемчә, бәхетсезлекләр булмау. Якыннарыңның берәрсе авырып китсә, бу — бәхетсезлек. Эшсезлек — бәхетсезлек. Мохтаҗлык — бәхетсезлек. Эчүчелек тә шулай ук. Менә шундый хәлләр җаныңны әрнетеп тормаса, шул инде ул бәхет. Анлата алдыммы, Тәскирә?

— Ә ятимлек?

— И-и, аннан да авыр бәхетсезлек юктыр инде.

Тәскирә бераз башын иеп торгач, нәтиҗә ясап куйды:

— Халык, бәхет ул җан тынычлыгы, дип юкка гына әйтмидер шул.

Сүзгә Равил кушылды:

— Безнең җан тынычлыгы чамалы гына әлегә. Мин кафедан киттем бит. Менә эш табу мәсьәләсе килеп басты.

Озатырга чыккач, Равил энесенә эчен бушатты.

— Тәскирәнең сиңа карап торуларына, йөзендә нурлар уйнавына игътибар иттем, ул сине ярата дип уйлыйм мин, абый, — диде Рифат. — Кешенең күз карашы бик күп нәрсә турында сөйли. Тәнзиләң түгел бу кыз, юк.

— Авызың бер пешсә, салкын суны да өреп кабасың, энем. Ялгызлык та бәйрәм түгел...

— Бәхетне дә җан тынычлыгына бәйләде. Җаны җылыга сусаган аның. Үзе бик унган да күренә.

— Дөрес. Минем буйдак тормышымны гөл иттерде.

— Ятимлек дип бая юкка гына әйтмәгәндер. Кемнәре бар соң?

— Бабасы белән әбисен генә белә. Әтисен бөтенләй хәтерләми. Әнисе аны ике яшендә калдырып, Ташкент ягына китеп барган да шунда яшәп калган.

— Дөрестән дә, ул ятимә икән. Әйтәм йөзендә моңсулык чалымнары шәйләнә.

— Урта мәктәпне алтын медальгә бетергәч, Казанга килгән, тик медицина институтына керә алмаган.

— Татар мәктәбен бетергән авыл баласына кая инде ул рус телендә дәүләт имтиханы бирү. Ә ятим балага түләүле уку турында уйларга да юк.

— Шулай шул. Ятим булмаса да, сиксәнешәр-йөзәр мең сум акча авыл кешесенә каян килсен, абый.

— Эш эзли торгач, «Арена» дигән төнге клубта савыт-саба юучы булып эшли башлаган. Андагы стриптиз кызларының берсе бик матур җырлый иде, ди. Аңа кушылып җырлый башладым, ди. Тәскирәнең тавышы бик матур.

— Шуннан күреп алганнардыр инде алайса.

— «Олы юлның тузаны» дигән җырны теге Роберт Зарипов бик ошаткан икән. Тәскирәне массажистлар курсына урнаштырган.

— Аңлашылды. Шуннан ул аны Зияледәге кунак йортына йөртә башлаган, димәк.

— Әйе, Робертның тозагы нык аның. Яхшы түләгән. Роберт ярдәмчел зат ул. Тик аның ярдәме кыйммәткә төшә. Үзем дә татыдым. — Равил тирән итеп көрсенеп куйды. — Әлегә бер массаж салонында эшләп йөри.

— Абый, без болай итик әле. Әйдәгез, безгә кайтып бераз ял итегез. Без дә Тәскирә белән якынрак танышырбыз. Безнең тормышны күреп китәрсез. Миңа да киңәш кирәк. Без авыллы-шәһәрле яшибез, үзең беләсең. Сезнең эш турында да уйлашырбыз. Мин квартирага барып аласы әйберләрне алыйм да янә сезгә кагылырмын.

Тәскирә бу тәкъдимгә балаларча сөенде. Аның тиз-тиз генә җыена башлавын күргәч, Равил:

— Ашыкма әле, сенел. Рифат әле квартираларына барып килəм, диде.

— Мин дә кибеткә чыгып керим. Кунакка буш кул белән бармыйлар.

— Молодец!

— Әйдә алайса, мин дә синең белән барам.

***

Равилләр авылда өч атналап кунак булдылар. Рәшидә белән Тәскирә сөйләшеп туймадылар. Кунак кызына бакчадагы чәчәклек аерата ошады. Хуҗабикәгә ул һәр эштә булышып йөрде, бернәрсәдән дә тартынып тормады, идәнен дә юды, керен дә уды, бакча эшендә дә калышмады. Күрше Нәкыя күзәтеп йөргән икән кунак кызының уңганлыгын, пөхтәлеген бик ошатып, ут икән бу кыз, ут икән, дип мактап чыгып китте.

Вакыт-вакыт Тәскирәнең ялгызы гына монсуланып утырганын күреп, Рәшидә, бер мәлне:

— Алла бирсә, тиздән сезнең дә тормыш рәтләнеп китәр. Бергә-бергә рәхәтләнеп яшәрбез, килендәш, — диде.

— Килендәш түгел шул, Рәшидә апа, — диде Тәскирә.

Тегесе аптырый калды:

— Ничек инде?

— Белмим. Равил абый суза да суза. Без бит өйләнешмәгән.

...Бу хакта Равил белән алар арасында сүз булган иде инде. Равил кулындагы китабыннан аерылып, карашын бер ноктага төбәп уйланып утырган Тәскирә янына килде дә кулын иңенә салды.

— Сеңелкәй, ник тагын моңаеп утырасың? — диде.

Тәскирә борылмыйча гына аңа сыенды:

— Әби белән бабай һаман күз алдымда. Төшемә дә борчылып керәләр. Аларны бик сагынам. Ялгызлык бәласе инде.

— Ә мин? Мин?

— Синме? Син дә һаман читләшәсең. Мин кем монда?

— Тәскирәкәй, ничек кенә аңлатыйм икән, кадерлем... Йөрәктәге яралардан һаман кан саркып тора бит. Үземнең генә түгел, синең дә ялгызлыгыңны теләмим мин. Кабат-кабат...

Тәскирәнең без бит язылышмаган да, дигән сүзе Рәшидәне аптырашта калдырды. Бергә яшә дә аерым йокла. Ничек була соң инде бу? Рәшидә чыдамады, җаен туры китереп, Равилгә сүз катты:

— Равил абый, син нишләп безнең тормышка борын тыгасың дип ачуланма

әле. Тәскирә менә дигән татар кызы. Күңеле саф, уңган-булган. Теге таш курчак түгел. Бөтен күңеле белән сиңа тартыла. Еш кына шундый монсулана ки, балам кебек башыннан сыйпыйсым килә.

Күрә Равил, күрә. Аның да күкрәгендә таш түгел ләбаса, кайнар йөрәк. Аның да күңелендә әллә кайчан Тәскирәгә җылы хисләр уянды. Тик әле кайчан гына бөтен тормышын көл иткән янгынны ничек онытасың? Хикмәт аның үзендә түгел, Тәскирәдә бит. Ул ялгышмыймы икән? Яшь бит әле. Тора-бара Равил башыннан үткәннәрне телгә ала башласа... Равил үзе дә күптән инде барын да уртага салып сөйләшергә йөри дә, тик кинәт кенә бары да өзелеп китсә нишләр? Рәшидә әйткәч, сөйләшми дә булмый. Ниһаять, Равил кызга барча уйларын ачып салырга җөрьәт итте.

— Мин синең җаның кыйналганын күрми дип уйлама, сенел, — диде ул. — Минеке артыграк та кыйнала. Кешенең үткәне койрык шикелле гомере буена артыннан ияреп йөри. Беләсең ич, мин өйләнгән идем. Яратып өйләндем дип уйлый идем. Чынында матурлыкка сокланып, ихлас ялгышканмын икән. Хатыным бик чибәр иде. Курчак кебек. Ә эчтән... Тормыш арбасын да бер максатка тарттык дип ышана идем, алай булмаган икән шул. Икебезгә ике кыйбла булып чыкты. Салкынайганнан салкынайдык. Аннан инде бүтән хаталарга да ерак калмады...

Тәскирә сүзне бүлдерде:

— Равил абый, мин барын да беләм. Син кафега урнашуга, хатын-кыз халкы әллә кайлардан төпченеп өлгерде. Читләшеп йөрүең нәрсәдән? Син мине уйнаш кызга санап йөрисең мәллә? Ялгышасың, Равил абый. Зиялегә барып йөргән кызлар арасында кем генә юк. Үзең дә беләсең. Күбесе бүләккә сатыла иде — норка тунга, алтынга, квартиралы булырга йөрүчеләр дә бар иде. Күрден, минем норка туным да, алтын-көмешем дә юк. Беркемнең кочагына кермәдем. Кунакларга массаж гына ясый идем. Роберт мине күпме көндерергә маташты, үгетләде, куркытып та карады... Бирешмәдем.

Равил кызны күкрәгенә кысты:

— Тәскирә, кадерлем. Син фәрештә бит, җаным. Беләсеңме шуны? Фәрештә. Син минем таш булып катып барган күңелемне кузгаттың, бозын эреттең... Тик..

— Нәрсә «тик»?

— Минем баштан узган хәлләр уртак тормышыбызда йөрәгеңне кимереп ятмасмы? Мине битәрләмәссеңме? Мин бит гел шуны уйлап йөрим. Ә син аны читләшү дип кабул иткәнсен.

— Мин сине йөрәк түремә ничек бар, шулай алдым, Равил абый. Калганы синнән тора.

— Бу минем өчен әйтеп бетермәслек шатлык, кадерлем. Алайса, без менә дигән гаилә корабыз, акыллым.

— Ярар, мин риза, Равил абый. Ә син мине ташламассыңмы?

Менә тагын Равилнең йөрәге упкынга төшеп киткәндәй булды. Әнә ниләр уйлап монсулана икән ятимә кыз. Ә ул, ир кеше, үз борчуларын алга куеп, якын кешесенең рухи халәтенә, күңеленә кадалып торган боз сөңгеләренә игътибарсыз йөргән. Табылган Алланың кашка тәкәсе. Нишләп без, ирләр, вакыт-вакыт шундый мәгънәсез булабыз икән?

— Тәскирә, җаным. Мин сине исән чагымда беркайчан да ташламам. — Равил күңеленнән ташыган сүзләрен тагын әйтергә теләгән иде, тик нык дулкынланудан сүзләре тамагына төер булып утырды.

— Рәхмәт, Равил абый. — Тәскирә кочакта эреде.

...Инде килешенгән булса да, алар тагын загска бара алмадылар. Тәскирә

эшеннән күзләре ничектер сүнеп, йөзе көксел төскә кереп, күңелсезләнеп кайтты. Равил аптырады:

— Тәскирә, акыллым, сина ни булды? — дип янына килеп утырды. — Моның берәр сәбәбе бардыр, әйт әле.

— Ни дип әйтергә дә белмим, Равил абый, — диде кыз.

— Һаман абый дисең. Җитәр инде. Мин сине үз итеп, яратып өлгердем. Киләчәгемне синсез күз алдына да китерә алмыйм. Язылышырга барабыз дип йөргәндә тагын күңелсезләнәсең.

Тәскирәнең башы салынып төште, ул сулкылдый ук башлады.

— Ник елыйсың? Әйт инде... Мин бит ихлас күңелемнән...

Тәскирә башын чайкап куйды:

— Юк, Равил абый... Без бергә була алмыйбыз.

Равил торып басты да арлы-бирле йөренде.

— Һич аңламыйм, Тәскирә. Шундый матур яшәп киткән идек. Аңлат әле, зинһар. Каян килде бу үзгәреш?

Тәскирә сулык-сулык килеп Равилгә борылды:

— Мин сезнең кибеткә кереп, элеккеге хатыныңны күреп чыктым.

— Ә-ә, менә нидә икән хикмәт?!. Ниләр сөйләде? Мине пычраткандыр инде?

— Ник мин аның белән сөйләшеп торыйм?! Сөйләшмәдем. Ул мине белми... Читтән генә карап тордым да чыгып киттем.

— Кәефең шуңа киттеме? Ярар, күрдең, ди.

— Ул шундый чибәр икән. Бик. Син аны оныта алмаячаксың. Сез янадан кавышачаксыз.

— Тәскирә, кадерлем. Безнең ара мәңгегә өзелгән. Күкрәк читлегендә пыскып яткан кисәү башлары гына калды. Аны чибәр, дисең. Әйе, чибәр. Ә син мең мәртәбә чибәррәк... Сәбәбе шул гынамы?

— Әйе.

Равил Тәскирәнең башыннан сыйпады:

— Әй, юләрем! Мин бит әллә ниләр уйлап өлгердем... Син минем иң якын кешем. Мин сине беркемгә дә бирмим. Туганнарым да сине ярата, якын итә. Эмир яныңнан да китми. Җә, киттекме загска?

Тәрәзәдән төшкән кояш нурыннан Тәскирәнең күзләре камашып китте.

— Әйдә!

***

Беркөнне иртән Равил:

— Ярар, энем, бик зур рәхмәт. Бик яхшы кунак иттегез, безгә инде китәргә вакыт, — диде. — Сезнең тормышка без бик шат. Хәтерлисеңме, теге чакта син авыл, авыл дип авыз суыңны корыткач, мин ул якка карама инде, дигән идем..

— Хәтерләмичә...

— Ялгышканмын мин. Монда бөтенләй икенче вазгыять. Һаваны гына истә тотып әйтүем түгел. Авыл әхлакый яктан да күпкә өстен. Тик монда да наркота, эчүчелек канат җәеп килә. Теге көнне кызмача килгән егетне кисәтеп бик дөрес иттең.

— Шәһәргә якын булу бер яктан әйбәт. Икенче яктан, атна саен ялга кайтып, туган-тумачаларын хәмер белән сыйлап йөрүчеләр дә җитәрлек. Авыл хезмәте шәһәрнеке кебек түбә астында гына түгел бит. Ярар, син ниндирәк эшкә урнашырга телисең соң?

— Мин хәзер укытучы була алмыйм инде. Тәскирәне дә юньлерәк эшкә урнаштырасы бар әле.

— Унган кыз икән ул, абый. Бәхетле генә яши күрегез инде. Арагызны законлаштыруыгызга мин бик шат. Югыйсә, гражданский брак дигән нәрсә гаилә, булачак балалар алдында җавапсызлык дигән сүз бит ул.

— Сузылды шул. Тәнзилә белән булган хәлләр искә төшә дә сискәнеп китәм. Шуны ачыкладым әле: ул бит миңа беркайчан да яратам димәгән икән. Нәрсә карап йөргәнмендер мин.

— Ярар, абый. Башыңны катырма. Үкенүдән ни файда? Узган эшкә салават, ди әти. Кара әле, абый. Сиңа бер сүз әйтим әле. Әйдә, сез дә монда кайтыгыз. Бергәләп яшик. Теләсәң, әнә кибет ачып җибәр. Тәҗрибәң бар.

— О, юк. Сәүдә дигән нәрсәдән гарык мин. Әти дә аны өнәмәде. Эш түгел ул, ди.

— Син аны аңламагансың, абый. Ул бит бөтән нәрсәне истә тота. Сату-алу дигәндә, арзанракка алып кыйммәтрәккә сатуны яратмый. Ә без үзебез житештергәнне сатарбыз, дим. Әти әйтмешли, үз күкрәк көчебез белән. Бу бит икенче нәрсә... Башлаган эшне бергәләп киңәйтик.

— Дөрес. Бу инде төптән уйлаганда, элеккечә әйтсәк, спекуляция түгел. Син кибет, дисең. Ә аны нәрсә хисабына төзергә соң?

— Фатирларны сатарга була. Монда йорт җиткерергә дә рәхәтләнеп яшәргә. Шәһәргә дә бик якын.

— Ә Тәскирә нишләр?

— Кибеттә эшләр. Кечкенә генә булса да кошчылык фабрикасы төзесәк. Инкубатор тагын. Эш муеннан булачак.

Равил тирән уйга калды. Ир уртасы кешегә каңгырап йөрү килешми инде, килешми. Төпләнеп, киләчәгенә нигез салырга кирәк. Кыргый капитализм элекке, совет чорындагы социаль тәэминат түгел шул. Сине кайгыртучы юк.

— Син, Рифат, күңелне кузгаттың бит әле, энекәш. Без Тәскирә белән уйлашыйк әле. Үзең дә Рәшидә белән киңәш. Ул ни діяр? Беркөн теге күрше авылдан килгән ир кеше тире, йон җыю кебек эшләр белән шөгыльләнүче юк хәзер, дигәч, үземнең дә башыма бер уй килгән иде. Менә дигән, табышлы бизнес бит бу. Үзеңә дә, кешегә дә файда.

— Менә бит. Сиңа тагын бер фикеремне әйтим әле, абый. Минем янга шушы авылдан Гайфетдин атлы олы яштәге бер ир килгән иде. Ул үзенең җир паен арендага бирмәгән икән. Тенкәмне корытып бетерсәләр дә бирмәдем, ди.

— Җире белән нишләмәк була икән соң ул?

— Миңа тәкъдим итте. Ал, сатам, ди. Күрәм, син җитди егет, сиңа эшеңне киңәйтергә әйбәт булыр, ди. Җитди кешеләрне мин ерактан ук сизәм, үзем элек колхоз рәисе булып эшләгән идем, ди.

— Соң? Ул җир белән нишлисең?

— Зуррак инкубатор төзим дисәң, җиләк-җимеш, яшелчә үстерим дисәң, җир аз булмый.

— Һе! Пае кыр уртасында булса?

— Әнә теге калкулыкны күрәсеңме?

— Җә?

— Шуның артында икән. Яхшы урыннан, авылга якын җирдән алып калган. Ут, су кертергә дә якын. Трассадан да ерак түгел. Суга артезиан коесы казысаң да була.

— Шәп бит бу! Пае зурмы?

— Биш гектар.

— О-о! Күп ич ул. Кыйммәт сорыймы?

— Килешербез, законлы эшләрбез, ди.

— Анысы дөрес. Барыбер күп. Кош-корт асрыйм дисәң, ул тикле җирнең кирәге юк, дип уйлыйм.

— Әй, абый. Йортлар салып куярбыз. Кирәк икән, экологик чиста икмәк игәрбез, җиләк-җимеш, яшелчә үстерербез.

— Әй, хыялый! Монда ничек өлгермәкче буласың?

— Авылда эшче куллар җитәрлек. Әнә хәзердән үк эш сорап киләләр. Авыл халкы җилнең кая искәнен бик тиз сизә.

— Җил дигәннән... Кошчылык фермаларын торак урыннардан читтә салалар бит, Рифат. Монда да шулай тиештер бит инде.

— Абый, син дөрес әйтәсең. Безнең ферманың исе авылга килмәячәк. Бердән калкулык артында, икенчедән, Роза ветров дигән нәрсә бар бит әле. Җил бу якта авылга таба бик сирәк исә, диләр.

— Димәк, экология комиссиясе каршы килмәс дисең инде? Ә җирле кенәзләр ни дияр икән?

— Каршы тормаслар, дип уйлыйм. Без яңа эш урыннары булдырабыз ич. Җирле салымнар да алар кассасына керәчәк. Файда гына ич бу.

— Молодец! Төптән уйлаганың күренеп тора. Тик мәсьәлә акчага килеп терәлә.

— Бизнес-план төзеп, кредит алырга була. Икенче юл — вакытлыча квартираларыбызны сату. Аннары сузмый-тартмый эшкә керешү. Эшне җайга салсаң, җәен-кышын керем килеп тора. Күрдәкләр кышын да үрчи икән.

— Тел белән тегермән корып булмаганы мәгълүм. Шулай да бүгенге сөйләшүнең зыяны юк.

— Мин монда караштыргалап йөрим... Толковый егетләр бар. Кызыксындырсак, эшебезне күрсәтә алсак, барысы да яхшы булыр.

— Алла бирса, диген.

— Алла бирса.

— Ә оборудование? Махсус җиһаз?

— Республикада тавык, үрдәк фермалары эшләп тора ич. Тапканнар бит әнә. Без дә табарбыз. Без әле мондый эшкә яналык та кертә алачакбыз. Мин бер журналда Венгриядә каз үстерү тәҗрибәсе турында кызыклы материал укыдым. Анда каз йоны да шәп кенә табыш китерә. Ә бездә?.. Җайга салынмаган ул эш. Җайга саласы иде бит...

— Алайга китсә, кош-корт тизәген дә сатарга була. Ашлама ич ул.

— Менә күрдеңме? Җә, ничек?

Равил баш чүмечен кашып алды. Йөзеннән төрле уйлар чагылып узды. Уен түгел шул, тормышыңны өр-яңа юлга борып җибәрү бит бу.

— Киңәшик әле, энем, киңәшик. Белгечләр белән, юристлар белән. Киңәшле эш таркалмас, диләр бит.

— Анысы бик дөрес. Әмма шунысы бәхәссез: үз язмышыбызга үзебез хуҗа.

***

Беркөнне Рифатлар йортына туган авылларыннан бер егет килеп керде.

— Рифат абый, Галиябану әби сезгә Газыйм бабайның авырып китүен әйтергә дип җибәрде. Кайтсыннар, хәле шәптән түгел, дип әйтергә кушты.

Рифат белән Равил шунда ук юлга чыктылар. Рәшидәнең дә барасы килде, тик Рифат каршы төште, чөнки хатыны авырлы, соңгы айларын йөри иде. Газыйм бабай улларын күрүгә, торып утырмакчы булды, тик көче җитмәде. Уллары аның баш астындагы мендәрен кабарттылар, син ятып кына тор инде, өзлегә күрмә, диделәр.

— Өзеләсе өзелгән инде, улларым, — диде карт. — Ярый әле кайтып өлгердегез. Мин әниегез янына җыенам инде. Яшәвен яшәдек, кеше көлдермәдек. — Бабай

Равилгә карап куйды. — Ярар, бәхилләшик... Бер-берегезне ташламагыз. Бәхил булыгыз... Ахирәт барын да онытмагыз. Монда сатарлык әллә нинди җиһаз жук. Йорт дигәнебез болай жарыйсы гына әле. Сатарсыз... акчасын бүлешерсез. Догадан калдырмагыз. Галиябануны да онытмагыз, рәхмәт аңарга. Тәрбия кылды. Лә иләһе иллә аллааһы, Мөхәммәд Рәсулулла...

Газыйм бабай тагын нидер әйтергә теләгән иде, тик хәлсезлектән башы янә мендәргә салынып төште, аннары ияген җинелчә генә кагып китеп тә барды.

Картны соңгы юлга бөтен авыл халкы җыелып, хөрмәт белән озатты. Мәрхүмнең кырыгын уздырып, берничә көн үтүгә, Рәшидә кыз бала тапты. Тапты дию дөрес микән? Табиблар бу яшьтә бала китерү бик авыр эш дип, аңа кесарево ясарга тәкъдим иттеләр, ә ул, әлбәттә, риза иде. Дүрт килолы нәни кыз дөньяга шаулап елап килеп керде, тәмләп имде, чем-кара күзләре белән шатлыктан дөньясын оныткан әнисенә, түбәсе күккә тигән әтисенә карап елмайгандай итте. Бермәлне аның биләвен таратып, астын алыштырганда, әнисе янына Эмир килеп басты да аптырап калды:

— Әни, аның аяклары кайда соң?

— Әй, абыем, абыем! Менә ич минем аякларым. Әллә күрмисеңме? — Рәшидә кызының аякларын суздырып куйды. — Үсәм, үсәм әле мин, абый, менә шулай үсәм. — Тәнен сыпырганда сабыйның кытыгы килдеме, матур итеп елмаеп, тыпырчынып, үзенчә ыгы-ыгы килде.

— Әни, нәрсә ди ул?

— Әй, абый, абый, ди. Минем аякларым синекеннән дә озынрак, төзрәк булачак әле. Менә күрерсең, ди ич.

...Нәни кызга исемне Рифат белән Рәшидә бик озак сайлады, ә табуын Эмир тапты:

— Ә мин аны әллә кайчан таптым инде, — диде ул.

— Ә ник безгә әйтмисең? Әйт инде.

— Динә ич ул.

Әкбәровлар көндәлек эшләре хакында сөйләшеп утырганда, аларга Гайфетдин абзый килеп керде. Ике куллап күреште, дога кылды. Аннары:

— Сез әле чәйләп утырырга да вакыт табасыз икән. Мин әллә болар ашамый-эчми җөгереп кенә җөриләрме икән, дип уйлыйием, — диде.

— Син үзең дә әле тегендә, әле монда чабасың. Егетләрмени. Гайфетдин абзый тик тора белми ул, дигәннәр иде. Дөрес икән, — диде Рифат.

— Чапкан чаклар бар иде ул, энем, бар иде. Тик җыллар үзенекен итә шул. Олыгайгач, сәламәтлек чыгымлый. Күңелдән дә тынычлык качты. Менә әйтегез әле, нишләп безне бүгенге көн белән яшәргә өйрәтәләр, ә? Кем белән сөйләшмә, иртәгесен бер Алла гына белә, дип зарлана. Карангыдан карангыга тикле эшләгән авыл халкы ник мантый алмый? Аны нәрсә көтә? Оптимизация дигән нәрсә уйлап таптылар. Мәктәпләрне, сәламәтлек саклау пунктларын ябып куялар.

— Тормышның житешсез яклары күп инде анын, күп, Гайфетдин абзый.

— Унай жаклары да әз түгел, Равил. Анысын да күрәбез. Әмма сукыр бозау түгел бит без, әле монда, әле тегендә төртелергә. Тәгълиматын аласыңмы, сәясәтенме, икътисадынмы... янә президент телевизордан коррупциянең тамырын корытабыз, дип тора, ә ул котыра гына бара. Кичә минекеләр Казанга барып кайтты. Киленгә операция ясарга кирәк, дигәннәр. Беләсезме күпмегә төшә ди — ике йөз меңгә! Кая карама, шул хәл бит. Бер яктан — ал да гөл, икенче яктан — хәл гел мөшкел.

— Кирәк икән, без дә ярдәм итәрбез, Гайфетдин абзый.

— Рәхмәт яхшы сүзеңә, Рифат. Сез дә бөтен халыкка ярдәм итеп бетерә

алмассыз. Кара инде, еге-мege дип, балаларның котын алып, имтиханга сак астында йөртә башладылар. Тьфү, валлаһи. Кая карама таркаулык... Чәчелми калган жир өчен йөрәк әрни.

— Элек тә булган инде ул, абзый. Үзең беләсең.

— Бар иде, энем. Бөтен эш өчен бер партия җаваплы иде. Тәртип ие. Хәзер әнә хакимияттә генә дә өчәү алар, ә тулкы юк. Әйткәч әйтим инде. Элек эшчеләр, крестьяннар сыйныфы бар ие. Ә хәзер алар юк, урта сыйныф кына, диләр. Ә кемнәр соң ул? Каян килде? Ә тегеләре җиргә убылдымы? Капиталистлар, алпавытлар туды дияргә батырлыклары җитми.

— Син дөрес әйтәсең, Гайфетдин абзый. Әнә бит суверен демократия дигән нәрсә уйлап таптылар. Ә үзләре аның ни икәнен дә белми.

— Менә дөрес, энем. Демократия дигәч, халык мәнфәгатен кайгыртырга кирәк ләбаса. — Гайфетдин абзый тирән итеп сулыш алды да ник килүенең сәбәбен аңлата башлады. — Күрәм, күрәбез, сез эшлекле кешеләр булып чыктыгыз. Авыл халкы бәяне бик төгәл бирә. Һәммәсе сезне булдыклы, ди, үз итә. Ни арада фабрика салып, ничәмә ничә кешене эшле иттегез. Нинди матур, зур коттеджлар салып кердегез. Кибетегез бик уңайлы булды.

— Йә инде, Гайфетдин абзый, безне артык узындырма инде.

— Узындырмыйм, Равил, булганын сөйлим. Яңа мәчет салырга биргән акчагыз да бик ярап куйды. Рәхмәт. Көзгә салып бетерәбез, Алла бирса... Их, яшьрәк чагым булса! Өчәүләп дөбердәтер иек дөньясын... Менә нәрсә, жегетләр. Авыл халкы белән киңәштек тә без, Рифат, сине Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат итәргә булдык. Тиздән сайлау җитә бит. Бер мандатлы округтан дип торабыз.

— Бик зурдан купкансыз, абзый. Ул бик җаваплы эш бит. Зур хәзерлек сорый торган эш.

— А как же! Сорый! Хәзерлән, энем, хәзерлән. Кулыгыздан эш килә. Иң мөһиме шул. Анда да әллә кемнәр утырмый, сезнең ише кешеләр ич. Давай, риза бул. Баш тартма, халык сорый.

***

Беркөнне Рифат мунча керергә хәзерләнеп йөргәндә, капкадагы кыңгырау яңгырады. Кунак Галиябану әбинең кияве иде.

— О, Ильяс, исәнме? Син икәнсең әле. Кем булыр бу дип тора идем, — диде Рифат. — Ә Рузалия кайда? Әллә үзең генәме?

— Сәлам. Үзем генә... Ну, коттеджларны салгансыз. Шәп, шәп. Бусының алгы ягында гына да егерме тәрәзә санадым. Акчаны хәйран суыргандыр инде. Расхудын, әйтәм. — Ильяс чыннан да сокланган иде.

— Булды инде. Хәзер бөтен нәрсә көннән-көн кыйммәтләнә бара. Шөкер, көчебез житте. Үзебез канәгать. Бездән соң балаларга калыр дип тә тырыштык.

— Без дә шул бала, бала дип яшибез инде.

— Әйдә, Ильяс, өйгә керик. Чәй эчик. Аяк өсте сөйләшеп тору килешми.

— Керербез лә. Минем сезгә йомыш та бар әле.

— Нинди йомыш?

— Йомыш дип... Мин әбине алырга килдем. Үзе күренми, өйдәме соң?

— Әнә кайтып килә. Күрше урамдагылар ашка чакырганнар иде. Кулына тагын бер төргәк йон тоткан. Ярты авыл ул бәйләп биргән оекбашлар киеп йөри бугай инде. Ильяс, аңламадым, алырга килдем дисеңме? Ничек алай?

Галиябану әби ирләргә күтәрелеп карамыйча гына узып китәргә теләгән иде, Ильяс Рифатка күз кысып:

— Ай-һай, әби, үсенүең житте, безне хәзер танымый да башладың, — дип сүз катты. — Исән-сау гына йөрисенме?

— Әстәгъфирулла! Ильяс, син ич бу! Рифат чит кеше белән сөйләшеп тора, мин комачау итмим дигәнием. Безнең Рифат яныннан кеше бетеп тормый. — Карчык ирләрнең әле берсенә, әле икенчесенә карап алды. — Нишләп йөрисен, кияү? Бер-бер хәл булмагандыр ич.

— Булды да, булмады да.

— Жә, жә, әйт. Сузма.

— Теге шалопай һаман бимазалап кына тора. Рөстәмне әйтәм. Түләүле укуы гына житмәгән. Компьютер алдырган ие инде. Житмеш меңгә. Хәзер тегесе ватылды дип, яна, ноутбук дигән нәрсә күтәреп кайткан... Бурычка кереп. Кесә телефоны дигәннең тагын яңасы чыккан. Шуны сорап теңкәгә тия.

— Бер-береннән күрәләр инде алар.

— Әле өр-яңа джинсы чалбар алган гына идек. Мода дип, шуны игәүләп, өч-дүрт тишек тишкән. Һаман расход, расход.

— Әй, кияү. Узындырмагыз дип күпме әйттем ләбаса. Юк, «бала бит, бала».

— Бернәрсәгә кулы ятмый. Ялкаунын ялкавы.

— Үзеңә үпкәлә инде, Ильяс. Ир бала бит ул. Үз янында йөрт, кул астына керсен, эшкә өйрәт дип күпме инәлдем. Эш эшләсә, эштән баш тартмаса, әллә нинди тәртипсез кешене дә рәткә кертеп була. Юк икән — юк инде. Әнә Рифат Эмир улыбыз белән гел бергә. Аның белән киңәшә. Эш куша белә... Ярар, әле нишләп йөрисең соң?

— Сине алырга килдем. Әйдә, жыен.

— Мене сиңа мә! Тыныч кына яшәп ятканда. Нәрсәгә кирәк булдым?

— Рифатлар коттеджларын салып бетергәннәр ич инде. Бүтән расходлары юктыр.

— Аңламадым, кияү.

Рифат та кунакка сораулы караш ташлады:

— Ильяс, сезгә безнең расходларнын ни катнашы бар соң?

— Әй, әйтсәм әйтим инде. Әбинең пенсиясе безнең дә эчне тишмәс иде.

Галиябану әби аптыраашта калды:

— Әстәгъфирулла! Бу ни дигән сүз. Ник соң пенсия акчасын кирәгегезгә тотмыйсыз?

— Без аны ничек тотыйк инде. Монда кирәк булгач.

— Ильяс туган, син нидер бутыйсын. Безгә Галиябану апанын бер тиене дә кирәкми. Баштан ук шулай килештек ич, — диде Рифат.

Галиябану әби бу хәлгә төшенеп бетте бугай, киявенә шелтәле карап аңлатып бирде:

— Ильяс, минем пенсия акчам Казандагы саклык кассасына килеп тора. Рузалия белә ләбаса. Казанга барганда, мин вак-төяккә дип акча алырга теләсәм дә, Рифат үпкәли. Кирәк нәрсәнне миңа гына әйт, үзем алам, ди. Алланың рәхмәте яусын. Ә кассадан акчаны тотарга мин Рузалиягә, ничек диләр әле, ышаныч кәгазе диләрме, шуны язып калдырдым. Син белмисең дәмени?

— Юк. Әйткәне дә юк. Ник тотмый икән соң ул аны?

— Анысын инде үзеннән сора. Кыенсынадыр, күрәмсең. Гомер буе базымсыз булды инде ул. Тотыгыз, тот, рөхсәт. Син мине оятка калдырасын бит. Әйдә, кер, кара. Миңа картайган көнемдә рәхәттә яшәргә язган икән. Рифат белән Рәшидәгә рәхмәтләремне укып бетерә алмыйм. Китү дигәндә, юк, юк, мин моннан китмим.

Ильяс бик унайсызланды.

— Син түгел, мин монда оятка калдым әле, әби. Әллә ничек кенә килеп чыкты. Рифат, зинһар, үпкәләмәгез. Теге малай аптыратканга гаҗиз булып йөрим. Шуның өчен көчемнән килгәнне эшлим бит, олы юлга кеше таларга чыга алмыйм ич инде.

Рифат Ильяснын кулын кысты:

— Ярар, Ильяс. Аңлаштык. Мин ике сөйләргә яратмыйм. Үзе китәм димәсә, без Галиябану апаны беркая да җибәрмибез. Әниебез урынында ул безнең. Әйдәгез, тәмләп чәй эчеп алыйк. Мунча да өлгергәндер инде.

***

Беркөнне Равил Казаннан кайтып төшкәч, Тәскирәсен күреп гаҗәпкә калды. Яшь хатын туй күлмәген киеп, фата бәйләп, көзге каршында көязләнеп басып тора иде.

— Әллә минем хатын тагын кияүгә чыгарга җыена инде? — дип, Равил хәләл җефетен биленнән кочты.

Тәскирә иренең муенына сарылды:

— Равил абый, син минем бу күлмәгемне тәүге кат кигән көнне хәтерлисеңме? Ул көнне син миңа гүзәл алиһәм дигән идең.

Әй, хәтерләмиме соң Равил, ничек кенә хәтерли әле. Әйдә, матурым, җыен, язылышырга барырга сиңа никах күлмәге сатып алыйк, дигәч, Тәскирә балалардай шатланып биергә тотынды. Равил туй салонындагы кызлардан кәләшенә иң матур, гәүдәсенә иң ятышлы күлмәк сайлап бирүләрен үтенде. Тәскирә сөттәй ак, каурый болыттай җиңел күлмәк киеп чыккач, Равилнең тез буыннары йомшап китте. Аның сөйгәне, шагыйранә әйтсәк, фәрештәдәй гүзәл, ә дулкынланган, чиксез бәхет, шатлык ташып торган йөзе иртәнге шәфәкъ нурыдай балкый иде. Кайсы гына кыз бала менә шулай аккош сыман киенеп, сөйгәненең кочагына керергә хыялланмый икән! Менә ятимә Тәскирәнең дә күптәнге, аңа беркайчан да тормышка ашмас кебек тоелган хыялы чынбарлыкка әверелде.

— Син миңа ул көнне гүзәл алиһәм дигән идең. Минем гел шундый булып каласым килә. Без бу күлмәкне саклыйк әле. Шатлыклы көннәребездә мин аны киеп синең каршыңа килермен. Син ризамы, Равил абый? — диде Тәскирә.

— Мең кат риза, фәрештәм! Ул гомеребез буена безнең иң истәлекле көннәребезне хәтерләтеп торыр.

— Менә бүген нәкъ шундый көн... Минем бик зур шатлыгым бар бит, Равил абый.

— Нинди шатлык ул, әүлиям?

— Ничек дип әйтергә дә белмим инде... Сиңа шатлыктырмы ул, юкмы...

— Йә, йә, тыңлыйм, Тәскирә.

— Мин... Мин... буйга уздым бит, Равил абый.

Равил сөйгәненең яшьләнгән күзләрен, алсу битләрен үбәргә кереште:

— Шундый зур шатлыкны ник моңа тикле әйтми йөрдең, матурым? Бу бит... бу бит мин ничә еллар буена хыялланып йөргән бәхетле яңалык, сөеклем.

Тормышта шундый чаклар була, бар дөнья нурга күмелә, җаның җилкенә, очып кына йөрисең килә. Равил дә шундый халәттә иде. Ул хатынын күтәреп алды, җаным, бәгърем, бердәнберем дия-дия, аны назга күмеп бер урында әйләнә башлады. Мәхәббәт ләззәтеннән изрәгән шушы бәхетле мизгелдә йөрәге астында хәрәкәт сизеп, Тәскирә сискәнеп, әллә нишләп китте. Чиксез

дулкынланудан сулышы кабып, ул сүзләрен бүлә-бүлә, ире колагына кайнар пышылдады:

— Равил... тукта әле... бәгърем... тукта әле дим. Менә әле генә минем йөрәк түремдәге балабызга ... җан инде. Равил, бәгърем, аңа ... җан инде!

## ЭПИЛОГ

Хөрмәтле укучым!

Сүземнең ахырында бераз алгарак китеп, шуны әйтәсем килә: Равилнең дә, Тәскирәнең дә хыяллары тормышка ашты, үбеп-кочып, сөеп-яратып, күкләргә чөя-чөя үстерәсе килгән бала — алсу йөзле, чем-кара күзле, түгәрәк, йомры иякле уллары Марат инде тәпи йөри. Туганнан туган абыйсы Эмир икенче сыйныфта бик яхшы укый, Рифатка хәзер эти-абый дими, эти, ди. Сеңлесе Динә тыпыр-тыпыр йөгереп аның тирәсендә бөтерелә, укырга өйрәнә. Үскәч кем буласың дип сораганда, әни булам, ди.

Әкбәровларның уртак тырышлыклары бушка китмәде. Аларның авылдан ерак түгел җиләк-җимеш, яшелчә бакчасы матур булып күтәрелеп килә. Язларын бакча алма, чия, слива чәчәгенә күмелә. Ак, кызыл, кара карлыган, кара миләш, кура җиләге, крыжовник, виктория, помидор, кыяр мул уңыш бирә. Кибетләреннән күрдәк итен халык яратып ала.

Рифат хәзер Дәүләт Советы депутаты. Авылдашлары ышанычын аклап, халык мәнфәгатен кайгырта. Сезонына карап унбиш-егерме эш урыны булдырганга, җирле хакимият җитәкчеләре дә бик канәгать. Минем геройларым якыннары, дус-ишләре белән гөрләшеп, житеш тормыш эчендә кайнап, хезмәтләреннән тәм табып яшәп ята. Намазга баскан саен, аларга бәхет-сәгадәт, саулык-сәламәтлек, иминлек-муллык теләүче Галиябану әбигә кушылып без дә изге теләктә калыйк. Киләчәктә аларны катлаулы да, бер үк вакытта күңелле дә вакыйгалар тулы тормыш көтә. Бусы инде икенче кыйсса, русча әйтсәк, это уже другая история.

***Редакциядән:***

*Бу айда каләмдәшебез Әнәс Хәсәновка 80 яшь тула. Күпсанлы укучыларыбыз исеменнән язучыны ихластан котлыйбыз, аңа сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез!*



Лена
Шагыйрьҗан

# ТУГАН ТЕЛЕҢ УЛ БИТ – МОГҖИЗА

## Казан — безнең газиз башкалабыз

Сиңа атап шигырь чыгарабыз,
Сиңа атап җырлар башкарабыз.
Син бит үзебезнең Үзәк-бәгырь,
Мәңге яшә, Казан — башкалабыз!

Заманында иңләп-буйлап Илне,
Җирен, суын, һаваларын гизеп,
Кая гына барып чыкмый идек,
Тел вә җан-кардәшлек сулышын сизеп...

Рәсәй белән бергә тарих кичеп,
Гыйбрәт алдык бик күп нәрсәләрдән.
Таркалмаслык ныклык кирәк икән,
Таран белән китереп бәрсәләр дә...

Без яуладык хокук — Туган җирдә
Яшәтергә Туган телебезне!
Борынгылык мөһерен сукканчы ук
Дөнья таныган иде инде безне...

Казан — татарларның хәләл бишеге.
Күпләр өчен рухи мәктәп тә ул.
Казан безнең былбыл-сандугачлы
Моң бакчабыз, шигъри Мәккә дә ул!..

Без Казан дип шигырь чыгарабыз,
Без Казан дип җырлар башкарабыз.
Мәскәү, Питер — бөек пайтәхетләр,
Әмма
Казан безнең — милли башкалабыз,
Мәдәни һәм төрки башкалабыз!!

Лена ШАГЫЙРЬҖАН — *шагыйрә; «Шигырьләр, поэма», «Бożра вә Хөҗрә», «Кәрәз төбе каты бал...» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## «Шәһәр дулкынына» көйләнеп...

Кичә генә ямь-яшелдән иде,
Бүген инде ап-ак киемнән
Карап тора дөнья тәрәзәмә,
Чык дөньяга, диеп, өеңнән.

Чык урамга, монда мәңгелек җил
Исеп тора — үсәр күңелең...
Эш бетми ул — хәлең бар чагында
Син урамны әйлән иң элек...

...Авыл җире түгел түгелен дә...
Үз болдырың, капка төпләрең,
Ишегалдың булса, син соң өйдә
Утырыр идеңме соң бикләнеп?..

Җәй дә, кыш та, яз да, көз дә күптән
Минем «табигать»не өйрәнгән...
Минем тормыш инде ярты гасыр
«Шәһәр дулкыны»на көйләнгән...

Кайталмыйча калдым авылыма,
Иптәш-ярым янда булмагач.
Ялгыз башым кайтсам, «урман» көлер,
Каян күчкән, диеп, бу агач?

Берүземә анда көн итәргә
Килер иде тагы да кыенга...
Шуңа гына җаным минем монда
Фатир почмагына сыенган...

## Насыйп булмаган ярым

Кемне көттем икән соң мин?..
Һәрбер егетем артында
Ул тора иде басып...
Күзәтми дә, кисәтми дә,
Чакырмый да, эндәшми дә...
Аңладым инде соңыннан:
Шул булган икән минеке,
Шул булган икән хыялым,
Ярым — Түгелем насыйп...
Насыйп түгелем, җан ярым.
Бердәнберем — шул булган...
Шуңа күрә, сүзсез генә,
Хуҗа булырга омтылган
Һәр гашыйкны ул куган...
Күләгәме, шәүләме —
Хәзер инде шәйләмим...

Хәзер инде беркемнән дә
Җылыйсы да юк качып...
Югалды «Насыйп түгелем»,
Ул үзе нәрсә көткәндер —
Китмәде серен ачып...
Кисәтмәде, сүз әйтмәде,
Яратканын күрсәтмәде —
Шулай да ул бар иде...
Әмма ул нәрсә көткәндер,
Ник вакыт әрәм иткәндер —
Китмәде серен ачып...
Хыялым ярында һаман
Торадыр сыман басып,
Ярым — «Түгелем насыйп»...

# Әле соң түгел

**(«Соңгы» поэма)**

*...Кеше җырын зурлый торган*
*Чын йөрәк тибә бездә...*

Г.Садә

Җир йөзендә соңгы поэмасын
Язып утыра Шагыйрь...
Укырга
Табылырмы Кеше?! — Тәмамлагач,
Чыгып укыр аны ул кырга.

Ишетмичә калмас әле туфрак...
Һич югында, җилгә тынлатыр.
Ярсу йөрәккәен басар өчен,
Җилгә кушылып, курай чыңлатыр.

Кырда анысы кеше булмый калмас,
Ишетер ул Шагыйрь тавышын:
Сизми калмас аның сагыш катыш
Шатлык тулы йөрәк кагышын...

Бу поэма Сүз кадерен белгән,
Сүзнең тәмен тойган һәркемгә
Хәтерләтер арыш ипиенең
Изге тәмен — пешкән һәр көнгә...

Әйе, бәйрәмгә дип түгел, һәр көн
Ашар өчен пешкән икмәкнең...
Ипи-тоз кук кирәклеген хуплар
Кешеләргә шигъри хикмәтнең.

Колак салыр кырда эшләүчебез.
Ул — игенче, белә тир тәмен...
Ни хакында язылса да аңлар,
Җырга салса Шагыйрь җир ямен...

...Хикмәт нидә? Ни өчен соң әле
«Соңгы» поэма дип ачындым?..
Шигырь укымыйлар ди бит хәзер (?!) —
Капиталның асылы ачылды!..

Нәрсә укый икән соң ул? Бәлки,
Хәреф танудан да бизәр ул.
«Коръән укый» диеп акланырлар...
(Әйе, шигъриятле, гүзәл ул!)

Шигырь укымаган надан бәндә
Коръән сүзен ләкин аңлармы?
Тормыш поэмасын сурәтләгән
Сүрә-аятьләрне санлармы?..

Музыка да, театр да, җыр да,
Киносы да, рәсем-сурәт тә —
Һәммәсе дә кирәк — биюе дә,
Сүз сәнгате — анысы бигрәк тә!

Сүз — авазлар гармониясе ул
Һәм аһәңе халык теленең.
Шул аһәңгә карап төсмерләнә
Холкы хәтта халкың, иленнең.

Ник соң җырлап кына сөйләшмиләр?
Ник соң биеп кенә йөрмиләр?
Курай, гармун, скрипка тагып
Көннәр буе «концерт» бирмиләр?

Аңлашалар сөйләм теле белән,
Остараклар сөйли шигырьләп:
Мәкаль, әйтем, тапкыр сүзләр өстәп,
Теле белән тарта «сихерләп»...

Сүз сәнгате — иң бөеге Җирдә,
Оныталар аның кадерен.
Арыш икмәгедәй — күнегелгән,
Һәрдаим ул кирәк — бәгырем...

Шигырь сөймәүчеләр үзләре үк
Сагыначак шигырь аһәңен.
Ник әдәбиятның кадере китте? —
Сәбәбе бар һәрбер бәһанең...

Халык теле — үзе шигырь бит ул,
Димәк, халык хакын хакла син!
Сөйләшмичә яшәп кара бер көн —
Андый хәлдән Ходай сакласын!

Ә үз телең — атаң-анаң теле,
Туган телең ул бит — могҗиза!
Бүтән бер телне дә белмәсәң дә,
Шуны белсә кеше — мең риза...

Барыбер аңлаячак аны дөнья:
Соң, ни әйтсен адәм баласы?! —
Тормыш сүзе — һәр көн кирәкле сүз,
Мантыйк белән генә барасы.

...Әмма телне төптән аңламасаң,
Шигырь тәмен белми каласың.
Шул затлы тәгамнән мәхрүм итмәк
Кайбер затлар адәм баласын...

Сүз сәнгатен камил белсәң — бәхет!
Аз шул «ипи-тозлык» кынасы...
Телгә нигезләнгән һәр милләтнең
Театры, җыры, киносы...

..........................................................................

Туры килде «Сонгы» поэманы
Бергәләшеп, җыелып укырга.
Тәмләп аш ашаган, чәй эчкән күк,
Кырык эшне куеп бер кырга...

Әфәнделәр! Булмый поэмасыз,
Яшәгәндәй йортсыз-түбәсез.
Ә Китап ул — Поэманың йорты,
Сез шул йортны читкә тибәсез!..

Кампитрдан шигырь уку — юк эш,
Житми китап тотып укуга.
Иң кадерле дустын тапкан сыман,
Ничек сыена, күрче, ул кулга!

Китап — ләззәт! Электрон «каплар»
Чыксын әйдә... Алар — саклагыч.
Дөнья исән-аман торган чакта
Китап тотып уку — соклангыч!..

Калын-калын, йөзәр-менәр томнар
Шырпы кабыннан да нәнирәк
Тартмачыкка сыеп бетсен әле! —
«Нәни технология!» — ни кирәк!

(«Нәни технология» дип йөртәм
Нанотехнологияне мин...)
Тукта, читкә киттем төп темамнан,
Онытып гүя шигырь гамен мин.
.........................................................

...Кырда шулай Шагыйрь игенчегә
Укыды да яңа язганын,
Күңеле тулып, жиргә чүгәләде,
Үбеп алды буразналарын...

Ә игенче арыш башакларын
Сыйпап куйды, күзе яшьләнеп...
Кеше жырын зурлап, нечкәрде дә
Тынды эчтән, артык дәшмәде.

* * *

...Зур вакыйга булды бүген Илдә:
Яңа шигъри әсәр тыңлады,
Башакларын чайкый-чайкый жилдә,
Киң күңелле иген кырлары...

«Кеше каны су түгел» дигәндәй,
Кеше жыры коры сүз түгел...
Чын йөрәктән мәхрүм калган затлар!
Кеше жанын тойган шагыйрьләргә,
Кеше хәлен белгән шаһ ирләргә
Бәя бирүчеләр сез түгел!
Уйланыгыз! Әле соң түгел!..

***Редакциядән:***

*Каләмдәшебез бу айда үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, озын гомер, иҗат уңышлары телибез.*



Шамил Хәнифов

# КЕШЕ БУЛЫП КАЛЫРГА

ӘДӘБИ-ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

*Ошбу автобиографик повестьның авторы Хәнифов Шамил Хәниф улы (1926-2012) — Бөек Ватан сугышы ветераны. Озак еллар Таҗикстанда яши. Аннан Түбән Камага күченеп кайта. Шунда вафат була. Ул, озак еллар яшәп, тормышның сикәлтәле һәм ифрат авыр сынауларын чын ирләргә хас түземлек белән кичергән, сынмаган-сыгылмаган, ә иң мөһиме — күңелендә кешелек сыйфатларының йомшаклык һәм олы җанлылык, тугрылык һәм дөреслек, чисталык һәм зыялылык кебек иң күркәм үрнәкләрен саклап калган шәхес. Аның гомере, бик күп ватандашларыныкы кебек үк, кемнәрнекенәдер охшаш һәм шул ук вакытта кабатланмас вакыйгалары, борылмалары, тирән психологик кичерешләре һәм кылган гамәлләре белән бары тик үзенә генә хас. Туган телен яхшы белсә дә, күп еллар читтә гомер итәргә туры килгәнлектән, язма әдәби телне алай ук камил белми ул, шуңа күрә аның истәлекләре рус телендә язылган. Мин аларны татарчага тәрҗемә итеп, укучылар хөкеменә тәкъдим итәргә булдым.*

**Фирдәвес ХУҖИН**

## Тамырлар

Мин — Шамил Хәнифов — 1926 елда Шөгер (хәзер Лениногорск) районының Кирлегәч авылында туганмын.

Безнең йорт авыл читендә, тауга каршы урнашкан, ә тау астында зур булмаган инеш ага. Инешкә зур ташлар астыннан бәреп чыккан салкын сулы чишмә коя. Ана авылдашлардан хөрмәт белән карамаган кеше юктыр, мөгаен. Чөнки монда су алалар, кер юалар, бер-берсе белән яңалык уртаклашалар, монда гашыйкларның очрашу урыны да. Кечкенә чагымда яшьләрнең кеше күз алдында очрашу мөмкинлеге булмау турында ишеткәнем бар иде. Әнә шуна да инде кызлар көянтә-чиләкләрен күтәреп суга бару сылтавы белән, ә егетләр атларын эчерергә дип чишмә янына күрешергә килгәннәр.

Хәтерләвемчә, безнең өй шактый зур иде. Ул чагында миңа шулай тоелган. Әмма сугыштан соң авылга әйләнеп кайткач, мин бередәге йортларның кечкенәлеген күрдем. Дөрес, алар арасында безнеке инде юк иде.

Йорт янәшәсендә иркен ишегалды, артта — сирень, алмагачлар үсә; түтәлләрдә — кыяр, кишер, суган; умарталар тирәсендә — терлекләр өчен көйләнгән урын, ә арырак — бәрәңге бакчасы. Нәзек бүрәнәләрдән келәт күтәрелгән һәм андагы аерым бүлекләрдә бодай, арыш, борчак, карабодай, солы һәм шулай ук он саклана. Иртә язда кар белән тутырып куела торган зур баз бар. Җәй көннәрендә анда сөт, каймак һәм май салынган чүлмәкләр саклана.

Баздагы кар акрынлап эресә дә, көзге салкыннарга кадәр житә иде. Без сыер, ике ат, ишле санда сарыклар, үгез яисә башмак тана, тавыклар, казлар һәм күркә асрый идек. Куяннар тотучы Алёша кушаматлы зур ау этебез бар иде.

Әнием сөйләве буенча, безнең тагын бер йортыбыз булган, тик янгын вакытында, ул юкка чыккан. Шуннан соң күп тә үтмичә эти үлеп киткән. Мин анын вафатыннан соң туганмын. Шунлыктан гомерем буе «әти» сүзен әйтергә тилмереп яшәдем.

Мин дөньяны бераз танып белә башлагач, әни үзен ничек кияүгә бирүләре турында сөйләде. Беренче тапкыр тормышка чыккач, ул ире белән алты ел яшәгән, балалары тумагач, иренең теләге буенча алар аерылышканнар. Икенче мәртәбә иргә чыгуын әнинең әти-әнисе, минем әби белән бабам (аларны мин, әтине күрә алмаган кебек, үзләре исән чагында күрмәдем) хәл иткән. Ул Кирлегәчтән, минем булачак әтием — Хәниф булган. Инде никах турында сөйләшкәннән соң, әнинең абыйсы Ишмөхәммәт таныш чуваш кешесеннән булачак кияүнең жиде балалы әти икәнлеген очраклы гына белгән. Хатыны күптән түгел үлгән икән. Өйгә кайткач, бабайдан: «Әти, ничек була инде бу, сеңелкәшне жиде балалы иргә бирәсең икән бит син?» — дип сорый. Бабай, әлбәттә, бу турыда белгән. Тик анын уе буенча, «әни ирennән аерылган, аның үзенең балалары юк, ә гомер үтә ул, вакытында тиешле урынга урнаштыру хәерле». Һәм Ишмөхәммәткә барсын сөйләшеп хәл иткәнлекләрен белдерә. Әнигә шулай да Хәнифнең балалары өчәү дип әйтәләр. Әнием кияү йортына төшкәч, өй тулы бала-чага күрә, араларында инде житеп килгәннәре дә бар. Иң кечкенәләре — Мәгъдәнүс — яшь ярымлык, Фәрхури — чак кына өлкәнрәк, алардан соң Агиян, Гариф, Мәгъсүм, Харис һәм Хатиф. Соңгысы инде егет булган. Кич житкәч, әни балаларның һаман таралмавын күреп: «Күрше-тирә балалары, өегезгә кайтыгыз, соң инде, ата-аналарыгыз югалткандыр», — дип әйтә. Балалар ни диярге белмичә аптырап калалар. Шул чагында аның янына әти килә һәм, жилкәсенә кулын куеп: «Болар барсы да безнең балалар», — дип белдерә. Әни еларга да, көләргә дә белми.

Уртак тормыш башлана, әти белән әнинең янадан тугыз балалары дөньяга килә. Әтинең беренче никахтан туган өч баласын беркайчан күргәнем булмады, чөнки алар мин туганчы үлгәннәр иде, ә калган дүртесе белән иң якын туганлык мөнәсәбәтләрендә яшәдек. Алдагы язмышларына кагылып китсәк, тәгаллек өчен шуны әйтү тиештер: Хатиф абый һәм кыз туганнардан берәү Үзбәкстан туфрагына жирләнде, Харис абый — Украинада, ә кыз туганнардан Фәрхури апа — Татарстанның Түбән Чыршылы авылында. Без — әнидән туган тугыз баладан — исәннәр Фатыйх абый белән мин генә идек (әйтелгәнчә: автобиографик повестьның авторы 2012 елның көзендә вафат була — тәржемәче искәрмәсе). Мин — жәсәде Кирлегәч туфрагында соңгы сыену урыны тапкан әтиебезнең уналты баласы арасында төпчеге. Газиз әнием исә мәңгелеккә ерак Үзбәкстан якларында ятып калды.

## Колхозлаштыру

Ул узган гасырның утызынчы елларында башланды. Мин мәктәпкә кердем. Язар өчен дәфтәр дә, авторучка да юк, шахмат тактасы кебек жыела торган кара төстәге такта гына бар. Анда акбур белән язабыз. Соңрак карандашлар һәм тупас кәгазьле блокнотлар күренгәли башлады. Бу әйберләрне без, акча булмаганлыктан, йомыркага алыштырып ала идек. Өлкәнрәк балалар бу вакытта кайсы кая таралышып беттеләр. Хатиф абый белән Мәгъдәнүс апа Урта Азиягә киттеләр, Харис абый Донбасска китеп шахтёр булды, Фәрхури апа Түбән Чыршылы кешесенә тормышка чыкты. Кирлегәчтә әни, Фатыйх абый һәм бер үсмер абыем белән миннән башка яшәр кеше дә калмады.

Күмәкләштерү башлангач, кемнәрдер колхозга, үгетләүләргә алданып,

яна һәм җинел, бай тормышка кызыгып керде. Кемнәрдер көтүне мәгъкуль күрде, ә кемнәрдер кискен каршы чыкты. Шәхси хуҗалыгында аты да, башка терлек-карасы да булмаганнар колхозга керүдә аеруча зур энтузиазм күрсәттеләр. Андыйларга шәхси хуҗалыкларында уңышка ирешүдә ни-нәрсә киртә булгандыр, анысын анык кына әйтә алмыйм, шулай да ялкаулык төп сәбәпләрнең берседер кебек тоела.

Үгетләүләр көчле булды, куркыттылар да хәтта. Халык арасында: «Бар да уртакка әйләнәчәк, хатыннарга кадәр», — дигән сүзләр йөрде. Салымнар искиткеч югары. Йон, сөт, ит, бәрәңге һәм тагын әллә ниләр җыеп тапшырырга кирәк, өстәвенә, дәүләт заемнарына яздырып тинтерәттеләр.

Район үзәгеннән уполномоченныйлар килеп, халыкны җыелышларга куалый. Салымын түли алмаучыларны төнгелеккә каталажкага ябып куялар иде. Бигрәк тә җирле активистлар котырынды: өй борынча йөреп икмәк эзлиләр; келәттә тапмасалар, бакча артына чыгып, махсус җәпле эзләгечләрен туфракка батыра-батыра, яшереп саклаучы урынны табарга тырышалар. Әгәр күмгән урын килеп чыкса, анда сакланучы һәммә нәрсәне алып китәләр.

Колхоз оештырылганчы барлык крәстиәннәрнең шәхси җир кишәрлекләре бар иде. Анда алар арышын-бодаен, солысын-арпасын, борчагын һәм башкасын чәчтеләр. Һәркемгә авыл җыенында печәнлекләр, урман делянкалары бүлеп бирелде. Җыеп кына әйткәндә, барлык эшләр кул белән эшләнсә дә, яшәргә мөмкин иде. Ә монда җирне тракторлар белән эшкәртергә, игенне комбайннар белән җыеп суктырырга вәгъдә итәләр. Шулай да кешеләр икеләнә иде әле. Барлык атларны колхоз абзарына җыеп алдылар, анда аларны бары тик бер ат караучы гына карый. Күпләр, башкалар күзенә чалынмаска тырышып кына, үзләренең атларын ашатырга бара, крәстиән өчен атыннан аерудан да кыенрак нәрсә бар димени?! Моңа кадәр һәркем үз кишәрлегендә урак белән игенен урды, көлтәләрен ат белән әвен астына яисә ихатасына ташыды. Хәзер юлда туктаталар да төялгән көлтәләрне зур ачык кырга бушаттыралар. Имештер, күмәк көч белән суктырачаклар һәм соңыннан иген өләшәчәкләр. Алдадылар шул, беркемгә берни бирмәделәр. Барысын дәүләткә озаттылар.

Бөтенесе кирегә китте. Терлекләрне, беренче чиратта, сыерларны, инде суярга хакыбыз юк, баш саны кими, янәсе. Ул да түгел, ике сыер асрауны тыючы закон чыкты, кәҗә-сарык ише хайваннар үрчетүне дә чикләделәр. Кайсы елда икәнен төгәл хәтерләмим, коточкыч ачлык башланды. Үләнен дә, ат кузгалагын һәм кычытканын да ашарга туры килде ачтан үлмәс өчен. Безнең атларны тартып алдылар, умарталары белән умарта кортларын гына түгел, келәт бүрәнәләренә кадәр төяп алып киттеләр. Хуҗалыгыбыз тәмам бушап калды. Инде мин үзебезнең колхозга керү-кермәвебез турында хәтерләмим. Әни олы яшьтә, абыем әле үсмер генә, ә мин үзем бөтенләй кечкенә идем. Эшләр кеше дә юк.

Чират кулакларга җитте. Азмы-күпме җитеш тормышта яшәүчеләргә кулак ярлыгы тагып, төркем-төркем Себер якларына сөрү кампаниясе башланды. Безнең авылдан башлыча Магнитогорскиның ул елларда төзелә башлаган металлургия комбинатына озаттылар. Әйтүләренә караганда, андагылар бернинди хокуксыз-нисез кол урынына эшләгәннәр. Күбесе ачлыктан, салкыннан һәм иң гади яшәү шартлары да булмаганлыктан, чебен урынына кырылганнар. Авылның байтак хәлле кешеләре, этап белән озатканнарын көтмичә, Үзбәкстан, Казакъстан, Украина якларына качып китте. Авылда тормыш көннән-көн авырлашты, түзеп булмастайга әйләнде. Адәм балаларының хәленнән килгәннәре сәнәгать предприятиеләренә китеп урнашырга тырышты, чөнки анда гаиләнне туйдырып яшәтергә мөмкинлек бар иде.

Берзаман аз-маз хәлле крәстиәннәрнең дә милекләрен тартып ала башладылар.

Бу хәл еш кына җирле активистларның әләкләре буенча эшләнде. Андыйлар үзләрен ярлылар (чынлыкта — ата ялкаулар) исәбенә кертәләр иде. Ул чорда крәстиәннәрне өч төргә бүлеп карадылар: ярлылар, урта хәлләр һәм кулаклар. Соңгыларын берниндидә икеләнүсез, мал-мөлкәтен конфискацияләп, Себергә урман егуларга һәм җир казу эшләренә сөрделәр. Кечкенә булсам да, мин шундый бер эпизодны хәтерлим. Кайсы елны икәнен төгәл әйтә алмыйм, әмма булып узган вакыйгалар зиһенемә шулкадәр тирән сеңеп калган ки, алар әле бүген генә булган кебек күз алдымда. Безгә ике урам аша әтиемнең энесе Нурулла абый гаиләсе белән яши иде, аларның алты балалары бар: Хәдичә апа, Ярулла абый, Һаҗәр апа, Габдулла, Хәмзә һәм төпчекләре — Габбас. Кышкы көн иде, мин аларга хәл белергә килдем. Тик ишегалдына керергә дә өлгермәдем, берничә җигүле чанага төялеп, авыл советы активистлары килеп төште. Килгән шәпкә акырып-бакырып сарыклар артыннан ташландылар һәм тоткан берсенең аякларын бәйләп, чаналарга ыргыта тордылар. Аннары амбар ишеген ватып, эчтән ат сбруйлары ташырга керештеләр. Моның белән генә чикләнмичә, арба, кошевка этеп чыгардылар, тагын нәрсәләрдер күтәреп чыктылар. Шактый озакка сузылды бу мәрәкәләр, келәттән иң соңгы итеп әллә ничә капчык бодай һәм он тутырылган капчыклар чыгардылар. Аннары сарайны ачып, ат, сыер, тана бозау куып чыгарылды һәм алар колхоз утарына илтеп тапшырылды. Талаучылар киткәнче тораташтай басып торган хуҗабикә Бибигайшә җиңгине бер читкә этәреп, йорт эченә дә узарга онытмадылар. Аннан савыт-саба, самавыр, урын-җир ише кирәк-яракларны да ташып төяделәр. Вакханалия моның белән генә тәмамланмаган икән. Активистларның берсе, Бибигайшә җиңги янына килеп: «Икенче сыерыңны кая яшердең?» — дип акырынырга керешә. Беркем бернәрсә эндәшми. Активист инде балаларның иң өлкәне — Хәдичә апаның кырына килеп басты, аңа да кычкырып, сыерны таптыра. Кечкенә балалар берни аңламыйча, куркынып әле әниләренә, әле аларның әйберләрен чаналарга ташып төягән усал чырайлы абыйларга карыйлар. Усал бәндәләрнең тешләрен ыржайтып: «Буржуй калдыклары, кулаклар, менә сезгә дә чират житте!» — дип сөйләнүләрен каян аңласын ди сабыйлар. Теге адәм актыгы һаман Хәдичә апага бәйләнүендә булды: «Без сезнең ике сыерыгыз бар икәнен беләбез. Кайда икенчесе?» — ди өзми-куймый.

— Юк. Безнең берәү генә.

Күзләре акайган абзыйның апасын һаман тынычлыкта калдырмавын күреп, кечкенә Һаҗәр: «Әнә теге урамдагы күршеләрдә», — дип куймасынмы. Сабыйның апасын кызганып, үзенчә аңа ярдәмгә килүе иде. Хәдичә апа йөрәгенә чыдаша алмыйча, ирексездән сеңлесенең йөзенә сукты, тегесенең борынынннан кан китте. «Экспроприаторлар» шулай итеп Харис абыйлар сараена яшерелгән сыерны да таптылар һәм Нурулла абыйның гаиләсен иң соңгы карап торган яшәү чыганагыннан да мәхрүм иттеләр.

Нурулла абый бу вакытта өйдә түгел иде. Күрәсең, йомыш белән берәр яры киткән булгандыр. Алар Гайшә җиңги белән икәүләп бик тәмле ак калач пешерәләр иде. Көне-төне хезмәттә иделәр. Шулай да гади авыл мичендә күпме генә пешереп булгандыр инде аны. Әнә шул чикләнгән күләмдәге калачларын Нурулла абый Кирлегәчтән җиде чакрым ераклыктагы Куаклы базарына илтеп сата иде. Аларның ипиләрен «ә» дигәнче алып бетерәләр, чөнки ул яхшы сыйфатлы булу өстенә, чагыштырмача арзан да иде. Һәм менә шул зур тырышлык куеп, берәмтекләп туплаган малларны килделәр дә алып киттеләр, бернәрсә дә калдырмадылар. Гайшә җиңги чыдамады, оятсыз елмаеп китеп баручы талаучыларга: «Сез бит безнең йокы йокламыйча, хәләл көч белән булдырган малларыбызны алып китәсез. Сигез кешелек гаиләне ата-ана моннан соң ничек туендырыр дип уйлыйсыз. Безгә ничек яшәргә соң?»

— дигән сорау бирде. Кайсыныңдыр, теге активистның булса кирәк, хихылдап: «Ничек телисез, шулай яшәгез», — дигән җавабын башка ишләренең хахылдап көлүе басып китте.

Нурулла абый киткән җиреннән әйләнеп кайтып, барысы турында белгәннән соң, төнне бездә үткәрергә мәҗбүр булды. Шулай берничә көн дәвамында кулга алынудан качып яшәгәннән соң, безне дә куркыныч астына куймас өчен, Урта Азия якларына чыгып китте. Соңыннан безгә аның җитди авырып китүе һәм барган җирендә вафат булуы ишетелде. Тик аның гаиләсенә ябырылган авырлыклар моның белән генә тәмамланмады әле...

Атлар юк, ә ул — крәстиәннең төп терәге. Терлек-туар саны да аз. Урманны шулай ук елатып кына (бик аз ягъни) бирәләр. Колхозда эшләгән өчен башта бик күп вәгъдә иттеләр, ә чынлыкта дәүләткә бушка диярлек бил бөгәргә туры килде. Гомумән, кыенлык, артык бөгүләрнең чик-чамасы юк иде. Шулай да объективлык өчен социализм чорында күп санда мәктәпләр ачылуын да әйтергә кирәк. Аңа кадәр укый-яза белү юк дәрәҗәсендә булды ич. Авылда укымышлы кешене табу кыен, бер-ике һәм шуның белән вәссәлам. Мәҗбүри белем алу системасы керттеләр. Хәтта өлкән яшьтәгеләрне дә ликбезларга җыеп укыттылар. Башлангыч мәктәпләр, мәдәният учагы — клублар ачтылар, кино китерделәр, радио барлыкка килде.

Боларга параллель рәвештә мәчетләрне яптылар, манараларын җимерделәр. Үсмер комсомолларның кызыл флаглар күтәреп, гармун тартып килгәннәрен һәм мәчет коймасы аша чыгып, аның түбәсенә флаг кадаклап куйганнарын хәтерлим. Картлар шунда баскан урыннарында елап торалар иде.

Шулай да тормыш кирәкле тарафка борылмаган иде әле. Кайберәүләр читкә акча эшләргә чыгып китә башлады. Әмма китүе ансат түгел. Чөнки производствода документ таләп итәләр: паспорт яисә справка. Колхозның җибәрүе турында инде бу. Ә колхоз җибәрә ди, бар. Без ул вакытта моның чын коллык галәмәте булуын аңлап кына бетермәгәнбез. Хәер, аңласаң да, ни хәл кыла аласың инде?! Калада, саладагыга караганда чагыштырмача яхшырак яшәргә мөмкин иде. Эш таба алсаң, әлбәттә. Ә эш дигәнең бар инде ул (бу уңайдан социализмны тәнкыйтьләү урынсыз), эзләргә һәм табарга гына кирәк. Кайберәүләр: «Никадәр каршылык!» — дияр, бәлки. Тик чынбарлык әнә шундый иде.

## Газапланып йөрүләр

Фатыйх абыем Харис абый ярдәмендә (әтиемнең беренче хатыныннан туган улы) Урта Азиягә китәргә карар кылды. Яшәгән йортыбызны, анда калган барлык әйберләре белән, күрше Сафинка авылына сатарга мәҗбүр булдык. Шулай итеп абый китте. Безгә әни белән туганнарның буш торган йортларында яшәүдән башка чара калмады. Соңыннан абыйның Ташкенттан ерак түгел урнашуы турында хәбәре килде. Кул белән такта яручы пилорамга эшкә урнашкан. Күрәсең, бу үзенә күрә «шабашка» булгандыр, һәрхәлдә, производство предприятиесе түгел. Абый күпме хезмәт хакы алгандыр, анысын әйтә алмыйм, тик ул безгә ара-тирә ситсылар, конфет, чәй һәм җиләк-җимеш тутырылган посылкалар җибәреп торды. Андый чакларда йортыбыздан әби-чәбиләр өзелмәде. Бөтенесе өрек һәм йөзем җимеше белән тәмләп чәй эчәргә, дөге боткасыннан авыз итәргә атлыга, чөнки авылда ошбу тәгамнәр ул чагында иң яхшы деликатеслардан санала иде. Тик хуҗалыгыбызда инде берни дә калмаганлыктан, яшәү торган саен авырлашты. Туганнар әнине нindидер бер тол карт белән кушылдырырга тырышты. Әни, бәлки, ризалык та биргән булыр иде. Тик карт танышу нияте белән безгә килгәч, мин аңа өзгәләп атардай бүре карашы белән карадым. Көнләшүем шулкадәр көчле булган, әнигә: «Әгәр аңа чыксаң, мин синең улың түгел, бүген үк качып

китәм», — дип янадым. Әнием картны кире какты, чөнки ул мине бик ярата һәм минем өчен борчыла иде. Әлбәттә, бу адымым юләрлек булган. Тик тугыз яшемдә моны аңларлык булмаганмын шул әле. Соңрак, үсә төшкәч, нинди зур хата ясаганымны аңладым аңлавын, әнидән гафу итүен дә сорадым. Ул: «И-их, син, аңгыракаем»,– дип көлде генә.

Язмыш кушуы буенча, әнием белән берничә тапкыр аерылып та торырга туры килде. Беренчесендә — әни урман эшләренә читкә киткәч. Богырыслан артындагы Колтубан урманында яллы эш бар икән дигән хәбәр таралды. Барлы-юклы акчаларны ничек кирәк алай поезд билетына җыйнаштырып, әни берничә иптәш хатыны белән акча эшләүгә китеп барды, ә мин яшәп торырга күрше карчыгы Минҗамал әбидә калдым. Минем кебек үк, әби үзе дә ачыга. Аптырагач, мин күрше Чирмешән районының Кара Чишмә, Туймәт авылларына хәер сорашырга чыгып киттем. Берсендә, хәтерлим, Сарыбиккол авылына юнәлдем. Кышкы юл. Авылны чыгып, бер чакрым үтәргә өлгермәдем, күз ачкысыз буран купты, бернәрсә күренми. Шулчак: «Тррр, малкай», — дигән аваз ишетелде һәм кемдер янәшәмдә атын туктатып, чанасыннан сикереп төште. Карасам, күршебез Ибрай абзый икән. Ул авыл инеше аша күпер салуда башлап йөрүчеләрнең берсе иде. Гаиләләре ач яшәми. Мин аның улы Исмәгыйль белән дус идем, мәктәпнең икенче сыйныфында бергә укыдык. Күп еллар узгач, Таҗикстанның Табошар шәһәрендә очраштык без аның белән. Ул сугышта катнашкан, безнең Табошарда яшәгәнне ишетеп, хәл белергә Корыксадан килде. Ә буранда адашуга килсәк, Ибрай абзый миннән: «Кая барасың, Шамил?» — дип сорый. Мин: «Әнә теге авылга. Ашарыбызга берни калмады», — дим. «Күрәсеңме нинди буран, борылып кайт, югыйсә катып үләсең», — дип күрше агай минем кулыма буханкасы белән ипи һәм бер сум акча тоттыра. «Карап торам кайтып киткәнеңне, бар инде, бар», — ди ул, җинелчә генә инемнән этәреп. Әйләнеп кайтуыма Минҗамал әби борчылып тора иде, ул мине күз ачкысыз буранда чыгарып җибәрүенә нык үкенгән. Үземне күргәч, шатлыгыннан кочаклап ук алды. Ә инде буханкасы белән ипи һәм акча да алып кайтканымны белгәч, сөенеченең чиге булмады. Шулай итеп, зур кыенлыклар белән булса да, кышны чыктык, ачтан үлмәдек.

Яз җитте, җир өсләре кипшереп, көннәр җылытты. Мин инде унбиш-егерме чакрым ераклыктагы авылларга да бара башладым. Кайда туры килсә, шунда кундым. Кемнәрдер төн чыгарга мунчаларына кертте, кемнәрдер — өйләренә. Берсендә Кара Чишмә авылында чиләкләрен күтәреп басып торган хатыннар төркеменә якынлаштым. Янәшәдә генә сепаратор пункты бар икән. Киң күңелле апалар миңа сөт салып бирделәр, кызганып, хәлемне сорашырга керештеләр. Арадан берсе минем чебиләп беткән яланаякларыма игътибар итте һәм ахылдап куйды. Чыннан да, аякларым пычрак һәм яргаланып беткән, урыны белән кан тамчылары күренә. Мине аеруча кызганган апа башкалардан үзен чиратсыз гына үткәрүләрен сорап, кулымнан җитәкләп өйләренә алып кайтты. Тазга кайнар су салып, кычулап беткән тәпиләремне яхшылап җебетте һәм юды, аннары сөт өсте сөртте. Мин анда өч көн яшәдем, инде аякларым да йомшарып, әчетми башладылар. Олы йөрәкле хатынның исеме Бибизәкия иде. Мин аның игелеген гомерем буена онытмадым. Сөенечкә, андый кешеләр тормыш юлымда байтак очрадылар.

Өч көннән соң Кирлегәчкә кайтып киттем. Авылга якынлашканда, башта тигезлектән барып, калкулыкка күтәреләсе. Инде менеп җиттем диярлек, аркамда киң күңелле кешеләр өлеш чыгарган әйберләр салынган кечкенә юл капчыгы, кинәт, карыйм — каршыма әнием йөгерә. Сүзен дә әйтә алмый бичара. Ул инде өч көн элек кайткан икән. Иптәш хатыннары белән атна буена җәяүләп өч йөз чакрым ара үткәннәр, аз-маз җыйган акчаларын поезд билетына «әрәм» итмәс өчен шулай эшләгәннәр. Минҗамал әбидән минем киткәнне белгәннән

сон, ул шушы калкулыкка килеп утырган һәм көтә башлаган. Соңыннан сөйләвенчә, үзе көтә, үзе: «Менә күренә, менә күренә», — дип сөйләнә икән. Баштагы мәлдә эзләп чыкмакчы булган, тик аннан бу уеннан кире кайткан. Тирә-юньдә авыллар күп бит, ничек эзләп табасың.

Берничә атнадан без кабат юлга кузгалдык. Әни белән мин, берничә хатын-кыз һәм Самат атлы бер яшүсмер. Самат миннән биш яшькә олырак. Без әниләрнең моннан алда эшләп кайткан урыннарына барабыз. Иртәдән кичкә хәтле юлда. Кояш баегач, кунарга тукталабыз, кайда туры килсә, шунда йоклыйбыз: кайчагында ачык басуда, кайчагында авыл янәшәсендә. Бер төнне Богырыслан шәһәрендәге күпер астында уздырдык. Ерак түгел ял паркы яисә клуб-фәлән урнашкандыр, күрәсең, чөнки бик озак тынлы оркестр уйнавы ишетелеп торды, һәм аның мелодиясе минем хәтеремә сеңеп калды. Еллар үткәч, инде Донбасста яшәгәндә, мин көйнең «Маньчжурия сопкаларында» дип аталуын белдем.

Тиешле урынга барып житкәч, без урман эшендә эшләүчеләрнең яши торган баракларын күрдек, дөрес, аларны бараклар дип әйтеп тә булмый, яшәү куышлары-землянкалар иде алар. Минем өчен дә эш табылды — коры-сары, кечкенә ботакларны жыю. Ә өлкәннәр сумала җыярга җәлеп ителде. Ашау яклары начар түгел иде, хәтта дуңгыз ите дә бирделәр. Әнием һәм аның иптәшләре чучка ите ашамыйлар, ә без Самат белән алар өлешен дә сыптырабыз, нәтиҗәдә шактый ук тазардык та. Землянканың жир идәнендә кем кая туры килсә, шунда йокладык. Төн буена кемнәрдер ах-ух килә, ыңгыраша, кемнәрдер кашына, бет һәм кандала ише канэчкечләр йокларга ирек бирми. Кешеләр иртә белән йокылары туймыйча уяна. Эшкә бармыйча калып булмый шул. Көз житкәнче тамак хакына гына эшләттеләр, акча чырае күрсәтмәделәр. Берзаман, моннан кырык чакрымнар ераклыкта шартлар яхшырак, дигән сүз таралды. Ул чакта, «анда яхшырак икән», дигән хәбәр ишетелсә, кешеләр озак уйлап тормый, тиз генә җыена да китеп бара иде. Безнең төркем төннәрнең берсендә нәкъ шулай эшләде. Яңа урында да әллә ни үзгәреш юк, нәкъ шундый картина. Шунысы бар: миңа эш табылмады. Жиләк җыеп, аны икмәккә алмашырга хирысланып киттем. Күбесенчә җиләкләремне бер гаиләгә илтә идем. Алар моның өчен каткан, ә кайчагында хәтта күгәрә башлаган ипи сыныклары бирә иде. Әни печән чабуда эшләде. Аларны анда ашаттылар. Еш кына, үз авызыннан өзеп, әнием миңа ризык алып кайта иде.

Берчакны мине үзенә ярдәмгә авыл көтүчесе чакырды, урыс кешесе. Көтешкән өчен тамагымны туйдырырга вәгъдә итте. Ризалаштым. Сыерлар саклыйбыз. Беркөнне иртән үлән өсте бәсәргән һәм бик салкын иде. Ә мин яланаяк, аякларым туңа. Башлыгымны салып җиргә куям да, аякларымны бераз җылыткач, башлыкны кабат башыма киям. Шулчак көтүче: «Малай, син көтүне караштырып тор, мин бераз черем итеп алам», — дип, ышык урын табып ятты. Басып торудан туеп, мин дә утырдым. Тагын да салкын булып китте. Чикмәнемне бөркәнеп яттым. Шулай йоклап киткәнмен. Жилкәмдә юешлек тоюдан уянып киттем. Яңгыр явып үткән икән, аны да сизмәгәнмен. Сикереп тордым. Көн караңгыланып килә. Көтү дә, көтүче үзе дә күренми. Шулкадәр йокларга кирәк бит, ә?! Хәер, гаҗәп түгел. Салкын һәм ачлык үзенекен иткән. Кайту ягына йөгердем. Яшәү урыныбыз ниндидер ташландык клубта иде. Кайтып керсәм, әни елап утыра. Көтүче, уянгач, минем юклыкны һәм малларның ерак киткәнлеген күреп, шул тарафка йөгергән. Анда мине тапмагач, кычкырып эзләп тә караган, җавап ишетмәгәч, кайтып киткән дип уйлаган. Әни мине башкача көтү көтәргә җибәрмәде.

Эшләр тәгәлләнгәч, барлык хатыннарга да кырыгар сум акча бирделәр һәм

без, ниһаять, өйгә, авылыбызга кайтып киттек. Инде төн кунарга авылларда гына тукталабыз, талаулардан куркабыз. Султановка дигән чуваш авылына життек, яңгыр коя, беркемнең дә кунарга кертәсе килми. Йөри торгач, татарча яхшы сөйләшә торган бер карт кертте тагын. Тик өенә түгел — мунчага. Мунча көндез генә ягылган булганлыктан, эсселеккә чыдар әмәл юк. Өскә кигән барлы-юклы киемнәрне салып, йокларга яттык. Эчтән ишек келәсе дә элэктерелгән. Төнлә хатын-кызлардан кайсыдыр, ишек ачылып, кемнеңдер кергәнен күрә һәм тавыш куптара. Барысы да уянып шаулаша башладылар: талаучы кергәндер, башка кем булырга мөмкин? Чынлыкта Самат кече йомыш белән чыккан икән. Соңыннан моны мәзәк итеп, авылга кайтып житкәнче көлеп искә алдылар. Шул хәлләрдән соң биш көн узгач, авылга кайтып життек. Инде кыш якынлаша иде.

## Сау бул, Кирлегәч!

Үзенең алты баласы булса да, безгә Фәрхури апа нык булышты. Аның ире, минем жизни — Сәетгали, Фатыйх һәм Харис абыйлар белән Донбассның Макеевка шәһәрендәге шахтада эшли иде. Ул безне алырга кайткан икән һәм юл уңаеннан Фатыйх абый жибәргән кайбер әйберләрне дә алып кайтуы булган, тик юлда әйберләрен урлаганнар. Сөйләвенчә, бер татар белән туры килеп, уңайлы гына кайтканнар. Станцияләрдә чиратлашып кайнаган су алып кергәннәр, берсе чыкканда, икенчесе әйберләрен саклап калган. Кайтып житәргә берничә станция арасы гына калгач, юлдашы Сәетгали абыйдан бу юлы аның чыгуын үтенгән, никтер авырып торам, дигән. Жизни әйләнеп керүгә, юлдашыннан да, ике фанер чемоданыннан да жилләр искән. Ул бик кәефе кырылып кайтып керде.

Жыелышып китәргә карар кылдык. Жизни жигүле ат табып килде һәм без Келәү станциясенә юнәлдек. Станция астарак, аңа тау түбән төшәсе. Анда электр утларыннан бөтен жир яп-якты, паровозлар ухылдый, чаңгылдау тавышлары, гудоклар ишетелә. Әни барыбыздан да ныграк курыкты. «Женнәр шәһәре», — дип, догаларын укырга кереште.

Вокзалда утырган арада әнием белән апам кырыйларындагы хатын белән сөйләшеп киткәннәр. Ул хатын аларга һәркайда жентекләп документ тикшерүләре турында әйткән. Әни һәм апа нык курыкканнар, чөнки Сәетгали абый белән минем тиешле кәгазьләр тәртиптә булса да, аларныкы юк иде. Колхоз беркемне беркая жибәрми, документ та бирми. Ахырда әни дә, апа да кире авылга борылып кайтырга булдылар. Жизни аларны утырып килгән атчы белән кире кайтарып жибәрде. Без вокзалда калдык. Төнне уздырганнан соң, жизни иртәдән кичкә кадәр, билет дип өтәләнде. Ниһаять, ансы да хәл ителде һәм без поездга утырып киттек. Минем өчен бар да яңа, барысы гажәп. Чөнки «тимер ат»ны һәм тимер юлны тәүге мәртәбә күрүем.

Төнлә барганда, вагон буенча ревизорлар билет тикшереп йөри дигән хәбәр таралды. Жизни миңа: «Тикшерүче алдында үрә катып басып торма, чак кына бөкрәя төш», — дип өйрәтә. Тикшерүче килде, билетларны алгач, миңа карый. «Бас әле», — ди үзе. Торып бастым. Аннары ул жизни белән нидер әйтеп кычкырыша башлады. Берни аңламыйм. Миңа ничек тә бәләкәйрәк күренергә кирәк булган икән, чөнки билет чирек бәягә генә алынган, ә мин олырак күренәм. Ревизор әйтүенчә, ярты бәя тиеш. Жизнигә ундүрт сум штраф салдылар һәм киләсе станциядә яңадан чирек бәялек билет алырга куштылар. Сәетгали утырып уйга чумды. Билгеле инде, штраф түләгән акчасы өчен кайгыра, әле тагын чыгым чыгарасы бар. Ул мине: «Мин сиңа бөкрәя төш дидем, ә син бүксәнне киереп басып торасың. Шуның аркасында штраф түләдек, — дип ачулана. — Ярар инде, бернишләтеп тә булмый. Акчам аз калды,

барып житәсе бар. Янадан билет сатып алмыйм. Сиңа әйберләр куя торган полкага менеп ятарга кирәк булыр», — дип өсти, бераз йомшап. Югары полка түшәм астында ук. Жизни кырыйда ята, ә мин аның артында эчкәредә. Астан караганда күренмим. Ревизор килүен ишетү белән, югары полкага үрмәлибез. Жизни өстән генә билетын суза, минем барлыгым-юклыгым беленми. Монда инде икенче ревизорлар һәм алар мине күрмичә дә калалар. Өстән жылыткыч торбалар үткәрелгәнлектән, түзалмаслык эссе, шулай да барып житкәнче тешне кысып булса да түзәргә туры килде. И-их, шундый хәл килеп чыкмаса, тәрәзәдән бөтен нәрсәне күзәтеп барган булыр идем дә, ярар инде, нишлисең. Донецк өлкәсенең Дебальцево станциясендә Макеевкага барыр өчен икенче поездга күчеп утырышлы икән. Бу кала тирәли София, Итальянка, Ивановка, Бутовка һ.б. исемле шахталар тезелеп киткән. Ниһаять, килеп життек. София шахтасы янындагы бистәдә без. Бу инде Октябрь инкыйлабына кадәр үк эшли башлаган иске шахта. Шахтёрлар арасында татарлар күп.

Нахаловка бистәсенә килгәч тә башта Харис абыйларда (әтиемнең беренче хатынының улы) кундым, икенче көнне бертуганым Фатыйх абый үз янына, буйдак шахтёрлар яшәгән тулай торакка алып китте. Икәүләп бер кешелек караватта йокладык. Минем чабатам тузып эштән чыккан иде, шуңа күрә тулай тораКтан чыгып йөри алмадым. Шулай да юл аркылы урамның икенче ягына урнашкан бәдрәфкә барып килмичә булмый. Көннәр язга авышса да, әле кар эреп бетмәгән. Мин аякларым туңганчы бәдрәфкә йөгереп барып кайтырга өлгерәм. Андыйга гына иялəнгән инде: авыллар буенча хәер сорашып йөрүләр, үзебезнең малларны көтүгә куу, көтүче ярдәмчесе булып йөрү дисеңме — берсе дә калмады, һәм барсы да ялантәпи килеш. Шулар чыныктыргандыр, мөгаен. Тик мин әле бу вакытта киләчәктә үземне нинди кимлек-авырлыклар көтүен, нинди сынауларга дучар ителәсемне күз алдына да китерми идем.

## Донбасста

Яшибез шулай. Фатыйх абый шахтада эшли, тик хезмәт хакы күп түгел. Аның да бер өлешен әнигә җибәрә. Мин күбесенчә тәрәзәдән карап утырам. Беркөнне абыем шәһәрдән миңа драп пәлтә, чалбар, сатин күлмәк сатып алып кайтты. Ботинкасы да бар, тик инде ансы кулдан алынган, шулай да яхшы күренә. Мине баштанаяк киендерде дип әйтергә була. Мин, ниһаять, урамга чыктым. Анда урыс. украин балалары уйнап йөри. Тулай торакта да ике малай — украин һәм чуваш — яшиләр иде. Урамда яңа кеше пәйда булуын күреп, мине бала-чага сарып алды. «Исемең ничек?» — дип сорыйлар. «Шамил», — дигән җавапны ишеткәч, алар: «Шурик булырсың», — диләр. Шуннан соң урыстеллеләр өчен Шурик (икенче төрле Саша дип тә әйтәләр) булып киттем. Ул вакытта әле урысча сөйләшмим, шулай да берничә сүз беләм һәм укый ала идем. Боларга мине урыс мәктәбендә укытучы туганнан туган абыем Ярулла өйрәтте.

Мине әйләндереп алган ишләремә Нахаловка бистәсендәге София шахтасына барырга җыенуымны аңлаттым. Туганнарыма яңа киемнәрдән күренәсем килә дигән булам. Анда барганда юлда очраучылар һәммәсе миңа карыйдыр кебек тоелды. Нахаловкада яшәүче үсмер туганнарым — Барый белән Кәшиф — шахта территориясенә алып барып таныштырырга алындылар. Минем өчен бар да кызык. Шулай да үкенергә туры килде: ялгыш чокырга таеп егылдым. Тартып чыгаргач, өстемдәге бөтен яңа киемнәремнең келәй шикелле массага батканы күренде. Харис абыйларга киттек, аның хатыны киеп торырга башка киемнәр бирде, ә минекеләрне юарга салды. Юып, киптереп, газета аша үтүкләп карасалар да, берниндй файдасы тимәде. Киемнәр яраксызга әйләнде, аларны киеп урамга

уйнарга чыксан гына инде, ә мина мәктәпкә барырга кирәк. Фатыйх абый кабат яңа киемнәр сатып алырга мәҗбүр булды һәм мине укырга егерме алтынчы номерлы татар мәктәбенә илтте, әмма моннан соң кысынкы режимда яшәргә туры киләчәге турында кисәтеп куйды. Без ачы кәбестә һәм кара икмәккә күчтек. Өстенә шикәр комы сипкәч, ярыйсы була икән болай һәм арзан да.

Урысчага мин тиз өйрәндем. Татар мәктәбе саналса да, анда урыс, украин, немец телләреннән дә дәресләр укытыла иде.

Акча житмәгәнлектән, папирос сату эшенә керештем. Күмер шахталарында тарту тыела, шуңа күрә шахтёрлар сменадан чыгу белән папироска үреләләр. Аларның кесәсендә һәрчак вак акча йөри. Чыгу белән безне — тәмәке сатып йөрүче малайларны — чакырып алалар һәм данәләп папирос сорыйлар. Утырып тартканнан соң гына юынырга кереп китәләр. Мин бер капны утыз биш тиенгә сатып алам, аннан унбиш тиен файда ясыйм. Ике данәсен бишәр тиеннән сатсаң, файда егерме биш тиен җыела. Көне- көне белән сигез-ун сумга кадәр акча эшләгән вакытлар була. Бу тыела иде. Безне милиция куалый. Берсендә мине участковый сиксән кап папирос белән эләктерде һәм барлык товарны ваклап ыргытты. Шуннан зур зыян күрдем.

Укырга дүртенче сыйныфка йөри башлагач, абыем шахтада забойщиклыкка күчте һәм аның хезмәт хакы да артты. Мин тәмәке сату шөгылен ташладым. Укытучы Асия апа да минем сатып йөргәнемне күреп калган һәм абыемны чакырып житди сөйләшкән, анысы да бер сәбәп булды.

Абыйга «стахановчы» исеме бирделәр. Ул чагында шундый хәрәкәт бар иде. Бөтен илдә атаклы Алексей Стаханов, тракторчы Мария Демченко, поезд машинисты Максим Кривонос исемнәре киң яңгыраш алды. Алардан үрнәк алдылар, алар ирешкән үрләргә тигезләшергә тырыштылар. Абый күмер чыгаруда зур күрсәткечләргә ирешеп, мактаулылар рәтенә керде дә инде. Аның хезмәт хакы бермә-бер артты. Акчаны кассир, стахановчылар өчен кертелгән тәртип буенча, өйгә үк китереп бирә. Болардан тыш та абыйга төрле бүләкләр, патефон һәм хәтта велосипед тапшырдылар. Ул елларда велосипед кешеләр өчен хәзерге вакыттагы машинага тиң иде. Тиздән абый авылга кайтып әнине алып килде. Без бергә яши башладык.

## Репрессия еллары

Мин кинофильмнар карарга ярата идем. Берсен диярлек калдырмыйм. Кайчагында бер кинотеатрдан чыгуга икенчесенә юнәләм. Үземә коньки белән футбол тубы сатып алдым. Хәлдән тайганчы конькида чабам, хәтта мәктәпкә дә шуларда барам. Өйгә арып-талып кайтып керәм һәм шундук йокларга авам. Җәй көне футбол тибәм һәм матчларның берсен дә калдырмыйм. Коньки белән футбол минем хобби иде (ул заманда әле бу сүзләрнең нәрсә икәнен дә белми идек, әлбәттә). Җәй көне яраткан шөгыльләремнең тагын берсе — иртәдән кичкә кадәр су коену. Кыскасы, тормыш үз җаена гына ага иде.

Бу — 1937-1938 еллар. Күп нәрсәне аңламаганбыз икән, чынлыкта бөтен әйләнә-тирәбез «халык дошманнары» белән тулган икән. Күпләрне төнлә белән кулга алып киттеләр. Көн саен кайсы да булса начальникны, депутатны яисә гади эшчене алып китүләре турында ишетә идек. Шахта директорын алдылар, Бандюга фамилияле депутатны да (сайлаулар вакытында аның портреты мәктәп ишеге өстендә эленеп торган иде) бер төнне «кара» машина алмага килгән. Безнең бистә янәшәсендәге юл буенча Макеевкадан Сталино (хәзерге Донецк) шәһәренә таба куылучы күп кешелек колоннаны күрергә туры килде. Аларны кораллы милиционерлар саклап бара иде.

Дүртенчеме, бишенче сыйныфтамы укыганда СССР тарихын өйрәнгән идек. Дәреслек битләрендә маршаллар: Тухачевский, Егоров, Блюхер, Гамарник портретлары төшерелгән иде. Кулга алулар башлангач, алар барсы халык дошманнары исемлегенә кертелде. Һәм без, малайлар, укытучылар күрсәтмәсе буенча, аларның портретларын язу ручкалары белән тишкәләдек, күзләрен чокып чыгардык. Нәрсә аңлый идек соң без балалар?! Балалар гына түгел, өлкәннәр дә ышана иде шул бу уйдырмаларга.

Безне дә кайгы сагалап торган икән: Фатыйх абыйны кулга алдылар. Ул: «Бу власть ялкаулар һәм тел бетләре өчен», — дип уйламыйчарак әйтеп ташлаган, озынколаклар сәгате-минуты белән тиешле урынга житкергәннәр. Абыем бик тә эшчән һәм тырыш кеше иде, шуның өчен аны хәтта житәкчелек соравы буенча, бронь биреп, армия хезмәтеннән дә калдырдылар. Тик системаның канаты аны да аямады.

Абый — стахановчы — төрмәдә утыра, мин — уникe яшьлек бала-чага, ә әниебез урысча бер авыз сүз белми. Шулай да абыйның дусларына кайбер нәрсәләрне ачыклау мөмкинлеге туа. Аны «өчлек» суды хөкем итәчәк икән, ә бу бик куркыныч. Өч кеше үзләре теләгәнчә срок бирәләр. Ул елларда өчлекләр аша миллионнар үтте. Шуннан башка безгә берни билгеле түгел. Билгесезлектә өч ай узды. Беркөнне участок башлыгы Тюрин килде һәм абый өчен исәп-хисап ясауны рәсмиләштерергә тәкъдим итте. Ул моны абыйга тиешле акчаларны алып, без ашыгыч рәвештә туган ягыбызга кайтып китә алсын өчен эшләде. Әни инде олыгайган, бер күзе дә күрми, ә мин әле эшләр өчен бик кечкенә. Юлга жыендык. Билетлар гына сатып аласы калды. Көтмәгәндә, төнге сәгать өчтә, кемдер ишек кага. Мин йоклый идем, әни торып ишек төбенә килгән һәм: «Кем бар анда?» — дип сораган. «Әни, мин бу, ач», — дигән жавап ишетелгән. Әни башта ышанмаган, талаучылар килгән дип уйлаган. Абый аптырагач, тәрәзә каршына килгән, һәм әни, аны күреп, аздан гына һуштан язмаган. Шулчак мин уянып киттем. Эшнең нәрсәдә икәнен аңлап, коридорга йөгереп чыктым һәм тиз генә ишекне ачып жибәрдем. Абый мине күргән шәйгә кочагына алды. Ул арада әни йөгереп чыкты. «Улым!» — диде ул иңрәп һәм икебезне бергә кочаклады. Шул халәттә күпме басып торганыбыздыр, хәзер әйтә алмыйм. Безнең чиксез шатлануыбызны аңлатыр өчен гади сүзләр генә житмәстер. Иртә хәл белергә дуслар, танышлар жыелды. Тюрин да керде. Ул әле расчёт ясамаган икән. Анысы яхшы булды. Абыйны жибәрүләре безнең бәхеткә иде, югыйсә бетәр идек.

## Абыйның гыйшкы

Абый кабат элекке урынында эшли башлады. Хезмәт хакы бик югары. Гаиләбез берничә дә мохтажлык кичерми. Мин гел киногa, циркка йөрим.

Абый һәм аның дуслары шахтада эшләүче кызлар белән очрашалар, аларның тулай торaклары ерак түгел. Абыйга Вера исемле матур гына украин кызы ошый. Мин аның сайлаганын хуплаган идем. Әмма берникадәр вакыттан соң ерак туганнарыбыз һәм якташлар аны татар кызы белән очрашырга кыстый башладылар. «Әниең ничек украинка белән аңлашсын, ул бит татарча гына сөйләшә», — диләр алар. Шулай итеп аны Рәшидә исемле зифа буйлы, сылу татар кызы белән таныштырдылар. Аны беренче күрүдә үк ошатмадым, чөнки ул миңа тәкәббер тоелды. Кызганычка, абыем, Вераны калдырып, Рәшидә белән очраша башлады. Тора-бара ул аңа баштанаяк гашыйк булды. Әйтерсең, тегесе сихерләде. Рәшидә мин укый торган татар мәктәбенең янәшәсендә генә яши иде. Мәктәптән чыгуыма ул инде көтеп тора. «Шамил, син өеңә жәяүләп кайтасыңмы, әллә трамвайдамы?» — дигән була. Биек үкчәле түфлиләре белән

жәяүләп йөрмәс әле дигән уйдан чыгып: «Жәяү», — дим. Ул ашыгып: «Мин синең белән», — ди. Алай икән. «Кире уйладым, трамвайда кайтам», — дип фикеремне үзгәртәм. Рәшидә: «Алайса мин дә трамвайда», — дип кабат әрсезләнә. Инде ачуым килеп, анын белән барырга теләмәвемне анлатам. Тик файдасыз, ул барыбер арттан калмый. Кайтып житкәч: «Федьканы чакыр әле» (татар кызы булса да, абыйны Фатыйх дими), — ди. Үзе өйгә керми. Мин абыйга: «Әнә, бар, килгән анда», — дип урамга ымлыйм. Абый киенә, ислемайлар сөртенә, галстугын тага, егермелек яисә утызлык акчасын кесәсенә салып чыгып китә. Әни алар артыннан: «Ай-һай, хәтта күренергә дә теләмәде», — дип баш чайкап кала.

Тиздән Рәшидә артыннан бер егет йөрүе ачыкланды. Вәли исемле. Рәшидә анын белән очрашырга теләмәсә дә, тегесе үзсүзләнеп йөрүен дәвам иткән. Дуслары белән Фатыйх абый янына килеп: «Әгәр минем кыз белән очрашуларынны туктатмасаң, ахыры синең өчен хәерле бетмәячәк», — дип кисәткән. Шулай да абый белән Рәшидә арасындагы мөнәсәбәтләр үзгәрмәде.

Берчакны Фатыйх абый очрашуга барган жиреннән канга батып кайтып керде. Кулындагы перчаткаларына кадәр канланып, сәер рәвештә тырпаеп торалар. Вәли өч иптәше белән аңа һөҗүм оештырган икән: берсе арттан килеп эләктергән, икесе ике кулыннан тотканнар һәм бармакларын чәйнәгәннәр, Вәли алдан килеп дөмбәсләгән. Ярый әле күзләренә зыян килмәгән.

Абыйны хастаханәгә салдылар. Бер бармагы нык чәрдәкләнгәнлектән, анысын хәтта кисеп ташладылар. Тюрин, ифрат изге жанлы кеше, бу матавыкларны производство травмасы итеп рәсмиләштерде, нәтиҗәдә абыйга дәвалануга һәм иминиятләштерүгә компенсация түләнде.

Безгә Билал абый еш керә иде. Тәбәнәк буйлы, төптән юан чыккан бу абыйдан тулай торакта яшәүчеләр куркып торалар. Сугышканда, ул каршы торучыга башы белән шундый итеп бирә ки, теге инде кабат торып баса алмый. Ул теге дүртлектән абыйның үчен алды һәм «геройлар» һәркайсы хастаханәгә эләкте.

Шул хәлләрдән соң бистәдә чын мәгънәсендә үзара аңлашулар, сугыш купты. Яшәү куркынычка әйләнде. Абый Донецкидан өч чакрым ераклыктагы Пролетарка шахтасына эшкә урнашу турында сөйләшеп кайтты. Аны беркаршылыксыз алдылар һәм, стахановчы буларак, участогы белән йорт бирделәр, махсус кенәгәсенә ай саен премия акчасы яза башладылар.

Йорт жиһазларын жыя башладык. Минем бер дә күченәсем килми иде. Ни әйтсән дә, иялəнгән урын, күптәнге дуслар. Абый: «Кал алайса», — дип көлә. Ничек калыйм? Кайда яшәрмен соң мин?

Бистәдә клуб бар, анда татар эшчеләрен укырга-язарга өйрәтәләр. Үзешчәннәр көче белән спектакльләр, концертлар куела. Макеевка ерак түгел, аннан да милләттәшләр килә. Яшәве күнелле иде.

Күченеп килгәч, шикләнүләрнен урынсыз икәнлеге беленде. Пролетаркада бистәдәгедән ким түгел, чөнки шахта тирәсендә татарлар күп яши. Урамнарда егетләр-кызлар гармун тартып, жырлар жырлап йөри. Алгарак китеп шуны әйтим: сугыштан сонгы авыр һәм юклык елларында да шуннан ким булмады. «Татарлар күнелләрен төшермиләр, бииләр, жырлыйлар», — дип әйтә торганнар иде.

## Көнбатышка!

1939 ел. Совет гаскәрләре азат итү миссиясе һәм Көнбатыш Украина белән Молдавия халыкларының «соравы буенча» аларның жирләрен басып керде. Сонрак Балтыйк буе илләрен дә кушу булды. Ил кинотеатрларында, сеанслар башланыр алдыннан, азатлык алып килүче Кызыл Армияне нинди тантаналы һәм югары энтузиазм белән каршылауларын күрсәтәләр иде (күп еллар узгач,

бу хәрбиләрне оккупантлар дип атадылар, ә бит Бөек Ватан сугышында бу илләрне һәм бөтен Европаны нәкъ менә совет гаскәрләре азат итте, дөньяны фашист коллыгыннан коткарды).

СССР халыкларының тормышында шактый нык сизелгән Финляндия белән сугыш башланды. Кешеләргә «заборный» дип аталган кенәгә тараттылар. Аны күрсәтеп, нормада каралган, җан башына тигән азык-төлек аласың. Ипигә дә хәтта норма каралган иде.

Бу сугышта байтак халык һәлак булды. Элегрәк кинотеатрларда фильм алдыннан сугыш турында документаль кино күрсәтсәләр дә, бу эшне тыйдылар, чөнки кешеләр еш кына экранда үзләренең туганнарын танып алалар һәм залда елау башлана. Әмма иң куркыныч сугыш алда булган икән әле.

## Училище

Хөкүмәтнең «Хезмәт резервлары» турында карары 1940 елда дөнья күргәндә, мин алтынчы сыйныфта укый идем. Ул карарда Сталинның «Кадрлар бөтенесен хәл итә» дигән гыйбарәсе ил буенча канатлыга әйләнде. Шуңа нигезләнеп, һөнәри училищелар, ФЗУлар оештырырга күрсәтмә бирелде, анда укучылар тулысынча дәүләт тәэминатына алынырга тиеш булып чыктылар.

Иптәшләрем: Фәрит Җамалетдинов, Мифтах Камалов һәм Иван Беляевлар белән тимер юл училищесына укырга керергә гариза бирдек, паровоз машинистлары буласыбыз килде. Тик Ветка шахтасының кабул итү комиссиясендә (анда укучылар туплау буенча эш җәелдерелгән иде) безгә биредә 12нче номерлы училище оештырылачагы һәм анда слесарь, токарь, шахта электрослесаре һәм тимерчеләр әзерләнәчәге турында әйттеләр. Мин — слесарьлыкка, Фәрит белән Мифтах электрослесарьга укырга ризалашты, ә Иван яше буенча үтмәде. Иванның әнисе — татар хатыны — улының училищедан соң юллама белән кая да булса дүрт елга эшкә җибәрәләр һәм син аны тиз генә күрә алмаячаксың, дип әнине куркыткан. Куркуга калган әни шуннан соң елап, мине укырга кертмәскә үгетләп маташты. Тик бу мина көлке тоелды. Без документларыбызны тапшырдык һәм 1940 елның декабрендә исемлеккә кертелдек. Училищега ундүрттән алып унсигез яшькә кадәргеләрне алалар иде. Ә миңа ундүрт яшь тулды. Училищеда егерме бишәр кешедән торган егерме группа бар. Мин унсигезенче группага туры килдем. Укырга кызларны да алалар, алар, егетләрдән аермалы буларак, токарьлыкка гына кабул ителә.

Безне Г формасындагы зур һәм ике катлы бинага урнаштырдылар. Икенче катта инвентарьлар һәм кирәкле әсбаплары белән уку класслары урнашкан, янәшәдә үк — яшәү бүлмәләре. Уку программасы сигез һәм хәтта югарырак сыйныфлар программасы буенча алып барыла. Физика һәм геометриядән тыш металл технологиясе, электротехника, слесарьлык эше һәм башка предметлар укытыла иде. Беренче катта кызыл почмак, яхшылап җиһазландырылган спортзал, иркен ашханә һәм башка кабинетлар урнашкан. Яши торган бүлмәдә тимер караватлар (аларның һәркайсына матрац, мендәр, одеял һәм ике простыня тәгаенләнгән) һәм алар янәшәсендә тумбочкалар тора. Бүлмә уртасында дәрес әзерләр өчен зур өстәл урын алган. Группада — уналты һәм хәтта унсигез яшьлек укучылар да бар, яшь аермалары булуга карамастан, алар барысы үзара дус-тату яшиләр.

Укулар ике елга исәпләнгән. Төшкә кадәр классларда теория укытыла, төштән соң мастерскойларга практик күнекмәләргә барасы. Анда һәр профессиягә үз профиле буенча җиһазлар бар. Бөтен җиргә строй белән йөрибез: ашханәгә, дәресләргә, практикага. Мастерскойларга ара ераграк, анда барышлый җыр сузабыз.

Барлык укучыларга форма бирелә. Рәешкә (парадный) кия торганнары: караңгы-зәңгәр төстәге сукно чалбар, ак яки ачык-яшел төстәге гимнастёрка, чүкеч һәм ачкыч эмблемалы тимер сәдәфләр. Гимнастёрка петлицаларына алтынсу-сары РУ-12 билгеләре беркетелгән. Боларга өстәп күн ботинкалар, караңгы зәңгәр шинель һәм солдатныкына охшаш, шулай ук РУ билгесе төшерелгән, зур аеллы каеш тиеш.

Шулай да берчакны ашау яклары начарайды. Май бирми башладылар. Буш вакытыбызда без, гадәттә, үз бүлмәбездә булабыз һәм безнең белән кече тәрбияче (башкача — кече комендант) Клочков әңгәмәләр үткәрә. Ул фин сугышында катнашкан. (Өлкән комендант та бар — Иван Иванович, шулай ук фин кампаниясендә катнашучы. Ул бик таләпчән һәм без аннан курка идек. Группа белән кая барсак та, стройда җырлап атлыйбыз. Әгәр дә җырларга теләмәсәк, ул безне әле гадәти адым белән, әле йөгертеп, аптыратып бетерә иде — җырламас жиреннән җырларсың. Иртәләрен, кышын да, җәен дә, ул юынгычлар янында басып тора һәм шул чагында бил тинентен чишенеп чыкмыйча һәм юеш сөлге белән сөртенмичә генә кара, тиз генә тынычлыкта калдырмый торган иде. Соңыннан, күп вакытлар узгач, Иван Ивановичны рәхмәт сүзләре һәм хөрмәт белән искә төшердек. Без «җитлекмәгәннәрне» чыныктырган һәм характер тәрбияләгән икән бит ул.) Шулай, Клочков безнең белән утыра һәм кинәт замполит килеп керә! Клочков сикереп торып: «Группа, торып бас! Үрә кат!» — дип әмер бирә. Аннары ул группаның тулы составта булуы, безнең белән уку һәм дисциплинага кагылышлы әңгәмә алып баруы турында әйтә. Ә без: «Сәламәтлек телибез, иптәш замполит!» — урынына: «Ашарга телибез!» — дип кычкырабыз. Ул баскан урынында катып калды, бераздан сүзсез-нисез ишеккә ташланды. Клочков, мескен, ап-ак булган. Бүлмәгә өермәдәй булып директор, замполит һәм хәрби эш укытучысы килеп керделәр. «Эш нәрсәдә? Сез үзегезне ничек тотасыз?» — дигән сораулар белән күмеп ташладылар, ачулы карашларын әле Клочковка, әле группа старостасы Хотинга юнәлтәләр. Без, бер-беребезне бүлдерә-бүлдерә, ашау начарлыгыннан зарланырга керештек. Ашханәдә үк инде: «Тары да тары!» — дип тавыш куптарган идек. Ашханә мөдире — яһүд кешесе, икмәк кисүче шулай ук яһүди, Лёва. Алар икәүләп ниндидер махинацияләргә керешкәннәр һәм тукландыру начарайган. Комиссия төзелеп, тикшерү уздырды һәм тиешле рационның киметелүе, еш кына сыйфатсыз ризыкларга алыштырылуы ачыкланды. Ашханә мөдирен һәм тагын берничә хезмәткәрне алыштырдылар. Мөдир итеп бер хатын-кыз билгеләнде, шуннан соң ашау яклары нык яхшырды. Клочковка да эләкте, тик без төркемебез белән аның бу эшләргә бернинди катнашы юклыгын яклап чыктык, шуннан соң аны тынычлыкта калдырдылар. Клочков — сугышчан орден кавалеры — безгә: «Сез нәрсә инде, егетләр, шулай эшләдегез? Миңа алданрак әйтергә кирәк иде», — дип бераз үпкә сүзләре дә белдерде.

Училище тормышы билгеле бер тәртибе белән дәвам итә: иртән йокыдан тору, юынырга бару, урын-җирне җыештыру, аннары — иртәнге аш; иртәнге аштан соң классларга таралышабыз, дүрт дәрес укыгач, төшке аш. Төштән соң — өч сәгать практика, училищега әйләнеп кайткач, буш вакыт. Спортзалда, мәҗбүри программадан тыш, кем нәрсә белән шөгыльләнәсе килә, шуның белән шөгыльләнә. Миңа бигрәк тә бокс, волейбол һәм футбол ошый иде. Төнлә килеп уятсалар да, уйнарга чыгып йөгерергә риза. Кыш көне конькидан төшкәнем юк, хәлдән тайганчы шуам.

Училищеда миңа ошый. Ял көннәрендә, увольнительный бирсәләр, парадный формаларны киеп өйгә кайтабыз. Әлбәттә, увольнительный алу өчен тәртип бозмаска һәм яхшы укырга кирәк. Бәхеткә, минем фамилиям

## СУГЫШ СӨРЕМЕ ҖАНДА УТЫРА

**Сугыш беткәнгә җитмеш ел...**

**Соңгы елларда Бөек Ватан сугышы турында төрле язмалар укырга, чыгышлар тыңларга туры килә. Берәү: «Совет илен немец фашистлары тоташ яулап алган булсалар, безгә — татарларга күп җиңеллекләр бирер иде», — дисә, икенчесе Җиңүгә җитмеш ел тулган көннәрдә бер чарада чыгыш ясаганда, бу көнне: «Так называемый «җиңү» көне», — дип кенә җиппәрә. Бөек Ватан сугышы чорына шикле ревизия ясарга маһирлар бар ул. Безнең арада да, читтә дә. Кем кемнең тегермәненә су коя монда? Җавап эзләп баш ватасы юк.**

**Украинада Совет чоры атрибутларын юк итүгә тотындылар. Иң беренче итеп күренекле полководец Г.К.Жуковның һәйкәлен җимереп аттылар. Андагы хәлләр кем кушуы һәм тоташ контрольлеге астында баруы сер түгел. Дөньяны үзенчә үзгәртеп корырга маташкан яңа дәвер «карчыгалары» немец-фашистларын тар-мар иткәндә, совет гаскәрләренең тоткан урынын кечерәйтеп күрсәтү өчен бернәрсәдән дә чирканмыйлар.**

**Сугыш афәтләрен кичкән авылдашларымны һич онытмыйм. Туган авылым Әмәкәйдән (Мөслим районы) 380 кеше фронтка китә. Шуларның алтысы — хатын-кыз. 253 кеше яу кырында ятып кала. Җиңү яулап авылга 87 кеше кайта. Шулардан 41 кеше — сугыш инвалиды.**

**Күңелемнән нәселебездән яу кырында ятып калган дистәләгән туганымны санап чыгам. Әнкәйнең өч абыйсы да сугыш корбаннары. Бертуган абыйлары Шәйхаттар һәм Шәйхенур һәлак булалар, өченчесе — Мәхмүт абый ике кулсыз әйләнеп кайта. Сугыштан алган яралардан яшьли дөнья куя. Әткәй сугышның беренче көнендә үк яуга китә, фронт юлларын үтеп, Берлинны алып, кырык алтынчы елның башында авылга кайтып керә. Башта кавалериядә, дошман тылында дистәләгән рейдларда катнаша, аннан артиллериядә наводчик була. Өч мәртәбә яралана, госпитальдән, яралары төзәлмәс борын, кабат яу кырына ыргыла. Кыю яугир булганлыгы турында Хәрби архивтан алынган документлар сөйли.**

**Әткәйгә йөз яшь тулып килгәндә, телевидениедән берәү нотык тота: «Чын батырлар алар яу кырында ятып калдылар. Бүген ветеран дип йөрүчеләр каһарманнар түгел...» Әткәй көрсенеп, телевизор каршыннан читкә китеп утырды. «Их, бала, сугышның ни икәнен читтән генә бер күрсәтәсе иде сиңа, — диде ул сыкранып. — Барлык кеше дә сугышта һәлак булып калса, җиңүне кем яулар иде соң? Без үзебез өчен дә, һәлак булганнар өчен дә сугыштык, Берлинны алып, фашистларны үз өнендә тончыктырдык. Ни сөйли бит, башсыз нәрсә!» — диде. Моңарчы сугыш турында сөйләшергә яратмаган әткәйнең җаны кайнаганын сиздем.**

**Маршал Жуковның тууына 100 ел тулу хөрмәтенә (1896-1996) ветераннарга маршал Жуков медален тапшырдылар. Әткәй медальне кулына алгач: «Улым, моны костюмга, сугыш орденнары янына тагып куй әле», — диде. Шаяртып: «Әллә орденнардан да өскәрәк тагыйммы?» — дигән булдым. «Әйе, — диде әткәй ныклы тавыш белән, — иң өстә булсын, Жуков сурәте анда. Җиңү маршалы бит ул!»**

**Факил САФИН**

өлгерүчеләр исемлегендә. Безнең йортыбыз училищедан ерак түгел, чокыр аша гына чыгасы.

Безнең төркемдә читтән килеп укучылар күп. Минем кебек якында яшәүчеләрне өйгә еш җибәрәләр. Ә инде Ветка шахтасы тирәсендә яшәүчеләр, училище шунда урнашканлыктан, өйләреннән йөреп укыйлар. Алар белән безнең арада еш кына сугыш-бәргәләшләр килеп чыга. Фәрит Жамалетдинов белән Мифтах Камаловны еш кына үзләренең группаларында кыерсыталар. Алар мина бу турыда зарландылар. Алар икесе дә кечкенә буйлы. Бигрәк тә Фәрит, ул шунын өстенә конгырт тәнле һәм кысыграк күзле. Аны татар-монгол дип котырталар, кыйнап та аталар. Барлык кыерсытучыларны мин аерым-аерым саклап торып дөмбәсләп ташладым. Начар сугышмый идем, бигрәк тә баш белән. Миннән зарланып директорга житкергәннәр. Чакыртып алып төпченделәр: ни өчен дә фәлән-фәсмәтән. Сүземне өздереп: «Әгәр кимсетәләр икән, жавап бирәм. Минем тәртибем турында группадан яки старостадан сорап белә аласыз, бернидән оялырлыгым юк», — дип әйттем.

(Сугыштан соң Үзбәкстан якларында шахтёр булып эшләгәндә дә үзбәкләрне «хайван», «ишәк» кебек ямьсез исемнәр илә мыскыллаган кешеләр белән каршылыкка кердем һәм үземә дошманнар арттырдым).

Безнең группада музыкантлар күп иде. Араларында гитарада, мандолинада, балалайкада уйнаучылар бар, ә берсе — барабанчы. Үзенә күрә тулы бер оркестр инде менә. Инструментлар да табылды. Буш вакыт булды исә — уйныйбыз. Бик күнелле килеп чыга. Тыңларга башка группалардан да жыелалар, араларында кызлар да бар. Хәзер инде мин группабыздагы егетләрнең барысының исемнәрен хәтерләмим дә, күп еллар узган шул. Истәлекләремне дә житмеш өч яшь тулгач кына яза башладым.

Группабыз футбол командасы белән дә данлыклы иде. Училище буенча оештырылган ярышларда һәрчак беренче урыннарны яуладык. Сонрак, РУның жыелма командасы оештырылгач, мин аның составына алындым. Һөнәри училищеларның өлкә буенча үткәрелгән ярышларында командабыз икенче урынга чыкты.

## Беренче май парады

1941 елда училищебыз Сталино (хәзерге Донецк) шәһәрендә узган 1 Май парадында катнашты. Училище урнашкан Ветка шахтасыннан шәһәргә кадәр булган ара өч чакрым тирәсе. Иртәнге сәгать биштә үк торгызып, парад формаларын кияргә һәм шәһәргә юнәлергә әмер бирелде. Тиешле урынга килеп житкәч, квадрат ясап тезелгән хәрби частьларны: пехотачы, артиллеристлар, очучылар һәм шулай ук милиционерлар вә янгын сүндерүчеләрне күрдек. Алар барысы да хәрби парад башланганын көтәләр. Атлы кавалерия, танклар, тачанкалы пулемётлар да тезелеп баскан.

Ниһаять, озатып йөрүче бертөркем командирлар белән парадны кабул итүче генерал пәйда булды. Ул һәрбер гаскәри төркем каршына килеп, кулын козырёгы янына китерә һәм кычкырып: «Исәнмесез, иптәшләр!» — дип сәламли, гаскәр төренә карап: «танкистлар», «кавалеристлар» һәм башкалар дип эндәшә. Жавап итеп йөзләгән күкрәкләрдән: «Исәнлек телибез, иптәш генерал. Ура! Ура! Уррр-а-аа!» — дигән авазлар яргыла. Төркемнән төркемгә күчә торгач, генерал свитасы белән без басып торган урынга да якынлашты һәм училище курсантларын хезмәт резервлары буларак сәламләде. Аннары хәрби марш башланды. Башта танклар кузгалды, алар артыннан — пулемётлы тачанкалар, кавалеристлар, пехотачылар һәм башкалар тынлы оркестр фанфараларына күмелеп агылдылар.

Шулай итеп, унбиш яшьлек чагымда, гомеремдә беренче мәртәбә хәрби парадта катнашырга насыйп булды. Мин һәрчак, хәрби хезмәт узмыйча, үземне чын ир заты дип саный алмыйм дип уйлый идем. Хезмәт итәргә туры килмәде — хәер, анысы турында алдарак язармын әле.

## Абыйның уңышсыз гаилә тормышы һәм икенче өйләнүе

Тормыш үз җаена ага бирә, укулар да бара. Увольнительныйлар буенча өйгә кайтканда, мин инкүлек аша үтәм һәм табигать күренешләре белән хозурланырга яратам. Бигрәк тә мина күптән түгел генә утыртылган төрледән-төрле агач үсентеләрен күрү ошый. Кайчагында әйләнгечтән, трамвай белән кайтуны да хуп күрәм. Чөнки ул елларда кешеләр арасындагы мөнәсәбәт, аралашу культурасы иң югары кимәлдә иде. Җәмәгать транспортында йөрүчеләрнең үзара сөйләшкәндә бер-берсенә «рәхим итегез», «зинһар утырсагыз икән» дип эндәшүләре колакны иркәли, йөрәккә сары май булып ята иде. Хәзерге заманның рәхимсезлеген, еш кына кешеләрнең бер-берсенә дорфа һәм тупас җавап бирүләрен, җәмгыятьтәге әдәп-әхлак нормаларының тапталуын күреп җан әрни. Үткәндәгеләр белән бүгенгенең аермасы — җир белән күк арасы. Темадан читкәрәк киттем бугай, ярый, монысы сүз уңаеннан гына.

Берсендә шулай чираттагы ялыма кайтып киттем. Өйгә якынлашуга, ниндидер тавышлар ишетәм. Ишегалдында мендәр мамыклары очканы күренә. Җилкапканы ачып керсәм, Фатыйх абыйның ярсып кычкырына-кычкырына түмәркә өстенә одеялдыр, күлмәктер һәм башка ниндидер кием вә урын-җир әйберләре куеп балта белән тураклаганы күзгә ташланды. Бу гайре табигый хәлне күрүдән мин башта тораташ кебек катып калдым, аннары исемә килеп, абый кулындагы балтага барып ябыштым — ычкындырды. Мин балтаны яшелчә бакчасы ягына томырдым һәм... чак кына ниндидер узгынчыга туры китермәдем.

Бу әкәмәт — абыемның хатыны Рәшидә белән соңгы «өй сугышы» булган икән. Рәшидә әнием белән мине үзенә артык йөк дип санаган. Мин инде ярый, училищеда укып йөргәнлектән, өйгә сирәк кайтам. Ул хатын әнине ярым ач тоткан, абый өйдә булганда гына ашата икән. Әни, улы белән килене арасындагы мөнәсәбәтләрне бозмас өчен, беркайчан зарланмады. Рәшидә болар өстенә чын спекулянт та иде әле. Ул елларда кибетләрдә товар күләме нык чикләнгән иде, әйберләр бөтен кешегә җитми дә. Тукымага һәрвакыт чират, кешеләр кичтән үк басып, язылып куя. Ә иртән җан башына метрын биш сумнан унар метр сатин сату башлана. Училищега кергәнче бу хатын мине үзе алган сатинны базарда метрын ундүрт-унбиш сумнан сатарга мәҗбүр итте. Болардан башка ул әле украин ирләре өчен тәгаенләнгән күлмәкләр дә тегә иде. Аларына утыз биш сум сорарга куша, ә мин утыз җиде сум сорыйм, чөнки мин ач һәм һәрвакыт ашыйсым килә. Ул миннән: «Шамил, ни өчен синнән алмыйлар?» — дип сорый. Билгеле инде: «Белмим», — дию белән чикләнәм.

Ул чагында бездә фатирда торучылар да бар иде. Алар әнигә килен кешенең пачкасы-пачкасы белән акча яшерүен күрүләрен сөйләгәннәр. Абый да зур хезмәт хакы алып эшли иде бит әле. Шулай булса да, әни белән мин һәрвакыт ач. Берсендә Рәшидә абыйга: «Ярар, Шамил укырга керде, хәзер әниеңне авылга — Татарстанга кайтарып җибәрергә кирәк, ул бер авыз сүз дә урысча белми, кибеткә чыгып ипи дә ала алмый хәтта. Әгәр шулай эшләмәсәң, мин теге Макеевкада сугышкан егет янына китәчәкмен», — дип белдергән. Болай да юкка-барга гауга чыгарулардан туйган абыйның сабырлыгы шартлап өзелгән. «Әле шулаймыни? — дигән ул. — Алайса, бар, хәзер үк чыгып китә аласың.

Әнием укымаган, инде олыгайган, бер күзе дә рәтләп күрми. Ул минем берәү генә, ә янәшә-тирәдә хатын-кызлар буа буарлык, барысы да синең кебек тә түгел. Әнине мин беркемгә алышмыйм, үзе тыныч, юкка чебенне дә рәнҗетмәс. Монда яшәгән дәвердә аннан берәр начар сүз ишеткәнен булдымы? Юк бит. Бетте, шунда нокта куябыз».

Абый эшкә киткәч, Рәшидә, машина чакыртып, өйдә нәрсә туры килә, барысын рәттән төйи башлаган. Яши торган йортыбыз шахтадан ерак түгел иде. Шахтага төшәр өчен эстакадага күтәрелгәч, абый ишегалдындагы машинаны һәм аңа йорт җиһазларын төяүче кешеләрне күреп ала. Һәм менә мин анын балта белән тураклаган чагына туры килдем дә инде. Әни белән аны чак тыя алдык. Рәшидә төянеп китеп барды. Күпмедер вакыт узгач, Фатыйх абый: «Энекәш, Макеевкага барып, Вераны алып кайтам мин», — диде. Бу анын Рәшидәгә кадәр ошатып йөргән кызы иде. Шулай итеп бишәүләп — Вера, аның бер яшьлек кызы Валя (аны әни Алинә дип атады) һәм без өчәү — яши башладык. Вера искиткеч хатын булып чыкты, әни белән уртак тел таптылар дию генә аз, алар берсе өчен икенчесе җаннарын ярып бирергә дә әзерләр иде. Мин хәл белергә өйгә кайтканда, Вера һәрчак кулыма акча тоттыра, Рәшидә белән чагыштырганда, җир белән күк арасы инде — көне буе базарда сату итеп тә, Рәшидәнең ашарыма бер сумса алып биргәне булмады.

Шулай итеп, йортыбызда тыныч кына бер көйгә агучы шатлыклы тормыш урнашты. Валяны барыбыз да яратабыз. Ә сугыш башланыр алдыннан Гөлсинә туды. Матур һәм тиктормас бу бөтерчекне иркәләп туя алмадык. Бигрәк тә әнинең шатлыгы эченә сыймады.

### Сугыш

Училищеда укулар дәвам итте. Еш кына карьерга — ату полигонына алып баралар, «Ворошиловча төз атучы» значогын алыр өчен тырышабыз. Аннан башка да төрле спорт нормативларын үтәү өчен ярыштыралар, нинди генә юк аларның: «БГТО», «ГТО», «ПВХО» һ.б. Без бу билгеләрне күкрәкләребезгә тактык. Үсмер тормышыбыз училищеда шул рәвешчә акты. Тик алда безне кара язмыш сынаулары көткән икән. Мин комсомолга алуларын сорап гариза яздым. Ул чагында: «Соңрак карарбыз, әлегә яшең житми», — дигән җавап алдым. Барып чыкмады. Безнең территорияне фашистлар басып алды.

***

1941 елның 22 июнендә радиодан сугыш башлануы турында хәбәр иттеләр. Киевны да бомбага тотканнар. Кешеләр, кайда нинди радионокта бар, шул тирәгә җыелып, Совинформбюро яңалыкларын тыңлый. Левитанның тантаналы тавышы ишетелү белән, халык башта шөбһәләнеп, аннары җанланып китеп колак сала. Дикторның: «Дошман җиңеләчәк, җиңү безнең якта булыр!» — дигән сүзләрен ишеткәч, өмет уяна. Ул өметләрнең аклануын барыбыз да беләбез.

Сугыш бара. Кичләрен барлык тәрәзәләрне яктылык күренмәслек итеп томалыйлар яисә утны бөтенләй сүндерәләр. Мәктәптән ерак түгел, үзебезнең көч белән, бомбадан саклану урыны казыттылар. Һава тревогасы игълан итүләр ешайды. Андый чакларда тәрбиячебез Иван Иванович йөгереп керә һәм безне бомбоубежищега ашыктыра. Анда һава тревогасы тәмамланганчы утырабыз.

Химик һөҗүм булу мөмкинлеге турында сөйлиләр, шунлыктан противогазлар төзелешен өйрәнәбез. Иприт, фосген һәм башка газлар турында укыталар. Тормыш тамырдан үзгәрде, тынгысыз һәм моңсуга әйләнде. Хәбәрләрне тыңлагач, бигрәк тә куркыныч булып китә. Дошман бер-бер артлы шәһәрләрне

кулга төшерә. Яралылар тулы эшелоннар көнчыгышка агыла. Инде ярты Украина дошман кулына калдырылган. Көтүләре белән малларны тылга куалар. «Каян сез?» — дигән сорау бирәбез. «Славянскидан, Константиновскидан», — дигән җавап ишетелә. Болар бит инде бездән ерак түгел! Якындагы мәктәп яралылар белән тулган. Яшь кенә егетләр: кемнеңдер аягы юк, кемнеңдер — кулы, ә кемдер күзсез калган. Кайберәүләр бинт белән уралып беткән, кешене танышлы да түгел. Тәннәр чемерди! Яңадан бер партия яралыларны алып килгәч, якындарак яшәүчеләрне җыеп: «Өйләрегездә яшәрсез һәм шахтаның мастерскойларында эшләрсез», — дип белдерделәр. Болар яралылар өчен, без яши һәм укый торган бүлмәләрне бушату өчен эшләнде.

Мастерскойда эшчеләргә насослар һәм башка шахта җиһазлары ремонтлауда булыша башладык. Аннары безгә шомартыр өчен ниндидер кечкенә детальләр алып килделәр. Нәрсә икәнлеге белән кызыксынгач: «Гранаталар өчен бөҗралар», — дип җавап бирделәр. Фронт хәбәрләре көннән-көн шомлырак төс алды. Безнең гаскәрләр дошманга көчле каршылык күрсәтсә дә, бер-бер артлы кала вә салаларны калдырырга мәҗбүр иделәр.

Фәрит белән Мифтах һәм мин, училищены тылга эвакуацияләр икән дигән хәбәр ишетеп, моның дөреслеген белү максатыннан, замполитка мөрәҗәгать иттек. Ул безгә кырыс кына: «Вакыты җитәр, әйтербез», — дип җавап бирде. Фашист инде гел якында дигән хәбәр таралып, кабат училищега йөгердек. Анда янә: «Паника куптарып йөрмәгез, хәрби вазгыять вакытында бу куркыныч нәрсә», — дип кисәттеләр. Өйгә кайтырга куштылар. Аннары училищены алып китәннәрен ишетәбез. Шул якка ташланабыз, ә анда ташлап калдырылган кәгазь кисәкләрен куалап җил генә уйный. Шул тирәдә яшәүчеләрдән тәнлә киткәннәрен белдек. Ул чагында йортларда телефоннар юк иде шул әле. Ашыгыч әмер килеп төшкән — бернәрсә эшләргә өлгермәгәннәр. Станциягә йөгердек, дежурныйдан безнекеләрне кая озатуларын сорыйбыз. Ул: «Малайлар, барыгыз, эшләргә комачауламагыз», — дип кулын селти. Бөтен җир төрле йөк һәм җиһазлар төялгән эшелоннар белән тулган. Без янә дежурныйга тагылабыз. Шул училищедан икәнебезне кабат исенә төшерәбез. Аның вакыты юк, үзе бик каудар. «Нишләп калдыгыз соң, комачауламагыз дип әйттем ич инде. Сез нәрсә, шпионнармы әллә?» — дип инде бу юлы ачулы эндәшә. Аптырашып бераз басып торгач, вагоннар тирәсендәге сак өстенә сакны күреп, анда үтә алмаячагыбызны аермачык төшенгәннән соң, кире өйгә кайтып китәбез.

***

Тиздән бистәдәге барлык шахтёрларны җыйдылар. Хезмәт хаклары булгандырмы — акча өләштеләр һәм барсын да танкка каршы чокырлар казырга җибәрделәр. Шахтаның шактый өлешен шартлатканнар иде инде, котельныйны да шартлаттылар. Тимер юл рельсларын да шартлатулар дәвам итте. Әмер шундый: ни-нәрсәне алып китәргә мөмкин, алып китәргә, мөмкин булмастайны — шартлатырга! Берни дә дошманга калырга тиеш түгел. Күпләр китә алмыйча калды. Тимер юллар артыгы белән тулган, ә автомобильләр ул чагында әле бик аз. Булганы да фронтка кирәк. Коммунистларның күбесе китмәде. Аларны немецлар, басып алгач, беренчеләрдән булып аттылар.

Бераз артка чигенеп, училищеда укыган вакытка әйләнеп кайтырга телим. Сугыш башланган иде инде. Немецлар СССР территориясенә ыргыла. Мин шахта янында калкып чыккан — террикон дип аталучы — буш породалардан өелгән тауга менәргә иялэнеп киттем. Әлеге шахта 1928 елда ук ябылган. Сөйләүләренә караганда, аны халык дошманнары — троцкистлар шартлаткан. Ул заманнарда әгәр берәр төрле шартлау яисә авария килеп чыкса, аны «халык

дошманнары» эше дип әйтәләр иде. Шпиономаниягә багышлап бихисап кинофильмнар да төшерелде. «Инженер Кочинның хатасы», «Чик йозакта», «Зур тормыш» — шуларның кайберәүләре. Совет властеның җиңүләре, гражданнар сугышындагы кызыллар белән акларның сугышулары турындагы фильмнардан «Чапаев», «Щорс», «Сергей Лазо», «Пархоменко» дигән киноленталар аеруча популяр; «Ленин 1918 елда», «Ленин октябрьдә», «Без Кронштадтан» фильмнары һ.б.лар яшьләрне эчке һәм тышкы дошманнарга каршы тору өчен берләштерүдә, аларны патриотизм һәм Ватанга бирелгәнлек рухында тәрбияләүдә колоссаль тәэсир итү көченә ия булды. Алардан башка әле без «Сазлык солдатлары» һәм «Оппенгейм балалары» фильмнары карадык. Аларда фашистик Германиядә барган вакыйгалар һәм ничек итеп яһүдиләрне газаплаулары вә юк итүләре сурәтләнә. Соңрак язмыш минем үземне кинода күргән түбәнсетү-кимсетүләрне кичерергә мәҗбүр итте. Шулай да мин исән калдым.

Ярый, хуш, тауга әйләнеп кайтыйк. Мин еш кына яраксыз күмер тавының иң очына, кош оча торган биеклеккә үрмәли идем. Аннан искиткеч панорама ачыла! Хәтта Сталино каласы һәм якын-тирәдәге бистәләре белән шахталар күренә. Торып басам да әйләнә-тирәне озаклап күзәтергә керешәм. Һәм мина бик тә, бик тә моңсу булып китә. Ни өчен икәнен үзем дә аңламыйм. Утыргач та әле күзәтүләремнән туктамыйм. Ни өчендер башка бу күренешне күрә алмамдыр кебек тоела. Кайчагында, утыра торгач, мин вакыт исәбен дә югалтам. Безнең группадан кайбер малайлар тулай торактан чыгып: «Ханифов, төш инде, тәрбияче килде», — дип кычкыралар. Тәрбияче үзе дә гаҗәпләнеп: «Нишлисең син анда? Еш кына шунда күтәреләсең», — дип сорый. Ә мин: «Карап торам», — дип җавап бирәм. «Ярый, бер карадың, ике. Гел анда югалып торып булмыйдыр бит инде?»

Мин моның сәбәбенә үземне Германиягә алып киткәч кенә төшендем: кешегә алдагы тормышындагы үзгәрешләрне яисә үзен сагалап торган бәхетсезлекләрне алдан сизенү хас икән. Минем белән дә шулай булды. Язмышыңнан кача алмыйсың шул.

## Дошман һаман якыная

Бистәдәге шахтёрлардан ополчение отрядлары төзи башладылар. Аларны көн саен клуб янына җыеп стройда йөрергә һәм хәрби әзерлек эшләренә өйрәтәләр. Без — 15-16 яшьлек малайлар — аларны карарга киләбез, аларның «пичәтле» адым белән йөрергә тырышуларын, корал сүтеп-җыю белән шөгыльләнүләрен читтән генә күзәтәбез. Алар еш кына күмәкләшеп «Катюша», «Өч танкист», «Зәңгәр яулык», «Үзәннәр, урләр буйлап» һәм башка җырларны җырлыйлар.

Бистә тынып калды. Кибетләр ябылган, сәүдә дә гөрләми. Баштарак милиционерларның саклап йөргәннәре күренә иде, соңрак алар да югалды. Беркөнне кибетләрне талый башлаганнарын ишеттек. Ишекләрен ватып, ни туры килсә, шуны ташыйлар, имеш. Боларга милициянең югары чиннарыннан берәүнең: «Без китәбез, дошманга эләккәнче, үзебезнең халык файдалансын ичмасам», — дип әйтеп калдырган икән дигәннәре дә килеп өстәлде. Без житешеп килгәндә, витриналар ватылган һәм инде бушап калган иде. Шулай да кәтүкле җепләр һәм кабы-кабы белән энәләр күренә. Без — малайлар — аларны кирәксенмәдек, яраксыз нәрсәләр итеп кенә карадык. Ялгышканбыз. Аларның да товар икәнен каян белик ди. Әйләнеп килгәндә, аларны инде кемдер алган иде. Аны украин авылларында кукуруз, арпа, бодай ише культураларга алмашып булу мөмкинлеген кем уйлаган.

Берничә көн тыныч торды. Безнекеләр дә, фашистлар да юк. Тимер юл ягында да тынлык урнашты, моңа кадәр шартлаулардан колаклар тона иде. Рельсларны һәм юллардагы күперләрне шартлаттылар.

Танк чокырлары казырга киткән җирләреннән шахтёрлар әйләнеп кайтты. Алар эшләгән чакта, көтмәгәндә арттан немецлар килеп чыгып, автоматлардан ут ачканнар. Кешеләр йөзтүбән җиргә капланып ятканнар. «Рус, кайтып кит!» — дип кычкырганнар дошман солдатлары. Кайтып китүдән башка чара калмаган.

Без — берничә малай — шәһәр белән тимер юл станциясен тоташтыручы олы юл кырыена урнашып, ерактан гына туктаусыз агылучы хәрби техниканы, гаскәрләрне күзәтәбез. Арада немец кына түгел, итальян, румын частьлары да бар. Безнең тирәдә бәрелешләр булмады. Шәһәрдә дә җимереклекләр аз иде. Безнекеләр зур каршылык күрсәтмичә генә чигенде.

Сонрак, немецлар барлык кешене шәһәрдәге хезмәт биржасында теркәлергә мәҗбүр иткән вакытта, сугыш алдыннан гына җиткерелгән Тарас Шевченко исемендәге кинотеатрның өлешчә зыян күрүен ишеттем. (Аннан башка тагын берничә бина җимерелгән, диделәр.) Шул һәм шәһәрнең икенче башындагы «Комсомолец» кинотеатрына, сугышка кадәр, кинофильмнар карарга еш йөри идек. Сеанслар иртәнге сәгать уннан башланып, төн уртасына кадәр диярлек дәвам итә иде. Һәр сеанс алдыннан балалар өчен оркестр уйный. Яхшы вакытлар иде ул. Мин һәрчак җәнлекләр бүлегенә, көлке бүлмәсенә, төрле күңел ачуларга керергә тырыша идем. Болар бөтенесе бар иде һәм менә кинәт кенә бөтенесе юкка чыкты.

## Оккупация

Оккупантлар килде. Урам буйлап һәр йорт ишегалдына кереп йөриләр. Этләр өрә, улый, чиный һәм тавыклар кыткылдаганы ишетелә. Немецлар этләрне аталар, тавыкларны тоталар. Әгәр тота алмасалар, аларны да аталар. Этләрне атып бетерделәр диярлек.

Бистәдә өлкән яшьтәге һәм авыру, Кудрявцев фамилияле кеше яши иде. Аны һәм Войцеховский дигән тагын берәүне атып үтерделәр — коммунист булганнары өчен.

Безнең өчен кара көннәр килде. Ашарга юк, ут һәм су да юк. Өйне ягып җылытырга да берни калмады. Суны ерактагы буадан алып кайтышлы. Без — абый, аның хатыны һәм ике кызы, әни белән мин — алтау, бернинди запассыз. Әле немецлар килгәнче үк продуктлар норма буенча бирелә иде, алар көннеке көнгә ашалып бетеп бардылар. Немецлар бистәгә 1941 елның 25 октябрендә килеп керделәр.

Азык эзләп колхоз (элекке) кырына чыктык. Сугылмыйча калган урыннар да бар. Кукуруз басуына юлыктык. Каралып өши башлаган кукуруз чәкәннәрен ашыгып капчыкларыбызга тутырабыз. Тик җилкәгә күтәреп күпме генә алып китәргә мөмкин соң?.. Өйгә кайткач, орлыкларны кабыгыннан арындырып, кыздырып ашадык. Ике утын агачы һәм чуен пластинканы яраклаштырып, кул тегермәне әмәлләдек һәм анда кукуруз оны тарта башладык. Хәер, он дип әйтмәсәң хәтере калыр — эре ярма кисәкләре иде. Хатын-кызлар аннан кабартмага охшаш ризык пешерделәр. Ябышмасын өчен, табага юка гына итеп солидол сөрттеләр. Кечкенәләр өчен бездә әле бераз ак он калган иде, анардан пешерелгән коржиклар бары аларга гына.

Ашарга берни калмагач, өйдәге савыт-саба, урын-җир һәм кием-салымнан кайбер әйберләрне алып, абый белән Украина авылларына чыгып киттек. Аларны арпа, бодай, кукурузга алмаштырабыз. Кайчагында көнбагыш маена да алышу бәхете елмая. Бер баруда кул чанасына салып ике-өч пот азык-төлек алып кайтабыз һәм кабат юлга чыгабыз. Ана кадәр, хатын-кызларга авырлык китермәс өчен, җиде чиләк сыешлы кисмәккә су ташып калдырабыз. Сарайны сүтеп утынга файдаланырга туры килде.

Шәһәрнекеләр, озын чылбыр хасил итеп, авылларга агылдылар, барсында кул чаналары. Сугышны исән-имин чыкканнар кырык бердән кырык икенче ел кышының кырыс икәнлеген хәтерлиләр булыр. Баштарак 30-40 чакрым ераклыкка йөрсәк, сонрак — 40-50, аннары 100-150 чакрымга кадәр китә башладык. Әйләнеп кайтулар бер атнадан ике атнага кадәр сузылды, чөнки якын-тирәдәге авылларда инде алыр әйбер дә калмады.

Юллар халык белән тулы: кемнәрдер азык эзләп чыккан, кемнәрдер инде шәһәргә кайтып килә. Бөтенесе авыл кешеләреннән кунарга кертүләрен сорый; һәр авылда юлаучыларга төн куну өчен махсус йортлар бирү гадәткә керде. Кул чаналарын ишегалдында калдыра, ә капчыкларын үзләре белән ала юлаучылар. Өй эчендә борылырлык та урын калмый, кисмәккә балык шыплап тутырылган кебек. Йоклау урыны — идән. Ягылмаса да, шундый кысанлыкта салкынлык сизелми. Әмма иртә белән начар истән баш авырта.

Берсендә, төн уздырып чыккач, без чанабызны калдырган урынында тапмадык. Инде нишләргә? Ике капчык орлыгыбыз бар. Хуҗалардан бау сорап алып, рюкзакка охшаш әйберләр әзерләдек. Әле тагын илле чакрымлап ара үтәсебез бар иде.

Барган чагында немецларның юлда батып яткан җиңел машиналарын күрдек. Машина эченнән аюдай олы гәүдәле немец хәрбие чыкты, икесе кабинада селкенмичә утыра. Алыптай фриц безгә, кул хәрәкәтләре белән, машинаны этәргә куша. Этәбез, этәбез — селкенми дә, каһәр. Эчтән янә бер мәлгуне чыкты. Күнитекләре өстеннән әллә ниткән сәер аяк киеме киеп куйган. Җылырак булсын өчендер инде. Алар бездәге салкыннарга чыдый алмыйлар һәм нәрсә туры килсә, шуны киеп, бакча карачкысына охшап калалар. Еш кына гади кешеләрнең дә киемнәрен тартып алалар. Шуңа күрә күпләр иң начар киемнәрен кияргә тырыша, салдырмасыннар гына. Немецлар өчен барыбер, кеше салкында анадан тума шәрә калса да исләре китми, автомат белән янап, үзенә кирәген ала да ары китә. Кешеләрнең сәләмә киенүләренең икенче сәбәбе — юньле-рәтле өс-башының калмавында, чөнки алар инде күптән азык-төлеккә алыштырылган. Авылларда да запаслар төкәнеп килә. Сугыш узган җирләрдә колхозчылар иген-таруны җыеп алырга өлгермәделәр һәм бар нигъмәт кар астында калды. Җыеп алганнарын исә немецлар тартып алды...

Шулай итеп, юлдагы фрицлар кычкыра-кычкыра үзара нидер сөйләшәләр. Аннары берсе кулын селтәп куйды. Мин моны китәргә рөхсәт дип аңладым һәм борылып, ике потлы капчык авырлыгыннан бөкрәйгән хәлдә, китү ягына атладым. Ничә генә адым атлаганмындыр, шулчак артыма китереп тибүдән берничә метр карны сөреп, чәчрәп барып төштем. Бусы гына җитмәгән, капчыгым аерылып, бөтен орлыгым чәчелде. Түзмәдем, каты итеп сүгенеп җибәрдем. Фриц миңа кабат китереп типте. Мине якларга абыем чабып килде. Ул арада немец кобурасыннан пистолетын тартып чыгарды да атып җибәрде. Кая атканын да аңышмадым, тик абыем исән-сау һәм бернинди ярасы да күренми иде. Икенче бер немец кулы белән селтәнеп нидер кычкырды. Якынлашып килүче кешеләр төркеменә күрсәтә икән. Барыбызны бергә әйдәкләп, машинага килеп ябышырга мәҗбүр иттеләр. Мотор үкерә, без җан-фәрман тырышабыз. Ниһаять, этеп чыгардык. Фрицларның нәрсә уйлаганнарын кем белгән — арадан берсе машина тәрәзәсеннән атып җибәрде, ярый әле беркемгә тимәде. Һәм алар китеп бардылар. Минем иген орлыгым кар белән буталып беткән иде, аның бик азын гына җыеп ала алдым. Капчыкта аз-маз калганы белән бергә ун кило чамасы йөгем тупланды. Энә белән җепне үзебездән беркайчан калдырмый идек, капчыкны тегәр өчен миңа кайчан кирәге чыкты. Фашистлардан беренче «сабак» алуым шулай тәмамланды.

## Азык эзләп

Азык эзләп оештырылган походларыбыз Донецк өлкәсеннән Запорожскига һәм аннан Днепропетровск өлкәсенә күчте, хәтта Гуляй-Полега да барып чыктык. Аны кайчандыр батько Махнонын «башкаласы» булган, диләр. Берсендә Красноармейск тимер юл станциясе аша үткәндә, коточкыч күренешкә тап булып, чәчләр үрә торды: дар агачына асылган алты кешенең яланаяклы, салкында бозланып каткан гәүдәләре жилдә чайкалып, бер-берсенә бәрелүдән ямьсез чыкылдау авазлары чыгара иде. Фашистларның андый җинаятьләрен байтак очратырга туры килде. Кешеләр юлда да күп катып үлделәр. Еш кына тунган һәм ачыккан адәм баласы азрак ял итеп алырга дип утыра һәм ничек йоклап киткәнен дә сизми, шуннан инде, бичара, уянмый да.

Тагын бер эпизод. Маршрутыбызны үзгәрттек. Юлыбыз Селидовка районына, анда кадәр кырык чакрым булыр. Көннәр инде нык кыскарган иде, һәм без район үзәгенә барып җитә алмадык, чөнки оккупацион властьларның күрсәтмәсе буенча караңгыда хәрәкәт итү тыела. Карповкага кадәр килеп җиттек. Бу — немец авылы. Монда күптәннән Украинага күчеп килгән немецлар яшәгән. Тик анда бер җан иясе дә калмаган. Сугыш башлану белән, аларның барсын җыеп тирән тылга — Казахстан, Урта Азия якларына озатканнар. Соныннан гына кырым татарлары, чечен-ингушлар, карачайлар, калмык һәм башка бик күп халыкларның да шундый ук ачы язмышка дучар ителүен белдек. Сталин һәм аның режимы күп халыкларның язмышын «кайгыртты» шул, сугыштан соң да бик күп еллар туган якларына кайтырга тилмереп яшәде алар.

Әйтүемчә, Карповкага җитүгә караңгы төшкәч, барырга куркыныч дип, ошбу авылда төн кунарга ниятләдек. Беренче очраган йорт ишегалдына үттек — беркем күренми. Өй эченә кердек — буп-буш. Ниятебез — төнне уздыруга, кабат юлга чыгу. Күзәтү уздыргач, йорт эчендәге барлык нәрсәнең нәкъ хуҗалары яшәгән вакыттагыча — кузгатылмаган да икәнлеген ачыкладык. Хәтта сарайда тавыкларга кадәр йөри. Украина һәм Идел буенда немецларның Екатерина II заманнарыннан ук күченеп яшәүләрен ишеткәнебез булса да, аларның йорт вә хуҗалыкларын ни рәвешле алып баруларын белми идек — җай чыкты. Өйдән чыкмыйча гына чардакка, сарайга, базга һәм башка җирләргә эләгеп була икән. Чардакка менсәк — андагы бодай запасын күреп шаккаттык. Ашыгып капчыкларыбызга бодай тутырдык. Ишекне яхшылап эчтән терәттек тә йокларга яттык. Иртә белән иртүк торып кайтып китәргә исәбебез. Төнлә ишегалдына бер көтү немец солдатлары килеп керде. Хәтта сулаудан туктадык. Алар ишекне этеп-этеп карадылар да бераз читкә киттеләр, аннары җилкәләре белән кабат бәреп ачарга омтылдылар. Алай да булмагач, нишләптер ватып кермәделәр, чаналарына печән төяп китеп бардылар. Төннең калган өлешен үзебезне энә өстендә утыргандай хис итеп чыктык. Әгәр безне орлык тулы капчык белән күргән булсалар, һичшиксез, атачаклар иде.

Иртән, таң сызылыр-сызылмас, капчыкларны күтәреп урамга чыктык. Барабыз, авылның һаман чиге күренми. Һәм менә инде чыгып життек дигәндә, каршыбызга винтовка тоткан һәм беләгенә ак чүпрәк бәйләгән кеше килгәнлеген күрдек. Абыем белән миннән башка безнең бистәдән тагын берәү бар иде. Ул чак кына капчыгын ташлап йөгереп китмәде. Соңыннан әйтүенчә: «Качып кая бара алам соң, дип уйладым», — ди. Абый шул чагында гаҗәп салкын канлылык күрсәтеп, ишетелер-ишетелмәс: «Тыныч, тыныч булыгыз, курыкканыгызны күрсәтмәгез», — дип кабатлады. Мылтыклы кеше безнең белән тигезләшкәч, капчыкларны капшап: «Бодаймы?» — дигән сорау бирде. Абыем тыныч кына: «Әйе, бодай. Соңгы костюмымны алмаштым», — дип

жавап бирде. Мылтыклы: «Каян килешегез?» — дип төпченүен дәвам итте. «Селидовкадан», — ди туганым. Каравылчы (ул кизүлек итүче иде бугай) Селидовкадан Карповкага кадәр булган ун чакрым араны ничек шулай тиз үтә алуыбызга гаҗәпләнә, карангыда йөрергә рөхсәт ителмәвен ул яхшы белә. Без, сәгатебез булмаганлыктан, вакытның күпме икәнлеген белмәвебезне һәм, яктыра дип уйлап, иртә чыгуыбызны аңлатабыз. Ул беравык уйланып басып торды һәм: «Йә, ярар, барыгыз», — дип әйтеп куйды. Бу — шушы авылда яшәүче һәм украин телен яхшы белүче немец булган икән. Авыл халкын кыска гына вакыт эчендә сөргенгә куалап киткән НКВДчылардан ничек котылып кала алгандыр, анысын бер Алла белә.

Безгә, әйтерсең, канат куйдылар: йөгереп диярлек кайтабыз. Өйгә кайтып житкәч, йөгебезне үлчәп карасак, бодайның утыз кило икәнлеген белдек. Абый, гаҗәпләнеп: «Нык, син, энекәш. Нык», — дип соклануын яшермәде. Чынлыкта, ялга туктагач, урынымнан чак торып китә алган идем, аякларым сызлады. Әнә шул курку дигән нәрсә безгә көч өстәп, һаман алга куалады. Арттан эзәрлекләп чыгуларыннан да шикләндек. Нәтиҗәдә инде без кичкә өйдә идек. Әни белән җингинең гаҗәпләнүенә чик-чама юк: «Әле болай тиз әйләнеп кайтканыгыз юк иде», — диләр. Куанудан йөзләреннән елмаю китми. Мул итеп бодай боткасы пешерделәр, бодайны кыздырып та ашадык. Зур запас барлыкка килде. Ә салкыннар һаман саен көчәйде. 1942 ел якынлаша иде. Алмашырлык әйбер-сәйберләр дә бетеп килә. Болай дәвам итсә, тиздән берни калмаячак.

Минем язмаларым хронологик эзлеклелек белән язылмаган. Әгәр моннан 25-30 еллар элек кенә яза башлаган булсам да, конкретрак килеп чыгар иде. Бигрәк күп вакыт үткән шул. Вакыйгалар хәтердән әле жуелалар, әле калкып чагалар. Кайбер хатирәләр беркайчан да онытылмыйлар. Йокларга яткач, коточкыч эпизодлар күз алдыннан уза, йокы кача. Оеп киткәч, төшкә әллә ниләр керә. Сикереп торып кычкыра башлаганымны үзем сизмим дә. Иртә белән хатыным: «Бүген төнлә тагын бастырылдың», — ди. Менә шундый хәлләр.

## «Сез миңа туганнарым кебек...»

Бер эпизодны калдырганмын икән. Вакыйга 1941 елның октябрь-ноябрь айларында булды, инде оккупация вакытында. Бездән ерак түгел Сталино станциясе белән шәһәрне тоташтыручы шоссе юлы үтә иде. Өйдә утырабыз, урамга яктылык төшмәсен өчен тәрәзәләр одеял белән томаланган. Әгәр яктылыкны немецлар күреп алса, тәрәзәгә аталар. Яктылыкны сирәк кулланабыз. Кулланганда да консерв банкасына трансформатор мае салып, аңа фитиль урынына чүпрәк жгут батырабыз. Майны шахта ишегалдыннан тапкан идек, аны бик экономияләп — балалар төнлә елап уянганда гына яндырабыз.

Йокларга жыена идек. Сирәк кенә ату тавышлары ишетелде. Аннары ул көчәеп китте дә кинәт тынып калды. Нәрсә булыр икән? Шулчак кемнеңдер сак кына тәрәзә какканы ишетелде. Абыем «лампаны» сүндерергә кушты. Вера ул әйткәнне үтәде. Абый одеялның бер читен ачып урамга күз салды, ә анда — кеше, кул хәрәкәтләре белән нидер аңлатмакчы була. Абый тәрәзәгә капланды, урамдагы затның аңа татарча эндәшкәне ишетелде. Абый ишеккә таба атлады. Әни белән Вера аны туктатмакчы булдылар, тик ул тыңламады, урамга чыгып китте. Хафага төшеп көтәбез. Андый чакта минутлар сәгать булып тоела. Ниһаять, керделәр. Юлаучы какча гәүдәле, нык талчыккан күренә, өс-башы да пычракка баткан. Ул татарчалап исәнләшкәч, урындыкка утырды һәм тирән итеп тын алды да идәнгә ауды. Абый хатыны белән икәүләп аны кухня ягындагы ятакка кертеп салды. Икенче көнне иртән ул инде юынган-чистарынган,

гражданский киемгә киенгән. Һәм бездән гафу үтенә. Без аның кем икәнен дә, каян килгәнен дә белмибез. Абый бөтенебезне җыеп кисәтеп куйды: «Сез беркемне күрмәдегез, аңладыгызмы? Авызыгыздан бер сүз чыкмасын. Әгәр ялгыш кына сыңар сүз ычкындырсагыз да, баш бетте дигән сүз. Бу бигрәк тә сиңа кагыла, Шамил. Дусларыңа сер итеп тә ача күрмә». Абый үзе дә бу кешене белмәвен әйтә: «Аңа кыен, вакытлыча яшәп торсын инде», — дигән була. Бераз бөгештерә, аның турында нидер белә ул.

Чардак почмагында аның өчен чүпрәк-чапрак һәм саламнан ятак өлгерттек. Хәер, мин моны соңыннан күрдем, ә әлегә абый анда барырга рөхсәт итмәде. Ул кеше бездә шактый озак яшәде. Көннәр суыта башлаганда, ул инде ярыйсы ук ныгыды, тазарып китте, кыскасы, гадәти кешегә әйләнде. Алар абый белән еш кына сөйләшеп утыралар, тик нәрсә турында — анысын белмибез. Аның кем булуын шулай да сизенә идек, чөнки ул безгә кергәндә, өстендә тузып-таушалып беткән хәрби форма иде. Аны мичтә яндырдылар. Абый аның кияренә фуфайка, бүрек һәм җылы чалбар бирде. Ул безнең белән саубуллашып киткәндә, барыбызга да рәхмәтләр укыды. Күзләрендә яшь иде аның. «Белегез, мин көчсезлектән түгел, шатлыгымнан, сезнең миңа күрсәткән игелегегездән күңелем тулып елыйм. Әгәр мин фронт сызыгын узып, исән-сау калсам, сугыштан соң сезне, һичшиксез, эзләп табармын! Сез миңа туганнарым кебек», — диде ул һәм караңгылыкка кереп югалды.

Соңыннан абый аның каян килеп чыгуын бәян итте. Кызылармияче әсирләр колоннасын Сталино станциясеннән шәһәр ягына куалыйлар. Хәлсез яисә яралы солдатлар егылса, фашист конвоирлары аларны юл буенча атып барганнар. Икенче көнне яктыруга, якын-тирәдә яшәүче халыкның атып үтерелгән әсирләрнең күплегеннән исләре киткән. Бичараларны җыеп, якындагы ерганакка җирләгәннәр (сугыштан соң анда һәйкәл куелды). Шуннан шул: фрицларның егылган сугышчыларны атуыннан файдаланып, безнең таныш булмаган танышыбыз җаен туры китереп сузылып ята, колонна ары китә. Караңгы төшә. Озак ята әле ул аяк тавышларының тәмам тынганын көтеп. Аннары торып, безнең бистәгә китә, күршебездә яшәүчеләрнең тәрәзәсен кага. Анда өлкән яшьтәге урыс кешеләре яши иде. Алардан татарларның кайда яшәве белән кызыксына. Безнең йортны күрсәтәләр. Калганы инде билгеле. Әлбәттә, күршеләр качкынның бездә яшеренеп ятканын белгәннәр, әмма бу турыда беркемгә дә әйтмәгәннәр. Ышанычлы, олы җанлы карт белән карчык иде алар. Ул чагында әгәр кемне дә булса яшереп яткырганыңны сизсәләр — аталар. Бу хакта кая карама комендатураның белдерүләре эленеп тора: хезмәт биржасында исәпкә басмасаң — аталар, төнлә урамда йөрсәң — аталар һ.б. Күпләр биржага бармый, чөнки оккупантларга эшләргә теләмиләр иде. Шуңа күрә теләсә кайчан килеп атып үтерергә мөмкиннәр. Әнә шулай яшәдек инде.

## Әнием белән икәү генә...

Бодаебыз аз калды, әйберләр дә бетеп килә. Тиздән ризык юнәтер өчен алышырлык нәрсәбез дә калмаячак. Кышның зәмһәрир салкыннары, аның арасында күз ачкысыз бураннары — хет өеңнән чыкмыйча утыр. Абый белән Вера хәлдән чыгуның төрле вариантларын эзлиләр. Ахырда абыйның хатыны, анык фикергә килеп: «Әйдә, Федя, авылга, минем әти-әни йортына кайтыйк, югыйсә, без монда бетәчәкбез», — ди. Аларның яши торган җире моннан өч йөз чакрымдагы Днепропетровск өлкәсенең Шандровка авылында. Анда кадәр ничек кайтырга? Уйлаша торгач, әни белән мине әлегә монда калдырырга, ә алар балалары белән кайтырга булдылар. Язга чыккач, Фатыйх абый безне килеп алачак.

Шахта котельные тирәсендә мин ташкүмер өеме тапкан идем. Ул, котельный торбасын шартлатканда чәчелгән кирпеч ватыклары астында калганлыктан, кеше күзенә чалынмаган. Без өйгә берничә чиләк ташып житештек, калганнарын башкалар күреп ташып бетерделәр. Мин тагын металл угольниклар да табып алдым һәм, мичкә ташкүмер ягып, угольниклардан кул чанасы ясау хәстәренә керештем. РУда слесарьлыкка укуым бик тә ярап куйды. Инде мин ачкычлар, табалар ясау, чиләк төпләү серләрен дә белә идем. Тимер чананы зур итеп ясадым, чөнки анда яхшылап төрелгән сенелләремне утырту өстенә кайбер кирәк-яракны да төяргә кирәк иде. Абый белән хатыны, чанага тагылган бауга икәүләп жигелеп, тартып киттеләр. Юлда нинди мажараларга очрап, күпме булганнардыр, анысын әйтә алмыйм, тик алар Шандровкага кайтып житкәннәр.

Әни белән икәү генә калдык. Мина тагын ризык эзләп авылларга чыгып йөрергә кирәк. Хәзер инде бик еракка барасы. Әни өчен кисмәкне су белән тутырып куям, ташландык йортлардан ягар өчен такталыр-утындыр ташыйм. Әни ялгызы кала. Мин өйдәге иң соңгы әйберне — училищеда бирелгән шинельне алып, юлга чыгам. Әйткәнемчә, якын-тирә авылларда сөйләшеп тә тормыйлар — кире боралар. Ниһаять, йөри торгач, шинельне ике чиләк үрә башлаган бодайга алыштыра алдым. Кайтканда ашарыма бирәр нәрсә бирүләрен соранам. Кайберәүләрнең ачуы килә, хәтта куып чыгаралар. Аларга үпкәләп булмый, чөнки авыллар буйлап соранып йөрүче хәерчеләрнең чиге юк. Кайбер авылларда, тәмам гарык булып, басу капкасына хәтта: «Карантин. Тиф», — дигән язулар элгәннәр. Андыйларга кермичә кире борыласың. Әгәр керсәң, җәза бирәләр.

Бистәгә кайткач, чәчтарашка барырга ниятләдем. Абый бераз совет акчалары калдырган иде (инде гамәлдә немец маркалары). Сугышка кадәр эшләгән зур булмаган чәчтарашның пыяла ишеге аша эчке якта елап басып торган бер картны шәйләдем. Якын килгәч, картның янында берничә немецның да барлыгын күрдем. Кире борылмакчы идем, кемдер якамнан эләктереп, арттан этеп җибәрде. Әйләнеп карасам, әзмәвердәй фриц басып тора. Әфисәрләре бугай, гади солдатка охшамаган, үзе мина бармагы белән төртеп күрсәтеп шаркылдый. Бичара карт сатарга галошлары белән итек алып чыккан булган, фрицлар аны тартып алганнар. Бабай: «Карчыгым авырып ята, ачка үлә ич инде», — дип такмаклап елый. Немецлар аңа бер маркалык акча бирәләр, ул алмый, акчаны идәнгә төшереп җибәрә. Фашистлар аны, «рушин швайн», дип сөйләнә-сөйләнә, шашынып кыйный башлыйлар, акчаларын аяк астына ташлаганга ачулары килә. Аннары өстерәп урамга чыгарып ташлыйлар.

Немецлар арасында бер гражданский да бар иде. Ул миннән: «Ә син нишләп монда?» — дип сорады. Мин үземне этеп кертксән әзмәвергә күрсәтеп, аның «ярдәме» белән керүемне, үзебезнең совет власте вакытында бирелә чәчтараш булуын һәм хәзер чәч алдырырга килүемне аңлатам. Гражданский киемле (мин аны таныдым, ул элекке тикшерүче — Кулешов иде) тәржемә итә. Әзмәвер гәүдәле фриц котмәгәндә минем борыныма, күз төбемә китереп тондыра. Борынымнан кан ага. «Нәрсә өчен?» — дип сорыйм ирексездән күземнән бәреп чыккан яшемне кул аркасы белән сыпырып. Кулешов: «Безнең власть вакытында», — дигән сүзләрен өчен дип аңлата. Теге фриц: «Сезнең власть юк. Без сезне азат итәргә килдек!» — дип җикеренә. «Менә сиңа азат итү! Инде икенче тапкыр фашист — азат итүчеләрдән эләгә үземә», — дигән уй бөтерелә башымда. Мине тиз генә җибәрмиләр. Нишләп килүем, пыяла ишек аркылы күзәтүем, тыңлап торуымның сәбәбен кабат-кабат төпчениләр:

партизан түгелме янәсе. Үзем дә сизмәстән, янә «безнең власть вакытында», дигән сүз ычкындырам. Фриц кабат йөземә китереп суга, аннары төрткәләп урамга чыгарып җибәрә.

Әни миннән өйгә кайткач: «Кем белән сугыштың?» — дип сорады. Ә мин: «Фашист мәлгунь тукмады», — дип җавап бирдем.

Әнием белән ачлы-туклы яшибез. Ул чагында абый һәм аның гаиләсе турында әле берни дә белмибез. Өйдә сатар әйбер калмады, ашарга да юк. Мин сугышка кадәр үк алынган ике чиләкне сатып карарга ниятләдем. Алар яңа диярлек. Авылларга барып тормыйча базарга киттем. Басып торам шулай, беркем яныма килми. Халык бик аз күренә. Шулчак күрәм: дүрт немец солдаты һәм бер офицер минем яшьләрдәге берничә үсмерне куалап киләләр. Чиләкләремне эләктереп алдым да йөгерергә тотындым. Автомат чираты тырылдады, баш очымнан ядрәләр сызгырып үтте. «Рус, хальт!» — дигән команда ишетелде. Мин туктап, борылып карадым. Бер солдат туры миңа таба чаба, үзе автоматын төбәгән. Килеп житкәч, автоматының көпшәсе белән күкрәгемә төртеп, ияге белән теге үсмерләр ягына ымлады. Шулар янына барырга әйдәве. Мине дә төркемгә китереп куштылар. Бара торгач, безнең кебекләр дистәгә җыелды. Кешеләр безгә карыйлар, баш чайкап үзара сөйләшкәннәреннән кызганулары күренә. Бигрәк тә карчыкларның: «Нәрсә өчен, бигрәк яшь бит әле алар, балалар диярлек», — дип сөйләнүләре күңелләрне кузгата. Безне кая һәм нәрсә өчен алып баруларын беркем белми. Үзара сөйләшү тыела. Станция артына алып чыктылар. Анда, тимер юлдан ерак түгел, озын һәм биек бина сузылып киткән. Аның тирәсендә күп санда җигүле атлар һәм солдатлар күренә.

Немецлар бер читкә өстәл чыгарып куеп, бездән сораша, алынган мәгълүматларны язып куя башладылар. Документларны да карыйлар. «Документ юк», — диючеләрне тентиләр. Чиратым җиткәч, миннән дә хезмәт биржасында теркәлү турында таныклык таләп иттеләр. Бернинди биржада теркәлү узмасам да, документымны өйдә калдырдым дип ялганладым. Адресымны да дөрес бирмәдем, башка шахтаны атадым.

Тимер юлдан озын бинага кадәр булган арага юл түшәр өчен, немецлар безне таш ташу эшенә куштылар. Носилка белән таш китерәбез. Аларны өлкән яшьтәге элекке ике кызылармияче солдат (әсирләр) түшәлгән комга тәртибе белән салып тора. Мин кулдашым белән чираттагы носилканы бушатканда, янәшәдәге солдатлардан берсе, читтәрәк тәмәке тартып, шаркылдаша-шаркылдаша сөйләшкән сакчы фрицларга сиздермичә генә: «Егетләр, бераз түзегез инде. Алар монда озак тоткарлана алмаслар, күп дигәндә — бер ел. Куачаклар аларны, әйткән иде диярсез», — дип безнең күңелләрне күтәрергә тырышты. Чыннан да, ул хаклы булып чыкты. Дөрес, мин бу турыда соңрак белдем. Ошбу урыннарны Кызыл Армия азат иткәндә, мин бик еракта идем.

Төшке аш вакыты житте. Ерак та түгел кыр кухнясы килеп туктады. Безнең янда ике сакчы калдырып, башка фрицлар шунда киттеләр. Аларның котелоклары капкачлы. Пешекче котелокларына нәрсәдер бүлә, ә капкачларына нindидер куе әйбер сала. Тәмле ис борыннарны кытыклап, ашыйсы килүдән авызга төкерекләр җыела. Фрицлар ашап туйгач, повар, безнең якка күрсәтеп, офицерларына нидер әйтте. Казанда ашлары калган икән. Пешекче шул ашны безгә ашатырга рөхсәт сорап офицерга сүз каткан: «Барыбер түгәм мин аны, теге урысларга ашатсак, яхшырак булыр, тырышыбрак эшләрләр», — дип аңлатты. Немец ризалашкан. Бу турыда урысчаны вата-җимерә пешекче (әллә эстон, әллә латыш) безгә соныннан җиткерде. Тик ашны салырга савыт юк. Ничек ашарга? Минем чиләккә салдылар. Хәзер инде калак кирәк. Фрицлар

көлә-көлә: «Рушин швайн», — дип, безгә кул белән ничек итеп чиләктән алып ашарга кирәклеген хәрәкәтләр ясап күрсәтәләр. Карт солдат: «Түксәләр түгәрләр, алай эшләмәгез!» — дип кисәтә. Аннары каяндыр калаклар табып китерделәр. Беребез дә селкенмичә басып тора бирәбез. Офицер ямьсез тавыш белән акырып җибәрде, ашарга боерды. Ачулы карап торганнан соң, нәрсәдер исенә төшепме, вокзал ягына атлады. Яныбызга мыеклы, өлкән яшьтәге немец солдаты килде. Офицер ягына кулын селтәп («игътибар итмәгез сәнә үзенә», диюе булса кирәк) алгач, үзләренчә сөйләнә. «Ашамасагыз, хәлегез булмас», дип аңлатуын чайкала-чайкала йөреп күрсәтүеннән чамаларга мөмкин. Ашадык без. Киреләнеп, үзебезгә зыян гына салуыбызны аңламаслык түгел идек. Кичкә кадәр эшләткәч, офицер өйләребезгә кайтарып җибәрүләрен, иртәгә иртүк килергә һәм үзебез белән калаклар алып килергә кирәклеген аңлатты. Алар безгә аерым аш пешерәчәкләр, имеш.

Өйгә кайтуга, әнине елап утырган хәлдә күрдем. Ул мине кочаклап алып нәрсә булуы турында сораштыра башлады. Мин бөтенесен сөйләп бирдем, немецларның, әгәр килмәсәк, атып үтерү белән янаулары турында да әйттем.

Икенче көнне бармадым. Әнием бик курыкты һәм бертуктаусыз: «И-и, Ходаем, нәрсә булыр инде?» — дип кабатлады. Мин аны юатырга тырыштым, фрицларга ялган адрес биргәмне әйттем.

Ул чагында кемнәрдер бөтен урыннарга — коймаларга, йорт диварларына, кеше күп җыела торган җирләргә — немецларның ныклы контроленә карамастан, листовкалар ябыштыра иде. Ул листовкаларда оккупантларга эшләмәскә, әгәр эшләргә туры килсә, аларга зыян салырга өндәүләр ярылып ята, җиңүнең барыбер безнең якта буласына ышандыралар иде. Листовкаларны укып торганыңны күрсәләр дә, допроска алып китәләр, аларны таратучыларны эләктерсәләр — аталар. Бөтен җирдә немец комендатурасының кисәтүләре эленеп тора: «Партизаннарга теләктәшлек белдергән өчен атарга», «Властьларга буйсынмаган өчен атарга» ... һәм тагын әллә ниләр өчен атарга. Бөтенесен санап бетерергә дә мөмкин түгел. Киләчәктә ничек яшәргә?

Сугышка кадәр бездә, фатир чираты җиткәнне көтеп, ике кызы һәм улы Каюм белән Хәдичә апа яшәп торды. Беркөнне шул Каюм кереп чыкты һәм үзләрендә дә нәкъ шундый ук хәл — гаиләләренең ачыгуы, өйләрендә ризыкка алышырлык әйберләре дә калмавын сөйләде. «Әйдә, авылларга чыгыйк, — ди бу. — Бәлки, берәр эш табылыр, ирләр хәзер фронтта, хатын-кызлар үзләре генә башкара алмаган эшләр дә бар. Инструментларымны, резина келәен дә алырмын. Аяк киемнәрен төзәттерергә теләүчеләр дә табылыр дип уйлыйм». Ул чагында резин итекләргә калын табан ябыштыру гадәте бар иде. Һәм менә без таушалган-купкан итекләргә табан ябыштырабыз, аны, тагын да ныграк булсын өчен, чыдам тегәрҗеп белән дә тегәбез.

Яз якынлашып килә иде. Кар эреп, күп урыннарда аяк астында күлдәвекләр барлыкка килгән, шуңа күрә заказ бирүчеләр аз түгел. Хезмәтебез белән беркадәр арпа, кукуруз һәм азрак бодай тупладык. Барлык тапканыбызны берьюлы алып китә алмадык — юллар пычракка әйләнгән, йөгебез авыр һәм кайтасы да ерак. Игеннең бер өлешен Микула атлы бер агайда калдырып торырга, аяк аслары кипшергәч, аны кабат килеп алырга сөйләштек. Авыл кешеләре бездән энә белән җеп тә алып килүебезне үтенделәр. Әмма әйләнеп кайтулар насыйп булмаган икән.

Әлегә алып кайткан ризык белән җан асрыйбыз. Май ае якынлашты, йөрерлек булып юл төште. Тик, Каюм авырып киткәнлектән, юлга чыга алмадык. Савыгып җиткәндә, ул миннән базарга барып кирәкле әйберләрне алуымны үтенде. Бүген-иртәгә кузгалырбыз дип торабыз.

## Облава

1942 елның 12 мае. Мин базарга киттем. Рәтләр арасыннан йөри генә башлаган идем, шулчак: «Облава», — дип кемдер оран салды. Халык төрлесе төрле якка пыр тузып кача башлады. Базар киртә белән әйләндереп алынмаган, рәт-рәт булып ларёклар һәм кечкенә кибетләр генә тезелеп киткән. Теге вакытта алыптай олы гәүдәле фашист борынымны җимереп кайтарган элекке чәчтараш бинасы да шунда ук урнашкан. Мондый облавалар турында инде мин белә идем. Бер тапкыр андый казадан чак качып котылдым. Авылларда немецларның исемлекләр төзеп, эшкә ярардай егет һәм кызларны, үсмерләрне туганнарыннан аерып, Алманиягә эшкә куалауларын еш ишетергә туры килде. Азык эзләп йөрүчеләрне, туры килгәндә, юлдан да алып киткәннәр. Моңа кадәр безгә бәхет елмайды.

Мин ике бина арасындагы тар гына аралыкка ташландым. Тик шул чагында итальян солдаты юлыма аркылы төште, винтовка прикладына белән кулбашыма китереп орудан мәтәлеп киттем. Икенче мизгелдә ул мине базардан читтә торучы машиналар ягына сөйри иде инде. Качып китү мөмкинлеге юк диярлек, чөнки оккупантлар базар территориясенә берьюлы берничә юнәлештән басып кергәннәр. Һаман саен кешеләрне китерә тордылар. Кемнедер машина әрҗәсенә этәләп менгерделәр, кемнәрнедер күтәреп ыргыттылар. Әрҗәдә сакчы автоматчылар утыра. Облава төгәлләнгәннән соң, машиналар кузгалып китте.

Һәм менә без станциядә. Анда инде буш товар вагоннарыннан (аларны халыкта мал вагоннары, диләр) торган эшелон әзер. Ул вагоннарның кеше биеклегендә чәнечкеле тимерчыбык белән каймаланган тимер рәшәткәле тәрәзә-тишекләре бар. Иртә белән малайларны аерым, кызларны аерым вагоннарга бүлгәләп тараттылар. Ниһаять, паровоз авыр уфылдап урыныннан купты, тагылган вагоннар ризасызлык белдергәндәй дыркылдашып алдылар да теләр-теләмәс аңа иярделәр. Берәүләр тавышсыз гына елый, икенчеләр нидер әйтеп кычкыра. Кая алып киткәннәрен беркем белми иде. Шул чыгып китүдән мин әнием белән бары 1946 елда, фашист коллыгыннан әйләнеп кайткач кына күрешә алдым.

## Тоткынлыкта

Бик озак алып бардылар, состав станцияләрдә дә озаклап туктап торды, күрәсең, башка ашыгыч йөкләрне чиратсыз үткәрәләр иде. Ашатулар сирәк, анда да ниндидер сыек баланда яисә ипи кисәге белән су гына эләгә. Йомыш үтәргә ачык урыннарда гына туктап чыгаралар: бер якка — малайларны, икенче якка — кызларны. Ничек оят! Тик берни эшләр хәл юк. Сакчылар бармак белән төртеп күрсәтеп шаркылдашалар. Аннары кабат вагоннарга куалап кертәләр.

Вагонда яктылык төшәрлек ике генә тәрәзә уемы бар. Без алар янына чиратлап барабыз һәм тышка күз салабыз. Илебездән ераклашканнан ераклашканны тоюдан күнелне сагыш баса, йөрәкләр кысыла, күзләргә яшь килә.

Баштарак поездны Украина далалары озатып артка чабышса, аннары урманнар китте. Төнлә Днепр елгасы аша чыгу хәтергә нык сеңеп калган, чөнки состав бик акрын барды. Днепрогэс нык зарарланган, шунлыктан, диделәр. Белая Церковь шәһәрен үттек, аннары — Львовны. Перемышль станциясенә житкәч, вагоннардан төшереп, өчәр ярусль нарлар урнаштырылган зур бер бинага куалап керттеләр. Монда распределительный пункт икән. СССРдагы тимер юл колеясы белән көнбатышныкының киңлеге ягыннан, имештер, аермасы бар һәм шуңа безне башка эшелонга күчереп утыртачаклар ди. Бинадан

кабат урамга куалап чыгардылар. Анда кыр кухнялары тезелгән. Һәр кешегә бирәр жамаяк баланда өләштеләр. Ул баланда кабыгы әрчелмәгән вак бәрәңгене суга салып пешерелгән нәмәрсә булып чыкты. Сакчылар артында яхшы киенгән эшләпәле ирләр, бизәнгән-ясанган ханымнар басып тора; тәржемәче аларга: «Менә алар Советлар вакытында да, хәзер дә шундый ризыкны яратып ашыйлар», — дип сөйли. Тегеләре баш селкеп кызыксынып тынлыйлар һәм безне, сирәк хайваннарны тамаша кылгандай, гажәпләнеп күзәтәләр иде.

Янадан вагоннарга утыртып инде Польша территориясе буенча алып киттеләр. Алда безне ләгънәт төшкән Алмания көтә иде.

## Алмания

Ниһаять, эшелон ниндидер станциягә житеп туктап калды. Ары таба жәяүләп барасы икән. Бөтен жирдә яшеллек, яз тантана итә. Тик боларның берсе дә күзгә күренми. Озак бардык. Кояш инде югары күтәрелеп, кыздырыпмы-кыздыра, үтереп эчәсе килә — авыз эчләре кибеп, телләр аңкауга ябышкан. Төштән соң ниндидер инешкә життек. Сакчыларга эчәсе килүебезне аңлатабыз. Тегеләр, ачулы мыгырдансалар да, рөхсәт иттеләр. Ашыгып суга ташландык, хайваннардан бер дә артык жиребез юк. Бер эчә башлагач, белешмичә, һич аерылып булмый. Немецлар туктарга кушалар. «Рушин швайн!» — дип акырулары ишетелә. Ату тавышлары яңгырагач кына, судан аерылып, аякларыбызга бастык. Һәм безне кабат юл буенча куаладылар. Артык күп эчүдән кайберәүләрнең хәле начарайды. Фрицларның аңарда эше юк, кычкыруларын беләләр, ара-тирә көч-хәл белән сөйрәлүчеләргә автомат прикладлары белән бәргәләп тә алалар.

Кич житкәндә, чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алынган ниндидер бина янында туктаттылар. Бөтенебезне шунда кертеп, ишекләрне бикләп куйдылар. Тәмам хәлсезләнгәнлектән, кем кая туры килсә, шунда идәнгә ауды. Караңгы төште. Йокы килә, аннан битәр үтереп ашыйсы килә. Ачлыктан хәтта башлар әйләнә. Шулай да арыганлык үзенекен итә — онытылганыңны сизми дә каласың.

Никтер иртә белән дә ишекләр ачылмады. Жаннарны изә торган авыр тынлыкта өйләне житкердек. Ниһаять, ишекләрне ачтылар һәм чыгарга әмер яңгырады. Баланда өләшәләр икән. Яшел төстәге сыекча безнең яктагы кычыткан суын хәтерләтә. Без аны башта ашарга шикләндек, тик ачлык үзенекен итте: комсызланып баландага ташландык. Болай ярыйсы гына икән үзе. Соңыннан белүебезчә, шпинат дип аталучы ошбу үсемлекне немецлар махсус үстерәләр, имеш.

Безне әлеге бинада ике атна карантинда тоттылар. Немецлар һәртөрле йогышлы чирләрдән, беттән куркалар иде. Көннәрнең берендә бинадан ерак түгел ачык урынга куалап чыгарып, рәтләргә тезделәр. Бер-беребездән басып торган ара ераклыгы өч-дүрт метрдан да ким түгел. Ул арада безгә таба якынлашып килүче ирләр һәм хатын-кызлар төркеме күренде. Өлкән яшьтәге немец ирләре каурыйлы эшләпәләрдән, ә хатыннары — зонтиклар тоткан, икенче кулларыннан ирләре култыклап алган. Килеп житкәч, безне товар сайлагандагы кебек, үзара сөйләшә-сөйләшә һәм көлешеп, кулларындагы тростьлары белән әле беребезгә, әле икенчебезгә төртеп күрсәтә-күрсәтә күзәтергә керештеләр. Моннан берничә көн алданрак яныбызга урыс эмигрант хатын-кызлары килеп, фамилияләребезне, кемнең кайда яшәгәнен һәм эшләгәнен язып алып киткәннәр иде инде. Әгәр авылдан икәнсең, күкрәгеңә яшел бирка асалар; әгәр шахтёрлар бистәсеннән булсаң — караны; төзүчеләр гаиләсенә караганнарга — сарыны. Биркалар түгәрәк һәм картоннан эшләнгән. Соңыннан боларның

нәкъ менә бу карт немецлар өчен эшләнгәненә төшендек. Алар безне үзләренә хезмәткә сайлап алалар иде. Фермада эшләр өчен хезмәткәр кирәк икән — яшел биркалыны сайлый; шахта хуҗалары — кара биркалыны һ.б. Сайлап алулары да үзенчәлекле: күкрәкне, кул мускулларын капшап карыйлар; искәрмәгәндә генә, тешләрне күрсәтергә кушып, таяклары белән авызга китереп төртәләр. Авызны ачтыргач, җирәнүдән йөзләрен җыерып, аңкауларны тикшерәләр. Сайлаучылар күңелләренә хуш килгәнне алып китеп баралар.

Бу хурлыклы процедура берничә көн дәвам итте. Малайлар гына түгел, кызлар да шундый түбәнсетүләр үтте. Урыс һәм украин гүзәлләрен терлекләрне капшагандай тикшерүләрен күргәч, ачудан куллар йодрыклана. Тик берни эшләр хәл юк, без дошман өнендә коллыкта идек.

Күпләрне алып киттеләр. Яңа хуҗаларны бирегә бауэрлар дип йөртәләр (бездә — фермерлар). Аларның бер өлеше өлкән яшьтә булса, араларында урта яшьләрдәге ханымнар да бар. Аларның ирләре фронтта, ә кайберләренеке инде һәлак булган. Андый ханымнарга эләгүчеләргә бик авырга туры килде. Мескеннәрне хайван асрый торган абзарларга япканнар һәм аларга мөнәсәбәт тә хайваннарныкыннан әлләни аерылмаган, ирләре үчен шул бичаралардан алганнар. Азат ителгәннән соң, безгә кайбер немец хуҗалыкларында булырга туры килде. Малайлар һәм кызлар тотылган сарайларда алар белән ничек идарә итәргә өйрәткән инструкцияләрне дә укып тетрәндек. Бәхетсезләрнең кайберләрен үтергәнче кыйнап, яшелчә бакчасына күмеп куйганнар. Үзем колбиләүчеләрнең үтерелгән үсмерләрне мәҗбүри рәвештә казытып алдырган ике очрагына туры килдем... Әлеге сортировка пунктында тотылуым ике айга сузылды.

***

Калганнарны соңрак әллә ниткән биниһая зур корылмалар янына куып китерделәр. Магнат Герингның заводлары, диделәр. Заводлар территориясе искитмәле зур мәйданны били. Аның аша бик озын күпер салынган. Һәм шул күпер астыннан, әче сызгыртып, ары-бире кечкенә паровозлар йөреп тора. Аларга кызыл төстәге кайнап торган металл тутырылган дәү сыемнар тагылган (минем моңа охшаш күренешне үзебезнең Макеевкада да күргәнем бар иде). Күпернең һәр ике ягы буйлап икешәр рәт чәнечкеле тимерчыбыклар тарттырылган. Тимерчыбыклар арасында торымнан торымга сак каланчалары калкып тора, ә аларда, һәр мизгелдә атарга әзер булып, автоматлы сакчылар урын алган. Бирегә меңнәрчә кешеләрне куып китергәннәр. Төн кунарга казематта өч ярусны нарлар яраклаштырылган. Кем ничек булдыра, шулай урнашты. Барыбыз да ач һәм нык алҗыган. Әле анда, әле монда борын тартып мышкылдаган авазлар ишетелә. Казематлар өстендәге машиналарның туктаусыз дөбердәвеннән күзгә йокы керми диярлек. Төнне чак уздырдык. Иртәнге биштә торгыздылар. Нарлардан куып төшереп санарга керештеләр. Аннары, иртәнге физзарядка дигән булып, ятарга — торырга, ятарга — торырга мәҗбүр иттеләр; тегендә-монда йөгерттеләр.

Һәркемгә чөгендер кушып пешерелгән берәр кисәк ипи өләштеләр һәм эчәргә нindидер болганчык төстәге сыеклык бирделәр. «Әле мондый кофены сезнең эчкәнегез юк», — дип көлгән булалар фрицлар. Әйе, мондый бурданы эчкән юк иде, һәм эчәргә дә язмасын. Аннары безне эшкә куаладылар, ком ташырга. Кич белән кайткач, берәр савыт баланда өләштеләр. Ул баландада сирәк-мирәк әчегән кәбестә кисәкләре күренә. Төнгә — кабат өстә дөбердәгән авазлар бер минутка да тынып тормаган казематка. Акылдан язарлык. Кич белән өстәге яруста ятучылардан кайсыдыр моңланып җыр сузды. Минем мондый җырны әле ишеткәнем юк иде кебек. Ул болайрак:

Үләм инде, үләм инде,
Үләм инде, күмәрсез.
Туганнарым, каберемне
Беркайчан да белмәссез.

Жырлый да бу, елый. Жырлый да бу, елый. Болай да бәгырьләр таш кебек каткан. Аның өстенә әлеге иптәшнең шыншуы жаннарны изә. Ана төрле яктан: «Житте сина, тукта!» — дип кычкыралар. Ә ул колагына да элми, сузыпмы суза. Кич белән соң гына сакчылар тикшерергә керде. Бөтен каземат тынып калды, бары тик теге адәмнең моңлануы гына ишетелә. Немецлар аның янына йөгереп барып, үзләренчә нидер кычкыралар. Алар телен аңламасак та, туктарга кушып икәнен чамалыйбыз. Тәржемәче сыйфатында бер полякны табып китерделәр. «Офицер сиңа жырлавыннан туктарга куша», — ди тәржемәче, урысчаны ватажимерә. Тик теге туктамый. Немец аның нәрсә дип жырлавы белән кызыксына. Поляк аңлаткач — көлә. Жырчыга янә туктарга кушып жикеренәләр. Тик файдасыз. Ахырда фашистлар аны нарыннан сөйрәп төшереп каядыр алып чыгып китәләр. Шул көннән соң без аны башка беркайчан да күрмәдек.

Һәр иртәдә безне куалап эшкә алып китәләр, ә кич белән куалап кире казематка алып кайталар. Ярымсаташулы төн башлана. Өстебездә коточкыч дөбердәү авазлары. Аерма шунда: безне турыдан-туры таптап кына китмиләр. Арыганлык үзенекен итә: томанлы онытылу үз кочагына ала. Юньләп ял итәргә дә өлгермисең, торырга боерган әмер яңгырый. Аңгырайган башлар юньләп эшләми, сикерешеп торган унайга бер-беребезгә бәреләбез-сугылабыз. Сакчылар: «Рушин швайн, шнель», — дип сөйләнә-сөйләнә, без — әсирләрнең сыртларына камчылары белән сыдыралар. Көн дә бер үк төрле кабатланган коллар тормышы башлана.

## Лагерь

Бу хәлләр көзгә кадәр дәвам итте. Өстәге киемнәр сәләмәгә әйләнде. Бик нык ябыктык, йөзләр агарып калды. Көннәр суытты, инде ятып торырга да мөмкин түгел. Хәрәкәтләнеп кенә аз-маз жылынып була. Тик ачлыктан, авыр эштән хәлсезләнгән кеше бертуктаусыз хәрәкәтләнеп тора ала димени?

1943 ел якынлашты. Беркөнне безне казематлардан чыгардылар да, стройга тезеп, башка юнәлештә алып киттеләр. Тимерчыбыклар белән әйләндереп алынган караңгы төстәге агач бараклар янына житкәч туктаттылар. Капкаларда автоматчылар басып тора. Лагерь бик зур, әллә ничә рәт бараклар тезелеп киткән. Арада баракларны икегә аерган киртә бар. Территориянең бер ягы — ирләр, икенче як хатын-кызлар өчен тәгаенләнгән. Ирләр ягында үсмерләрдән тыш өлкәнрәк яшьтәгеләр булса да, хатыннар ягында бары 14-16 яшьлек кызлар гына. Кыз балаларны эштән алып кайтканда, без бараклардан йөгереп чыгып, алар колоннасына карыйбыз. Арыган кыяфәттәге бичаралар аякларын чак сөйрәп атлыйлар. «Кызлар, сез кайдан?» — дип, сораулар яудырабыз. «Ворошиловградтан», «Харьковтан», «Донецкидан», — дигән жаваплар ишетелә. Соңгылары миңа, үзем дә Донецкидан булганлыктан, аеруча якын тоела. Надзиратель безне сөйләштермәс өчен камчылар белән кыйнап куалый.

Безнең лагерь «№23» дип атала. Янәшәдә поляклар өчен «лагерь №22» бараклары тезелеп киткән. Полякларның күкрәгенә латинча «R» хәрефле сары төстәге билге тагылган. Безнең лагерьда урыслар, украиннар, берничә әрмән һәм, мине дә исәпләп, ике татар бар. Безнең лагерьдагыларның киемнәрендәге күкрәк турына «OST» дип язылган квадрат формасындагы чүпрәк кисәге тегелгән. Бу — көнчыгыш эшчеләре — «Ostarbeiter» дигәнне аңлата. Андый билгесез йөрү

тыела. Әгәр билгесез тоткарласалар, камчы белән суктыралар. Ир затыннанмы син, хатын-кызмы, кемнең-кем булуына карамастан, эскәмиягә сузып салып, чалбарны төшертәләр һәм ялангач артны камчы белән каезлыйлар. Мондый «процедурадан» соң адәм баласы озак вакытлар, алган яраларыннан, урындыкка утыра алмый.

Такта бараклар бик озын, һәркайсының эчендә өч ярусылы нарлар тезелеп киткән. Һәр баракка 450шәр кеше кертелгән. Аларда суларга һава житми, начар ис анкый. Безнеке шикелле лагерьлар янәшәдә әллә ничә. Аларны кай арада төзеп өлгерткәннәрдер. Тотыклары: итальяннар, чехлар, французлар, греклар, алжирлар, тунислылар һәм тагын әллә күпме халыклар. Хәрби әсирләр өчен дә концлагерьлар бар. Инглиз әсирләренең аркаларына буяу белән: — «England», французларныкына — «France», ә совет әсирләренә «SU» дип язылган. Һәммәсе Беренче бөтендөнья сугышыннан калган немец солдатлары киеменә киендерелгән. Алар ничек шулкадәр күп һәм шулай озак сакланганнардыр — бусына гаҗәпләнергә генә кала. Арада иң бәхетсезләре, газапланган, ачлыктан шешенгәннәре шулай да безнең совет хәрби әсирләре иде. Аларның хәтта күзләре дә пыялаланып тора иде кебек тоела. Мин үлгәндә дә бу тилмерүле карашларны оныта алмамдыр, мөгаен.

## Антонио Миотто

Кайчагында безгә — хәрби әсирләргә якында гына эшләргә туры килә. Бригадирыбыз — итальян Антонио Миотто, ул чыгышы белән Миланнан, эшкә ирекле ялланып килгән. Алмания белән Италия союзниклар булганлыктан, Алманиягә килеп эшләүчеләр күп иде. Миотто искиткеч киң күңелле кеше. Берсендә ул миңа зур гына ап-ак шикәр чөгендере бирде. Ашыгып кимерергә керештем һәм шулчак үземә кемнеңдер төбәлеп карап торуын сиздем. Күтәрелеп карасам, йөзен сакал баскан ябык кына кеше. Күз карашын язып кына аңлата торган түгел. Муенын суза төшеп, төкрекләрен йотып торганы күренә. Карашымны читкә алып, мин аңа арка белән борылдым һәм чөгендерне алагаем зур бетон кисәгенә ордым. Жирдән бер кисәкне алып теге кешегә таба атладым, ул — миңа таба. Кулымдагы кисәкне аңа суздым, ул шундук тешләрен чөгендергә батырды. Тик чәйнәргә өлгермәде, ату тавышы яңгырады. Ул миңа карый, мин — аңа. Беребез дә егылмый. Тораташтай катып торганда, кемнеңдер аяк тавышы ишетелде. Сакчы икән. Чабып килгән унайга хәрби әсирне мылтык түтәсе белән сугып та екты, аннары миңа ташланды. Шулай да сугарга өлгермәде, безнең арада стена булып Антонио Миотто калыкты. Ул мине тизрәк башка иптәшләрем эшли торган урынга алып китте. Сакчы солдат белән Антонио үзара кычкырышалар, нәтиҗәдә, фриц барыбер үз урынына китте. Миоттоны зур белгеч, хәтта аның белән завод житәкчелеге дә санлаша, диделәр. Ул немецлардан курыкмавы турында әйтә, вакыты белән «Интернационал»ны да жырлап жибәрә иде. Итальянча белмәгәч, моның өчен асарга мөмкиннәр, дип кул хәрәкәтләре белән бугаздан урап күрсәтәм. Ул бары көлә генә.

Инглиз әсирләре тышкы кыяфәтләренең чисталыгы белән аерылып тора. Французлар да алардан калышмый диярлек. Ә безнең совет хәрби әсирләренә карасаң, жан елый: сакал-мыек баскан, өсләре сәләмә, тере мәетләр инде менә. Бичараларның бил турына котелок тагылган, ул котелокка тәүлеккә бер мәртәбә сыек кына баланда салалар. Баланданы хәтта дуңгыз да ашамас иде. Сонрак белүемчә, инглиз һәм француз әсирләренә Кызыл Хач җәмгыяте булышкан һәм шунлыктан аларга мөнәсәбәт тә йомшаграк булган икән. Безнекеләрне чебен урынына кырганнар, сугыш вакытында күп миллионлаганы фашистлар территориясендә ятып калган. Минем кебек оккупацияләнгән жирләрдән куып китерелгән яшь жилкенчәк тә шактый кырылды ул елларда. Безнең лагерьда гына

Украинадан китерелгән өч мең үсмер егет һәм ике мең кыз бала тотыла иде. Андый лагерьларны санап кем очына чыккан. Безнең лагерь Брауншвейгтан 18 чакрым ераклыкта гына. Әйткәнемчә, халык күп кырылды. Ачлыкка чыдый алмыйча, калдыклар түгелүче чокырга барып актарынган өчен генә дә үтергәнче кыйныйлар иде. Анда килгән мескенкәйне качып сагалап торалар һәм эләктереп алып: «Рушин швайн», — дия-дия, резин тукмаклар белән дөмбәсләргә керешәләр.

Лагерь башлыгы — немец, ә аның ярдәмчесе һәм урынбасары — Николай Лысенко атлы адәм актыгы. Ул Октябрь инкыйлабы вакытында ук Алманиягә качкан. Һәрвакыт кыска күн курткадан һәм озын кунычлы күнитекләрдән йөри. Башына тироль немецларыныкына охшатып, каурыйлы эшләпә киелгән, кулына камчы тоткан булыр. Йөргәндә шул камчысы белән итегенә суккалап алырга да онытмас. Бездән ул үзенә дядя Коля дип эндәшүебезне таләп итә. Чын ерткыч инде менә. Мин аны башкача атый алмыйм. Аның хатыны һәм 16 яшьлек Николай исемле улы бар. Немец танышлары арасында аны Николь дип кенә йөртәләр. Әтисе дә шулай дип дәшә. Тик малай Николай яки Коленька дип дәшкәннәрен ярата, әнисе дә аңа шулай дәшә. Коля, әтисе каядыр киткәндә, еш кына безнең баракка керә һәм әнисенең аңа Россия турында сөйләвен әйтә иде. Ул безне бик кызгана һәм берни белән дә булыша алмавына үкенеч белдерә. Әтисенең таш бәгырьле, ә әнисенең йомшак күңелле икәнлеген сөйли. Әнисе туган илен бик сагына икән. Озакламый аны армиягә алырга тиешләр, имеш. Тик аның Россиягә каршы сугышка барасы килми, әнисе дә шулай исәпли. Әтиләренең бу турыда белүеннән куркалар. Күпмедер вакыт үткәч, Коля килми башлады һәм без аны башка беркайчан да күрмәдек.

Лагерьда полицайлар да бар иде, икесе — Анатолий. Берсенең фамилиясе Кравченко, икенчесенекен хәтерләмим. Алардан башка ике фин да бар. Чәчләре, хәтта кашларына кадәр ак үзләренең. Шул полицайлар көнен дә, төнен дә иснәнеп йөриләр, тоткыннарның нәрсә сөйләшкәннәрен тыңлыйлар, тентүләр уздыралар. Эштән кайтканда, капкада тентүчеләр дә шул ук полицайлар.

1943 ел бара. Немецларда ниндидер үзгәрешләр сизми мөмкин түгел. Безгә карата мөнәсәбәт тагын да рәхимсезләнә төште. Немец балалары, строй белән эшкә алып барганда, өстебезгә ташлар ыргыталар, төкеренәләр. Боларның сәбәбен соңрак төшендек, Сталинград астындагы зур җиңелүләрен кичерә алмаганнар икән.

Илдә вакытта ук Сталин репрессиясенә эләккәннәрнең:

Палачлар, сезгә ләгънәт юллыйм,
Гаепсез кешеләрне харап итмәгез…

— дигән әчтәлекле җырларын ишеткәнем бар иде. Мин аны бераз үзгәртеп, иптәшләремә болай дип җырладым:

Фашист палачлары, сезгә ләгънәт укыйм,
Бер гаепсезләрне харап итмәгез.
Килер вакыт, халык барсын белер,
Шул чагында шәфкать көтмәгез!

Әле хәтта аны немецча җырлый алуым турында мактандым. Антонио Миотто мине кыска гына:

Кайне буттер, брут, кайне шпик.
Русишь ком, а дойтеш вег,

— дип өйрәткән иде. Ул тәрҗемәдә болайрак килеп чыга:

Нет масла, хлеба, нет сала.
Русские идут, а немцы бегут.

Җыр белән мавыгып, саклык чаралары күрү онытылган, баракка Кравченко белән бер фин полицае йөгереп кергәч кенә искә килдек. Тик инде соң иде, мине эләктереп алып, барактан комендатура ягына сөйрәделәр. Анда бертөркем немец полицайлары белән лагерь-фюрер ярдәмчесе — Лысенко («Коля дәдәй» ягъни) инде көтеп торалар. Кулларымны каерып сөйрәп кергән фашист «этләре» аңа минем ничек итеп өченче рейхка каршы пропаганда алып баруымны сөйләп бирделәр. Лысенко ирония белән: «Әйдә, композитор, без дә тынлап карыйк инде», — дигән була. «Җырламыйм», — дип кырт кисәм. Лысенко инде йомшаграк итеп: «Җырла, мин аларга башкачарак тәрҗемә итәрмен», — дип мина күз кыса. Бу бәндәгә ышанмасам да, нәрсә булса — шул дигән нәтиҗәгә килеп җырладым. Лысенко тәрҗемәләгәннән соң, барысының күзләре акайганын күреп, алдануымны аңладым. Мине эскәмиягә сузып салып, кулларымны тарттырып бәйләделәр һәм, чалбарымны төшереп, егерме биш мәртәбә резин тәпәч белән суктырдылар. Аннары җибәрделәр. Баракта иптәш малайлар кайтуымны түземсезлек белән көтеп торганнар. Суктырудан чиләнеп торган урыннарны күргәч, «ах» иттеләр. Иртә белән көчкә аягыма бастым, авыртуга түзәрлек түгел. Хәер, әле бу башы гына булган, алда мине тагын да хәтәррәк вакыйгалар көтеп торган икән.

## Павел Кайденко

Беренче мәлләрдә барак эче такта белән бүлемнәргә бүленгән иде, соңрак ул бүлемнәр бетерелде. Һәм барак эче, гөжләп торган умарта кучедәй, шау-шулы булып калды. Бөтен халык бер-берсеннән кемнең кайдан булуы белән кызыксына. Монда Украинаның бөтен почмакларыннан да бар. Бер егет баракның аргы башыннан килеп: «Егетләр, Сталино яисә Донецкидан кем дә булса бармы?» — дип сорады. Мин аңа: «Пролетарка шахтасыннан булам», — дип җавап бирдем. Ул үзе Славянскидан икән. Шулай итеп танышып киттек. Исеме Паша, Павел Кайденко икән. Украинча гына сөйләшә. Макеевкадагы татар мәктәбендә урысча да, украинча да укытканнар иде, шул ярап куйды: мин өч телдә дә җиңел аралашам.

Якташлар буларак дуслашып киттек. Башкалар белән сөйләшеп, хәтта нарлардагы урыннарны да янәшә күчердек. Алгарак китеп булса да, адреслар бюросы аша, сугыштан соң аны эзләп табуымны һәм очрашуыбызны әйтеп китәм. Ул бик яхшы кеше һәм бер дигән дус булып чыкты. Авыр чакта нык ярдәме тиде. Ул булмаса, ай-һай, исән калыр идем микән? Иптәшләрнең байтагы ачлыктан үлде.

Ашханәдә Марьян атлы чех эшли иде. Ул еш кына кемне дә булса үзенә ярдәмче итеп ала. Ярдәмче булу бәхете күбесенчә Павелга елмая. Павел аннан буш кайтмый, әлбәттә, артып калган баланда алып кайтып, мине һәм тагын кайберәүләрне сыйлый. Бу лагерьда без аның белән сугыш ахырына кадәр булдык. Бусы — егерме беренче номерлы штраф лагерен санамаганда. Павел «егерме берледә» — ике, ә мин өч тапкыр булдым. Соңгысында америкалылар коткарганга кадәр. Ошбу урын чын тәмуг иде.

## Анатолий Гесс

1943 ел бара. Мин инде немец лагерьларында елдан артык газап чигәм. Безнең янәшәдәге нарда Ставрополь краеның Тихорецк станицасыннан Гриша Чумаченко дигән казак урын алган. Аны еш кына лагерь комендатурасына чакыртып алалар. Нигә чакыртулары белән кызыксынганнан соң, ул кулын гына

селти. Өченче баруыннан аны яхшы гына тәпәләп кайтарганнар иде. Бу юлы ул түзмәде, чишелеп китте. Советлар вакытында аларны кысулары турында исенә төшергәннәр һәм хәзер үзләренә хезмәткә чакырганнар икән. Ризалашмагач, дөмбәсләгәннәр. Шулай да әлегә җибәргәннәр. Кайчагында лагерьга ниндидер кешеләр килеп чыга. Үзләре урысча яхшы сөйләшәләр. Алар килгәч, бар халыкны плацка куып чыгаралар һәм агитпропаганда тотына: «Кемнәргә унсигез тулды, хәрби хезмәткә чыгыгыз, яхшы ашарсыз һәм киенерсез», — диләр алар. Тик беркем дә язылырга ашыкмый. Немецлар котырып, камчылар белән селтәнә-селтәнә һәм: «Әрәмтамаклар, сезне ачка гына үтерәсе!» — дип безне куып тараталар. Бу хәл әллә ничә мәртәбә кабатланды. Әмма менә карап кына фашистларга хезмәткә яллануучы табылмады.

Безнең баракта Анатолий Гесс атлы егет бар иде. Аны да даими рәвештә комендатурага дәшә башладылар. Ни өчендер төннәрен. Берсендә ул: «Егетләр, үпкәләмәгез, мин сездән башка лагерьга күчәм инде», — дип белдерде. Алтынчы номерлы бу лагерьда «фольскдойчелар» тотыла икән. Алар иркле диярлек йөриләр, немецларга тыңлаштерәләр үзләрен, тик барыбер дә тулы канлы ариецларга кермиләр, имеш. Анатолийны шунда күчерделәр. Шулай да ул берникадәр вакыттан соң безнең янга кайтты. Кыяфәте кызганыч, кыйналудан йөзләре шешенгән иде.

## «Гитлерюгенд» белән раунд

Безне төрле эшкә куалыйлар. Җир дә казыйбыз, вагоннардан ком, гравий бушатабыз. Барыннан да бигрәк цемент бушатуы авыр. Көн саен иртә таңнан караңгыга кадәр эш тә эш. Тышкы дөнья белән бәйләнеш юк диярлек, кайбер нәрсәләрне Антонио Миоттодан гына ишетеп беләбез.

Иртән тору вакыты биштә. Чөгендер катнаштырып пешерелгән 150-200 грамм тирәсе ипиенне алгач, колонна белән эшкә алып китәләр, кич белән алып кайталар. Лагерьда шпинаттан әзерләнгән баланда кетә. Аны тизрәк алу җаен карарга кирәк, югыйсә чүмеч белән баш түбәнә менеп төшәргә дә күп сорап тормыйлар.

Безне карьерга алып баралар. Колоннаның һәр рәтендә бишәр кеше. Юл кырыйлап алмагачлар тезелеп киткән һәм аларда кызарып пешкән алмалар ымсындырып тора. Авыздан сулар килә, и-их, берсен генә булса да ашасаң икән! Юл кырыйлары буйлап ундүрт-унбиш яшьләрдәге немец үсмерләре тезелеп баскан. Барысы да конгырт төстәге кыска ыштаннардан, шундый ук төстәге кыска җиңле күлмәкләреннән җиңнәрендә свастика төшерелгән. Муеннарындагы кара галстуклары, билләренә тагылган кортиклары һәм башларындагы кокордалы пилоткалары аларны менә кадәр без күрмәгән башка яшьтәшләреннән аерып тора. Болар махсус «гитлерюгенд» командаларында тәрбияләнүчеләр икән. Мин әле күп еллар дәвамында бу күренешне төшләремдә дә күреп саташачакмын һәм салкын тиргә батып куркып уяначакмын. Ул чагында түзмәдем, стройдан чыгып, тиз генә бер алманы эләктердем. Тик кире урыныма басканчы, арттан ныгып җитмәгән үсмерләр авазы ишетелде. Колонна алдындагы конвоирлар: «Хальт», — дип, туктарга кушып оран салдылар. Гитлерюгендчылардан бер үсмер, сакчылар янына чабып килеп, безнең якка күрсәтә-күрсәтә, нидер аңлата башлады. Автоматлы конвоир мин басып торган тирәгә якынлашты һәм, чыгарга кирәк икәнлеген ишарә белән аңлатып: «Рушин швайн», — дип акырды. Мин һаман алманы кулымда тотып басып торам, чыгарга җыенмыйм. Фашист бөтен колоннаны яткырып-торгызып азаплый башлады. Бу хәл берничә минут дәвам итте. Аннары кабат чыгарга кушкан әмер яңгырады. Чыгучы күренмәгәч, немец

янә яткырды-торгызды. Бу хәл берничә мәртәбә кабатланды. Фриц түзмәде, автоматыннан һавага чират бирде. Ул да түгел, инде котырынып, көпшәсен безнең якка төбәде.

Мин уртадарак идем, уң һәм сул ягымдагы иптәшләрем: «Синә чыгарга кирәк, югыйсә башкалар да зыян күрәчәк. Фашистларның берни алдында да туктап калмаганнарын үзең дә беләсең», — дип пышылдадылар. Чыкмыйча чара юк. Менә мин строй читендә, кулымда — алма. Немец, алмага төртеп күрсәтеп: «Син өзденме?» — дип сорый. Мин инде бераз алар телен аңлый башлаган идем. Алманиядә урлашкан өчен каты җәза икәнен дә беләм. Ничек итеп алманы ташлавымны сизмичә дә калдым. Немецлар мондыйны гафу итмиләр иде. Конвоир, оран салган кечкенә фашистны чакырып китереп: «Бу урыс дунгызын тукма», — дип кинәшен бирде. Гитлерюгендчы мине боксёрларча бәргәләргә кереште. Саклану чаралары күрәм, һөнәри училищеда укыган чактагы бокс секциясенә йөрүләрем менә кайчан ярап куйды. Фашист баласына минем кебек уналты яшьләр булыр, тик шунсы: ул — өреп кабарткан кебек, ә мин — ябык. Ул селтәнүен белә, мин сакланырга тырышам, аңа сукмыйм. Бөтен конвоирлар ошбу тамашаны карарга җыелды. Ат урынына кешниләр. Конвоирларның күбесе элекке фронтовиклар, арада бераз урысча сукалый торганнары да бар. Берсе шунда, вата-жимерә: «О, рус курка! Әйдә син дә сук, без карап торабыз», — димәсенме. Немчура, суга торгач, минем борынымны канаткан иде. Өстәвенә бу сүзләр утка май сипкән кебек тәэсир итте. Фашист калдыгын ике куллап якасыннан эләктердем дә баш белән танавына бирдем. Ул егылды, борыныннан шарлап кан китте. Гитлерюгендчылар шуны гына көткәннәр диярсең, өерләре белән миңа ташландылар. Аяк асларына салып типкәли дә башладылар. Башымнан: «Бетүем шушы икән», — дигән уй чагылып узды. Гомерем бетмәгән икән: өер янына кара төстәге җиңел машина килеп туктап, аннан югары чиндагы ике офицер чыкканы күренде. Сакчылар һәм гитлерюгендлар аларны күреп үрә каттылар һәм, уң кулларын алга ташлап: «Хайль Гитлер!» — дип сәламләделәр. Чины буенча өлкәнрәк бер конвоир, офицерларга ни булганын аңлатып булса кирәк, өзек-өзек нидер әйтте. Офицерларның берсе, кулы белән ишарәләп, миңа аягыма басарга кушты. Аннары күзләрен кыса төшеп, бермәл минем күзләремә төбәлеп торды. Язмышымның бу мизгелдә шушы фашист кулында икәнлеген аермачык сиздем һәм, сер бирмәскә тырышып, карашымны читкә алмадым. «Яволь», — диде офицер, нииндидер карарга килеп, нотык укыгандай, үзенекеләргә тагын берничә сүз әйткәч, иптәше белән машинага утырып китеп тә барды. Мин исән калуыма ышанырга да, ышанмаска да белмичә, баскан урынымда катып калгандай, тик торам. Өлкән конвоир стройда урыныма басарга кушып әмерен кабатлагач һәм җилкәмнән этеп җибәргәч кенә исемә килеп, элекке урыныма бастым. Ниһаять, колонна кузгалып китте. Гитлерюгендчылар бүре карашлары белән озатып, йодрыкларын селтәп калдылар.

*(Ахыры киләсе санда)*



Мөхәммәт
Мирза

# КЫСЫР ГАРИФ

ПОЭМА-КЫЙССА

*Йөзләрчә миллион кешеләрне һәлак иткән, гарипләндергән, ятим калдырган, коточкыч мохтаҗлыкка дучар иткән Икенче Бөтендөнья сугышы тәмамлануга ук җиһанда «салкын сугыш» кабынып китте... Соңгы сугыш җимереклекләреннән, югалтуларыннан мантымаган СССР дәүләте кабат сугыш кабаласына юлыкты... Җирдә тигезлек, бәхетле җәмгыять төзү идеяләре белән яшәгән илне тәмам таркатып ташлады ул сугыш. Әллә соң ул идеяләр утопия, кысыр хәсрәт кенә булганмы? Сугышларны хакка-нахакка, явызга-изгегә аерып карау үзе үк кешелек алдында гаделсезлек, әхлаксызлыктыр. Сугышларны дөнья байлыкларын кабат бүлешү, таланган-яуланган байлыкның хуҗаларын аклау-саклау өчен махсус китереп чыгаралар дип бәяләүчеләр хаклымы әллә?*
*Салкын сугышның әлегәчә туктаганы юк. Аның корбаннарының тулаем исәбен-хисабын әйтеп бирә алучы да булмас... Ул корбаннар арасында минем якташларым, якыннарым да бар...*

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Авылдан хат: Гариф вафат...
— И бәндә язмышлары...
Сугыштан соңгы буынның,
Дөньяга мәҗбүри килеп,
Ләгънәтле каргышлары...

Әткәсен көткәннәргә ул
«Уйнаштан туган» иде.
Аның әткәсе дә юкса,
Кемнәрнендер әткәсенә
Бик якын туган иде.

Аның әткәсе дә юкса
Сугышта булган иде:
Гайнелгыйлем санитарның
Сул кулын терсәк төбеннән
Кыйпылчык уйган иде.

Мөхәммәт МИРЗА (1953) — *шагыйрь; «Киек каз юлында», «Тере су», «Елганың аргы ягында» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Гайнелгыйлем — ике сугыш
Күргән карт солдат иде.
Жәен-кышын гәләфиен
Салмаганга, «солдат» дигән
Кушамат алган иде.

Сугыштан исән кайтканнар
Тансыктан-тансык иде.
Чулак, чатан булсалар да,
Тоз утырган иннәрен дә
Мир йөге баскан иде.

II

Гайни солдат — ветсанитар,
Һөнәренең остасы.
Жиде авыллы колхозның,
Өч йөз җитмеш хуҗалыкның
Ышанычы-терәге.

«Касторка» мае — белгәне:
Бәйләгәне, сөрткәне...
Калхуз маллары элгәре,
Аннары чираты белән
Өйдән-өйгә кергәне.

...Сыер малларын янәдән
Сәвитләр җыеп алды.
Жаннарын саклап торырга
Шыр-ялангач гаиләләргә
Кәҗә, сарыклар калды.

Кәҗә, сарык бәтиләре
Өлешенә кереп тә
Имә иде ятимнәре...
Искә төшә шул хәлләре:
Елатып та, көлеп тә...

Толлар зарыгып көтсә дә,
Кайтмады көткәннәре.
Кайсылары өмет өзеп,
Гәләфиле Гайниләрне
Кунарга керткәләде.

Гөнаһына керәсе юк,
Кем дисәң дә — ул булыр.
Гайни тәкә печкән йортта,
Тугыз ай үтәр-үтмәстән,
Елап нарасый туыр.

Елап туар нарасые —
Дәгъвасы булыр чиксез.
«Уйнаштан туган малай», — дип
Рәнҗетелгән шул сабыйның
Үпкә-үче — үткесез.

Гарифнын әнкәсенә дә
Ягылды кара яла:
— Гайни солдат-ветсанитар
«Касторка» маен сөртә дә,
Авыллар үрчеп бара.

«Уйнаштан туганнарга» да
Күлмәк, ыштан кистеләр...
Сөннәтле булсалар да, тик,
Ни кызганыч, дөньясына
Алар үчле үстеләр.

Ач тамакка төер булып
Утырды ачулары...
Сугыш соны ятимнәрен,
«Уйнаштан» тамгасы тагып,
Ачлык белән сыйлады...

### III

Ачлыкның күзе гел яшьле,
Карашы тоныk, ямьсез...
Көнозыны бил бөгеп тә,
Өй тулы бала-чаганы
Ачлык тотты икмәксез.

Калхузлар — күмәк коллыкның
Кот чыгарлык үрнәге...
Хезмәт көне — кенәгәдә,
Шәрә өстәл-сәкеләре
Чәйнәр ризык күрмәде...

Яз житсә, каен суына —
Урманга сыендылар.
Жәй башыннан кузгалагын,
Жуа, балтырганын жыеп, —
Болыннан туендылар...

...Уйнаштан туса да Гариф,
Уенны күрде сирәк.
Жәен — арба, кышын — чана —
Көн дә, төн дә ни булса да
Табып кайтырга кирәк.

Утыртма читән, коймасы —
Тал курпы, чыра гына.
Кизәк-тирес «кирпечләрен»
Изеп тау-тау киптерәсе —
Кыш ягып чыгарына.

Салам түбә — йорт курасы —
Ел да бер янартасы...
Кайдан ни дә булса чәлеп,
Чытырма шул «уф» арбасын
Көн-төн жиглеп тартасы...

Алты яшеннән тәртәгә
Җигелеп тартты Гариф.
Тарткан саен ни дә булса
Чирәмле ихатасына
Кайтарып атты Гариф.

Табыласы көнен барлап,
Төнен кармап саласы...
Салганында — күчәр сына,
Тартканында — тәртә сына, —
Сынмый Адәм баласы!..

Гайни солдат-ветсанитар
Тамчыдан төшкән улын
Күрсә дә — күрмичә үтте...
Хәлен белеп сузмады бер
Хет гарипләнгән кулын...

Гайни солдат гәләфиен
Салмады гомре буе...
Җиде авыллы калхузның
Тишек-ертыгын ямаулап
Йөрүдә булды уе...

Уйнаштан туган малайлар
Бер Гариф кынамы соң...
— Әтиең кем, кайда? — дигәч,
— Сугышта үлеп калган, — дип
Җавап бирде барысы...

Җаваплары хөкемчедән
Аклану кебек иде.
Җәрәхәтле җан итеннән
Кансыз сөлек кан эчүдән
Саклану кебек иде...

IV

Житмеш йорттан йөз ун ирне
Суырып алды сугыш.
Житмешенең җанын кыеп,
Җәсәдләрен чит җирләрдә
Чәчеп калдырды сугыш.

Өчпочмаклы хаттан алда
Козгын китерде хәбәр...
Хәбәренең хәтәреннән
Черек салам түбә өйләр
Дерелдәп торды мәгәр...

Бер хәбәрсез югалды дип,
Хәбәр килде берсеннән...
Сабан туе иртәсендә
Ярәшеп вәгъдәләшкәне —
Көткәне әнкәсенең.

Гарифжанның әнкәсенең
Бәгырьләрен өтте ул.
Хәбәрсезлек хәбәреннән
Өмет чырасын сүндерми
Нәкъ жиде ел көтте ул.

Чыра яктысы сүрелми,
Корым, сөреме кала.
Хәбәрсез югалды, дигән
Жавап кына килде бары —
Кайда язып карама.

Сугыш чоры, сугыш соңы —
Көткәнгә аерма юк...
Көтеп көтек булганнарның,
Ятимә-тол калганнарның
Канатын каерган ул.

Әсирлектән кайтканнар да
Сөрелде әсирлеккә...
Өметен жуеп, гаиләләр
Ишек, тәрәзен кадаклап
Китеп югалды читкә...

...Жәен — чиллә, кышын — кырыс,
Язы-көзе баткак саз.
Мул утырды аркага тоз...
Житмәгәне тол-ятимгә —
Бер жылы кул, жылы наз.

Мулдан булды куркытулар,
Ачуның — яман үче...
Калхузлары күтәрәмдә...
Дәүләт саплам жеп бирмәде
Ертыгын ямар өчен.

Уйнап түгел, уйлап әйткән
Кемдер кайнар башыннан:
Хакыйкатьтә калхуз үзе
Тома ятим туган икән
Дәүләтнең уйнашыннан.

Бу дәүләт үзе туган ди
Сугышып кан коештан...
Гасырлардан жыйналган үч,
Нәфрәт, ачу — яшен ташы
Булып тулган сулышка...

Ачның ачуы ямандыр,
Үксездә үч үткесез...
Гарифжанның әнкәсенә
Ел тәүлеге «таяк сызган»
Бригадир бер күзсез...

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Җиде сыйныфны тәмамлап,
Гариф керде атлы эшкә...
Утыз яшьлек карт алаша —
Иң беренче тарту көче —
Калхузда эшкә керешкә...

Утыз яшьлек карт алаша
Атлап бара, алып чапмый,
Унга-сулга борылырга,
Туктарга йә кузгалырга
Бер сүз җитә: «Йәле, малкай!»

Хезмәт көне бер таяклы
Тамга сызып төшерелә.
«Таяк» саны өч йөз булса,
Язын чәчкән көзен уңса,
Өлеш төшә көшеленә.

Калхузның тегермән ташы
Тешне чарлап әйләнәдер...
Калхузга аягың керсә,
Гәүдәңне суырып алып,
Гомерлеккә бәйләнәдер...

...Калхуз малын таяк сызып,
Биш ел тоташ көтте Гариф,
Алашасын аргамакка
Алыштырып, кыр болында
Очырттырып йөртте Гариф.

Яздан-көзгә Агыйделнең
Җәйләвендә җәйләде ул.
Әрәмәдә тал-курасын
Кисеп, чабып, кыш чыгарлык
Утын-печән җайлады ул.

Хезмәт көне — таяк кына...
Болынның мул байлыклары.
Агыйделдә, күлләрендә
Үренте тал мурдасына
Тулып керә балыклары.

Агыйделнең тугаенда
Июльнең тулган аенда,
Юкә ябалдаш эчендә,
Тулып түгелә балы да —
Сәбәп туа сыйланырга.

Әрәмәдә — гөлҗимеше,
Бөрлегәне, карлыганы.
Авылның бар яше-карты,
Җәй җитүгә, бердәм булып,
Әрәмәгә агыладыр...

Әрәмәдә үлән, чәе,
Балан, кагы табыладыр.
Кузгалагы — кош-кортына,
Курпы-күрән — терлегенә
Кыш чыгарлык чабыладыр.

Мең михнәттән торган тормыш
Җәйләвендә ни җайлана...
Табигатьнең кочагында
Рәхимлеген, шәфкатен дә
Таба икән ятим бала...

II

Ат җене кагылган Гариф,
Аттай эшләде: «Булсын, — дип, —
Аяк ялы — тамак ялы,
Бригадир сызган таяк
Өч йөз алтмышка тулсын», — дип...

Сызган таяк — көн дә барлау...
Салган займ — таныклыгы...
Унтугызы тулган көздә
Армиягә чакырдылар
Күреп бәдәне ныклыгын...

Парлап җигелгән арбага
Менеп басканнарын күр син,
Сугыштан соң туган буын
Беренче кат армиягә
Җырлап озата бер-берсен...

Пар атларда зур урамны,
Тыкрыкларны урадылар...
— Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар! — дип,
Бәгырьләрне турадылар.

Басу капкасын чыгуга
Саубуллашу, хушлашулар...
Кыз бүләге — чиккән яулык:
Исеме язып, асылдан
Таслап төрелгән, хушбуйлап...

Чиккән яулык сөйгәненең
Хисләре дә, ядкаре дә...
Күңеленнән разый булып,
Ышанып, өметләндереп:
— Көтәрмен, — дип әйткәне дә.

Чиккән яулык сагынганда
Сагышын басар өчен дә...
Зат күрмәгән ят җирләрдән
Яры көткән ярларына
Кайтыр юл табар өчен дә...

Гариф көтәр яры барын
Күрмәгән шул — көн-төн эштән.
Күрше өйнең күршесендә
Аңа тине — Нәфисәсе
Гөлҗимештәй булып пешкән.

Басу капкасын чыгуга
Килеп житте янып, чабып:
— Гариф абый, хатларың яз,
Җавапларым сөйләр барын —
Вәгъдәм-яулыгым учыңа!

### III

Гәләфиен киеп алгач,
Тач охшап калды Гайнигә...
Ветсанитар малаеның —
Аталы ятим баланың
Аһ, күнеле тулды нигә?

...Әткәсен күреп: «Әткәй!» — дип
Әйтәсе бик килгән чакта
Бер гөнаһасыз бу бала
Ничә тапкыр качып кына
Көтеп алыр иде чатта...

Көтеп алыр иде чатта —
Чабып керергә кочакка
Әзер иде, тик әткәсе —
Айныр-айнымас санитар
Уйламый иде бу хакта...

...Ун ел узды вафатына:
Калып ауган арбастында
Төнозыны тартышкан ул
Гомер иткән соңгы көне
Һәм үлеме арасында...

Хәтергә уелган барсы,
Яндырып тирәнгә кереп...
Солдатка алынган көннән
Жан сорап торган сынаулар
Алырлар аны бөтереп...

### IV

Күрәчәге йөртә микән,
Йөртәме жыяр тәгаме?
Карантин үткән солдатны
Мәңгелек төн дингезендә
Дәшә язмышы әләме...

Мәңгелек төн дингезендә
Дулкыннары калган катып,
Офыклар карадан-кара,
Төнне ярып кораб бара,
Тау-тау дулкыннарны ватып.

Боз дулкыннар шуып менә
Корабының итәгенә...
Ун көнлек юлны төн йотып,
Бозлы ярга килеп туктый
Дөм караңгы иртә белән.

Кап-караңгы бозлы ярда
Бурап-бурап боз-кар ява.
Корабтан кара шәүләләр,
Трап буйлап күтәрелеп,
Кара ярда югалалар.

Чакрымлап атлап үтүгә, —
Кап-кара тимер капкадан
Чыкты каршы алучылар:
Этләре — усал сакчылар,
Барлап алдылар тамгалап...

V

Өч ел үтәчәк хезмәте
Җирнең җиде читендәге
Дөм караңгы утравында:
Монда күрмәссең очкан кош,
Монда үсми чирәме дә...

Монда бозлы күкерт таштан
Гайре һични искитәрлек,
Берни юк, дип уйлаганнар...
Анда исә бу дөньяның
Астын-өскә китерерлек,

Яктыртып сукыр итәрлек,
Шартлатып күмер итәрлек,
Кешелек әле белмәгән
Могҗизалары житәрлек
Уран ятмасы табалар...

Урал, Себер — алтын базы,
Донбасс, Кузбасс — күмер базы.
Әлмәт, Баку — нефть базы —
Ходай безгә мулдан биргән
Жиһанның бай казылмасын...

Мәңгелек төн диңгезендә,
Бозлы күкерт-таш иленда
Илнең якты киләчәге,
Байлык, муллык бирәчәге —
Тагын биш гасыр кимендә...

— Үр артында түгел, якын,
Коммунизм — кулсузымда...
Тик дошманнар һаман читтән
Кызыгып гел кыжрап тора,
Шул байлыкка кул сузарга.

Эчке дошманнар да хәтәр —
Эш итәләр гел астыртын.
Шуңа мәхбүсләр казыйлар
Монда уран шахтасын да
Безнең үткен сак астында...

Дәүләтнең стратегиясе —
Мондагы бар хезмәтебез.
Бүген кайда, кем белән сез,
Вазифагыз — дәүләт сере —
Үзегезне күзәтербез!!!

Сер сандыгы бикле торсын,
Канун белән ул саклана!..
— Анабыздай газиз илне
Сакларбыз, — дип антын биреп,
Һәрбер солдат имза сала...

— Иминлеген, бөтенлеген
Саклый алса гына Ватан, —
Диеп тәкрарлый замполит.
— Илебездә заргып көткән
Коммунизм таңы атар...

Уран шахтасы авызы
Төпсез кара чоңгыл кебек,
Бөтереп ала үзенә —
Кәйлә, көрәкләрен тотып,
Менләп мәхбүс китә кереп.

Бер мең мәхбүсне, чиратлап,
Биш йөз солдат барлап тора...
Таш диварда лозунглар,
Чакырулар алга дәшеп,
Хезмәтләрен данлап тора.

Мәңгелек төн диңгезендә,
Шул күкертле таш утрауда
Дерелдәп куя бар җиһан,
Сискәнеп куя күкләр дә —
Бер төш ядрәсе шартлаудан...

Сугыштан соң егерме ел...
Шартлауларның юк тынганы...
Бөтен дөнья, кубарылып,
Корал сыный, корал туплый —
Салкын сугыш, диләр аны...

Салкын сугыш салкыннарын,
Кайнарлыгын күрде Гариф.
Сугыш сорый корбаннарын:
Жиде айда сызып сүнгән
Жәсәдләрен күмде Гариф...

Жиде ай саен зур җирдән
Кораб килеп китәр иде...
Бер мең мәхбүсне калдырып,
Серле контейнерлар төяп,
Төнгә кереп китәр иде...

Ике ай конвой хезмәтен
Үтәгәннән соң, Гарифны
Госпитальгә күчерделәр:
Ул моргта санитар да,
Кочегар да булды инде.

Төн дингезе ак аюга,
Моржларга гына кулай.
Яктылык кытлыгында тик,
Алар өчен генә монда
Яшәү-гомер итү унай.

Адәм баласының хәле
Мөшкелдән дә мөшкел монда:
Авырлыгын тәмам җуя
Яктылык җитмәүдән бәндә
Жиде ай төн золымында.

Жиде ай төн золымында
Жиде солдат кибеп калды.
Госпитальдә шул афәттән
Йолып-коткарып алырлык
Шифа-дәва табылмады...

Остадан эш өркә, диләр...
Корал тота белә кулы:
Ул ясады табутларын,
Ул җирләде җәсәдләрен,
Ул — санитар Гайни улы...

Жиде ай төн золымында
Шахтаның бай токымында
Корып кипкән мәхбүсләрнең
Җәсәдләрен яндырды ул:
Хәбәре — көл корымында.

Хәбәре — көл корымында,
Кайда икән җанкайлары?..
Егерменче Җиңү язын
Көткәндә монда тәүге кат
Күрде ул Кояшны, Айны...

Төн дингезенең Кояшы,
Сүрән яктысы, җылысы...
Төн дингезенең Аенда
Зөһрә Сылу — бик ямансу —
Юктыр шул юатучысы...

Шыксыз шәрә күкерт ярга
Язын килеп житте кораб:
Солдатның көткәне хатта...
...Мәхбүсләрне төшерделәр
Номерларын атап, санап...

Әнкәсенең хатларыннан
Әрәмә тыны бөркелә...
Нәфисәнең нәфислеге
Тезеп язган юлларыннан
Йөгреп күз алдына килә...

Сонарган бер кочак хатта
Төсен жуймый жуймагач та,
Агыйделнең бар аклыгы,
Болынының бер мең гөле
Йөзенче кат укыгач та.

Чабып үтә аргамагы
Тоякларын төеп-төеп,
Тирәкләр биеп әйләнә,
Жил күтәреп кибән коя,
Күбә, чүмәләсен өеп.

Хатларында хуш хәбәр бар:
Йөзләрендә ае тулган,
Яңа елдан хезмәт хакын
Түли башлаган калхузлар,
Насыйп булырмы кайтулар?

Мәңгелек боз илендә дә
Тәнне жылыта тик жаннар...
Яктылык кытлык жирендә
Хатта килгән жан жылысын
Мохтаж бары үзе анлар...

VI

Мәңгелек боз утравына
Кораб өченче мәртәбә
Килгән жәйдә... Гариф сынды:
Үр менеп килгәндә кинәт —
Тәкъдире типте тәртәгә...

Язмышы типте йөзенә —
Йөзе сулды, нуры качты.
Олы жиргә озатырга
Карар кылдылар, ике ай
Госпитальдә аунагачтын...

Утрау-утрау бозлар ага,
Кораб итәгенә кага...
Ике ел тулар-тулмастан,
Үтмәслек хаста йоктырып,
Солдат илгә кайтып бара.

Солдат илгә кайтып бара.
— Кайтам, — дип язды хатын да.
Юллар ерак: борма-борма
Мәңгелек туң тундрада
Кара урманнар артында...

Олы җирдә җиде атна
Укол белән тунадылар.
«Не годен на строевой», — дип,
Пичәтләрен кат-кат басып,
Ил-йортына юлладылар...

Кайтып керде бусагадан
Кыл уртасында августның...
«Гайни солдат», — диеп тора,
Белгән-күргән, әткәсенә
Охшатып анның буй-сынын...

Гайни солдат күкрәгендә
Медаль иде «За отвагу»...
Гарифҗанның үпкәсенә
Су җыелган, ютәленә
Буыла язып куя ул...

...Әнкәсе белән Нәфисә —
Әнкә-кыздай дип торырсың...
Көн дә мунча кыздырдылар,
Чаптылар һәм сыладылар
Пешереп җитен, солысын...

Бурсык маен кыш озыны
Өзмәделәр тамагыннан...
Гәүдәсен тирегә төреп,
Кызган табага бастырып,
Чир кудылар табаныннан...

Кипкән җиләк, үлән чәе —
Әрәмә аптикәсеннән...
Агыйделдә боз кузгалып,
Ташкыннарына бөтереп,
Чирен алып китте сыман...

Җан биргәнгә җүнен бирер...
Җаныңны саклый фәрештә.
Күрәчәгең — тәкъдиреңдә,
Күрми керү юк гүреңә —
Тәкъдир языла гарештә...

Тәкъдирендә әнкәсенең
Ялварулы догалары:
— Раббым Бер, ярлыкагыл,
Белми, белгән гөнаһларым —
Өзмә гомерен бу баламның.

Өзмә гомерен, кирәксә ал
Үземнекен — мең разыймын.
Инанып Бар, Берлегенә
Тәүбә кылам, рәхмәтенне,
Шәфкатенне мин сорыймын!..

Тәкъдиренә карусызлар
Ирешә тик морадына.
Тәненең сихәтләнүен,
Яшәү уты кабынуын
Тәкъдиренә юрадылар.

Көл төсендә иде йөзе,
Чәчләре тоташ көмештә...
Маңгаенда буразналар —
Илле яшен биреп булыр
Егерме өчтә килеш тә...

Аягына басты Гариф —
Арык тәнендә җан исән.
Ишегалдын урап керде,
Әйләнеп кайтты урамны,
Янәшәдә — Нәфисәсе...

## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Җан биргәнгә җүнен бирде,
Инде бетте дигән мәлдә...
Нәфисәсе белән бергә
Веттехникумга укырга
Керде алар Бөгелмәдә...

«Алга» колхозын алгары
Җибәрү алар көчендә...
Ел тәүлеге фермасында
Дүрт куллап хезмәт куйдылар
Үрчемнәр артсын өченгә...

Үрчем артымы малларның
Кысыр калмавыннан тора...
Миллионер калхузлары —
Серен бик беләсең килсә,
Син Кысыр Гарифтан сора...

«Кысыр» кушаматын авыл
Мәңгегә такты аңарга...
Насыйп булмады ир белән
Нәфисәсенә утыз ел
Яшәп бер бәби табарга.

Утыз ел тормыш кордылар —
Калмады нидер табары.
Мәхрүмлеге — баласызлык...
Төн иленең афәт нуры
Көйдергән икән тамырын...

Кысыр Гариф ихатасы —
Эчләре урап чыккысыз...
Кысырлык үзеннән битәр
Нәфисәсенең бәгырен
Телгәләп кисте пычкысыз...

Салкын сугыш — чарасызлык —
Тәкъдире дип юрасынмы?
Гайнелгыйлем санитарның
Ник өзелде нәсел жебе —
Кабереннән сорасынмы?..

## II

«Кырык ел серен сакларга», —
Дип имзасын салган иде...
Ил-дәүләтнең үзен әнә
Таратып-сатып яталар...
Калхузы да калмас инде...

Атказанган Кысыр Гариф
Үрчетте нәсел малларын.
Пенсиягә озаттылар...
Ике елдан калхузының
Югалды миллионнары!..

Ялангачлык, мохтажлыкның
Ни икәнен күреп үсте...
Ил кодрәте — корал, гаскәр —
Бозлы, тозлы дингездә дә
Бар нәрсәдән булды өстен...

Ил кодрәте — ил чикләрен
Саклый алуыннан тора...
Дошманның борын төбендә
Баллистик ракеталары:
Кирәксә, шунда ук ора.

Ил кодрәте — болытларның
Артына ук яшеренгән.
Дошманының, кирәк икән,
Йолдызлардан торып төзәп,
Күзен алыр яшененнән...

— Ил кодрәте — илдәшләрнең
Дуслыгы, туганлыгында, —
Дип яшәделәр житмеш ел...
Күз бугандай юкка чыкты:
Шик туа булганлыгына.

Кодрәтле ил гаскәрләрен,
Коралларын тараттылар.
Никадәрле тиз таралса,
Читләр безне шулкадәрле
Үз иттеләр, яраттылар...

III

Гарифның бакча артында
Буровойдан нефть бәрде.
— Авылыгыз Кувейт булыр —
Кая куеп бетерерсез
Бу кадәрле мал-мөлкәтне? —

Дип шаяртты якын-тирә,
Баксаң, нефть күле өстендә
Утыра икән үзләре.
Нефть дөнья базарында
Бәһасен көн-төн үстерә.

Көн-төн үстерә бәһасен,
Кирәксә куя төшереп...
Базар алыш-бирешендә
Кем алдый — кем алдануын
Булмый тиз генә төшенеп...

Мичкәсенә саф алтыннан
Түлиләр чит-ятлар килеп,
Читләрнең акчадан гайре
Берниләре дә юк икән —
Яшиләр, ди, гел тилмереп...

Читләр, акча-алтыннарын,
Алыштырып газ-нефтькә,
Саталар да табышлары
Алтын булып кайтып керә,
Биш тапкыр артып кимендә...

Шуңар Гариф бакчартында
Чыккан нефть — кара алтын...
Сары алтын булып һаман
Кайтып керә алмый йөри —
Йолыр иде кара атын...

Бакчартында яткан байлык,
Үз көне, сәгатен көтеп.
Үлчәменә салсаң әгәр —
Мең ел илне туендырып
Торыр, өс-башлары бөтен...

Үлчәменә салсаң, маллар
Үрчем санын арттырырга —
Җир шарының алтыдан бер
Иксез-чиксез җире җитмәс,
Көтүләп тараттырырга.

Гарифҗанның исәбендә,
Кем ни-нәрсә дисә — дисен,
Мәңгелек төн дингезендә,
Бозлы күкерт таш базында
Илен саклады, ул — исән!

Исәнлеге — иле-көнен
Исәп итәр өчен кирәк...
Кысыр Гариф, дисәләр дә,
Иле-кодрәте өченгә
Кысырлар да кирәк, димәк.

***

...Мең төрле уй тулган башын
Салуга ук мендәренә,
Кайнарланып тулды кинәт...
Күзләре калды шар ачык —
Йокыга талды мәңгегә...

Мәңгелеккә күчте жаны,
Калдырып кысыр җәсәден.
Яшьтәшләре күптән гүрдә...
Сорасалар, кемдер әйтер
Дип, «Кысыр булып яшәде...»

Кемдер әйтер: Гайни солдат
Үрчеткәнен авылларын...
Кемдер әйтер, үч иткәндәй,
Кысыр улы үрчеткәнен
Калхузларның терлек-малын.

Кемдер әйтер йә гел әйтмәс —
Гыйбрәтләнеп дәшми торыр...
Уеннан уймак чыгарсаң —
Дошманнарың гына түгел,
Дус-ишләрең сугыштырыр...

Килү-китү дөньясы гел
Сугышлардан торыр микән...
Авылдан хат: «Гариф вафат...»
Җавабым күпкә соңарды —
Укучысы булыр микән?!.



Рәхим Саттар (Габделсаттаров Габделрәхим Сөләйман улы. 1912-1943). Шагыйрь. Антифашистик хәрәкәттә Муса Җәлилнең көрәштәше. 1943 елда әсирлектән кача һәм хәбәрсез югала.



Хәйретдин Мөҗәй (Хәйретдинов Мөҗәһит Хәйретдин улы. 1901-1944). Шагыйрь, прозаик, полковник. Башкортстанның Туймазы районыннан. Әсирлеккә эләгә. Антифашистик оешманың җитәкчесе була. Дахау лагеренда үтерелә.



Нур Баян (Баянов Нур Галим улы. 1905-1945). Шагыйрь, мөхәррир, офицер. Бөек Җиңүгә 15 көн генә калгач, Австрияне азат иткәндә һәлак була.



Вәдүт Мифтахов (Мифтахов Вәдүт Кәшшаф улы. 1915-1942). Шагыйрь, педагог. Җәсәде Тула өлкәсенең Рыдань авылы янындагы туганнар каберлегендә җирләнгән.



*Бу фоторәсем моннан 30 ел элек — 1985 елда Бөек Җиңүнең 40 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә Казанның Горький паркы каршындагы Мәңгелек ут янында төшерелгән. Бер төркем фронтовик язучылар – уңнан сулга: Нәби Дәүли, Мәгъсүм Насыйбуллин, Геннадий Паушкин, Сафа Сабиров, Рәйсә Ишморатова көрәштәшләрен искә алып уйланып басып торалар. Хәзер инде безгә — исәннәргә аларның үзләрен яд итәргә генә кала.*

## *Алар бүген дә безнең сафта*



*Хисам Камал (Камалов Хисам Нуретдин улы. 1926 елгы) — Татарстанның халык язучысы, Республиканың Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.*



*Фәйзи Галиев (Галиев Фәйзи Әхмәт улы. 1925 елгы) — фронтта яралангач туган ягына кайта. 49 ел колхоз рәисе булып эшли.*

# ЮГАРЫ СӘНГАТЬКӘ ЮЛ



*Быел Казан дәүләт консерваториясе ачылуга — 70 ел. Шул уңайдан консерватория ректоры, профессор, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе **Рубин Кәбир улы Абдуллин** белән әңгәмә кордык.*

**– Рубин Кәбирович, Казанда консерватория ачылуның әһәмиятен моннан 210 ел элек Казан университеты ачылуга гына тиңләп буладыр. Университет белән чагыштырганда, бик яшь әле консерваториябез. Шуңа да карамастан, аның шанлы тарихы бар... Шул тарихка кечкенә генә күзәтү ясап алыйк.**

– Консерваториягә нигез салу — ул үзе тарихи вакыйга иде. Ана хәтле булган мөһим күренешләрдән, университетның ачылуы белән беррәттән, Казанда опера театрына нисбәтле профессиональ музыкантларның, алар арасында дөньякүләм йолдыз — Фёдор Шаляпинның булуын әйтеп китәр идем. Һәм, әлбәттә, барлык татар композиторлары диярлек белем алган музыка училищесының 50 еллык эшчәнлеге бик зур роль уйнады. Алга таба музыка белемен тагын да югарырак дәрәҗәгә үстерү таләбе туды, һәм моның өчен Мәскәү консерваториясе каршысында татар студиясе ачылды. Казанда Нәҗип Җиһановның «Качкын», «Алтынчәч» опералары, Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты сәхнәләштерелде. Татарстанның музыкаль сәнгате үсешендәге бу казанышлар республикада консерватория ачу ихтыяҗын арттырды, музыка белемен югары биеклеккә җиткерү кирәклеген ачык күрсәтте. Р.А.Гуммерт оештырган музыка мәктәбендә, аннары музыка училищесында һәм Мәскәү консерваториясе каршындагы опера студиясендә белем алган музыкантлардан безнең тарихи шәһәребез өчен кирәкле булган профессиональ рухи җирлек оешты. Татарстанның Композиторлар союзын оештыру, беренче музыкаль спектакльләр, симфоник әсәрләр кую тәҗрибәсе, музыка коралларында уйнау — барысы да сәхнә сәнгате формалашуны таләп итә иде. Консерватория иҗтимагый-мәдәни өлкәне һәм профессиональ сәнгатьне яңа дәрәҗәгә күтәрү ихтыяҗыннан чыгып оештырыла. Нәҗип Җиһанов шушы өлкәдә булган барлык көчләрне һәм шәхесләрне берләштерә, ләкин бу гына җитенкерәми. Югары музыка белеме йортын лаеклы дәрәҗәдә булдыру өчен, Җиһанов дөньякүләм танылган музыкантларны консерваториягә эшкә чакыра: Мәскәү консерваториясе профессорлары Генрих Литинский, Григорий Коган, Ленинград консерваториясе профессоры Михаил Юдин килә. Профессиональ музыкантларның бөтен илебез өчен бик авыр булган сугыштан соңгы беренче елларда консерватория ачу идеясе тирәсендә берләшүләренә сокланырга гына кала. Шулай итеп, бөтен авырлыкларга да карамастан, Казанда югары музыка белеме йорты булдырыла.

**– Консерватория Бөек Җиңүгә санаулы көннәр калган вакытта ачыла. Татар язучыларын, рәссамнарын фронтка озаткан кебек, яшь-яшь композиторларыбызны да суырып ала сугыш. Беренче олы иҗат җимешләрен күрә алмыйча, алар анда мәңгелеккә ятып кала. Бездә сугыш чоры әдәбияты дигән иҗат дәвере бар... Музыкада да андый чор-дәвер аерып караламы?**

— Әлбәттә, музыкада да бар ул чор. Татар музыка сәнгатендәге сугыш чоры исә — ул музыкантларның сугыш елларындагы иң авыр шартларда иҗади активлык үрнәге күрсәтү, үз-үзләрен аямыйча, тулысынча бирелеп эшләү чоры. Әлеге еллар Татарстан профессиональ музыка сәнгатенең барлыкка килеп, үсеш алуында мөһим этап булып тора. Бу чорда төрле жанрдагы күркәм әсәрләр языла: Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзинең киң даирәдә башкарыла торган героик-патриотик җырлары һәм маршлары, Нәҗип Җиһановның «Илдар», «Түләк», Мансур Мозаффаровның «Зөлхәбирә», Михаил Юдинның «Фәридә» опералары. Симфоник жанрлар да туа. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: Идел буе республикаларында — Чувашия, Мордовия, Удмуртиядә — сугыш елларында музыка уку йортлары ябылса, Казанда музыка училищесы да, музыка мәктәпләре дә эшләп килә. Укыту белән генә чикләнмичә, алар музыкаль тормышның үзәгенә әверелә. Концертлар үткәрелә, педагоглар киң дәрәҗәдә музыка белеме бирү эшләре белән шөгыльләнә. Музыкантларның тырышлыгы Казан консерваториясенең уңышлы эшли башлавына да зур этәргеч бирә, чөнки әлеге уку йортына нәкъ менә сугыш елларында музыка училищесында белем алган беренче студентлар кабул ителә.

**— Консерватория диюгә, күз алдыбызга симфоник оркестр, опера, балетлар килеп баса. Соңгы дистә елларда дөнья опера сәнгатенең алтын хәзинәсе булып танылган җырчыларның иҗат очы — юл башы консерваториябездән башлана. Димәк, безнең мәктәбебез дөньякүләм стандартларга тиң... Милли опера сәнгатебезнең киләчәген ничек күзаллыйсыз?**

— Консерваториядән башка профессиональ симфоник оркестрның барлыкка килүе дә мөмкин булмас иде. Бүген дә Республика Дәүләт симфоник оркестры артистларының 95 проценты безнең консерваториядә укыган. Әйтергә кирәк, оркестрга нигез салучы Натан Рахлин коллективка төрле шәһәрләрдән бик күп музыкантлар тартты. Бу опера театры труппасына да кагыла. Театрның оркестры да, хоры да, опера труппасы да безнең югары музыка мәктәбен үткән музыкантлардан тора. Бу исә татар композиторлары язган әсәрләрнең опера театры сәхнәсендә һәм симфоник оркестр концертларында ешрак яңгыравына этәргеч бирде. Бүгенге көндә Казанда берничә симфоник коллектив, камера оркестры эшли һәм аларның һәрберсе даими рәвештә яңа әсәрләр башкара. Әлеге коллективлардан берсенең Яңа музыка оркестры исемен йөртүе дә очраклы хәл түгел. Консерваториянең үзендә генә 8 иҗат коллективы эшли: симфоник оркестр, опера студиясе, хор, милли инструментлар оркестры, камера оркестры, тынлы оркестр, фольклор ансамбле, репертуарының зур өлешен татар музыкасы тәшкил иткән Татарика оркестры. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: опера дигән музыкаль спектакль — сәнгатьнең синтетик жанры ул. Ул автордан симфоник культураның һәм вокаль сәнгатьнең нигезләрен тирәнтен өйрәнүен, спектакльнең темасын төгәл билгеләвен, аның җәмгыять өчен әһәмиятен аңлавын таләп итә. Консерваториябездә композиторның, симфоник коллективның, солистлар төркеменең, хорның иҗатын берләштерә торган опера студиясе нәтиҗәле эшләп килә. Соңгы ун ел эчендә генә дә опера студиясе тарафыннан 40 спектакль куелган. Студия репертуары нигезен чит ил һәм рус классик операларыннан торган классик хәзинә һәм шуның белән беррәттән Татарстан композиторлары әсәрләре, Салих Сәйдәшев, Җәүдәт Фәйзи, Нәҗип Җиһановларның яңартылган музыкаль спектакльләре тәшкил итә.

**— Милли музыка белгечләрен, музыка укытучыларын әзерләү буенча эш ничек тора? Консерваториядә белем алучыларның үз республикабызда эшкә урнашу мөмкинлекләре нинди?**

— Казан консерваториясе, илдәге барлык профессиональ музыка уку йортлары кебек үк, сәнгать өлкәсе өчен расланган дәүләт стандарты нигезендә эшли. «Стандарт» төшенчәсе үзе миндә каршылыклы хисләр уята, чөнки сәнгать ул күренешләрнең көндәлек чикләре артына чыгуны күз алдында тота, безне иҗади талантлы музыкантлар эзләүгә, сәнгать әсәрендә бүгенге тормыш контекстын



*Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең студентлар хоры һәм оркестры.*

гадәти булмаган яктан, югары дәрәҗәдәге рухи кыйммәтләрне чагылдырып аңлатуга этәрә. Әмма канунга барыбыз да буйсынырга тиеш. Музыка белгечен әзерләү — белем, осталык һәм традицияләрне берләштергән бик катлаулы процесс. Шуның нигезендә музыканы башкару осталыгы, композиторларның иҗат итүе, музыка белгечләренең фәнни эзләнүләре үсеш ала. Һәр музыкаль белгечлек буенча белем бирү өчен, бездә лицензияләр булдырылган һәм шул нигездә уку-укыту процессы алып барыла. Белем алган белгечләр өчен эш мөмкинлекләре бик күп: шул исәптән мәдәният һәм мәгариф өлкәләренә караган музыкаль мәктәпләр, урта махсус музыкаль уку йортлары, профессиональ музыка коллективлары. Һичшиксез, музыкаль җәмәгатьчелекнең югары зәвыклы һәм таләпчән булуы башкаручыларның осталыкларына карата яңа, тагын да югары дәрәҗәдәге критерийларны куллануны таләп итә. Әйтергә кирәк, Казан консерваториясе, минемчә, дөнья күләмендә музыка сәнгатендәге югары дәрәҗәгә лаек һәм безгә чит илләрдән килеп укырга керүчеләр саны елдан-ел арта. Мисал итеп, дөньяның иң танылган опера театрларында чыгыш ясый торган җырчыларыбыз Альбина Шаһиморатова, Михаил Казаков, Алексей Тихомировларны китерү дә җитәдер. Шулай ук бөтен дөньяда танылган пианистлар Рэм Урасин һәм Евгений Михайловларны әйтеп үтү кирәктер. Казан консерваториясенең студентлар хоры исә ничә еллар инде Европа илләрендә уңышлы гастрольләр алып бара. Мин китергән мисаллар академик музыка белгечләренә кагыла, бу өлкәдә артистлар арасында көндәшлек искиткеч зур. Шуңа күрә Казан мәктәбе Европаның иң дәрәҗәле музыка вузларына һәм, әлбәттә, безнең иң өлкән Санкт-Петербург һәм Мәскәү консерваторияләренә тиң булырга тиеш.

**– Консерваториядә чит илләр, чит континентлардан килеп укучылар да күренә. Алар өчен аерым укыту программасы бармы?**

– Чит ил студентлары Россия студентлары белән бер үк программа нигезендә укый. Алар, әлбәттә, тел өйрәнүгә һәм уку шартларына яраклашуга күбрәк көч сарыф итәргә мәҗбүр. Болар исә, гадәттә, аларның укуга әзерләнү елына туры килә.

**— Журналыбызның 5нче санында, Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан, Кырымнан җырчы Шәфыйка Котдусованы операда җырларга чакырып алулары һәм аның Казанда төпләнеп калуы турында язма басылды. Сезнең дә биографиягез Кырым белән бәйле... Бүген һәм киләчәктә милли музыкабызның язмышын ничек күзаллыйсыз?**

— Өлешчә җавап бирелде инде бу сорауга. Милли традицияләрне саклау — Казан консерваториясенең төп бурычларыннан берсе. 1991 елдан бирле бездә татар музыкасы кафедрасы эшли, музыкада милли традицияләрне туплау өстендә эшли торган Татарика оркестры оештырылды. Ел саен татар музыка сәнгате факультеты студентлары җәйге экспедицияләр вакытында фольклор үрнәкләрен җыя. Соныннан җыелган материал профессионаллар тарафыннан эшкәртелә, аның чынлап та яшәп килгән традициягә кагылышлы булуы тикшерелә. Шуның нигезендә этномузыкологиягә караган фәнни хезмәтләр бастырыла. Урта Идел төбәге — гасырлар дәверендә төрки, угро-фин һәм славян традицияләре янәшә яшәп килгән һәм сакланган күпмилләтле регион ул.

**— Соңгы дистә елда консерваториябезнең йөзе танымаслык булып үзгәрде. Концерт залы... Өр-яңа инструментлар... Орган үзе генә ни тора... Консерваториябез дөньяның кайсы музыка үзәкләре белән хезмәттәшлек итә? Сез консерваторияне тагын егерме биш елдан соң ничек күз алдына китерәсез?**

— Һәрдаим күрсәткән игътибары һәм консерваториянең материаль базасын үстергәне өчен, коллективыбыз Татарстан президентына һәм аның хөкүмәтенә рәхмәтле. Озакламый татар музыка сәнгате факультеты Зур Кызыл урамындагы бинага хуҗа булыр дип өметләнәм, чөнки ул бит шуның өчен дип билгеләнгән иде. Консерваторияне материаль яктан заманча дәрәҗәдә тәэмин итү эше өзлексез алып барыла һәм күп көч сорый. Европа стандартлары буенча эшлибез икән, димәк, музыкантларыбызның эш шартлары да һәм студентларыбызның яшәү шартлары да шул дәрәҗәдә булырга тиеш дигән сүз. Без Европа институтлары белән партнёрлар дәрәҗәсендәге мөнәсәбәтләрдә яшибез: болар — Лондонның король музыкасы академиясе дә, Берлиндагы Тюркология институты да, Германиянең Любектагы һәм Штутгарттагы Югары музыка мәктәбе дә. Бу учреждениеләрнең күбесендә үзебез укытып чыгарган белгечләр эшләгәнен дә онытмаска кирәк. Шулар бит инде музыкаль белгечлек өлкәсендәге әлеге контактларны урнаштырырга ярдәм итә. Россиядә болар — Санкт-Петербург һәм Мәскәү консерваторияләре, Гнесиналар исемендәге Россия музыка академиясе, Себер һәм Ерак Көнчыгыш, Әстерхан, Саратов, Түбән Новгород консерваторияләре. Россиядә аерым гына бер консерваториянең эшләвен күз алдына китерү мөмкин дә түгел. Бу бит киң даирә профессиональ музыкантларның фәнни иҗат, сәхнә хезмәте өлкәсендәге эшчәнлекләре бергә үрелеп бару дигән сүз.

**— Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт! Уңышлар Сезгә!**

*Әңгәмәдәш* — **Илфак ИБРАҺИМОВ.**

# ГАЛИМНЕҢ ӘДӘБИ-ТЕОРЕТИК ФИКЕР ДӨНЬЯСЫ

## Гали Халитнең тууына 100 ел

Күренекле галим Гали ага Халит белән мин үткән гасырның кырыгынчы еллары ахырында, университетта укып йөргән чакта таныштым. Ул безнең группада Мәҗит Гафури иҗаты буенча махсус семинар алып бара иде. Аның җитәкчелегендә реферат яздым. Ул зачёт куярга яраклы дип табылды.

Студент һәм аспирант елларында без Гали аганың «Халык шагыйре Тукай», «Мәҗит Гафури иҗаты», «Татар әдәбиятында реализм мәсьәләләре», «XX йөз башында татар әдәбияты» китапларын игътибар белән өйрәнә, кайбер урыннарын язып та ала идек. «Тормыш һәм ирек җырчысы: очерк» китабына рецензия дә язарга насыйп булды. Ошбу китап Мәҗит Гафуриның тормышы һәм иҗаты турында иде. Икенче басма. Бу шагыйрь турында Г.Рамазанов, Х.Госман, Ә.Нигъмәтуллин, С.Кудаш, П.Тычина һәм башка авторларның татар, башкорт, рус телләрендә чыгарган җитди китаплары, мәкаләләре, истәлекләре бар. Гали Халит үзенең әлеге китабында әдип иҗатын өйрәнү юлында моңа кадәр ирешелгән барлык гыйльми казанышларга, шул җөмләдән үз тәҗрибәсенә дә таяна, ләкин аларның берсен дә кабатламый, үз карашын, үз концепциясен тәкъдим итә. Кирәк урыннарда автор Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында һәм башка оешмаларда, музейларда саклана торган кульязма архив материалларын файдалана, шулар ярдәмендә әсәрләрнең бөреләнү тарихын ачыклый. Хезмәттә мөһим теоретик положениеләр бар. Әмма алар берсе дә абстракт фикер йөртү рәвешендә генә барлыкка килмәгәннәр, бәлки әдәби фактларның үзләреннән килеп чыкканнар, язучы әсәрләрен тирән өйрәнү, иҗат процессын гомумиләштерү нигезендә туганнар. Язучының идея-поэтик эволюциясен күзәтү дәвамында без китап авторының да фикерләре тоташ үсә баруын күрәбез.

Хәзерге татар прозасында психологизм турында монография һәм диссертация язганда, мин Гали Халитнең «Шагыйрь, чор, герой», «Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән», «Рождённые революцией» китапларына еш кына мөрәҗәгать иттем, ул китаплар белән киңәштем.

«Психологизм в современной татарской прозе» дигән докторлык диссертациясен миңа Алма-Атада, Казакъстанның фәннәр академиясендә якларга туры килде. Гали Халит оппонент иде. Бу уңай белән кайбер иптәшләр, ничек дип әйтим, сорау рәвешендәге фикерләрен дә сиздереп куйдылар. Гали Халит — бик таләпчән тәнкыйтьче бит. Ничек курыкмадыгыз, дип әйтүчеләр булды. Ләкин мин үзем Гали аганың оппонент булуын сорадым. Ул аеруча тирән белемле, киң эрудицияле, принципиаль галим. Яклауга чыкканчы шундый остазның иләгеннән үтү зыянга булмас дип уйладым. Оппонент булып моннан тыш тагын Уфадан Башкорт дәүләт университеты проректоры Мидхәт Гайнуллин, Алма-Атадан Казакъстан фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты Ш.К.Сатпаева билгеләнде. Диссертация советы составына өстәмә рәвештә Казаннан Нил Юзиев, Алабугадан Тәлгат Галиуллин кертелде. Казакъстан фәннәр академиясенә, шулай итеп, Россиядән биш кеше барып төштек — бишебез дә СССР Язучылар союзы члены идек.

Үзенең чыгышында Г.Халит диссертациягә төпле анализ ясады. Совет әгъзалары

канәгать калдылар. Зур хезмәтне бәяләргә риза булганы, тәвәккәлләп ерак юлга кузгалганы өчен Гали агага — өлкән галимгә ихлас рәхмәтлемен. Мин шулай ук Мидхәт Гайнуллинга, Нил Юзиевкә, Тәлгат Галиуллинга, Ш.К.Сатпаевага, Алма-Ата диссертация советына рәхмәтле. Яклау күнелле үтте.

Совет чорында оппонентлык өчен академия системасында хезмәт хакы түләнә иде. Кассир акчаны утырыш залына кертеп үк тапшыра иде. Иҗат йорты бакчасында ял итеп йөргәндә, Гали ага, кинәшкәндәй, әйтеп куйды:

— Гонорар акчасына әллә костюм алыйм микән? — диде. Бераз торгач өстәде:
— Аны сон туздырып булыр микән?

Иҗат йортында ял итүче казакъ, уйгыр язучылары Рәсәй кунаклары белән бик җылы аралаштылар, хәл-әхвәл белештеләр. Уйгыр язучысы Абдукәрим Ганиев бишебезне дә зурлап үзенә кунакка чакырды. Бер бик ачык йөзле, шаян-шук уйгыр композиторын да дәшкән иде. Ул озын саплы думбрасын күтәреп килеп керде, бик матур, колакка ятышлы көйләр уйнады. Мәҗлестә уйгырлар үзләренчә, татарлар үзләренчә сөйлиләр. Һәммәсе дә ачык анлашыла. Композитор әйтә:

— Ул инде татар сүзләрен авызны бераз кыйшайтып әйтсән, уйгыр кәлимәләре килеп чыга, — ди.

Биредә рухи якынлык, уртаклык яхшы тоелды, уйгыр мәдәнияте тарихынын тамырлары бик тирәнгә киткәнлеге сизелде.

Ул вакытта, үткән гасырнын сиксәненче елларында, Гали Халит тә, Нил Юзиев тә ИЯЛИдә эшлиләр иде. Яшь аермасы хәтсез булуга карамастан, алар бик дус иде. Үзара якын, җылы мөнәсәбәт аларнын һәр сүзеннән сизелеп тора иде. Казакъстанга да бергә килделәр, бергә киттеләр. Шөкер, исән-имин кайтып җиттеләр.

Г.Халит Тукай иҗатын яратып өйрәнде, «Тукай үткән юл», «Габдулла Тукай и татарское литературное движение начала XX века», «Тукай и его современники» китапларын чыгарды. Моннан тыш Дәрдемәнд, Ф.Әмирхан, С.Рәмиев, Ш.Бабич, С.Сүнчәләй, Н.Думави иҗатын тикшерде, поэтик үзгәлекләрен, уртаклыкларын яктыртты.

Г.Халит совет чоры әдипләренен тормыш юлын, язмышларын өйрәнүгә дә күп көч салды. Такташ поэзиясенен серләрен ачуга «Шагыйрь, чор, герой» (1971), «Поэзия дерзаний: Творчество Хади Такташа и вопросы метода, героя и стиля в татарской поэзии 20-х годов» (1980) китапларын һәм мәкаләләрен багышлады. Биредә «Гыйсъянчылык һәм Такташ», «Яна герой һәм яна сурәтләр эзләгәндә», «Киләчәккә карап» дигән мәсьәләләр тикшерелә.

Г.Халит хезмәтләрендә шулай ук Г.Ибраһимов, Ф.Бурнаш, К.Тинчурин, М.Җәлил, Ф.Кәрим, Н.Исәнбәт, Ә.Еники, Ф.Хөсни иҗаты мөһим урын алып тора.

Г.Халит XX йөз татар әдәбияты тарихын гыйльми анализлау белән бер рәттән сүз сәнгатенен теориясен яктыртуга да җитди игътибар бирде. Анын бу юнәлештәге тирән карашлары «Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән» (1975), «Поэзия дерзаний» (1980), «Портреты и проблемы» (1985), «Многоликая лирика» (1990) китапларында бәян ителгән. Боларда автор тизләтелгән әдәби үсеш һәм иҗат методларын, әдәби-эстетик фикерләр мәйданынын киңәюен, метод һәм стиль, әдәби-эстетик фикер үсеше, лирика һәм лирик герой, җан диалектикасы, шагыйрь образы, әдәбиятнын халыкчанлыгы мәсьәләләрен яктырта. «Әдәбият теориясе» китабын язганда, мин боларга еш мөрәҗәгать иттем, алар аркылы фикерләрнен нигезләме, түгелме икәнлеген сынадым. Бу эштә гүяки Гали ага шәхсән үзе дә ярдәм итә килде. Ул «Фәрит дуска, хөрмәт белән, Г.Халит» дигән автограф куеп, саллы китапларын бер-бер артлы бүләк итә торды. Ничек укымыйсын ди аларны!

XX гасыр татар әдәбиятын гыйльми яктыртуда филология фәннәре докторы Гали Халитнен өлеше шактый зур булды.

**Фәрит ХАТИПОВ**

# ОСТАЗ КҮРСӘТКӘН ЮЛДАН...

Без аны олылап, үзенә Гали абый дип эндәшә, ә ул югында анын турында Халит абый дип сөйләшә идек. Ә инде китапларга куелган исеме — Гали Халит дигәне һәркайсыбызда ана карата чиксез хөрмәт һәм бераз курку катыш ихтирам уята иде. Гомумән, без аны әдәбиятыбызның әйдаманы, әдәбият фәненен символы итеп санап йөрдек.

Бу «без» дигәнем — узган гасырның алтмышынчы елларында зур әдәбият дөньясына керергә талпынган бер төркем татар яшьләре рәвешендә аңлашылсын иде. Мин үзем университет тәмамлап, алты ел дәвамында авыл мәктәпләрендә укытучы булып эшләгәннән соң, Фәннәр академиясенен Тел, әдәбият һәм тарих институтына, аспирантурага кердем. Мине әдәбият секторының өлкән фәнни хезмәткәре Гали Халиткә беркеттеләр. Шундый дәрәҗәле гыйльми җитәкче карамагында өйрәнү һәм эшләү перспективасын аңлап алгач, күнелемне зур өметләр һәм җаваплылык тойгысы биләде. Ул безнен ише яшьләрнең буе җитмәслек белемле, авторитетлы, бөек зат булып тоелды.

Һәм менә бик җитди, кыяфәткә кырысрак, усал күренгән кеше каршында торам, күзгә-күз карашып сөйләшәбез. Ә ул бик тә игътибарлы, итагатьле булып чыкты: ашыкмый гына хәлләремне, килеп чыгышымны, нилләр белән кызыксынуымны сораштырды. Озак та үтмәде, үзара килештереп, булачак диссертациямнең темасын, анын төп юнәлешен дә ачыклый алдык.

«Фатих Хөсни һәм анын прозадагы осталыгы» исемле диссертацияне мин бик яратып һәм үз-үземә ышанып эшләдем, — чөнки һәрдаим җитәкчемнең киңәшләрен ишетеп, юл күрсәтүен тоеп тордым. Нәтиҗәдә, әдип турында китабым, татар һәм рус телләрендә күпсанлы мәкаләләрем басылып чыкты, диссертациям дә уңышлы якланды. Шулай итеп, әдәбият фәне, әдәби тәнкыйть өлкәсенә кулымнан тотып диярлек алып керүчем Гали абый Халитов булды. Аннан соң да бик күп еллар үтеп, азмы-күпме әдәбият белгече буларак танылганмын икән, монысы өчен дә мин иң беренче нәүбәттә Гали абыема бурычлы.

Сәнгать һәм әдәбият күренешләрен аңлар һәм аңлатыр өчен әсәрләр уку гына җитми — аларның казанында кайнарга, мөхтәрәм затлар — әдип-язучылар, галимнәр белән гел очрашып, аралашып торырга кирәк. Фатих ага Хөсни белән тәүге очрашуны да Гали Халит оештырды. Фатих абый баштарак миңа шикләнебрәк карагандай тоелды: янәсе, «ай-һай, бу малай минем иҗатта колач җәеп йөзә алыр микән?» — тик тора-бара мондый шикле мөнәсәбәт юкка чыкты, башка төрле, илтифатлы мөнәсәбәткә алышынды — язганнарымны олы әдип җылы кабул итте, хуплады, рәхмәтләрен дә белдерде.

Бәхетемә, аспирантураны тәмамлап, институтта эшкә урнашкач та, шактый еллар дәвамында миңа Гали абый белән бер бүлмәдә утырып эшләү насыйп булды. Бу кечкенә генә, ике-өч кеше генә утырып эшләрлек бүлмәбезгә шул заманның байтак кына танылган мәшһүрләре, әдәбият затлары кергәләп йөри, күренешләргә үз карашларын белдереп, яңалыклар сөйләп, кыйммәтле киңәшләрен биргәләп чыгалар иде. Шул чор әдәбиятының флагманы Мөхәммәт ага Гайнуллин, проза белгече, үтә дә ягымлы, тәмле телле Хәсән ага Хәйри, төртмәлерәк итеп сөйләшергә яратучы, ироник карашлы Хатип ага Госман, студентлар кумиры, мөлаем Якуб ага Агишев, кыю фикерле галим-педагог Ибраһим Нуруллин, һәрчак шат күңелле, фольклорчы Хәмит ага Ярми кебек мөхтәрәм затларны күреп сөйләшүләр күңелдә җуелмаслык булып истә калган. Бервакыт бүлмәдә үзем генә эшләп утырган чакта тәбәнәгрәк, карсаграк буйлы бер кеше килеп керде. Үзе белән таныштырып та

тормыйча, сораштыра башлады. Мин аңа әдәбият тарихы томнарын әзерләвебез турында әйттем. Ул миңа озак кына текәлеп карап торды, башын чайкап алды һәм: «Их, егетләр, сез бернәрсә дә белмисез шул...» — дип сүзсез генә басып торды да чыгып китте. Сонрак, бу сәеррәк кешенен кемлеген Гали абый үзе ачыклады: ул егерменче елларның актив функционеры, репрессия елларында нык кыйналган, ләкин сынмаган Мәхмүт Бөдәйли булып чыкты. Бәхетебезгә, безнен буынга культ һәм сугыш еллары афәтләрен дә бар тулылыгында татырга туры килмәде, бәлки шуңа күрәдер, шул еллар сөремен кичергән өлкән буынның, без яшьләрнең тәҗрибә ягы чамалы икәнлеген белеп, сәләт, мөмкинлек һәм көчләребезгә бигүк ышанып житмәве, әлбәттә, табигый иде. Алты томлы татар әдәбияты тарихы проектын эшли башлагач, Хатип ага Госман әйткән сүзләр дә истә калган — нәтиҗәсе, әлбәттә, тискәре булачагын исәпләп әйтте ул аны: «Сверигин, Сез, ул алты томны чыннан да башкарып чыгарбыз дип уйлыйсызмы әллә?» — дип ярып салды. Мин дә алдын-артын уйлап тормастан, өлкән кешегә үз тонында җавап биргәнмен: «И-и-и, Хатип абый, юкка борчылып йөрисез, әдәбиятларны өйрәнербез, укырбыз да язып чыгарбыз әле», — дигәнмен икән. Бу сөйләшүне мин оныткан да булыр идем, тик аны миңа тиз искә төшерделәр — Хатип Госман, житәкчелеккә кереп, «Зур эшкә ник алай жинел карыйсыз, — әнә Сверигиныгыз «укырбыз да, язарбыз», — дип утыра дип, шелтәләп, зарланып та чыккан.

1965 елда Мәскәүдә «Фән» нәшриятында «История татарской литературы», озакламый татар әдәбияты тарихы да яктыртылган алты томлы «История литературы СССР», алтмышынчы-житмешенче елларда алты томлы «Татар әдәбияты» тарихы китаплары басылып чыкты. Боларны ИЯЛИ галимнәренең, ижат коллективының уңышлары дип бәяләп була. Әнә шулай, олы галимнәрдән килгән ижади чылбыр өзелмәде — ул даими дәвам итә. Әлбәттә, казанышларга ирешү тормышны нык өйрәнү, сәнгать-әдәбият өлкәсендәге ижади эзләнүләр һәм классик әдәбият традицияләренә таянганда гына мөмкин икәнлеген яшьләр дә аңларга тиеш иде. Әлеге китапларга үземнең дә өлешем керүен күреп горурландым: язганнарым — әдәбият хроникасы материаллары, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләжев турындагы мәкаләләрем уңай бәя алды.

Гали Халит янында миннән олырак, тик барыбер яшьләр дип саналучы бер төркем галимнәр кайнашып, эшләп йөрде. Талантлы Рөстәм Башкуров, энциклопедик белемле, Мәскәүдәге хөр холыклы, «алтын яшьләр» тормышыннан хәбәрдар Вячеслав Воздвиженский, жанлы әңгәмәдәш, балаларча саф күңелле Нур Гыйззәтуллин һәм чордашларымнан Зөфәр Рәмиев, Флүн Мусин — остазымның шәкертләре, фикердәшләре — барысы бергә Гали Халит мәктәбен тәшкил иттеләр һәм мин дә аларга кушылып, шул мәктәп традицияләренең дәвамчысы булырга тиеш идем.

Бу — әдәбиятның реалистик традицияләренә нигезләнгән, аның совет чоры казанышларын, заман рухын объектив чагылдыручы, чорның идеологик таләпләре белән нык бәйләнгән юнәлеш иде. Мәгълүм ки, минем ул чактагы төп тикшерү объектым булган Фатих Хөснинең уйнак, йөгерек, тормышның житди мәсьәләләреннән читтәрәк торгандай жиңел стиле социалистик реализмның каты кысаларына сыешып бетә алмады. Димәк, алтмышынчы-житмешенче елларда мондый стильне аңлату, анализлауның да башкачарак ысулларын табарга кирәк иде. Фатих Хөсни әсәрләрендәге күңел нечкәлеге, лирик, жанлы сурәтләр муллыгы, геройларның күңел төпкелләренә төшеп яктырту — болар үз күңелемә дә аваздаш нәрсәләр икәнлегенә төшенгәч, язучының әдәби осталыгына кагылышлы стиль төсмерләрен аңлату артык кыен булмады сыман. Ә Гали абый исә минем анализдагы субъектив күзәтүләр һәм ачышларыма каршы төшмәде, күбесен хуплады, бәхәсле жирләрдә дә үзен өстен куймады — гел миңа ярдәм итәргә тырышты. Нәтиҗәдә, аның рекомендациясе белән, Татарстан китап нәшриятында 1968 елда «Фатих Хөсни» дигән беренче китабым дөнья күрде.

Гали Халит әдәбият гыйлемендә кырыс реализмның һәм революцион романтизмның социологик хасиятен алгы планга куеп тикшерүче теоретик буларак танылды. Кайберәүләргә бу караш эстетик кануннарны читкәрәк кую янсә хәтта

санлап житкермәү булып та тоелгандыр. Һәм, әлбәттә, моның шаукымы, мондый «социологизм»ның йогынтысы миңа да нык кына тәэсир итми калмады. Фатих абый Хөсни — әдәбиятның чын эстеты — аның үтә катлаулы нечкәлекләрен тоеп яза белүче миңа бу турыда әйткәләде дә. Менә бер әңгәмә вакытында, мин әйткәннәр белән килешмичә, үзенә хас балаларча ихласлык белән кул селтәгәне хәтеремдә калган: «Әй, мин синең белән ник сөйләшеп торам соң?! — Син бит — Гали Халит шәкерте!» — дигән иде.

Ничек кенә булмасын, Гали абый язганнар бүген дә әдәбият тарихы һәм әдәбият белеменең кыйммәтле хәзинәсеннән санала. Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Мәҗит Гафури, Һади Такташ, аерым чорларда әдәбият үсеше турындагы хезмәтләре бүген дә киң кулланылышта — мәктәпләрдә һәм башка уку йортларында файдаланыла. Г.Халит — теоретик кына түгел, югары хәзерлекле педагог та иде. Мәгълүм ки, тәрбияченең иң үтемле ысулларының берсе — башкаларны үз мисалында, үз тәртибең, үз рәвешең аша тәрбияләү. Шушы яктан да ул безгә чын үрнәк иде. Пунктуаль төгәллек, сүзеңдә тору, әйткәнеңне вакытында җиренә житкерү — болар барысы да аның канына сеңгән диярсең. Иртән нәкъ 9га эшкә килеп житә, пиджагын салып, пөхтәләп элеп куя, җиңнәре ямаулы кара халатын иңенә сала һәм өстәле артына утырып, эшенә керешә — китапларына, язу-сызуына тотына. Бу вакытта аңа сүз кушарга да, артында тыз-быз килеп, кереп-чыгып йөрергә дә ярамый, эшлисең килсә дә, килмәсә дә, аның үрнәгендә син дә утырып эшләргә тиеш һәм мәҗбүр буласың — башкача ярамый. Төшке ашка барып килүне искә алмаганда, мондый каторгадагыча режим сәгать өчләргә яки дүртләргәчә сузыла һәм мәтрыбызның яисә гуруның безгә таба ниһаять борылып, беренче анекдот сөйләве белән тәмамлана торган иде.

Рөстәм Башкуров, Нур Гыйззәтуллин, Слава Воздвиженский кебек ирек сөюче, хәрәкәтчән натуралар мондый «режим»нан җиңел котылалар — алар эш көнен күбрәк коридорда уздыралар яисә китапханәгә киткән булып, шәһәргә чыгып таю ягын карыйлар иде. Һәм минем өчен аеруча гаҗәп тоелганы — алар да фән өлкәсендә башкарасын башкаралар, язасын язалар иде. Күрәсең, ничек тә ярагандыр — алар минем шикелле үк остазга беркетелмәгәннәр: миңа ярамый — мин беркетелгән аспирант, һәм, дөресен әйтергә кирәк, диссертациямне бик ашыгып якламадым да — әле МНС (кече фәнни хезмәткәр) сыйфатында да байтак вакыт Остазым карамагында, аның кулы астында булдым. Аның каравы, нәкъ шул чорда күп нәрсәләргә өйрәндем.

Иң беренчесе — житәкчем мине фәнни эшнең тәртибенә, вакытның кадерен белергә өйрәтте, шунда гына рациональ, логик фикерләүнең нәрсә икәнлеген аңладым. Г.Халит ачык логик төгәл фикер тарафдары иде — буш сүз, демагогияне бер дә яратмады.

Икенчедән, ул бик туры сүзле кеше иде — уйлаганын, фикерен, кемнең кем булуына карамастан, күзенә карап әйтә иде. Кеше булып калыйм дигән кеше өчен бу сыйфатның үтә зарурлыгын тора-бара аңлыйсың икән. Әмма дошманнарың кимер дип уйлама, киресенчә, алар арта гына барачак. Г.Халитнең ачы телен татыган, үткен тәнкыйтен онытa алмыйча, гомере буе ачу саклап йөрүче затлар бүген дә берән-сәрән күренгәли әле.

Өченчедән, Г.Халиттән мин әдәбият-сәнгатьтә нәрсәнең әһәмиятле, кирәкле, ә нәрсәләрнең чүп-чар икәнлеген танырга өйрәндем дип беләм. Ә моны аңламаганнарның әдәби тәнкыйтьтә сүз алып сөйләнергә бөтенләй хаклары юк.

Ә, гомумән, Гали абый үзенең теләктәшләренә, дусларына, коллегаларына бик игътибарлы, кайгыртучан кеше иде. Хәтта шәхси тормышымда да ул миңа бердәнбер дөрес юлны табышырга, сайларга булышты. Гомер юлымда шундый затка тап булуым белән үземне бик бәхетле дип саныйм.

**Рифат СВЕРИГИН**

# СЕЗНЕҢ ЯЗМЫШ СУГЫШ УТЫ БЕЛӘН ҮРЕЛГӘН

**НУР БАЯН**
*(БАЯНОВ НУР ГАЛИМ УЛЫ)*
*(1905–1945)*

Нур Баянның тормышына, иҗатына яңалык өстәгән һәрбер факт, һәрбер документ безнең өчен кадерле. Татарстан Республикасының Милли архивында мин Нур Баянның үз кулы белән язылган анкетасын эзләп таптым. Менә ул анкета *(ТР МА. Р-7083 ф. 3 тасв. 14 эш. Төп нөсхә).*

1905 елның 15 маенда Татарстанның хәзерге Актаныш районы Әнәк авылында крестьян гаиләсендә туа. 1923 елда Казанга килә һәм 1923-1926 елларда Татар-башкорт хәрби мәктәбендә курсант, 1926-1928 елларда типографиядә корректор, 1928-1929 елларда «Кызылармееџ» газетасы редакциясендә, 1929-1931 елларда «Кызыл яшьләр» журналының сәркәтибе, аннан соң «Трактор» газетасының /Чаллы районы/ мөхәррире итеп билгеләнә /1931-1932/. 1930 елдан ВКП/б/ члены.

1932 елда Н.Баян янадан Казанга кайта һәм 1933-1934 елларда Татарстан Язучылар берлегенең оештыру комитетында инструктор, Таттосиздатта мөхәррир булып хезмәт итә. 1934-1936 елларда Марксизм-ленинизм институтында студент. 1938 елда Нур Баян тулысынча язучылык эшенә күчә.

1939 елны Нур Баян Татарстан партия оешмасының өлкә конференциясендә «Ант» шигыре белән чыгыш ясый. Шагыйрь үзенең Советлар Союзы партиясе члены булуы белән горурлануын һәм, кирәк икән, Ватаны, халкы өчен гомерен дә бирергә әзер торуын белдерә.

*Мин члены бөек партиянең*
*Һәм күтәреп шушы исемне,*
*Залга килдем бер җырчысы булып,*
*Сөйләр өчен йөрәк хисемне.*
. . . . . . . . . . . . . . . . . .
*Мин ант итәм сиңа: пычратмаска,*
*Тапламаска синең исемеңне.*
*Һәм бирергә соңгы сулышкача*
*Халкым өчен йөрәк хисемне!*

Совет хөкүмәте аны 1940 елда «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкли.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, Нур Баян Казанның Свердлов район хәрби комиссариатыннан армиягә алына һәм фронтка китә.

1941 елның ноябрендә «Коралга, халкым, коралга!» дигән шигырендә ул болай дип яза:

*Ерткыч Гитлер безне кол итмәс,*
*Безнең җирдә муйнын сындырыр.*
*Без беләбез, җиңү бездә булыр,*
*Күкрәп халкым алга ургылыр.*

Нур Баян Калинин һәм Көньяк-Көнбатыш фронтларында 78нче укчы дивизиянең «За Родину» исемле газетасында мөхәррир урынбасары булып хезмәт итә. Әлеге җаваплы эш белән бергә иҗатын да дәвам иттерә. Бу елларда язган хатлары һәм патриотик шигырьләре алгы сызыктагы дәһшәтле сугыш картиналарын күрсәтә, туган илгә, партиягә һәм халыкка булган кайнар мәхәббәтне, фашист илбасарларына булган үч һәм нәфрәтне көчле итеп чагылдыра.

1943 елның маенда Донецта язылган шигырендә ул болай ди:

*Тик бер генә фашист үтерсәм дә,*
*Файда булыр төсле илемә,*
*Һәм китәм мин алга, мылтык тотып,*
*Гранатамны тагып билемә.*

Күп еллар үтүгә карамастан, танылган шагыйрь язмышы турында мин, бөртекләп яңа мәгълүматлар җыеп, шундый нәтиҗәгә килдем:

1. Майор Нур Баян 1944 елның октябрь ае уртасында яралана (22.11.44тә язылган хаты).

2. «Ике айлап госпитальдә ятып чыкканнан соң, хәзер резервта ятам. Тагын кая җибәрерләр — билгесез», — дип яза шагыйрь Мирсәй Әмиргә (30.1.45).

3. Резервтан шагыйрь янадан үз дивизиясенә әйләнеп кайта, чөнки Нур Баянның тормыш иптәше гаризада иренең соңгы адресын 39 337 «Ч» кыр почтасы дип күрсәтә (бу 78нче дивизиянең хәрби адресы). Бу мәгълүматны мин Казандагы Бөек Ватан сугышы музей-мемориалның директоры Черепанов Михаил Валерьевич ярдәме нәтиҗәсендә ачыкладым.

27нче Армиянең 33нче гвардия укчы корпусы 78нче укчы дивизия, Австриягә кергәч, Өченче Украина фронты карамагына күчерелә. 1945 елның апрелендә Альп таулары итәгендә каты сугышлар бара. Немецларның «Империя» һәм «Вигинг» дип аталган СС дивизияләре, венгрларның укчы бригадасы Совет Армиясе сугышчыларының һөҗүмен соңгы көчләре белән туктатырга исәплиләр. Ләкин Җиңү көненә нибары унбиш көн кала, 1945 елның 23 апрелендә Австрияне азат итү өчен барган шушы канлы сугышта татар халкының танылган шагыйре, Совет Армиясе майоры Нур Баян Фюрстенфельд шәһәре янында батырларча һәлак була. Шул каты көрәштә 78нче дивизиянең командиры генерал-майор Николай Матвеевич Михайлов каты яралана, аны сугыш кырыннан тик шул көннең кичендә генә күтәреп алып чыгарга мөмкинлек туа.

Шагыйрьнең «Үч һәм нәфрәт» шигырендә мондый юллар бар:

*Ант иттем мин үчне кайтарырга,*
*Автоматым кысып кулыма.*

Патриот шагыйрь биргән антына тугрылыклы хәлдә, Ватаныбызның бәйсезлеге һәм азатлыгы өчен көрәшкән, ул сугыш кырында күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз, Беренче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнгән.

Нур Баянның шигырьләре — халык күңелендә. Туган ягына ул җыр һәм һәйкәл булып, батырлык символы булып кайтты. Аның мәрмәрдән эшләнгән һәйкәле Татарстанның Актаныш районы Әнәк авылында тора.

**Төхфәт Имаметдиновка**

*Төхфәт!*

*Мин бер ай буена Москвада политакадемиядә яттым. Күп кенә яхшы лекцияләр тыңларга туры килде. Хәзер инде дивизия газетасының редакторы итеп билгеләндем. 3 мартта Ташкентка чыгып китәм. Сәфәр Южный фронтка булыр, ахры. Кәефем ярыйсы. Бары тик синнән шуны гына сорыйм: минем семьяны кайвакыт хәтердә тоткалый тор. Аларның кәефләре яхшыдан түгел булса кирәк.*

*Ике Әхмәт тә вакытлыча Казанга кайттылар, уйлыйм: озакламый кире*

*чакырырлар. Чөнки газета работниклары күп кирәк. Андый кешеләр — газета өчен кадерле кадрлар. Ә запас һәрвакытта кирәк булып тора...*

*Кашшаф Гази, Ибраһим Гази, Кутуй, Шамов, Исхак дусларга сәлам.*

*Башка сүзем юк. Хат язгалагыз.*

*Сәлам белән, Нур.*
*2 март, 1942 ел*

«Казан утлары». 1970. №5. 143 бит.

**Татарстан Язучылар союзы идарәсенә**

*Имай, Кутуй һәм К.Газый дуслар! Мин сезгә күптән хат язарга йөрсәм дә, вакыт юклыктан, моңа кадәр яза алмадым. Гафу итегез. Үземнең сәламәтлегем бик яхшы. Армия тормышы минем өчен институт төсен алып бара. Дуслар һәм иптәшләр белән тирә-ягым тулы. Алар мине яраталар, ә мин аларны яратам. Дивизия командиры һәм комиссарыннан алып барлык кызылармеецларга кадәр ихтирам белән карыйлар.*

*Командованиедән частьны яхшы оештыру өчен приказ аша рәхмәт алдым. Үзем редактор булып эшлим. Секретарем — Язучылар союзы члены Мих. Яновский. Әдәби инструкторым — Лозневой дигән политрук. Һәрвакыт ярдәмгә килә торган һәм газетага шигырьләр белән катнашучы Беккер бар. (Ул клуб нач. булып эшли).*

*Бу китүдә юлым озын булды. Ташкент, Сәмәрканд шәһәрләрендә булып, Кострома аша үттем. Бу сәяхәт минем өчен зур тормыш байлыгы булып тора. Озакламый күптән теләп йөргән урынга китәбез[1]. Ә анда барып, күкрәк белән дошманга каршы сугышу — нинди шатлык! Гаять яхшы частька эләгү, командирларның бик яхшы булулары (күбесе сугышта булган кешеләр, часть, яхшы сугышканлыгы өчен гвардия частена әйләнгән) мине шатландыра. Үзем турында шулар.*

*Тик мине аталык хисе бераз гына борчый. Клаваның[2] язуына караганда, минем семьяма Язучылар союзының работниклары бик начар карыйлар. Хәтта Клава белән сөйләшәселәре дә килми. Ярдәм күрсәтмиләр. Мин аны акламыйм. Мин барда бөтенесе дә дус иде, ә китү белән мине оныттыгызмы, аңламыйм: китап миңа кадәр чыкмаган. Әгәр Иб. Газый һәм М.Әмирләрне алмаганда, семьямның тормышы белән бер кеше дә кызыксынмый. Мин үземне язучылыктан аерылган итеп хис итмим. Минем эшем хәзер дә язучылык. Шигырь һәм очеркларым газета саен чыгалар. Шул язучы буларак та мин командованием каршында ихтирам белән файдаланам. Уйлыйм: минем баламны һәм семьямны онытмассыз.*

*Кемнәргә сәлам әйтергә белмим. Бары тик Ибр. Газый һәм М.Әмирләрнең генә армиягә киткәнлекләрен беләм[3]. Хат языгыз.*

*Кайнар сәлам белән,*
*Нур.*
*Адресым: Полевая почта №1829. Политотдел.*
*31 май, 1942 ел*

ТР МА. Р-7083 ф. 1 тасв. 144 эш. 70, 70 әйл. бит. Төп нөсхә.

**Гази Кашшафка**

*Кашшаф дус!*

*Мин сиңа дусларча хат язсам да, ни өчендер җавап юк. Бәлки вакыт тардыр, гафу ит. Ихтимал, мине онытып ташлавың да. Ә мин дусларны онытмыйм.*

*Ибрайга хат яздым – җавабы юк. Союзга яздым – ләм-мим. Гаҗәп! Мине андагы бөтен яңалык кызыксындыра. Яңа Правлениене беләм. Эш ничектер, билгесез. Союзның барлык фронтовикларга язган хатын алдым. Байтак исемнәр саналган, ә мин читтә калганмын. Ватан сугышы чорында минем дә байтак хезмәтем бар. («К.Т.» газетасын кара). Өстәвенә шигырьләрем тәрҗемә ителеп, фронт газеталарында басылып тора. Әлбәттә, мин шапырынырга яратмыйм, аның кирәге юк. Ә фронтта мине командир итеп һәм шагыйрь итеп таныйлар. Нишлисең, оныталар икән, башны ташка орып булмый. Җиник, кайткач сөйләшербез. Үзем әлегә алга бара торган фронт участокларының берсендә. Сугышабыз, дошман җинелә. Бу сугышта катнашуым белән мин бәхетле.*

*Хат яз. Кемнәр кайда? Кави[4] нишләп йөри. Барлык иптәшләргә сәлам диген. Эш белән күмелгән Динмөхәммәтов хат язды, ә син һәм башка иптәшләр вакыт тапмыйлар.*

*Хуш хәзергә. Фронт сәламе белән, Нур.*
*Адрес: 1829 полевая почта, часть 055.*

ЯММҮ. 100 ф. 3 тасв. 96 эш. 18 бит. Төп нөсхә.

Хат датасыз булса да, кыр почтасы номеры буенча, аның 1942 елда язылганлыгын билгели алабыз.

*Гази!*

*Син язган хатны алдым. Рәхмәт. Тик дус Мөхәммәтовның үлеме генә бик борчыды. Мин бары тик фронтта түгел, тылда үлүе өчен генә кайгырам. «Үлде» дигән сүз хәзер мине гаҗәпләндерми, мин үлемне көн саен, сәгать саен үз күзем белән күрәм. Үземнең иптәшләремне үз кулым белән күмәм. Сугыш, нишлисең. Дәһшәтле сугыш. Сугышны тылда чакта гына сөйләве кызык. Ә үзең йөри башлагач, алай түгел. Ә сугышырга, илне, Ватанны коткарырга кирәк.*

*Әх, алар безнең илгә нихәтле авырлык, ничаклы үлем алып килделәр. Без алга барабыз. Кайчандыр шаулап торган яшел бакчалы авыл. Чынында бары тик авылның исеме генә калган. Анда йорт та, шаулап торган бакча да күренми. Бары тик туп астында исән калган мәче балалары гына хуҗаларын югалтып, инрәп ач йөриләр. Берәм-сәрәм генә калган колхозчылар каршы алалар. Алар ач, ялангач. Йөзләре көзге яфрак сыман сары! Аякларын көч-хәл белән генә атлыйлар. Әйе, сугыш.*

*Ә немец бандалары аларның барлык нәрсәләрен тартып алганнар. Һәр немецны үтерергә кирәк, рәхимсез үтерергә. Юкса алар безне үтерерләр. Лозунг: «Убей немца, иначе он убьёт тебя».*

*Ә шулай да, Гази, яшисе, күкрәп яшисе килә. Үзең шуннан аңла.*

*Хәзергә сау-сәламәт. Г.Ибрайга хат язган идем, ни өчендер җавап юк. Бер шигырь дә җибәргән булган идем. Бәлки урнаштырыр. Ә китапка бер ел, һаман чыкмый. Хәл шулай бит, әгәр кайта алсам, бәлки чыгар. Мине көтәдер.*

*Хәзергә барлык дусларга сәлам диген. Әгәр Динмөхәммәтовны күрсәң, әйт: безнең янда начпоарм.[5] Шилов булды. Ул ничектер мине белә. Динмөхәммәтовны яхшы белә. Сәлам әйтергә, хат язарга кушты. Аерым хат язарга вакыт юк. Бәлки фронтовикларга посылка да җибәргән булыр иде. Ул 30 нчы армиядә, туп астында булган. Онытмаган булса, хәтерлидер.*

*Бер дивизиядә Хәкимуллинны күрдем. Ул — артдивизионда комиссар. Озак сөйләшеп утырдык. Нинди якын да соң танышлар...*

*Хәзергә. Сәлам белән, Нур.*
*Адрес иске.*
*18 сентябрь, 1942 ел*

ЯММҮ. 100 ф. 3 тасв. 96 эш. 2, 2 әйл. бит. Төп нөсхә.

**Искәрмәләр**

[1] фронтка.
[2] Клава Кузьминична Баянова – Нур Баянның тормыш иптәше.
[3] 1942 елның мартында И.Гази һәм М.Әмир Сталинградта оештырылган командирлар хәзерли торган курсларга укырга җибәрелә, ләкин аларны комиссия Казанга кайтара.
[4] Кави Нәҗми (1901-1957), язучы.
[5] начпоарм. – начальник по армии.

*Хатларны һәм искәрмәләрне* **Әлфия ШАМОВА** *әзерләде.*

# ҖИҢҮЛӘР ҖИҢЕЛ БИРЕЛМӘДЕ

ТАРИХИ-ПУБЛИЦИСТИК ЯЗМА

## Мәңге истә

*Олы юлның тузанында*
*Югалттым эзләремне...*
Татар халык җыры

...1939 елның 30 ноябрендә СССР белән Финляндия дәүләте арасында сугыш башлана. Чама белән бик кыска гомерле дип бәяләнгән бу сугыш (1940 елның 12 мартында тәмамлана ул) аяусызлыгы, дәһшәтлелеге белән истә калган. Әлеге сугышта Германия хәрби көчләренең дә яшерен рәвештә финнарга ярдәм итүе сугыш барышын тагын да кискенләндерә төшә. Өч ай тулмастан, солых килешүе төзелә, финнарның җиңелүе таныла. Әмма бу сугыш халык күңелендә СССР хәрби көчләренең зур югалтуларга дучар булганлыгы белән истә калган. Ә ил җитәкчеләре һәм югары дәрәҗәле хәрбиләр бездәге сугыш техникасының заман таләбенә туры килми башлавын ачыклыйлар. Бигрәк тә безнең очкычларның тизлек һәм корал куәте буенча артка калуы күзгә ташлана. 1935 елдан сафта булган И-15 истребителенең (очучылар аны яратып «Чайка-Акчарлак» дип йөрткән) очу тизлеге сәгатенә 370 км чамасы, ә Германиядә житештерелә башлаган «Мессершмитт-109»ның исә 540 км булган. Шул сугыштан соң аерым танк бригадаларын һәм корпусларын тизләтеп оештыруның кирәклеге дә раслана. 1937 елда репрессияләнгән маршал М.Н.Тухачевский һәм аның фикердәшләре заманында оештырыла башлап та, кирәкмәс дип соңыннан таркатылган шундый гаскәри берәмлекләрне күбрәк оештыру кирәклеге ачыклана. Бөек Ватан сугышы башланганчы безнең армиянең бу эштә беркадәр соңлаган булуы бик аяныч нәтиҗәләргә китерәчәк. Вермахтның куәтле танк колонналарына каршы торырлык күләмдә шундый корыч колонналар бездә 1942 елда гына күренә башлый.

* * *

Тарихта Совет-фин сугышы буларак теркәлгән яуда Казанда тупланган 86нчы дивизия сугышчылары да, төп тупланышы Ульяновск тирәсендә булып, республиканың көньяк-көнбатыш төбәгеннән мобилизацияләнгән гаскәриләрне дә берләштергән 154нче дивизия дә иң алгы сызыкта, шактый ук хәтәр юнәлешләрдә сугышалар. 86нчы дивизиянең яу кырында аеруча батыр сугышкан яисә сугыш-бәрелешләрне оста оештырган, шул сәбәпле зур уңышларга ирешкән 13 гаскәриенә Советлар Союзы Каһарманы дигән мактаулы исем бирелүе дә шуны раслый. Алар Алтын Йолдыз медале һәм Ленин ордены белән бүләкләнәләр. Бу батырлар арасында полк командиры, полковник Михаил Зашибалов (озакламый ул дивизия командиры итеп билгеләнәчәк), дошман танкларына каршы торучы тупчылар дивизионы командиры лейтенант Хәбибулла Ибраһимов (1912-1975), укчылар ротасы командиры, лейтенант Гыймазетдин Вәзетдинов (1907-1940), пулемётчылар взводы командиры, лейтенант Хафиз Сабиров (1910-1940) һ.б. бар. Дивизиянең 342 сугышчысы орден һәм медальләр белән бүләкләнгән. Дивизиягә Кызыл Байрак ордены тапшырыла. Бу сугышта башка дивизия һәм бригадаларда хезмәт итүче якташларыбыз да катнашкан. Шулардан да әлеге югары бүләккә ия булучы берничә исемне атап үтик: танкистлар батальонынннан кече командир Гафиятулла Арсланов (1915-1945), укчылар батальоны командиры капитан Сәхип Майский (1901-1942), укчылар ротасы командиры, капитан Иван Зиновьев (1905-1942), шул яуда һәлак булган танк командиры, Минзәләдә туган якташыбыз Борис Винокуров (1915-1940)... Җәмгысы — 17 кеше, 17 Каһарман.

Без бүген аларны, сугыш афәтен үз язмышлары аша үткәргән шул меңнәрдән кайберләрен, аеруча зур батырлык күрсәтеп, олы хөрмәткә лаек булган меңнәрнең бер өлешен кабат искә алып китәрбез. Алар барысы да безнең кадерле кан кардәшләребез, дөресрәге, күпләребезнең әти-бабалары булган бит. Әйе, шушы дәһшәтле, гарасатлы сугышта күпләребезнең якыннары катнашкан. Алар арасыннан исән калып, туган-үскән якларына кайту бәхетенә ирешкәннәре дә, зур бәрелешләр барышында һәлак булып, төрле тарафларда ятып калганнары да меңнәрчә. Сибгат ага Хәким бер шигырендә бик төгәл итеп әйткәнчә, бөтен Европа киңлегенә — Иделдән алып Эльба елгасы буйларынача сибелде безнең якташ һәм милләттәш сугышчыларның каберләре.

## Яңа күршеләр, яңа дуслар...

*Атландым атның билenә,*
*Киттем Герман җиренә...*
Татар халык җыры

1939 елны безнең ил халкы өчен иң хәтәр елларның берсенә кертергә кирәк. Ил күләмендә ул ел шулай бәяләнергә тиеш тә. Бу елда Советлар Союзының көнбатыш чикләрендә дә тынычлык булмый. Анда бер-бер артлы кан коюлы сугышлар дәвам итә. Ләкин Совет хакимияте елларында ул сугышлар бездә сирәгрәк телгә алынды. Матбугатка да, тарихны барлаучы китап битләренә дә шул тарафтагы кан коюлы вакыйгалар өзек-төтек кенә үтеп кергәләде. Һәм ул хакта әле бүген дә бик җәелеп, төгәл саннар китереп сүз алып барылмый диярлек. Хәтта ул сугышларда катнашып дан алган, орден-медальләр белән бүләкләнгән батырларның тулы исемлеге дә юк, дигән хәбәрләр дә ара-тирә матбугат битләрендә күренгәләп китә...

Әлегә 1939 елның августына әйләнеп кайтыйк. Шул айның 23ендә фашистик Германия белән СССР арасында «дуслык» килешүе төзелә. Тарихта ул килешү бу илләрнең шул вакыттагы Тышкы эшләр министрлары И.Риббентроп белән В.М.Молотов исемнәренә бәйле рәвештә «Молотов-Риббентроп пакты» дип тә йөртелә. 1941 елгы сугыш башланган көннән соң ук диярлек Совет илендә бу килешү-пактны бик сирәк искә алдылар. Ә аның яшерен, күрше илләрне бүлешүгә багышланган пункт-параграфын искә алу гомумән дә тыела иде. Совет хакимияте таралуга барган бер чорда да әле СССР Югары Советы депутатлары шундый фактның булуын, бигрәк тә аның ике якка да күрше булган бер дәүләт биләмәсен икегә бүлү турындагы өлешен танымаска тырышып, күп мәртәбәләр трибунага күтәрелде. Фәкать А.Яковлев, А.Д.Сахаров, А.А.Собчак кебек аек фикерле депутатлар һәм шәхесләр тырышлыгы белән генә ул фактның булганлыгы турында рәсми карар кабул ителгән иде.

Әйе, безнең илдә кайбер шундый «уңайсызрак» тарихи фактларны онытырга тырышу, киң җәмәгатьчелек андый очракларны истә тотмасын дип, «изге ялган»га бару очраклары бер бу вакыйга белән генә дә төгәлләнми, билгеле. Әйтик, әле илленче еллар башында, бөек юлбашчыбыз И.В.Сталин заманында нәшер ителгән китапларда, шул исәптән югары уку йортлары өчен чыгарылган дәреслекләрдә дә 640 еллар элек булган «Куликово кыры» сугышын Рязань кенәзлеге кенәзе Олег оештырган, Тверь кенәзлеге кенәзе Михаил ана ярдәмгә үзенең кыз туганының якынын — Витовтны җибәргән дип яздылар. Мондый фактлар күренекле рус тарихчысы Николай Михайлович Карамзинның «История государства Российского» томнарында ук теркәлгән. Ә алтмышынчы-җитмешенче елларда идарә иткән кайбер идеологлар шул тарихтан төп фигурант Олег кенәзне төшереп калдырды. Ул яу-сугышны оештыру фәкать Мамайга, Олег тарафыннан чакырып китерелгән «киллерга» гына йөкләнә башлады. Хәзер әлеге кенәзләрнең ул тарихта катнашуын кайбер ике йөрәкле тарихчылар гына искә алгалый. «Молотов-Риббентроп пакты» да хәзер шулай сирәк искә алына. Әмма Бөек Ватан сугышы әлеге пакт нигезендә барлыкка китерелгән үзгәрешләр белән бик тыгыз бәйләнгән. Һәм безнең ил тарихы ул вакыйгаларны читләтеп үтә алмый.

1914-1918 еллардагы Бөтендөнья сугышы вакытында Россия белән Германия бер-берсенә каршы якта торып сугыша. Ә 1922 елда, патша Россиясе җирлегендә барлыкка килгән Совет хакимияте белән «яңа Германия» хакимияте арасында

беренче яшерен «дуслык килешүе» төзелгәнлеге мәгълүм. Андый адымга бу дәүләтләр 1919 елгы Версаль солых килешүеннән соң бөтендөнья илләре тарафыннан бераз читләтелгән булганлыктан баралар. Германия — элекке сугышта бик актив катнашучы буларак, ә СССР барлык капиталистик илләргә дошман дәүләт сыйфатында читләштерелә. Шул ук вакытта СССР юлбашчылары әле Карл Марксны тудырган Германия җирендә дә социалистик дәүләт барлыкка киләчәгенә өметләнеп яшиләр. Нишләп өметләнмәсеннәр ди, 1919 елда Берлинда һәм Мюнхенда немец хезмәт ияләре шундый талпыныш ясап карадылар ич инде! Бавария Совет Республикасы бер ай чамасы яшәп алды!.. Шул өметләрне дә истә тотып булса кирәк, Германия житәкчеләре тәкъдимен СССР башлыклары кабул итә. Шул рәвешле якын күршеләре өнәп бетермәгән ике ил арасындагы мондый якынлык мөнәсәбәтләрен урнаштыру акланган кебегрәк була. Һәм әүвәл 1922 елгы яшерен төп килешү, сонрак тагын берничә өстәмә килешүләр барлыкка килә, дип язган шул чор немец дипломаты Пауль Шмидт-Карелл «Гитлер идёт на восток» китабында *(Емельянов Ю. Был ли заговор Тухачевского? // Журнал «Слово». 1991, №12).*

Ул вакытта Германиягә корал житештерү, үз хәрби көчләрен тоту, укыту тыелган була. Шул сәбәпле ул ил башлыклары, СССРга яңа хәрби техника булдыруда ярдәмләшү тәкъдиме ясап, әлеге техниканы үзләштерүче гаскәриләрне дә безнең илдә укытырлык уртак хәрби мәктәпләр ачу тәкъдиме белән чыгалар. СССР житәкчелеге алар фикере белән ризалаша. Берлинда һәм Мәскәүдә үз конторы булган ярым рәсми «ГЕФУ» сәүдә фирмасы төзелә. Шул рәвешле СССРда берничә уртак хәрби завод һәм хәрби мәктәп ачыла. Ул заводларда эшләүчеләрнең күпчелеге, төп эш башкаручылар немец эшчеләре — киләчәктә Германияне социлистик ил буларак үзгәртерләр дип өмет ителгән кадрлар була. (Мәсәлән, Алтайда, Новокузнецк металлургия заводын аякка бастыруда катнашкан бер төркем эшче шундыйрак хыял белән мавыгып та ала бугай.) Шул заводларның иң эреләрен атап үтик. Германиянең «Юнкерс» фирмасы Мәскәү янәшәсендәге Фили бистәсендә 1924 елдан яңа төр металлдан (дюраль) коелган корпуслы самолётлар житештерүгә, башка бер компания Ленинград, Тула, Златоуст заводларында туп снарядлары коюга керешәләр. Пауль Шмидт-Карелл язганнарга ышансак, патша заманыннан бирле эшләп килүче, немецлар ярдәме белән бераз заманчалаштырылган соңгы өч завод елына өчәр йөз мең чамасы снаряд житештергән. Бу снарядлар да, аерым жиһазлар рәвешендә сүтелгән килеш зур әрҗәләргә тутырылган самолётлар да, гади сәүдә товары буларак, Балтыйк диңгезе буйлап Германиягә озатылып торган. Дөрес, ул козгын «Юнкерс»ларны ул еллардагы документларда, бәлки, кайбер илләрдә, шул исәптән СССРда да пассажирлар йөртү өчен кулланылган «юаш» «Юнкерс»лар белән тинләп яза торган булганнардыр. Бу «уртак» заводларның уртак булудан кайчан туктатылганлыгы төгәл генә мәгълүм түгел. Мөгаен, Адольф Гитлер Германия иленең «тәхетен» биләгәннән соң булган бугай андый хәл. (Бераз сонрак әлеге заводлар житештергән снарядларның һәм «Юнкерс» ише авыр бомбардировщикларның безнең илгә ничаклы зыян китерүен әйтеп һәм исәпләп бетерерлек тә түгелдер.)

Липецк каласы янәшәсендә 1924 елдан ярым яшерен СССР-Германия очучылары мәктәбе (4нче «совет» эскадрильясе), 1927дән Саратов ягында сугышта химик агулар куллануны үзләштерүчеләрнеке ачыла. Ә егерменче еллар ахырында Казан читендә, Урта Кабан күле тирәләрендә танкистлар әзерли торган «Кама» мәктәбе эшли башлый.

Бу мәктәпнең рәсми исеме «Осоавиахим» техник курслары» дип аталган була. 1929-1933 елларда әлеге уртак хәрби мәктәпнең житәкчесе немец офицеры Фридрих Кюн, аның урынбасары С.М.Ерошенко булган. Бу мәктәптә укучы вермахт курсантлары әзерлеген тикшерү өчен, 1930 еллар башында Казанга Германиянең булачак баш танкисты генерал Х.В.Гудериан да килеп киткән дигән мәгълүмат бар. Башлангыч елларда мәктәптә укучы вермахт курсантлары саны өчтән ике нисбәтендә булган. Германиядә хакимияткә Адольф Гитлер килгәннән соң, ике яклы килешүләр туктатыла. Уртак оешмалар бетерелә. 1933 елның сентябреннән алып 1941нең мартына чаклы бу хәрби мәктәп Кызыл Армия өчен генә танкист кадрлар әзерли. Аны тәмамлаучылар арасында Алабуга төбәгендә туган генерал, 10нчы танк корпусы командующие Василий Герасимович Бурков һәм безнең «Батырлар китабы»нда теркәлмәгән берничә Советлар Союзы Каһарманы да бар.

1941 елның март аенда бу уку йорты пехота мәктәбе белән берләштерелә һәм Казан танк училищесы дип йөртелә башлый.

«Юнкерс» ише «товар» житештерүче заводларга иң кирәкле чимал да, җайланмалар да Германиядән китерелгән. Шушы хезмәтләр өчен Германия бюджетының байтак өлеше тотылган. Мәсәлән, 1926 елда йөз илле миллион күләмендә дәүләт акчасы тотылуы теркәлгән. «Дәүләтнең ул елдагы бюджетының өчтән бер өлешенә якын сумма», — дип хәбәр ителә әлеге китапта. Димәк, «Үзен тапкан, үз башына төшкән бәла» дигән гыйбарә шушындый хәлләргә бәйле рәвештә тугандыр инде, мөгаен. Дөрес, 30нчы елларда Германиядә юлбашчылыкка Гитлер һәм аның фикердәшләре килмәгән булса, сугышка әзерлек өлкәсендә ике ил арасындагы уртак хезмәттәшлек, бәлки, болай ук фаҗигале юнәлеш алмаган булыр иде.

1939 елгы икенче дуслык килешүе исә ике ил арасында көтелгән сугышны берникадәр вакытка чигендереп тору, шул арада күбрәк көч-куәт туплау нияте белән төзелгән бугай. Әлбәттә, әлеге «дуслык килешүе»нең озакка бармасын ул килешүгә адым ясарга ниятләгән ил башлыклары аңлый. Әйе, ул килешүнең төп пункты бу илләрнең якын арада бер-берсенә каршы сугыш башламаячагын белдерү була. Ә инде икенче — яшерен пункты турында бераз соңрак сүз булыр. Ике ил арасында төзелгән ул килешүдән соң, СССР белән Германия халыкларының үзара дуслыгы турында вакытлы матбугатта төрле язмалар басыла башлый. Уртак башка чаралар да үткәрелә.

Шул рәвешле, ике арада «көтмәгәндә, капылт кына башланасы сугыш» берникадәр вакытка кичектерелеп тора. Бу вакытта вермахт гаскәрләре Германиягә күрше булган илләрне яулап алу сугышларын башлап җибәрә. 1939нын 1 сентябрендә, Польша дәүләтенең чиктәш өлкәләрендә күпмедер күләмдә немец халкы вәкилләренең дә яшәвен сылтау итеп, Германия бу илнең көнбатыш өлешен яулап алырга керешә. Ә киләсе елның май-июнь айларында Бельгия, Франция кебек илләрнең җирләрен басып ала.

Бу айларда СССР хөкүмәте дә тик ятмый, үз биләмәләрен көнбатыш тарафкарак киңәйтү чараларына керешә. «Молотов-Риббентроп килешүе»нең яшерен пунктында украиннар белән белоруслар күпләп яшәгән төбәкләрне СССРга кушу зарурлыгы да каралган була. Балтыйк диңгезе буенда урнашкан кечерәк өч дәүләт язмышы да шул «пакт» нигезендә СССР карамагына калдырыла.

Өлкәнрәк буын укучылар хәтерлидер, 1919-1920 еллардан башлап СССР белән «паннар Польшасы» арасында дошмани сәясәт яшәп килде. Ике ил арасындагы мондый мөнәсәбәт соңрак тагын да катлаулана төшә... Көнбатыш Украина белән Көнбатыш Белоруссия өлкәләрен һәм Балтыйк буе дәүләтләрен СССРга кушу өчен 1939 елның сентябрь урталарыннан кыска вакытлы яулап алу сугышлары башлана. Анда безнең күп кенә гаскәри берәмлекләр катнаша. Ә вермахт гаскәрләре инде бу вакытта «паннар» иленең көнбатыш төбәкләрендә исә үз тәртипләрен урнаштырып та өлгергән була. Шулай итеп, әлеге килешүне төзегән «дус» дәүләтләргә ашыга-ашыга яңа чик буйларын ныгыту эшләренә керешергә, анда яңа казармалар, яңа аэродром һ.б. төр корылмалар төзи башларга туры килә. Кемдер моңа тизрәк ирешә, кемдер соңлый, әлбәттә. СССРның шул чик буйларында урнашкан алтмышлап яңа аэродромыннан кайберләренең 1941 елның май-июнь айларында әле төзеп тә бетерелмәгәнлеге мәгълүм. Дөрес шул, әгәр алдан чарасын күрмәсәң, бәла көтмәгәндә килә...

Яңа өлкәләрне яулау, чик буен үзләштерү вакыйгаларында безнең якташларыбыз һәм милләт вәкилләре дә катнашкан. Ләкин элегрәк елларда, бигрәк тә Совет хакимияте дәверендә ул җирләрдә барган сугыш турында безнең илдә бик шауламадылар. Ул сугышларга багышланган истәлек язмалары да, тарихи хезмәтләр дә сирәк басылды. Шуңа күрә безнең халык күңелендә ул чор «герман солдатлары белән кыска вакытлы дуслык еллары» буларак кына истә калган. Шул ук «Батырлар китабы»на кергән, төрле вакытта Советлар Союзы Каһарманы исеменә лаек булган кешеләр арасында да көнбатыш чикләрне киңәйтү сугышларында катнашкан дистәләп исемне күрсәтеп була. Ләкин алар анда ни-нәрсәләр эшләгән — ул хакта сүз юк. Бу вакыйга алар биографиясендә фәкать «1939 елда совет гаскәрләренең Көнбатыш Белоруссиягә (яки Көнбатыш Украинага, Балтыйк буе өлкәләренә) походында катнашты», дигән бертөрлерәк җөмләләрдә генә теркәлгән. Әйтерсең, туристик походта булып кайтканнар.

1939-1940 елларның көзге һәм кышкы айларында дөнья күргән матбугат битләрендә СССР белән Германия дәүләтләренең «мәңгелек дуслыгы»на багышланган язмалар бар, газета-журналларда фотоматериаллар да урнаштырылган. Башына будённовка кигән, аркасына мылтык аскан совет кызылармеецы белән каскалы вермахт солдаты кочаклашып төшкән плакат сурәтләре дә матбугат битләрендә очрап тора. Польша җирләрендәге җиңү сугышларыннан соң вермахт гаскәрләре белән бергә уздырылган парадларда СССР гаскәриләренең һәм кайбер гаскәр башлыкларының катнашуын күрсәткән фотолар да очрый анда.

Язучы Мәхмүд Максуд — шул вакыйгаларның шаһиты булган шәхес. Шул хакта аның хатирә язмалары бар иде. Ул сугыш вакытында М.Максуд бер хәрби газета редакциясендә эшли, өлкән политрук. Шул сәбәпле ана «вермахт гаскәрләренең җиңү парадларын» күрү, киләчәктәге дошман армиясенең бериш командирлары һәм каскалы солдатлары белән якыннан аралашу да насыйп була. «Батырлар китабы»нда урнаштырылган Каһарманнарыбыз исемлегенә күз төшерсәк, якташларыбыздан 1939 елгы ул яуларда танкист Борис Винокуровның, укчы взвод командиры Семён Ильченко (1915-1962дән соң), шул сугыш чорында укчы ротада лейтенант, соңрак танылган партизан булган Иван Кабушкин (1915-1943), очучы Гали Мәҗитов (1912-1955тән соң) һ.б.ның катнашуын ачыкларбыз. Казанда туган каһарман очучы, яу кырында 1943 елда һәлак булган Василий Михайловка багышланган белешмәлектә генә бераз аңлаешлырак итеп: «Участник ввода Советских войск на территорию Западной Украины и Западной Белоруссии в 1939 г.», — дип язылган.

Шул елның беренче айларында алар да бит ике як гаскәриләренең дуслык очрашуларында булганнар. Танкист белән танкист, тупчы белән тупчы очрашканда, һичкайчан бер-берсенә төбәп атмаска сүз куешканнар... Шул яуда да булып, сугыш афәтләрен кичеп кайткан кайбер солдатлар әле илленче елларда да көнбатыш чик буендагы шундый очрашулар турында искә алгалап сөйләрләр иде. «Әйе, немец солдаты да безнең кебек кеше. Гитлер һәм аның иярченнәре генә алар холкын бозды», — дип әйтүчеләр дә булгалар иде.

* * *

«Яңа дуслар, яңа күршеләр» белән үзара сугыш башланыр алдыннан, яңарак барлыкка китерелгән чикнең ике ягындагы гаскәрләр күпме булган? Алар карамагындагы корал нинди һәм ничаклы булган соң? Бу сорауларга җавап бирүе безгә шактый авыр. Шунысы хак: дошман яхшырак коралланган була, самолёт, танк, туплар исәбенчә өстенлек аның ягында кала. Германия ягында торып сугышырга ризалык биргән илләр дә ишле генә: Италия, Венгрия, Румыния, Финляндия.

Ж.И.Гыйльмановның «Без сугышта юлбарыстан көчлебез» дигән китабына күз төшерик. «Ул вакытта бөтен Көнбатыш Европаның дип әйтерлек хәрби ресурслары һәм икътисады безнең дошман кулында иде... Кайбер Көнбатыш илләрен яуларга әзерләнгәндә һәм аларны басып алу вакытында кирәкле тәҗрибә дә тупланган була. Шуңа күрә Советлар Союзына баштарак бик кыенга туры килде. Сугыштан соңгы елларда хөкүмәт оешмалары тарафыннан да билгеләп үтелгәнчә, бу кыенлыкларны арттыруга үзебездәге житешсезлекләр — «фашистик Германиянең һөҗүмгә күчү вакытын билгеләүдәге ялгышлар да, заманча техниканың вакытында житештерелмәве һәм башка төр кимчелекләр дә өстәлә», — дип, хөкүмәт карарыннан бер җөмлә китереп яза ул. «Великая Отечественная война Советского Союза 1941-1945» *(Мәскәү, 1967, 33 б.)* китабында бу чорга караган кайбер саннар да китерелгән. Бөек Ватан сугышы алдыннан безнең дошманнар карамагында җәмгысы сигез миллион биш йөз мең чамасы гаскәри, унбер меңнән артыграк санда төрле куәттәге танк һәм үзйөрешле туп («бронялы пушка»), унбер мең чамасы самолёт булган, диелгән. Ләкин бу саннар 1980 елда нәшер ителгән «Советский энциклопедический словарь» белешмәлегендә (205 б.) бераз киметеп күрсәтелә. Бу вакытта чик буенда Германия белән союзниклары карамагында биш миллион ярым гаскәри, өч мең дә җиде йөз танк (алдагы саннан өч мәртәбәгә кимрәк), биш меңгә якын (икенче бер белешмәлектә төгәлрәк сан китерелә — 4980) самолёт булган, диелә. Безнең уйлавыбызча, әлеге саннарның икенчесе дөреслеккә якынрактыр кебек. Шуларның азчылык өлеше Германиянең башка

фронтларында (мәсәлән, Африкада) кулланылса, күпчелеге СССРга каршы ташланган. Германиянең һәм аның белән килешү төзегән илләрнең гомуми дивизияләре саны элегрәк йөз туксан булган дип күрсәтелгән иде. 1980 елгы белешмәлектә бу сан юк. Германия һәм аның җәптәш илләре самолётларының гомуми саны биш мең чамасы булса, «Великая Отечественная война Советского Союза 1941-1945» китабының 1965 елда нәшер ителгән басмасында күрсәтелгәнчә, бу санның яртысыннан күбрәге вермахт гаскәрләре һөҗүменең төп юнәлешен тәшкил иткән безнең Көньяк-көнбатыш һәм Көнбатыш хәрби округлары каршына туры килгән икән.

Менә СССР Авиация сәнәгате халык комиссариаты хезмәтләрендә теркәлгән, сугыш алдыннан безнең көнбатыш фронтлар карамагында булган самолётларга бәйле бер белешмә. Кара диңгез буеннан алып Төньяк боз диңгезенә кадәр сузылган озын чик буенда безнең 79 һава көчләре дивизиясе һәм 5 авиабригада булган икән. Аларның бер өлеше катнаш составлы булган, ягъни ул бригада һәм дивизияләрдә истребительләр дә, бомбардировщиклар да бер житәкчелеккә буйсындырылган. Ә гомумән алганда, чик буйларында урнашкан бу һава көчләре гаскәрләре сафында истребительләр — 59, бомбардировщиклар — 31, штурмовик-пикировщиклар 5 процент булган икән. Шул ук документта бомбардировщиклар санын бераз киметеп, истребительләр белән штурмовикларны анда күбрәк урнаштырасы булган икән дигән җөмлә дә бар. Бу дивизия белән бригадаларның 32се, ягъни яртысы чамасы, Көнбатыш хәрби округы биләмәсендә урнашкан була. Димәк, дошманның туп-туры Мәскәү тарафына юл тотасы юнәлешендә.

Чик буендагы безнең гаскәри берәмлекләрнең саны һәм көч-куәте тулаем безгә мәгълүм түгел. Ул саннар элек бездә күрсәтелмәде, киң җәмәгатьчелек өчен тулы килеш бәян ителмәде дә бугай. «Энциклопедик словарь»да безнең гаскәриләр саны 2,9 млн., танклар – 1800, самолётлар 1540 булган дип китерелә. Самолётлар саны алдыннан «яңа конструкцияле» дигән сыйфат билгесе дә куелган. Дөрес, беришe шулай яңарак эшләнә башлаган яңа төр очкыч та булгандыр. Бердән, аларның күпчелеге, бер мең дә ике йөзе, сугышның беренче көннәрендә үк юк ителгән бит. Ә ул чордагы безнең бомбардировщикларның ни хәлдә булуы белән бу хезмәтне укучылар әле таныша алыр.

Минск, Могилёв, Смоленск тирәләрендәге яу кырында көн дә диярлек булган хәрби корреспондент һәм язучы Константин Симонов үзебезнең беренче танкны, бер җинел Т-26ны июльнең дүртләре тирәсендә күрдем, дип яза. Ә 30 июнь иртәсендә Березина елгасы юнәлешендә фанердан ясалган иске ТБ-3 бомбардировщикларыбызның ничек бер-бер артлы юкка чыгарылуын шулай ук аның 1982 елда Мәскәүдә нәшер ителгән «Разные дни войны» китабыннан укып белеп була. Димәк, «яңа һәм яңартып» эшләнгән самолётлар әле сугышның башланган атналарында сугыш кырына бик аз күләмдә генә барып житкәндер. Аның шулайрак икәнлеге Авиация сәнәгате халык комиссариаты эшчәнлегенә кагылышлы кайбер язмалардан да чамалана. Мәсәлән, 1939-1940 елларда яңарак истребительләрдән иллеләп Як-1 (сугышка багышлы язмаларда бу самолёт бик сирәк искә алына, аз күләмдә чыккан булгангадыр), йөз егерме МиГ (аларның да егермесе генә МиГ-3, калганнары «устаревшие МиГ-1» диелгән) житештерелә. Ә 1941 елда исә өч мең дә бер йөз МиГ-3, жиде йөзләп ЛаГГ-3 эшләп чыгарыла. Ләкин бу МиГ, ЛаГГларның яртысыннан күбрәге сугыш башланганнан соң, шул елның соңгы чирегендә житештерелгән, дип язалар. Бомбардировщиклардан яңа Ил-4ләрне 126нчы завод 1940 елда йөз данә, 1941дә өч йөз сиксән биш данә чыгарган. ТБ-7 яки Пе-8ләр Казан заводында 1940 елда — 18, 1941дә 23 данә житештерелгән. Әйе, болары Мәскәү белән Казан заводларында эшләнгән. Бер карасаң, бездә дә самолётлар шактый ук житештерелгән кебек. Ләкин шуларны зур бер ил буйлап таратып чыксаң — анда да, монда да житешми башлаганлыгы күренәчәк. НКАП белешмәлегендә 1942 елның июленәчә житештерелгән самолётларның 47 проценты гына яңа төр очкычлар иде, диелә. Бигрәк тә бомбардировщиклар арасында бу сан бик түбән — 10 процент кына булган. Күпчелекне әлеге фанер ТБлар («тяжёлый бомбардировщик»лар) тәшкил иткән.

Ул вакытта безнең бөтен Көнчыгыш Европа-Азия буйлап сузылган илебездә 160 дивизия була. Бу сан тарихчы Ж.Гыйльманов хезмәтендә дә, К.Симоновның әлеге



*Казанда җыелган У-2 самолёты.*

китабында да китерелә. Аның Бөек Ватан сугышы тарихын яхшы белгәнлеге беркемдә дә шик уятмыйдыр, шәт. Архивларда тупланган бик-бик күп документлар белән дә таныш булган К.Симонов. Үзенең әлеге китабында да ул, көндәлектә теркәлгән берәр фактны раслау өчен, күп санда төрле архив чыганакларыннан алынган мәгълүматка таянып эш итүен белдерә. Ж.Гыйльмановның алда искә алып кителгән китабында: «Сугыш башланган айларда мобилизацияләнгән кешеләр исәбенә тагын кырыктан артыграк дивизия оештырыла», — дип язылган. Шуларга 1942 елда яна оешканнарын да өстәсәк һәм яу кырында юк ителгәннәрен чигерсәк, 1943 елда сугышчыларның милләт санын барлауда катнашкан 200 дивизия килеп чыгадыр, мөгаен. Сугыш башланган беренче җәйдә сугыш кырында күпме дивизиябез таркалган, камалышта калган, юкка чыккан соң? Саннар төрлечәрәк китерелә. 1941 елның җәй-көз айларында безнең егерме сигез дивизия юк ителгән яисә камалышта калып таркатылган дигән хәбәр бар. Менә сугыш башланган айларда ук гаскәри берәмлекләребезнең, димәк, солдат һәм офицерларыбызның ни дәрәҗәдә тиз кимүен дәлилләүче бер мисал. «Великая Отечественная война Советского Союза 1941-1945» китабында (90 б.) «1941нең сентябрь башында Көньяк-Көнбатыш фронт оештырган «Киев операциясе»ндә СССР ягыннан 677 мең гаскәри катнашты, шул операциядән соң 150 мең чамасы гына калды», — дип хәбәр ителә. Көнбатыш фронт юнәлешендә, икенче төрле язылганча укысак — «Смоленск төбәгендә барган сугышларда» безнең унбер дивизия юкка чыгарылган, дигән фактлар бар. Шулар арасыннан икесе — элек Казанда оештырылганнары. Әйе, 1984 елда Мәскәүдә нәшер ителгән «Великая Отечественная война. Вопросы и ответы» китабында да гаскәри берәмлекләр исемлегеннән төшерелгән дивизияләр санының егерме сигез булуы раслана.

Сугыш башланыр алдындагы ике ел дәвамында СССРның ашыгып корал житештерүен, яңа төр техника үзләштерә башлавын һичкем инкяр итмәстер, шәт. Бу табигый хәл. Бүген-иртәгә зур сугыш башлану ихтималын көткән һәр ил дә шулай эшләр иде. Бу елларда яңадан атаклы Т-34 танклары, яңа төр очкычлар житештерелә башлый. (Тухачевский төркеме кулга алынгач, Т-34ләрне һәм үзйөрешле тупларны чыгаруны туктатып торуны күпләребез, бәлки, ишетмәгән дә булгандыр.) Элегрәк әкрен йөрешле ТБ-3 очкычлары житештерелгән булса, бу елларда завод ангарларында Ил-4, ТБ-7 (соңрак бирелгән атамасы — атаклы Пе-8) сафка баса. Дөрес, сугышка чаклы бу очкычлар саны әле бик аз була. Әмма алар сугыш башланган җәйдә ук Берлин, Данциг, Кёнигсберг кебек бик ерактагы дошман шәһәрләрен бомбага тотарлык очкычлар буларак таныла. (Бу самолётларны житештерүдә, әлбәттә инде, Мәскәү янәшәсендәге заводта «Юнкерс»ларны эшләүдә кулланылган җиһазлар да катнашкандыр. Димәк, Германия белән элекке бер килешүнең файдасы да тигән икән.) Совет авиациясен яңадан-яңа очкычлар белән тулыландыру юнәлешендә Казан авиация заводы сугыш елларында уңышлы эшли. Бу уңышта, әлбәттә, сугыш башлангач ук Мәскәүдән Казанга күчерелгән заводның да өлеше зур. Бергә кушылган заводларның берсенең иске исеме калдырылуы да шуны раслый торгандыр инде. Шул ук елларда Казан заводында тагын да тизрәк очышлы, танк колонналарына төбәп туп-пулемётлардан атарга да, бомба ташларга да сәләтле Пе-2 «бомбардировщик-пикировщикларын» житештерүгә дә керешелә. Ләкин сугыш башланган чорда әле бу коралларның — яңа төр самолёт һәм танкларның саны житәрлек булмый шул. Казанда урнашкан 2нче, 387нче санлы завод та бу елларда



*Ольга Санфирова*

яна төр истребитель самолётларын — ЛаГГ-3не сафка бастыруда катнаша. Ул очкычларның канатлары әлеге Бишбалта заводына караган, хәзерге шәһәр стадионы тирәләрендә урнашкан цехларда эшләнгән. Ләкин бу заводның төп юнәлеше По-2 самолётларын житештерү була. Сугышка чаклы әлеге очкычлар шәһәрара элемтә урнаштыру, пассажирлар йөртү тармагында һәм булачак очучыларны очарга өйрәтүче уку йортларында кулланылган. Сугыш башлангач, аларны, фотоаппаратлар урнаштырып, дошман көч-куәтләрен барлаучы разведка эшләрендә дә, партизаннарга кирәкле корал ташу, яралыларны фронт сызыгы аша үзебезнең якка чыгару максатларында да кулланалар. Бомба ташлау жайланмалары беркетелгән По-2, У-2 (бераз сугыш шартларына жайлаштырылган вариант) самолетлары атаклы хатын-кызлар авиаполкының — каһарман очучыларыбыз Ольга-Ләйлә Санфирова (1917-1944), Мәгубә Сыртланова (1912-1971), кардәш казакъ кызы Һибазә Доспановалар полкының төп «аты» да булган бит. Сугыш елларында әлеге заводта унбер мең чамасы шундый биплан житештерелгән.



*Мәгубә Сыртланова*

Сугыш башлануын көткән айларда кайбер башка төр оештыру эшләре дә башкарыла, яна карарлар да кабул ителә. Мәсәлән, 1939 елның 31 августында кабул ителгән карарда хәрби хезмәткә мобилизацияләнүчеләрнең яшен яшәртү — 18гә төшерү, югары уку йортларында укучыларны хәрби хезмәткә алуны кичектереп торучы льготаны юкка чыгару каралган була. Әлбәттә, хезмәткә каралучыларның яшен ике яшькә яшәртү — өстәмә гаскәри берәмлекләр, дивизияләр туплау дигән сүз. СССР Югары Советы Президиумының 1940 елгы 26 июнь карары белән илдә элекке жиде сәгатьлек эш көне урынына сигез сәгатьлек эш көне кертелә. Эш атнасы да жиде көнгә житкерелә. Ягъни завод-фабрикаларда эшләүчеләр «базар көн»сез эшләү режимына күчерелә. Хәтта Яңа ел бәйрәмен дә «элекке бай-буржуйлар бәйрәме» дип бәяләү очраклары булган. Ул елларда фәкать Яңа ел, 1-2 май һәм 7-8 ноябрь көннәре генә рәсми бәйрәм көне саналган.

Димәк, корал житештерү өчен тагын сәгатьләр, көннәр өстәлгән. Совет-фин сугышыннан соң билгеләнгән яңа хәрби министр С.К.Тимошенконың 1941 елның май ахырында кабул иткән карары да «тиздән сугыш башланачак» дигәнне аңлатып тора. Ул карарда хәрби уку йортларын тәмамлап чыгу вакытын алгарак күчерү, аны тәмамлаучыларны, жәйге ялга таратмыйча, кичекмәстән хезмәткә билгеләнгән урыннарына жибәрү тиешлеге каралган була.

Ләкин, шундый чаралар күрелүгә дә карамастан, бик күпләр өчен ул сугыш «көтмәгәндә башланган» кебек кабул ителгән. Гади халык арасында гына түгел, байтак кына хәрби житәкчеләр арасында да булачак сугыш нәтижәләренә жиңелчәрәк карау чире — ваемсызлык өстенлек иткән кебек тоела. «Японнарны (Халхин-Гол сугышында), финнарны, әнә, бик тиз дөмбәсләдек, башкаларны да шулай тиз генә бәреп егачакбыз», дигәнрәк фикер күпләрнең күңелен юаткан булса кирәк ул елларда...

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН,**
**Булат ХӘМИДУЛЛИН**

*Дәвамы бар*

# «КАЗАН УТЛАРЫ» ЯКТЫСЫ

«Казан утлары» журналыннан берничә ел аерылып торган идем. Кабат алдыра башлагач, үземнең бик күп нәрсә югалтканымны аңладым. Минем кебек уйлаучылар тагын да бардыр, чөнки тиражыгыз шактый арткан.

Язылуымның сәбәбе — үзем укыткан укучымның мәртәбәле журналда эшләве, аның әсәрләренең басылуы. Сүзем — Айгөл Әхмәтгалиева турында.

«Таллыкүлдә былбыл бар» бәянын укый башлагач, үзеннән-үзе әсәр эченә чумасың, чөнки бу проблема һәр авыл укучысына якын, таныш. Мондый проблемалар күп язучыларның әсәрләрендә чагылыш таба. Ә менә геройлар, образларның бирелеше, язучы теленең сыгылмалылыгы, вакыйганың чишелеше — үзенчәлекле. Күп әсәрләрдә вакыйга бик күңелле тәмамлана, хыянәтләр дә читтә калмый. Ә Айгөл Әхмәтгалиеваның әсәре исә «чиста», күңелгә ятышлы. Менә шулар аның тәрбияви әһәмиятен арттыра.

Тормыш сазлыгыннан Наилә кебек чыгучылар да җитәрлек бит бүгенге тормышыбызда. Акча артыннан куып та күңеле тупасланмаган, кешелеклелеген җуймаган Шамил образы күңелгә аеруча якын. Андыйлар бит, гадәттә, «текә» машиналарда тузан туздырып кайтып күренеп китәргә генә яраталар. Бүгенге кырыс заманда ничек аңарда нечкә күңеллелек, кешелеклелек, авылны ярату, сагыну бетмәгән, сакланып калган? Нәрсә тартып кайтарган аны? Тамырлар монда булгангамы? Әллә инде кендек каны тамган, тәпи атлап киткән яшел чирәмнәр, Наилә белән бергә эшләгән чөгендер басулары, әбисенең әйткән сүзләреме? Әгәр тормышыбызда Шамил кебек эшмәкәрләр үз авылларын шулай яратып, кабат торгызырга алынсалар, бүгенге кризис чорында бөтен Татарстан өчен зур файда булыр иде. Бу әсәрне укыгач, күңелдә шундый уйлар туа.

Журнал саннары бик бай чыга. Кемгәдер Хисам Камаловның «Яңа шәһәрдә» бәяны ошаса, ялгызлык ачысын татыганнар Гөл Мирһадиның «Төш» бәянын елап укулары турында сөйлиләр. Ә барысы да яратып укыган хикәя — Айгөл Әхмәтгалиеваның «Капка» хикәясе. Телевидение аша Айгөл белән очрашу бу әсәрне укыйсы килү теләген арттырды. Журналны көтеп алдык.. Хикәяне укыгач, Мәхмүт Кашгарый исемендәге Халыкара хикәяләр конкурсында аның II урынны лаеклы рәвештә алуына ышанасың. «Капка» хикәясе Айгөлне зур юлга — Азәрбайҗан башкаласы Бакуга «алып баруына» укытучысы буларак бик сөендем, горурландым.

Тирән эчтәлекле, тәрбияви бу әсәр чынлап та олы бәягә лаек. Хикәядә бүгенге көн проблемалары һәркем күңеленә үтеп керерлек, тетрәндерерлек, уйландырырлык итеп күтәрелгән. Азмыни Касыймнан Коляга әйләнгән татар егетләре? Татар сүзе ишетергә тилмереп яшәүче милләттәшләребез? Кем гаепле? Сораулар, сораулар... Бүгенге татар авылларында, Айгөл язганча, буш нигезләр, тәрәзәләре кадакланган йортлар күп... Синең өчен бик кадерле йортның читләр тарафыннан сүтелүе гадәти күренешкә әверелеп бара. Кайтыр нигезе калмыйча, шәһәрдәге дүрт стена арасында читлектәге кош кебек бәргәләнүчеләр бүген дә җитәрлектер. Кайтыр җире калмаганнар, кулыннан эш килгәннәр, мөмкинлеге булганнар, Айгөлнең Шамиле кебек, туган авылында кемнеңдер буш нигезендә яңа йорт калкыта. Безнең авылларда шундый күренеш күзәтелә башлады. Бу күңелдә өмет уята.

«Казан утлары» журналының үткән елгы саннары кулдан-кулга йөреп, «мунчалага» әйләнеп беткән иде. Быел исә безнең кечкенә генә Качкын бүлекчәсенә уннан артык журнал килә. Ә бу үз чиратында журналның абруе арту турында сөйли. Иҗат уңышлары телим Сезгә! Әлеге әсәрләр кебек матур язмалар көтеп калабыз.

**Әсма КАШАПОВА.**
*Актаныш районы Качкын авылы*




*Россия һәм Татарстан арасында төзелгән тарихи Шартнамәне имзалау мизгелләре. Сул якта — Татарстан Республикасы җитәкчеләре. Уңда – Россия Федерациясе вәкилләре. Уртада — Россия Президенты Б.Н.Ельцин Шартнамәгә кул куя. 1994 ел.*




*Онытылмас 90нчы еллар шигаре.*



*Урам-мәйданнарда халык ташкыны.*



*Рөстәм Миңнеханов — Хөкүмәт җитәкчесе һәм спортчы. 2006 ел.*



*Киңәшле эш таркалмас. Минтимер Шәймиев һәм Фәрит Мөхәммәтшин. 1995 ел.*



*Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатлары Татарстанда. 2005 ел.*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

# БӘШИРИ «МЫРАУ»ЛАП КЫНА ЯЗГАНМЫ?

## ӘДӘБИЯТ ЕЛЫНДА МИРАСЫБЫЗ ТУРЫНДА БЕР УЙЛАНУ

*Әй, татар! Бу көнгә чаклы саклады, бел, кем сине?*
*...Шөбһәсездер, саклаган шәй – тик мөкатдәс тел сине...*
З.Бәшири

Соңгы елларда әнә шул мөкатдәс, бөек телебез саклаган рухи байлыгыбызның бер өлеше булган газиз әдәбиятыбызның егерменче гасыр башы чорына игътибар бик нык артты. Әйе, әйе, татарда чын әдәби ренессанс, алтын чорыбыз, милли, рухи дөньябызның иң югары үсеш ноктасы булган бу санаулы гына (1905-1917) елларга без күңелдә, уйда һаман ешрак кайтабыз. Нигез сагындыра! Шул нигезнең олуг баганаларыннан берсе Г.Исхакыйның бай иҗаты белән дә таныштык, ниһаять: аның тансык әсәрләренең унбиш томлыгы басылып, безнең кулларга һәм җаннарга ирешә. Тукаебызның алты томда булачак тулы әсәрләрен туплаган академик басмасының беренче томнары да инде дөнья күрде. Күптән көтелгән энциклопедиясе дә юбилеена чыгып җитәр дип ышанабыз. Тагын бер алтын баганабыз – Г.Ибраһимов иҗатын да тулырак ачачак яна «Әсәрләр»е әзерләнә дип беләбез. Соңгы елларда әдәбиятның аерым тармакларын, шул исәптән Тукай чоры шигъриятен колачлаган антология характерындагы мәҗмугалар, күмәк китаплар да дөнья күрде. Нәтиҗәдә, элек «онытылып» торган шигъри әсәрләр кабат кайтты. Әйтик, Н.Думавиның «Шәрык даһие», М.Гафуриның «Адәм вә Иблис», Ф.Бурнашның «Коркыт», Б.Мирзановның «Җен туе» кебек поэмалар, Сөембикәгә, Чура батырга багышланган шигъри әсәрләр, Сүнчәләй, Ченәкәйләрнең үзенчәлекле лирикасы, Ф.Ибраһимов, Г.Харис, Г.Сөнгати, Заһидә һәм Сания Гыйффәтләрнең һәркайсы үзенчәлекле шигъри мирасы бу китапларда тулырак бирелеп, узган гасыр башы поэзиясенең чикләрен тагын да киңәйтте. Болар арасында заманында Тукаебызның тәнкыйть, һөҗүенә юлыгып «тамгаланган» һәм шигырьләренә карата тик тискәре генә мөнәсәбәт булган Зариф Бәшири кебек шагыйрьләр дә кайтып, әлеге мәҗмугаларда (З.Рәмиев, Ф.Яхин төзегән китапларда) шигырьләре дә мулдан бирелеп, иҗатларын яңача бәяләргә мөмкинлек туды бугай.




Шунсын да әйтик: Тукайдан соңгы йөз елда шигъриятебез бик күп яңа исемнәргә баеса да, талантлы шагыйрьләр өстәлеп торса да, бер нәрсә бәхәссез: Тукай биеклеге һәм бөеклеге һаман «үсә», ачыла гына бара! Һәм гаҗәбе шул: Тукаебыз «үскән», биегәйгән саен, замандаш шагыйрьләренә, хәтта каләменә, тәнкыйтенә эләккәннәргә дә игътибар арта, алар кызыклырак, хәтта калкурак та күренә. Шуңа да аларны аерым-аерым өйрәнү, бүгенгедән торып иҗатларына яңача караш та сорала, мөгаен...

Гел-гел лилипутлар арасында «кылыч айкаган ялгыз Гулливер» булмаган лабаса Тукай: янәшәсендә Дәрдемәнд, С.Рәмиев кебек «дәү»ләр дә булган, алар белән дә, үзе әйткәнчә, «чәкәләшеп алган» ул. Кая инде ул 18-19 яшьлек, кичәге «Мөхәммәдия» шәкерте, Оренбургка китеп, «Шура»ларга «борныны тыгып», «Чүкеч»тә Тукайга каршы төрле тупас

язмалар чыгарган Зариф Бәшири белән санашу! Шәхси мөнәсәбәтләр ачыклауга да көчә алар — әле күптән түгел матбугатка бөтенләй белмәгән, яна гына газета-журналларга «тиенеп», кинәт кенә бәхет килгән бу каләмнәр — сүз мәйданын үзләренең зәвкы-холкына карап та файдаланмаганмыни? Каян килсен әле кичә генә «фикердә коллык жебен» өзгән яшь талантларга каләм этикасы, матбугат әдәбе? Төрле шәһәрләр, милли учаклар, матбугат тирәсендә дә үзара «тел ярышы» (Тукайча — «тиле ярыш»!) гына булмыйча, үзара көрәш, карашлар, максатлар сугышы булмаганмы? Шул чорның кайсы әдибен генә алып карама, публицистикасы үзара «сүгешү»дән башка булмаган икән, дисең. Хәтта, Ф.Кәрими, Г.Исхакый, Һ.Максуди, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимовлар эшчәнлегендә бу шулай... Ә Тукаебыз инде әлеге мәсьәләдә иң аяусыз һөжү остасы: ул аткан «ук»ларның жәрәхәте йөз елдан соң да төзәлмәгән — менә нинди ул әдәби сүз көче!

Менә шул сүз көченә юлыгасын, язмышында нинди роль уйныйсын яшь, дуамал, үзенчә горур Бәшири аңлап та бетермәгәндер әле... Аңлаганда инде соң була, мөгаен... Башка чорлар килә, яңа кешеләр, яңа карашлар... Сөрген, төрмәләр чоры...

Юк, Зариф Бәшири ижаты да онытылмады. Әле искә алынган антологияләрдәге шактый мул шигырьләре белән бергә, соңгы елларда «Идел» журналында атаклы «Чуваш кызы Әнисә» повесте, «Безнең мирас»та — «Мишәрләр» исемле этнографик язмасы басылып чыкты. Мәзкүр «Әнисә»се узган елда гына чуваш шагыйре В.Тургай тәржемәсендә чувашча (һәм татарчасы — бергә!) Чебоксарда чыкты; «Казан утлары» журналында режиссёр-әдип Ә.Зариповның З.Бәшири белән очрашуы, аның ижади язмышы, Г.Тукай белән мөнәсәбәтләре турындагы истәлек-уйланулар характерындагы язмасы басылды. Шулай ук әдипнең ижатына багышланган диссертация язып, С.Галимов аны Казанда уңышлы яклады да...

Ниһаять, узган ел ахырында Татарстан китап нәшрияты З.Бәширинең шактый калын, каты тышлыкта, затлы эшләнештәге «Сайланма әсәрләр»ен бастырып чыгарды (истәлекләр, бәян, публицистик язмалар, туган телгә багышланган ике шигырь). 430 битле бу китапның төзүчесе, кереш сүз («Бәхетсез почмак әсире»... Бу да — Тукаебыз гыйбарәсе!) — кыска, әмма шактый мәгълүмат, фикер сыйдырган, үткен, шагыйранә каләм белән язылган мәкалә авторы — шагыйребез Ркаил Зәйдулла икән. Ул — З.Бәширигә туган да тиешле — үзендәге кинлек, ижат холкы — өслүбе дә шул кайнар «кан»ның дәвамы түгелме икән, дип уйлап та куясың. З.Бәширинен сенлесе булган «ерак әбисе» әйткәндәй, даулы, шаулы шагыйрьлек шаукымы да: «Зариф агайдан инде бу, шунардан»! Чынлап та, 1888 елда Буа өязе Чүти авылында (атаклы Шәкүр Рәхимов та шуннан) туып, катлаулы озын гомер, аннан да бигрәк каршылыклы ижат юлы үткән З.Бәшири Уфада, нәкъ Ркаилебез туган 1962 елда вафат була; үзенең теләге буенча, бик ихтирам иткән замандашы, шагыйрь С.Рәмиев кабере янәшәсендә күмелә. Туксанынчы еллар башында яшь галимә Ч.Зариф белән без С.Рәмиев мәркаден З.Бәшири кабере янында икәнен белеп, шактый озак эзләп тапкан да идек. Уфаның тау башындагы мөселман зиратында, шагыйрьләр язмышын уйлап, озак тын торган идек. 1959-1961 елларда Уфада университетта укыган шәкерт чорымда әдәбиятка, Тукайга гашыйк мин — малай З.Бәширинең озак еллардан соң 1959 елда Казанда басылган юка «сайланма»сына да юлыккан идем. Башта көлеп кенә куйганым истә: янәсе, йә ни генә яза алсын инде ул «ямьсез мыраулаган», «Шура»ларга «борныны тыккан» Бәшири? Кем инде ул безгә бүген? Шәригем, элеккеге офицер, аннан «Кызыл тан» газетасында эшләгән, соңлап кына студент булган язучы Вазыйх Исхаков мине иплән кенә үгетли иде:

— Алай жинел генә карама син. Башта чоры белән бәйләп өйрән, укы... Объектив фикер йөртергә өйрән, бу сиңа киләчәктә дә кирәк булыр, — дип әйтә иде, тиздән Казаннарга таба кузгаласымны алдан белгәндәй. Өлкән дустым, әлбәттә, хаклы булган! «Сайланма»дагы шигырьләргә артык мөкиббән булмасам да (яна гына «ачкан» Бабич, Туфаннар белән шашкан, хыял күкләренә ашкан чак бит!), китаптагы «Чуваш кызы Әнисә»не бик яраттым. Гасыр башы язысы — яшь егетнең рухи үсешкә омтылышлары да, эзләнү, мәхәббәте, кардәш халыкларга мөнәсәбәте дә күңелемдә онытылмаслык эз калдырды. Бүген дә

фикерем шул: егерменче гасыр башы прозасының күренекле әсәрләреннән берсе ул! Һәм әдип иҗатында да бер биеклек үрнәге, дияр идем. Хуш, ә үзен, әле Уфада яшәгән исән әдипне нигә барып күрмәдем икән? Әнә бит, үзе язганча, Казаннан килгән студент егет, соңыннан олуг галимебез булачак Миркасыйм Госманов та З.Бәширине эзләп, Уфаның дәвамы Черниковскийга кадәр бара, торган җирен дә табып, аны күреп кайта. Кайчандыр, гасыр башында, Кытай чигендәге Капал дигән казакъ шәһәрендәге мәктәптә аның әнисе Гөлҗиһанны нәкъ менә З.Бәшири укыткан икән. Һәм аны, нәкъ илле елдан соң! — бүгенгедәй хәтерли дә булып чыга карт әдип. «Бәләкәй генә бабай кисәге»нең хәтеренә шакката Миркасыйм. Шулай, бу хәтер сарае кемнәрне генә сыйдырмаган да, нинди генә җирләрдә кайсы гына замандашлары үзенең эзен, истәлекләрен калдырмаган әдип күңелендә. Ә бит Капалдан башка, күпме мишәр авыллары, чуваш «пиччә»ләре, Оренбург, Алматы, Ташкент, Сәмәркандларда, Донбасста күпме булган ул эшләгән редакцияләр — татар, башкорт, казакъ, үзбәк, уйгыр халыклары вәкилләре белән бергә ул хезмәт иткән газета-журналлар, институтлар үз чорының күренекле вәкилләре белән күпме очрашулар, әңгәмәләр, бәхәсләр — З.Бәшири тормышында. Дәрдемәнд, Исхакый, Тукай, С.Рәмиев, Максудилар, Шәрәфләр, Гафури, Камаллар, Думави, Сүнчәләй, Мотыйгый һ.б. бик күпләр! Шуңа күрә ул язган мемуарлар китабын егерменче гасыр татар зыялылары тормышыннан мавыктыргыч, төрле персонажларга бай роман кебек укыйсың да.

Нәкъ менә Сәйфи ага Кудашның «Хәтердә калган минутлар» китабындагы кебек! Ул китапны искә алуның тагын бер ягы бар: анда 1916 елда бер төркем татар шагыйрьләренең Уфада очрашып, төшкән фоторәсеме дә бар: М.Гафури, С.Рәмиев, С.Сүнчәләй, Н.Думави һәм З.Бәшири... Китаптагы ул рәсемне университет буенча остазым — иске төрки тел укытучысы Закир ага Шакиров (тумышы буенча безнең күрше Карача-елга авылы кешесе. Аның улы Мидхәт Шакиров Башкортстан обкомының беренче секретаре булды... Аларның Уфадагы йортында бүген Башкортстан Язучылар союзы урнашкан — Тукай һәм Бабич турында истәлекләр сөйләвен сорап, Закир ага янына, шул йортка баруым иде. Нинди әрсезлек, ә?!) белән бергә карагач: «Кара инде, басып торганы Бәшири бит! Нинди көяз, мәһабәт... Хәзер бер бөтәшкән карт инде ул», — дигәне истә. Үзе озын буйлы, чал мыеклы матур карт иде Закир агабыз... Сүз җаеннан: соңгы «сайланма»сында фотосурәтләр дә күп бирелгән. Үзенең дә ялгыз йә дуслары белән төшкәннәре. Шактый мәгърур, чая кыяфәтле аларда Зариф агай Бәшири. Холык, уҗәтлек кайда да чагыла шул. Шулай булмаса, утызынчы, кырыгынчы елларны, төрмә-сөргеннәрне үтеп, исән калыр һәм үз чорының, замандашларының портретын язарга алыныр идемени әдип?!

Китабының Гафури, Бабич турындагы бүлекләрен Уфада, «Агыйдел» журналында бастыра ул. Аннан, тәвәккәлләп, Казанга юл ала: 1961 елда нәшриятка тапшыра... һәм 1968 елда, кульъязмасы бик каты кыскартылып, күп бәхәсләрдән соң гына укучыга барып ирешә «Замандашларым белән очрашулар» китабы.

Бәширинең — «бәхетсез почмак әсире»нең кара бәхете инде бу — язмышы шундый, күрәсең. Китапны үзе күрә алмый әдип. Ә басылмый калган өлешләре кайда? Соңыннан керми калган ике бүлеген Л.Хәмидуллин нәшрият архивыннан табып ала (алар яңа басмага кертелгән), ә «төшерелгән» башка бүлекләр? Бүгенге укучы күзлегеннән караганда, китап бит, һичшиксез, үз чорының реаль панорамасын тудыра алган. Тукайның «кайсына биргән яшен кибриа» дигән юлларын бу урында мемуарлар авторына карата да әйтеп буладыр: әдипнең эрудициясендә, чын художникларча күзаллау-күрүенең киңлеген, күп төсләргә байлыгын, классика дип әйтерлек яхшы тел-өслүбен танымаска мөмкинме? Барсы да колоритлы, чын мәгънәсендәге зур шәхесләр һәм көрәшчеләребез, халыкны яшәтү уе белән янган фидаи затларыбыз, милләт хадимнәре урын алган анда. Һәм, шуны да әйтү кирәк: узган гасырда тоталитар система кушканча, шул чор «стиле»нә хас булганча, шәхесләребезне төрле сыйнфый бүленеш һәм социаль каршылыклар аша күрсәтү дә чагыла китапта, советча «сайрарга» тырышып, бөекләребезнең кимчелекле якларын калкытып кую да сизелә. Әмма сәнгатьчә

дөреслек үзенекен итә: әдипнең сүзләренә хилаф рәвештә вакыйгалар, реаль эшләр, документлар киресен сөйли башлый: әлеге алтын чорыбыз, татар рухи дөньясының иң асыл сәхифәләре мәйданга чыга. Алыйк Рәмиевләрнең милли матбугатка иткән игелекләрен йә Уфалы морза Жантуриннның асыл затларга хас тәрбияле, затлы мөгамәләсен, – әйе, булган шул чын мәгънәсендә меценатларыбыз! Мемуарлар авторы да бик яшьли зур кешеләр белән очрашып аралаша: мадьяр галиме Ю.Мессарош, чуваш Ашмарин белән әңгәмәләре һәм шулар нәтиҗәсе буларак, этнографик хезмәтләре, «Шура»да басылган мәкаләләре туа бит инде. З.Бәширинең уйгыр һәм үзбәк халыклары белән озак аралашулары да эзсез узмый: егерменче елларда әдипнең «Уйгыр әдәбияты», «Үзбәк әдәбияты» исемле китаплары дөнья күрә. Ташкентта яшәгән, үзбәк газеталарында эшләгәндә, ул Фитрәт, Чулпан кебек шул чорның үзбәк шагыйрьләрен дә тәрҗемә итә. Кызганыч, истәлекләрендә 1917 елдан алып, Төркестан, Үзбәкстан чорына караган сәхифәләр бик аз. Ә бит анда бик куәтле татар диаспорасы булган ул елларда. Ш.Әхмәдиев, Г.Акчурин кебек партия житәкчеләре, К.Бәкер, Ш.Мөхәммәдьяров кебек чын зыялылар, Г.Сәгъди кебек галимнәр дә яши, эшли анда. Ә Ташкентта иҗат канатларын кага башлаган яшь Такташ белән мөнәсәбәтләре? Берсен-берсе «плагиат»та гаепләп, әдәби судларга кадәр барып житүләр?! Болар турында, шул күп милли өметләр уяткан чор турында кемнәр язар хәзер? «Нишләрсен, татар, теленне алып, аузына башка бер телне тыксалар?» – шулай язган Гафури, узган йөздәге явыз Дума эшчәнлеген аңлап. Ярый әле безнең чор – бүгенге Думада андый омтылышлар юк шикелле? Әллә бармы? Аһ, хөрмәтле Гафури, Бәшири агаларыбыз! Сез бит, нәкъ Тукаебыз кебек үк, газиз әнкә теле өчен янып-көеп, аның өчен көрәшеп яшәгәнсез, язгансыз.

Үзара әйткәләшүләр, үпкә-сапкаларны онытып, милләтне саклау юлында янгансыз сез, изге бер мәйданга шул максат белән җыелгансыз да. Шуңа да З.Бәширинең бүгенге «Сайланма»сы да (редакторы Ф.Жамалетдиновага да рәхмәт!) туган телгә багышланган шигырь белән башланып, ахыры да шундый ук газиз телебезгә мәңгелек яшәү теләгән хитаб-шигырь белән тәмамлануы гаҗәпме? 2018 елда юбилее да көтелгән З.Бәширинең шигырьләреннән дә сайлап яхшы бер томлык әзерләп чыгарырга кирәк түгелме?

*Һәр хакыйкать дошманына карата*
*бу ялкын телем,*
*Хакны куйма, эзне җуйма, җан телем,*
*алтын телем.*

Шундый юлларны язган, шөбһәсез, шигырьдә Тукай мәктәбеннән исәпләнергә хаклы З. Бәшири иҗатына без дә эзне җуймабыз, шаять.

**Рәдиф ГАТАШ**

---

*Кайтаваз*


## Бәйрәм бүләге

Халкыбыз Бөек Җиңүнең 70 еллыгын зурлап билгеләп үтте. Язучы Айдар Хәлим дә бу бәйрәмгә зур бүләк әзерләде. Ул — әдипнең «Паравыз кычкыртты» дигән хикәясе. «Казан утлары» журналының әлеге әсәрне бастырып чыгаруы да (2нче сан, 2015 ел) бик вакытлы булды. Сугыш башланган көнне генә никахлашкан ике яшь йөрәк — Газинур белән Тәнзиләнең язмышы турында тетрәнеп, яу кырында башын салган Газинурларыбыз белән горурлану хисләре кичереп укыдым. Тирән эчтәлекле хикәя язуыгыз өчен рәхмәт Сезгә, Айдар әфәнде!

**Мансур ҖӘЛӘЛИЕВ.**
*Казан.*

# СУРӘТЛӘРДӘ — ТАРИХ...

«Идел суы ага торыр, дулкыннарын кага торыр...» Идел буенда күпме халыклар яшәгән-киткән, тарихында күпме данлы-шанлы яисә дәһшәтле вакыйгалар кабатланып торган — узган, күпме буыннар берсен-берсе алыштырган. Ә Идел ага да ага... Тик, заманалар үзгәргән саен, Идел дә үзгәрә. «Бер кергән суга янадан кереп булмый», — ди халык мәкале дә. Ага да китә ул. Ә аккан сулар кире кайтмый. Хәтердә генә янара.




Өлкәнрәк буынга Татарстан телевидениесе һәм радиосы дикторы буларак яхшы таныш, соңрак, Казаныбыз турындагы үзенчәлекле открыткаларны, фоторәсемнәрне туплап, шуларны төрле формаларда халыкка ирештерүче филокартист, хажи Абдулла Дубинның соңгы вакытта тагын бер мавыктыргыч фотоальбомы басылып чыкты. Монысы — Иделгә багышланган. Аккан сулар турында хатирәләр дә, аның бүгенгесе турында уйлану, киләчәге турында борчылу да бар анда. Дистә еллар буе зур иҗтиһад белән тупланган күпсанлы открыткалар, күргәзмә әсбап вазифасын үтәп, әнә шул чынбарлыкны торгыза.

Идел дельтасындагы Әстерхан шәһәрендә туып-үскән Абдулла Дубин бу хезмәте белән туган җиренең игелекле улы булуын раслый. «Идел кешеләренә, туган шәһәремә, бөек якташларыма, ата-анам каберләренә, укытучыларыма, остазларыма, дошманнарыма теземне чүгеп багышлыйм. Автор», — дип яза ул китабының титул битендә үк.

Китапка сүз башын күренекле язучы, Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил премияләре лауреаты Рафаэль Мостафин язып калдырган:

«Идел — Россиянең төп елгасы булса, әлеге тирән зәвык белән төзелгән альбом шулай ук төп нәрсә — илнең генә түгел, тулы бер чорның мөһим артериясе турында сөйли. Бөек Иделнең зәңгәр тегәрҗебе Рыбинск сазлыкларыннан башлап, Әстерхан дельтасына кадәр бөтен ил аша сызылып үтә. Һәм бу китапта Идел — гасырларны бәйләп торучы җеп хезмәтен үти. Монда вакыт сулышы яши».

Алда ук әйтелгәнчә, әлеге фотоальбом филокартистның беренче тәҗрибәсе түгел. Аңа кадәр Казанның әүвәлге һәм хәзерге күренешләрен тасвирлаган открыткалардан төрледән-төрле тупланмалар әзерләп чыгарды инде ул. 2003 елда «Тарихи Казан» дигән, өч телдә (татар, рус, инглиз) язылган күләмле альбомы дөнья күрә. Автор анда филокартист эшчәнлеге турында менә нинди мәгълүмат бирә: «Филокартия» термины грекча «яратам» һәм латинча «карта» дигән мәгънәдә янгырый. Открыткалар җыю, бер яктан, җанга ял бирсә, икенче яктан, кешене рухи яктан да баета дип әйтсәк, һич ялгыш булмас. Филокартистның эшчәнлеге өч баскычтан гыйбарәт: беренчесе — материал туплау, икенчесе — аларны эзлекле бер системага салу, тәртипкә китерү һәм саклау, өченчесе — коллекция җәмгыятькә хезмәт итәргә тиеш. Әйе, бу купшы сүзләр түгел. Открыткалар коллекциясе, чыннан да, җәмгыятькә хезмәт итә ала».

Димәк, Абдулла Дубинның китабы — гади фотоальбом гына түгел, ул открыткаларда, фоторәсемнәрдә җанлы тарихның җуелмас эзе калган. Бу яңа альбом «Иске Идел» («Старая Волга») дип аталса да, анда Иделнең бүгенгесе, киләчәге турында тирән борчылу бар. «Уйлап тормыйча, борттан томырылган миллионнарча тәмәке төпчекләре, тонналаган кер порошоклары белән аралашкан көнкүреш һәм сәнәгать калдыклары елганың «сәламәтлеген» кискен какшата, әлегә исән булган җан ияләрен җитди авыруларга дучар итә. Чыннан да: «Тәкермә коега!..» — дип сыкрана автор.

«Идел — бөек рус елгасы» дигән

гыйбарәне кайсыбыз гына ишетмәгән. (Сүз унаеннан, альбомның монысы рус телендә.) Фотоальбомдагы открыткалар белән танышканда да бу сүзләр кабат-кабат хәтердә янара. Автор белдерүенчә, беренче почта открыткалары Россиядә 1895 елда пәйда булган дип исәпләсәк, ул чакларда безнең татарлар, мәсәлән, Явыз Иван фәрманы буенча, зур елгалардан ким дигәндә кырык чакрым ераклыкка сөрелеп гомер кичергән шул. Кая анда тарихи открыткаларда эз калдыру! Шулай да альбомның 13нче битендә искиткеч гүзәл Тверь мәчете төшерелгән открыткага юлыгабыз. Әстерханда чыккан открыткаларда исә кыргыз карты, кыргыз кызы, фарсы йөкчеләре, атларга атланган калмык кызлары-егетләре дә күренә. Гаиләләре белән махсус фото-остаханәләргә барып, бәйрәмчә киемнәрдән рәсемгә төшүчеләрнең сурәтләре сокландыра. Патша гаиләсе әгъзалары исемнәрен йөрткән пароходларда сәяхәт итүче аксөяк затлардан башлап, Идел бурлакларына кадәр шушы альбомда бер-бер артлы тезелеп, укучыны (караучыны) ерак елларда калган хыял илләрендә гиздерә.

Әйе, җир йөзендә бер әйбер дә мәңгелек түгел. Табигать-анабыз тудырган матурлыкларның фото-сурәтләрдә теркәлеп калуы киләчәк буын өчен дә олы ядкарь.

Открыткаларны, карталарны, мәгълүматларны эзләп табу, туплау авырлыкларын һәм сөенечләрен альбомның авторы үзе генә беләдер. Әмма танышларына-дусларына төрледән-төрле открыткаларын, календарьларын истәлеккә тапшырганда, Абдулла абыйның яратып әйтә торган бер сүзе бар: «Алу — бәхет түгел, бирү — бәхет», — ди ул. Бу фотоальбомын дөньяга чыгарып, кызыксынучан укучыга тапшыруы аны тагын бер кат бәхетле иткәндер. Һичшиксез, шулай!

**Фәйрүзә МӨСЛИМОВА**

---

*Котлыйбыз!*

## Вакыйф Нуруллинга 80 яшь

1935 елның 1 маенда Татарстанның Балык Бистәсе районы Югары Әшнәк авылында туа. Башлангыч мәктәпне тәмамлагач, ул бер ел колхозда эшли, аннан җидееллык мәктәпне һәм Олы Солтан авылындагы урта мәктәпне тәмамлый. 1954-1957 елларда армия хезмәтендә булып кайткач, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1961 елны, университетның соңгы курсында укыганда, «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясенә эшкә алына һәм 1977 елның июненә кадәр анда башта — хатлар бүлегендә әдәби хезмәткәр, аннан проза бүлеге мөдире булып хезмәт итә.



Вакыйф Нуруллин — 60нчы еллар башында әдәбият мәйданына чыккан һәм үзенчәлекле әсәрләре белән танылган язучыларның берсе. Шул чорда аның бер төркем хикәяләре басыла. 1964-1966 елларда үзенең беренче күләмле әсәрен — «Шинельсез солдатлар» исемле повестен яза. 1968 елда повесть «Казан утлары» журналында, аннары шул ук елны аерым китап булып басылып чыга. Сугыштан соңгы авыл тормышына багышланган һәм колхоз җитәкчесенең үзенчәлекле образын тудырган «Күпер чыкканда» (1968-1969) исемле икенче повесте да авторга уңыш китерә.

Җитмешенче еллар дәвамында В.Нуруллин, үз иҗатының төп тематик юнәлешен үстерә барып, «Әгәр син булмасаң» (1970-1973), «Аккан су юлын табар» (1978) повестьларын һәм «Яшьнәп үткән яшьлек» (1971-1975) исемле документаль әсәрен яза.

В.Нуруллинның язу стиле халыкчан гадилеге, эчке җылылыгы, ихласлыгы белән аерылып тора. Ул, әдәби иҗат эшеннән тыш, җәмәгать эшенә актив катнаша: Татарстан Язучылары берлегенең партия оешмасында өч ел рәттән (1974-1977) секретарь вазифасын үти, Казан шәһәр советына депутат итеп сайлана.

1972 елда аңа «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә.



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Зәки НУРИ**

## Көлдермәсә...

— Юмористтан көлке шигырь алып кайттым,
Юмор дигәч, ышандым бит, юләрмен мин:
Кил янымa, кил, кытыкла әле, хатын,
Укыганда, бәлки, бераз көләрмен мин.

## «Дан иясе»

— Менә шунда миңа һәйкәл куеп,
Төрле якка сукмак сузарлар.
Кешеләр килер, алар бер-берсеннән:
— Бу кем? — диеп сорап узарлар.

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

*Ркаил Зәйдуллага*

Дрессировщик! Син алай ук узынмачы,
«Мин йөрәкле», — дигән булып түш киермә,
«Мин циркта юлбарысны йөгәнлим», дип,
«Сез куркак», — дип шагыйрьләргә тел тидермә.

Арысланның авызына башны тыгу —
Шул да булдымы геройлык, и бичара.
Батыр булсаң, аек баштан, Ркаилдәй,
Театрда Президентны кочып кара!

**Рафаэль ХӘКИМ**

## Милләтче түгел

Мәскәүнең милли идея табасы килеп бәргәләнгән елларында Россия Федерациясендә безнең республиканың вәкаләтле вәкиле булып Назиф Мириханов эшләде. «Яңа идея» тирәсендә шаулаша башлауга, Мириханов дәррәү күтәрелеп каршы чыга, газеталарда кайнар мәкаләләр бастыра, радио-телевидениедән чыгышлар ясый, төрле инстанцияләргә, хәтта Россия Президенты аппаратына да, бу идеяне фаш итеп хатлар җибәрә. «Сезнең вәкаләтле вәкилегез — милләтче», — дип безгә югары даирәләрдән кисәтүле хатлар килә тора.

Бервакыт шылтырата бу мина:

— Ишеткәсендер, Куликово кырындагы сугышны искә алуны бөтенроссия милли бәйрәме итмәкчеләр. Русны татарга каршы котырталар. Моны рус коралынын татарны җиңүе дип буламыни?! Шулай бит?

— Килешәм синең белән. Алтын Урда эчендә барган үзара чәкәшеп алу гына бу. Туктамыш ханнын бердәме буларак, Дмитрий Донскойнын Мамайга каршы күтәрелүен купайтырга тырышу. Тарихчылар өчен бар да ачык.

Мириханов тагын да саллырак, тагын да кыюрак язмаларын бастыра башлый. Россия Президенты аппаратыннан: «Тыегыз бу милләтчегезне!» — дип усал тонлы хат килеп төшә. Аппарат җитәкчесе Әгъзам Самат улы, түземе бетеп, жалоба белән Президентка керә.

Мирихановнын «гөнаһлары» турында Минтимер Шәймиев сабыр гына тыңлый да гадилеге белән бөек фикер әйтә:

— Милләтче түгел ул, үзе шундый...

**Гараф ФӘХРЕТДИНОВ**

## Мулла

### *(нимес әсирлегендә күргәннәрдән)*

Беркөнне полицай Волков барыбызны да сафларга тезде дә көтелмәгән сорау бирде:

— Арагызда мулла бармы?

Каккан казыктай катып калдык. Саташамы бу әллә?.. Монда күбесе социализм төзегән яшьләр, нинди мулла булырга мөмкин?

Теге нәләтнең тавышы тагын да катырак яңгырады:

— Кем мулла, ике адым алга, марш!

Сафлар дәшми, бер-беребезгә аптырап карашабыз. Дустым Хәйдәр колагыма жуылдый:

— Димка, син сказкаларны яхшы сөйлисең, может, азанны да беләсең? Вота ул чакта ашап күрсәтер иек, муллага өстәмә пурсы бирәчәк тә бирәчәк инде...

— Кем вакытлыча мулла эшен башкара ала?!

Шул мәлдә тоттым да алга чыгып бастым. Сәләмә киемнән, яланаяк, кыяр түтәлендәге карачкы сыман басып торам. Кара күн перчаткалы, камчылы нимес офицеры, җир кортына караган шикелле чирканып кына мина күз атып, полицайга нидер мыгырдады. Полицай әшәке калын иренен җәеп елмайды да мина дәште:

— Син чынлап та мулламы, дога укып күрсәт әле!

— Мин мулла түгел, әмма мулла укыган чаклы гына булдырам, — дидем һәм шикләнеп тә куйдым. Әгәр бу җүнсез бәндә Коръәнне белсә. Әнә нимес тә камчы сабын елтыр итек кунычына суккалый башлады. Рәт-рәт тезелгән әсирләр тын да алмый карап торалар. Дустым Хәйдәрнең карашы «бетерделәр малайны...» дигән шикелле кызганулы... Шалишь, брат! Әнкәй мине малай чагымнан ук күп нәрсәгә өйрәтте. Кирәге булмады тормышта, ләкин аз-маз булса да кайбер догалар истә калган. Нишләп әле мин бу мокытлардан куркып торам? Боларнын берсе дә гарәп телен белми ич. Мин үзем дә укыганымның нәрсә аңлатканын белмим... Маршировкаларда җырлап чарланган көчле тавышым белән укып җибәрдем, агай...

— Бисмил-лаһир-рахманир-рахим. Әл-хәмдү лил-ла-һи Раббил галәмин. Ир-рахманир-рахим. Малики яу-миддин. Иййакә нәгъбүдү вә иййакә нәстәгыйн. Иһдин әс-сирател мөстәкыйм...

Полицай авызын ачкан, нимеснең күзе челт-челт йомыла, әсирләр чүгеп калды. Шулай бер-бер артлы укыйм белгән догаларымны, әмма белүем чамалы гына. Полицай тагын, тагын укуымны сорый, нишләргә, белмим дип, туктап калуы да уңайсыз... Әһә... Туктап калырга ярамый, мин сүзләрен үзем дә аңлап бетермәгән төрле сүрәләрдән алынган өзекләрне тезәм генә...

— Әл-хәмду лил-ләhи раббил гәләмин. Әр-рахманир рахим. Сталин үмер, Гитлер карт мөртәтин, — дип, кулны кушырып күтәрдем, әлбәттә, соңгы юлларны авыз эченнән мыгырданыбрак тәгәлләдем, шулай итеп, «Аллаhу әкбәр», дип амин тотам, йөзләгән әсирләр дә миннән күрмәкче, кулларын күтәреп амин тоталар. Бу мәрәкә тәмам булгач, полицай, нимес офицерына борылып, алман телендә нидер ләңгелдәде дә, безнең якка карап:

— Бүгеннән башлап менә бу (миңа төртеп күрсәтә) мулла булыр. Үзенә ярдәмче ал. Баланда аңа ике порция бирелергә тиеш.

Соңыннан мин Хәйдәр янына килеп:

— Син минем ярдәмчем булырсың, — дидем. Мишәрем күзләрен тасрайтып карады да:

— Ананны орган нәрсә! Азанчы икәненне белгән булсам, якын да килмәгән булыр идем! — дип ярып салды.

— Авызыңны яп! — дим тегеңә. — Мулла абзаң белән әдәпле генә сөйләш... Баланданы кешеләрдән күбрәк ашап, аякка баскач, моннан тайганда, миңа рәхмәт әйтерсең әле...

Хәйдәрем бу сүзләрдән соң йомшап калды.

Иртәнге намазга соңга калынган. Монда бит әтәчләр кычкырып уятмый, каян беләсең вакытны? Барактан чыктым да нидән башларга белмичә торам. Кран янына килеп, үземчә тәhарәт алган булдым. Башка әсирләр дә нәкъ минемчә кыланалар. Шуннан соң мин ташландык бина түбәсенә мендем дә көйләп жибәрдем:

— Аллаhу әкбәр... Аллаhу әкбәр... Әшhәду әл-лә иләhә илләллаhү...

Түбәнгә карыйм: йөзләрчә әсирләр, учларын кушырып, авызларын кыймылдатып нидер укыган булалар. И Хода бәндәләре, болар кичәге коммунизм төзүчеләр бит инде, югыйсә...

**Илдус ГЫЙЛӘЖЕВ**

## Таба алсалар

Археолог казып чыгаргач та,
Җайлы булсын танып алырга:
Жиде теше исән баш сөяге
Минеке ул, әйтеп калдырам.

## Бездәйләргә тәтемәс

Урак-чүкеч төшкән орденым бар,
Тырыш хезмәт өчен бирделәр.
Егетлекнең күрке иде элек
Түшкә таккан затлы билгеләр.

Тәкъдим итсәләр дә, бүген алмам
Дәрәҗәле дәүләт бүләген,
Йодрык зурлык тәре, ике башлы
Кошны күтәралмас күкрәгем.

«Гафу итегез», — дип баш тартырмын,
Мин мөселман, шуны белсеннәр.
Әй хыялый... мондый фикер белән
Кемнәр сиңа медаль бирсеннәр?!

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу — безнең сәхифә!

# РӨСТӘМ МАҖАРАЛАРЫ

### Әби әкияте

Моннан берничә ай элек, кышкы салкын көннәрнең берсендә, Казанга Рөстәмнең әбисе килде. Аның килүен Рөстәм түземсезләнеп көтте. Кадерле кунакның кайчан килергә җыенуын ишеткәч тә, Рөстәм календарьда билге ясап куйды һәм көн саен иртә белән:

— Тагын биш кенә көн калды, тагын дүрт кенә көн калды! — дип әйтә торды.

Әби календарьда билгеләнгән вакыттан бер көн элек килде. Рөстәм моңа шатланды да. Әбисен ул каршы чыгып алырга теләгән иде. Ә әби Рөстәм югында, Рөстәм кинода чакта килеп төште.

Әби аңа ап-ак җылы оеклар, ап-ак җылы киез итекләр, куян тиресеннән тегелгән ап-ак бүрек, ап-ак бияләйләр һәм бик күп итеп чикләвек алып килгән иде.

Шәфкатьле әбисен Рөстәм элек тә күргән иде. Үткән елны ул бөтен җәйне аның белән бергә авылда уздырды. Ләкин ул чакта әби дә, Рөстәм үзе дә әллә ничек бер-берсен аңламыйлар, сөйләргә сүз тапмыйлар иде. Ә хәзер... хәзер бөтенләй башка... Рөстәм дәресләрен хәзерләп бетерүгә, әби аңа һәр кич төрле-төрле көйләр җырлап җибәрә. Рөстәм башта әбинең җырлау рәвешен генә ярата иде, хәзер, иялəшкәч, аның көйләрен дә ярата. Моңлы итеп җырлый ул!

Шундый күңелле әбиеңне ничек яратмыйсың ди. Ярата, бик ярата Рөстәм аны! Ашка яки чәйгә утырганда, Гайшә апа беренче тәлинкәне, беренче чынаякны балага куя иде.

— Әбигә, әүвәл әбигә! — дип кычкыра башлады Рөстәм. Ярата, бик ярата Рөстәм аны! Хәтта ул мәктәп буфетыннан алынган конфет, прәннекләрдән да аңа өлеш чыгара. Ә әкиятләре ни тора әбинең! Нинди матур сөйли ул аларны... Тыңлап туйгысыз! Андый әкиятләрне Рөстәмнең китапларда да укыганы юк әле.

Кышкы кичләрнең берсе иде. Гайшә апа белән Һашим абый Академия театрына спектакль карарга киттеләр. Өйдә Рөстәм белән әби генә калды. Шул кичне Рөстәм яңа әкият тыңлады. Әби аны бик тәмләп, бик озын итеп сөйләде. Аның кыскача эчтәлеге менә болай иде:

Абага — карап торырга гап-гади үсемлек. Исе дисәң — хуш исе юк, яфрагы дисәң — яфрагы да әллә ни түгел. Ләкин шул абаганың искиткеч бер хикмәте бар. Абага чәчәк атмый, диләр. Ялганлыйлар! Ата икән. Мең вә миллион абагалар арасында бер абага очрый ди, менә шушы күп абагалардан сирәк очрый торганы яз көне, җиде төн уртасында, ике-өч секундка чәчәк ата ди. Ул чәчәк атканда, яшен яшьни, күк күкри, җен-пәриләр чыга, кара урман яктыра ди. Бу вакыт абага шундый матур була, ди, аның йолдызлардай атып торган чәчәкләреннән күзләр чагыла, ди, аннан таралган хуш истән башлар әйләнә ди.

Абага чәчәген өзеп, телләре астына кыстырырга өлгергән кешеләр кеше күзенә күренмәс хәлгә киләләр ди. Дөньяда тереклек булганнан бирле, тылсымлы абага чәчәген өзеп, кеше күзенә күренмичә йөрергә теләүчеләр бихисап күп булган ди. Ләкин андый абаганы табуы кыен икән. Кайберәүләр,

*Дәвамы. Башы узган санда.*

илдән илгә йөреп, бөтен гомерләрен әнә шундый абаганы эзләп уздырганнар. Әмма юкка: йә таба алмаганнар, йә аның чәчәк аткан вакытына туры килмәгәннәр, йә чәчәк аткан чакта яшен яшьнәүдән, күк күкрәүдән, җенпәриләрдән куркып, яктылык нурлары сугудан үлгәннәр.

Менә шуннан соң кешеләр абагадан ваз кичкәннәр, абага чәчәк атмый, дип йөри башлаганнар. Әмма ул чәчәк ата икән. Бары тик аның ату вакытын туры китерерлек бәхетле, аның чәчәген курыкмыйча өзә алырлык батыр йөрәкле кеше генә юк, дисәм, хата булыр... Борын-борын заманда андый бәхетле, андый гайрәтле бер кеше булган икән ди. Ул бихисап вакыт кеше күзенә күренмичә йөргән ди...

Их, менә хәзер булсын иде ул кеше! Адәм ашаучы фашистларны берәмберәм тотып ярсын иде ул кеше.

Шуннан соң әби Рөстәмгә абага чәчәген өзә алган батыр тузында әкият сөйләде. Ай арты ай узды, әби авылга кайтып китте. Ә аның абага турындагы әкияте мәңге онытылмаслык булып Рөстәмнең хәтерендә калды.

## Яз җиткәч

Абага турындагы әкият Рөстәмнең холкын да, тормышын да бөтенләй үзгәртеп җибәрде. Әкият аңа шулчаклы нык тәэсир итте ки, ул гел шул хакта гына уйлап йөри башлады. Аның абага чәчәген өзеп алырлык батыр буласы килде. Ул элек тә күп укый иде, хәзер исә китапка тагын да ныграк ябышты. Китапханәгә китаплар алмаштырырга барса, аның үтенеп сораганы бер генә булды: батырлар турындагы, табигать турындагы китап. Калын-калын романнарны укып чыкты ул. Робинзоннар, юлбарыс тиресе кигән витязьлар, үз йөрәген факел иткән Данколар, Әбүгалисиналар, диңгез асларында йөзгән капитаннар, айга очкан инженерлар, кеше күзенә күренмичә йөргән химиклар турында нинди генә романнар укымады ул! Ләкин маҗаралары белән баш әйләндергән иң кызыклы китаплар да абаганы истән чыгара алмадылар. Киресенчә, яхшы әсәр укыган саен, абага тагын да тирәнрәк, тагын да көчлерәк дулкынландырды аны. Хәтта төшенә дә керә башлады ул. Абага чәчәге турында хыялланып йөри-йөри, Рөстәм үзен фронтта, сугыш мәйданында итеп хис кылды һәм язны көтте.

Яз җиту белән, Рөстәм бакчаларга, урманнарга, рус, татар каберлекләренә йөри башлады. Шул ук вакытта ул үз-үзен курыкмаска да өйрәтте. Ата-анасы элек аны өйдә ялгызы гына калдырмыйлар иде. Театрга йә җыелышка китә калсалар, өй сакларга Рөстәм янына кеше чакыралар иде. Рөстәм үзе дә шуны тели иде. Тора-бара ул бөтенләй курыкмый башлады. Әти-әнисе кич белән кая да булса китәргә җыенсалар, берәүне дә чакырмагыз, үзем генә калам дияргә өйрәнде.

Ул, өйдә япа-ялгыз калып, үзенчә күнегүләр ясады. Утларны сүндереп, сәгатьләр буенча караңгыда утырды, төн уртасында ишегалдына чыгып торды.

Май башында әби кунакка килде. Әбине күреп алу белән, Рөстәм «бәхетем килде» дип уйлады. Шатлыгына чик юк иде аның.

Май ае уртасы иде. Рөстәм урманга китте. Ул анда җир астыннан бәреп чыккан ямь-яшел хәтфә үләннәргә сокланып карап йөрде; кыш көне туңып, яз көне яңадан терелә башлаган урманның сулыш алуын тыңлады. Ул икенче көнне дә кич белән урманга барды. Яшел чирәмгә ятып, күкне күзәтте: кояш баюына карап моңланды. Эңгер-меңгер вакыт җитте. Ләкин Рөстәм кайтмады: үзенең курку-курыкмавын сынарга теләп, тәмам караңгы төшкәнче урманда йөрде һәм, курыкса да курыкмаска тырышып, бу беренче сынауны яхшы уздырды.

Абага чәчәге турында хыяллану Рөстәмне ялгызлыкка өйрәтте. Әмма дәресләренә зарар китермәде ул: элеккечә тырышып укыды, алдынгы укучылар рәтендә барды. Бары тик дус-ишләре белән генә сирәк очраша торган булды. Берәрсе урамга уйнарга чакырса, олыларча:

— Уйнаудамыни хәзер баш! Күрәсең ич, сугыш... Муеннан эш. Юк, бара алмыйм, — дип җавап кайтара иде.

Агачлар күптән яфрак ярдылар. Дөньяга хуш ис, яз исе җәелде. Үсемлекләр кояшка карап чәчәк атарга әзерләнделәр. Шәһәрдә кошлар сайравы ешайды.

— Ашыгырга кирәк! — диде Рөстәм үз-үзенә. Рөстәм төн уздырырга урманга китте. Моңа ул берничә көн алдан әзерләнде. Аның кесәсендә кайралган үткен пәке, бер сызуда кабына торган чакма ташы, алдан ук агач төбенә илтеп күмелгән сохариларының калган кисәкләре һәм кружкасы бар.

Ул, әллә үзен гаепле санаганга, әллә булачак вакыйгаларны сизгәнгә, соңгы көннәрдә үзен авыру баладай назлы тотты. Китәсе көнне таңда ук уянды. Аяк очларына гына басып, тышка чыкты, битен юды, өс-башын киенеп, дәресләрен карарга утырды.

— Нишләп бик иртә тордың, улым? — Ананың ягымлы тавышы аның уйларын бүлде.

— Йокым туйды, әнкәй. Әткәйне уятыйммы? Сәгать җиде инде.

— Уят, улым, уят.

Рөстәм әтисен уятты, электр плитәсенә чәйнек куйды, куанычлы хәбәрләр булмасмы дип радионы җибәрде. Яңадан әтисе янына килеп, аңа киенергә булышты. Күлмәк якасын рәтләгән булып, әтисен кочаклады да, әнисе янына йөгереп килде һәм гаепле бала сыман, ояла-ояла, аны сөяргә кереште.

Гайшә апа:

— Авырыйсыңмы әллә, улым? Йөзләрең никтер кызарган, — дип, аның маңгаеннан үпте, күкрәгенә кысып сөйде.

Рөстәм мәктәпкә әтисе белән бергә чыгып китте. Алар артыннан ишек бикләргә чыккан әбигә ул яңагын сузды һәм:

— Әбекәй, уңыш теләп үп мине! — диде.

Урам чатында ул әтисеннән аерылды, ләкин мәктәпкә таба борылмады, эре-эре атлап, урман ягына юнәлде.

## Урманда

Яз көне сез урманда булсагыз иде, хозур кылып шунда йөрсәгез иде! Рәсәй урманнарының үзләренә хас хуш исе һәм матурлыклары бар. Авыз тутырып, тулы тавыш белән «һу-һу-һәй!» дип бер кычкыруы ни тора!

Карлар күптән эреп беткән, агачлар күптән яфрак ярганнар, аяк астын котырып үскән куе үлән каплаган. Җилдә җилфердәгән ефәк шәл чукларыдай, яшь яфраклар арасында иртәнге кояш нурлары уйныйлар. Дөньяга сулап туйгысыз татлы һава, иснәп туйгысыз ямь тарала. Дөнья керен әле күрергә өлгермәгән ямь-яшел яфраклар акрын тирбәлеп баш ияләр, әйтерсең лә алар кояшка җыр җырлыйлар. Табигать җырчылары — сандугачлар сайравы ишетелә. «Яшәү никадәр гүзәл!» дигән сыман, алар илаһи бер моң белән язны каршылыйлар, табигатьне яшәртүче кояшка һәм язга мәхәббәт укыйлар.

Рөстәм башта, ни өчен килгәнен онытып, матурлыкка, сандугачлар сайравына хәйран калып, «һу-һу-һәй!» дип, урман яңгыратты. Рус теле укытучысы кичә генә Брянск урманнары турында сөйләгән иде. Андагы партизаннарның эшләре, тормышлары белән укучыларны таныштырган иде. Гитлерчылар сугыш ачмасалар, кешеләр табигать кочагында, менә шушындый гүзәллек диңгезендә нихәтле ләззәтләнерләр иде. Рөстәм дә һәр атна саен ата-анасы белән бергә урманда бәйрәм ясап йөрер иде. Ә хәзер нәрсә? Бөтен халык эштә. Урманда Рөстәмнән башка һичкемне күрмәссең... Сугыш шул, сугыш!

Сугыш турында уйлау абага чәчәген хәтерләтте. Рөстәм агач ботагына букчасын элде һәм абагалар эзли башлады. Ул бик күп абага тапты. Ләкин кайсысы чәчәк ата аның?.. Менә монысымы, тегесеме, әллә әнә андагысымы? Шулай сайлап, эзләнеп йөри-йөри, Рөстәм кич җиткәнне сизми дә калды. Ул, арып, җиргә ятты — тәнгә салкын йөгерде. Димәк, болай ярамый, урын

хәзерләргә кирәк. Ул күп итеп үлән йолыкты, ботак-сыныклар җыйды һәм куе итеп үскән агач тармаклары арасында үзенә оя ясады.

— Менә шәп булды! — диде ул, шунда менеп. — Елан да чакмас, бүре дә тимәс, йокыга талып абага чәчәген дә күздән ычкындырмам.

Якында гына салкын чишмә бар иде. Рөстәм, шунда барып, туйганчы су эчте, сохари ашады һәм яңадан агач башына менеп утырды. Күзләре талганчы абагаларга карап торды. Кырын яткан урыны җайсыз булса да, үзен бишектәгедәй хис итте. Көчәйгән кичке җил аны тирбәлдерде, кошлар аңа бишек җыры көйләделәр. Көне буе йөреп арыды, күрәсең... Чүгез... Чү, кошлар!.. Тын кал... урман... туктагыз, җилләр, сез дә исмәгез!

Рөстәм йокыга талды.

Ләкин ул бик тиз уянды. Соңга калдым, ахры, дип ачуыннан еларга җитеште. Ашыга-ашыга агач башыннан сикереп төште. Эңгер-меңгер вакыты аңа сызыла-сызыла таң аткан күк тоелды. Урман караңгылыкка чумгач кына, ул бераз тыныч хәл алды.

Нәрсәдер кыштырдаган тавыш ишетелде, кемдер мышнаган төсле булды. Күзләргә, утлы күмердәй, яктылык чагылды, ул бер сүнде, кабынды, яңадан сүнде. Рөстәмне курку басты. Ул, үз-үзен тынычландырырга теләп, курыкмыйм, барыбер курыкмыйм, дип пышылдады, ә үзе, тотып алмасыннар дигәндәй, ашыгып-тырмашып, агач башына үрмәләде.

Рөстәм озак көтте, ләкин абага чәчәк атмады. Таң алдыннан ул яңадан йокыга талды. Кояшка җылынган хәтфә яфраклар аның йөзеннән үптеләр, колак артын кытыкладылар. Рөстәм төш күрде һәм яфраклар шаяруын әнкәсенең иркәләп сөюе дип уйлады.

Уянгач та, өйгә кайтып китәргә теләде. Абагаларны күрү аны бу уеннан туктатты. Алар аңа нидер әйтәләр. Рөстәмнән көләләр кебек тоелды. «Куркак ул, шүрләде, — диләр бугай, — курыксаң, бар кайт, куркаклар безгә кирәкми. Бүген төнлә без чәчәк атачакбыз», — диләр сыман алар.

Абагаларны күрмәс өчен, Рөстәм аларга арты белән борылды. Күз алдына әнисе килеп басты. «Кайт, улым! Ник кайтмыйсың? Без сине кичә көттек», — дип эндәшә, чакыра төсле. Рөстәм уйга калды. Ярый, кайтты ди ул. Ә: «Кайда кундың?» — дип сорасалар, ничек җавап бирергә? Алдаргамы? Иптәшемдә кундым дияргәме? Сөекле әнкәсенә ялган сөйләргәме? Юк. Рөстәм ялганлый алмый. Ялганлый башласа, аның йөзе кызара һәм барыбер тотыла. Ярый, ата-анасына ялганламады — дөресен сөйләде ди... Ә мәктәптә ни дип әйтер? Юк, юк, ни булса — шул булыр: кала ул, тагын бер төнгә урманда кала.

Рөстәм салкын чишмә янында учак якты, чәй кайнатып, тамак ялгарга утырды.

— Эш шәптән түгел! — диде ул, азыгын карап. — Туйганчы ашасам — бер ашауда бетерәм, азлап ашасам — өч ашауга җиткерәм...

Сохариларны ул өчкә бүлде, шуның бер өлеше белән иртәнге ашны уздырды. Аннары дөрес бүлмәдем, артыграк калдырдым бугай дип, теге ике өлештән янә бераз өлеш чыгарды. Чәй-шикәре юк иде, кружкага чәй урынына җиләк яфраклары салды, шикәр урынына тагын сохари алды.

Көн аңа гаҗәп озын тоелды. Салкын чишмәдә булу да, абагалар янында утыру да, кошлар сайравын тыңлау да аның күңелен күтәрә алмадылар. Мәктәбен сагынды. Төн тизрәк җитсен иде, ичмаса! Инде бүген дә абагалар чәчәк атмаса, ул бу урманга моннан соң мәңге аяк басмаячак.

Төнне тыныч каршылау һәм тизрәк каршылау өчен, Рөстәм йокларга ятты. Ләкин йоклыйсы килмәде. Әтисе аңа, йокы алмаганда, күзләреңне йом да ике йөзгә хәтле сана дия иде. Рөстәм күзләрен йомды һәм, сузып-сузып, берәү, икәү, өчәү... дип санарга тотынды.

**Гадел КУТУЙ**

*Дәвамы киләсе саннарда.*

*Хөрмәтле укучылар!*

*Бу санда без сезне Казан (Идел буе) федераль университетында эшләп килгән, бик күп язучы-шагыйрьләребезгә зур әдәбиятка юл ачкан, бай тарихлы «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсе әгъзаларының иҗаты белән таныштыруны башлыйбыз.*

***Редакция***



**Руфинә ГАБДРАХМАНОВА,**
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегендә V курста белем ала.*

***

Көз исеннән саташкан мизгелләр
Хәтердәме?
Казан урамнары
Безнең эздән
Тилергәндер.

Кафе һавасы,
вакыт үтсә дә,
хискә чыдам –
безнең илтифатсыз
җыр яңгырый:
«Good bye, madam!»

Аң төпкелен еш актаргандыр
хәтер иптәш:
соңгы көнгә йөгерепләр кайттым
иркәм киткәч.

...Бу дөнья безнеке иде күптән
Үз йортыбыз.
Уйладык:
Күктән өчкә биегрәк
без торырбыз.
Өнсез балконнарда безнең өчен
шәфәкъ сынды.
Кояшның актыгын яндырды,
кыздырды тынны...

Җанны телеп кергән
кәһвә исе
Синең янга
кайтарды мине –
хәтергә бер бөртек
рәхәт тамган.



**Айгөл АБДРАХМАНОВА,**
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегендә V курста белем ала.*

## Чана кайда?!

ХИКӘЯ

Биш яшьлек оныгы Рәзинәнең борчулы кыяфәт белән өй тирәсендә кайнашып йөргән күрсә дә, Әхәт бабай бер сүз дә дәшмәде. Кызчык исә үзенең күзәтү астында булуын бөтенләй дә сизмәде. Аның эше куәтле, дөресрәге, бик мәшәкатьле иде: чанасы, ике кыш буе яратып уйнаган кызыл бизәкле чанасы югалган бит!

Инде ярты сәгать вакыт узды – чана һаман да юк. Тик Рәзинә өметен өзмәде: әле гараж, әле келәт ишеген ачып, чанасы кача алырлык урын эзләде. Якын дусты сыярлык булмаса да, телевизор ише техникадан бушаган кәгазь тартмаларны да җентекләп тикшерде.

Кызчыкның кәефе торган саен кубрәк кырылды. Утын сарае – аның соңгы өмете иде.

Рәзинә янтая башлаган иске сарай каршына килеп басты. Ишек бер якка таба асылынган, тоткасы урынында – ике шөреп тишеге, ә кайчандыр зәңгәр төскә буялган, хәзер инде төсе уңган кечкенә тотка кар эчендә ята. Кызчык: «Моны ничек ачарга икән?!» – дип, бераз карап торды да ишек белән дивар арасында күренеп торган ярыкка нәни бармакларын тыкты. Бер чаты кар көртенә чумган ишек бик авырлык белән генә каерылып ачыла башлады. Әллә мультик геройларына охшарга теләп, әллә бик каты тырышканнан, йөзен чытты, кашларын җыерды Рәзинә. Эш шулай дәвам итсә, ишек берничә секундтан ачылган да булыр иде, бәлки, тик... Әллә каян килеп чыккан ала карга бөтен эшне бозып атты. Аның тамак төбе белән каркылдаган тавышыннан куркып, ишекне ычкындырганын сизми дә калды кызчык. Кечкенә йомшак бармаклар ике такта арасына кереп тә кысылды...

Тынлык...

Рәзинә: «Еларгамы, юкмы? Әллә кычкырыйммы икән?!» – дигән төсле, бер-ике секунд бармакларына карап торды да бар дөньяны яңгыратып елап җибәрде. Күзләреннән мөлдерәп аккан яшьләр шундый кайнар булдылар ки, карны гына түгел, аяк астындагы бозны да эретте. «Тып-тып-тып». Балавыз сыгу тагын бераз дәвам итсә, яз җиткән булыр иде, мөгаен.

Үзәк өзгеч тавышка, каушый-каушый, җитмеш биш яшьлек Әхәт бабай да килеп җитте. Башка чакта таягына таянып, бик сакланып кына йөрүче бабайның бу кадәр каударлануы читтән караганда кызык та, кызганыч та иде. Яраның җитди түгеллеген күргәч, карт җиңел сулап куйды һәм оныгын тынычландырырга ашыкты:

– Яле, тәти бармакларыңа өрим әле. Өф, өф. Бабаларның сулышы шифалы була ул, – диде бабай, шаян елмаеп.

Әллә авыртуы көчле булмады, әллә дәү әтисенең сулышы, дөрестән дә, килеште – Рәзинә «ә» дигәнче елавыннан туктады.

– Нишләп ул ярыкка кулыңны тыктың соң, кызым? Аны син түгел, атаң да саклык белән генә ача, – диде Әхәт карт. – Их, быел да яңа сарай төзи алмадылар шул! – дип көрсенеп куйды.

Кыз, дәү әтисенең кызгануыннан файдаланып, зарланырга тотынды:

– Дәү әти-и-и, – дип сузды ул, еламсырап. Шул арада, үзләренең чыгышларын көткән биючеләр кебек, соңгы яшь тамчылары күренде. Алар кызчыкның йөзендә тиз генә биешеп алдылар һәм эреп юкка да чыктылар.

– Дәү әти, минем чанам югалган! Бөтен җирдән эзләдем – беркайда да юк! – диде ул, борынын «мыш-мыш» тарткалап. Үзе шул арада тыпырчынып алырга да өлгерде.

Бабасы бер сүз дә әйтмәде, оныгын җитәкләп, капка төбенә таба атлады. Бакча рәшәткәсенә терәп үк ясалган агач эскәмиягә мамык юрган булып кар яткан иде. Карт аны ялан кулы белән сыпырып алуга, Рәзинә, бабасын уздырып, эскәмиягә менеп тә кунаклады. Дәү әтисенең йөзендә болыт астыннан чыккан кояш кебек елмаю барлыкка килде. Әллә оныгының өлгерлегенә куану иде бу, әллә әрсезлегенә аптырау – анысы аңлашылмады.

– Кызым, чанаңны соңгы тапкыр кайчан күрдең соң? – дип, чын тикшерүчеләр кебек, сүзен башлады Әхәт карт.

Рәзинә, яңа гына елап туктавын сиздереп, борынын тарткалап алды. Аннары, авызын турсайтып, саран гына:

– Кичә, – дип әйтеп куйды. Бу җавап дәү әтисен канәгатьләндермәгәнен сизеп булса кирәк, ашыга-ашыга: – Кичә Кече таудан чана шуып уйнаган идем, – диде.

– Ә аннары нәрсә эшләдең?

– Аннары бик каты ашыйсым килде, дәү әти. Өйгә кайттым.

– Алай икә-ә-ә-н, – дип сузды бабасы. – Ә чанаң? Аны алып кайттыңмы соң?

Кызчыкның зур булып ачылган һәм бер ноктага төбәлгән күзләренә караганда, чана Кече тау итәгендә калган. Ул, ишетелер-ишетелмәс кенә:

– Ю-у-ук, – дип сузды. Песи мияулавына охшаган бу сүздә хаталану ачысы да, аптырау да, гаҗизләнү дә бар иде.

– Әй, кызым, кызым, болай булгач, чанаң сиңа үпкәләгән инде. Синең кебек кечкенә балалар уенчыкларын комлыкларда, өй алдында яки урам уртасында гел онытып калдыралар. Шуңа күрә курчаклар һәм машиналар, хуҗаларын бик яратсалар да, алардан качып китәләр. Аларның үз әкият дөньялары була. Комлыкларда калган көрәкләр һәм чиләкләр шәһәр төзелешендә катнашалар, машиналар ком ташыйлар, ә курчаклар өй җыештыралар һәм ашарга пешерәләр.

– Ә чана? Чана нишли? – дип ашыгып, бабасын бүлдерде Рәзинә.

Тик кызчыкның соравы һавада эленеп калды – дәү әтисе, әле таягын, әле аягын күчерә-күчерә, ишегалдына кереп китте. Кыз, бабасына ияреп керергә, аптыратырга бик теләсә дә, урыныннан кузгалмады, чөнки дәү әтисенең мондый серлелеге артында һәрчак берәр сер яшеренгәнен белә Рәзинә. Ул, аякларын селки-селки, эскәмиядә утырып калды һәм чанасының Әкият илендә нинди эшләрдә катнаша алуын фаразларга тотынды: курчаклар, балаларын чанага утыртып, бакчага илтә алалар; Күрше абый кебек, елгадан су ташый алалар; курчакларның әби-бабалары авыр-авыр сумкаларын чанага куеп кайта алалар... Их, бик файдалы икән бит аның чанасы! Әкият илендәгеләргә бик рәхәттер инде хәзер!.. Тик минә Рәзинәнең үзенә дә бик кирәк бит ул!

– Ә синең чанаң...

Ишегалдыннан Әхәт картның ягымлы тавышы ишетелде. Бераздан тавыш иясе үзе дә чыгып җитте.

– Ә синең чанаң, – дип кабатлады бабай, – үзенең хуҗасын бик ярата. Син аны ташлап калдыргач та, Әкият иленнән үзе юл табып, өйгә кайткан.

Бабасының кулында кызыл бизәкле чанасын күреп, кызның кабарынкы иреннәре ике якка җәелеп китте, сөенечтән йөзе нурга күмелде. Күзләрендәге бәхет очкыннары салкын кышны да ямьләндереп җибәргән төсле тоелды.

Ул эскәмиядән сикереп төште дә:

– Дәү әти-и-и! – дип чыркылдый-чыркылдый, кулларын чәбәкләргә тотынды. Чанасын ташлап калдырган өчен оялу да һәм дусты табылганга шатлану да бар иде шушы ике сүздә.

Әле бабасын, әле чанасын кочаклаган кызның шатлыгы эченә генә сыярлык түгел иде. Ул чанасын тартып, Кече тауга чапты. Чананың әкият иленнән кайтуын әйтеп, дусларын да шаккатырасы, уенчыкларны бервакытта да ташлап калдырырга ярамаганлыгын бөтен балаларга да сөйлисе бар иде шул әле аның.



**Алсу САЛАХОВА,**
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегендә I курста белем ала.*

***

«Юк» диярга мең дә бер сәбәп бар,
«Әйе», – диям, чөнки яратам.
Казан автобусы бүген китә,
Ашык!
Мин аңарга билет таратам.
Казан автобусы бәхет шәһәренә
Иртән китә, сәгать алтыда.
Озак торыр өчен, Кояш булып кылан,
Көндез ян да, кыздыр, балкы да,
Кичен югал.
«Күтәрсенме?» – дисең, яшь тыгыла,
Ашык, жаным, инде ата таң!
«Юк» диярга мең дә бер сәбәп бар,
«Әйе», – диям, чөнки яратам.

# ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

## Төзәтә алмаслык хата

**SMSны укыгач, кыз бетте генә инде.... Анда өч кенә сүз язылган иде.**

«Мин башкага өйләнәм...» Әлеге коточкыч сүзләрне укыгач, Алия җансыз сынга әверелгән кебек катып калды. Кояш нурларыннан балкыган чалт аяз көнне кара болыт каплаган, аяк астында җир убылып, дөнья яшәешеннән туктаган сыман тоелды. Ул, мең төрле вак кисәкчекләргә бүленгән уйларыннан арынып: «Бу SMSны Айназ язмагандыр, кемдер безнең хисләребездән көләргә җыена», — дигән фикергә килде. Дөреслекне тизрәк беләсе килеп, кулы кесә телефонына үрелде. Күңелендә яшеренгән горурлык хисе аны бу гамәленнән тыеп: «Тукта әле, ул егет кеше бит, үзенең шалтыратуын көт», — диде. Әйе, бик дөрес, кыз бала үзенә генә хас булган тыйнаклыгын беркайчан да җуймаска тиеш. Аннары, әлеге сүзләр чын булса, бу хакта аңа Айназ үз авызы белән әйтеп карасын.

Көтелмәгән хәбәрдән башы әйләнгән вакытта күзе тәрәзәгә төште. Әүрамда бөтен дөньяны сафлыкка күмеп, җиһанны гүзәллек белән бизәп, ап-ак кар ява. Кар бөртекләре Алияне үткәннәргә, бары күңелле вакыйгалар белән хәтер сандыгында сакланган мәктәп елларына алып килде. Алия белән Айназ икесе дә бала чактан бергә уйнап үстеләр, мәктәп бусагасын тәүге тапкыр кулга-кул тотынышып атлап үттеләр. Озын кара чәчен үреп, ап-ак бантик тагучы мөлаем сыйныфташын ошату, якын итү хисе сабый вакыттан ук Айназның үзе белән бергә үсеп, чын мәхәббәткә әверелде. «5»ле билгеләренә укыган тырыш Алия генә үзе янында бөтерелгән малайларга артык игътибар итмичә, бөтен күңелен укуга бирде. Башында катлаулы мисаллар, әдәби әсәрләр генә булган кызның йөрәген яулау Айназга җиңел булмады. Алия гашыйк егеткә 11нче сыйныфта укыганда, район күләмендә үткәрелүче театр конкурсына әзерләнгәндә якынайды. «Әле кичә генә яз иде» спектаклендә төп рольләрне икесе бергә башкарганда, Айназның өмет чаткылары уйнаган күзләренә, нур балкыган йөзенә игътибар итте ул. Кулларының йомшаклыгы, тавышының ягымлылыгы, матур сөйләве кызның күңеленә сөю орлыклары салды.

Шул вакытлардан алар мәхәббәт диңгезендә пар аккошлар кебек бергә йөзделәр. Сихри айлы кичләрне, яшьлекнең гүзәл елларын күңелле үткәрделәр. Кирәк булса бер-берсе өчен гомерләрен бирердәй булып, ихластан сөеп-сөелделәр. Айназ программист, Алия чит телләр укытучысы дипломын алуга гомер юлларын мәңгелеккә бергә ниятләделәр. Максатларына ирешергә күп тә калмады, ярты елдан укулары тәмамланачак һәм гөрләтеп туй ясаячаклар. Көн саен мәҗлесне кайда, ничек үткәрү турында планнар корганда, кинәт Айназга ни булган соң? Нишләп аннан мондый акылга сыймас хәбәр килеп төште? Сөйгәненең шалтыратуын атналар-айлар буе өзелеп-өзелеп көтсә дә, юкка чыкты, югалды бердәнбере. Инде шалтыратуларын көтмәскә, йөрәгеннән алып ташларга тырышып йөргәндә, аннан башка яшәргә өйрәнгән көннәрнең берсендә, тулай торакның капка төбендә, Айназны очратты ул.

Аларның күзләре бер ноктада кисештеләр, икесенең дә беренче уйлаган уйлары нәкъ бертөсле булды: «Ник мин сине югалттым?» Сорауга җавап эзләп, кысып-кысып кочаклашу теләгеннән арына алмыйча, сүзсез озак басып тордылар. Алия аңлашырга тәкъдим ясаганнан соң, паркка таба атладылар. Үзләре яраткан парлы ак каеннарның икесе ике ягына килеп сөялгәч, Айназ Алиянең күзенә карамаска тырышып, кыюсыз гына сүз башлады. Аннан башка төнге клубка баруын, Казан кызы белән танышуын, очраклы очрашудан әлеге кызның бала көтүен, шул сәбәпле өйләнергә мәҗбүр булуын сөйләгәндә, Алиянең йөрәге күкрәк читлегеннән бәреп чыгардай булып ярсыды. Уйламыйча эшләнгән адымнан бәхетсезлеккә очраган егет үзенең беренче, гомерлек мәхәббәтеннән гафу үтенде:

«Мин туганнан бирле сине генә яраттым һәм соңгы сулышыма кадәр бары сине генә сөячәкмен!» — диде дә, чиксез соклану, сагыну хисләре кичереп, саклык белән озын чәчләрен сыпырды. Мөлдерәгән күзләреннән тамган ачы яшьләрен күрсәтмәс өчен, кинәт кенә борылып, башын аска игән килеш китеп тә барды.

Алиянең кадерле кешесенең юлына каршы төшәсе: «Мин синнән башка яши алмыйм!» — дип әйтәсе килде. Тик күз алдына ак биләүгә төрелгән гөнаһсыз сабый килеп басты. Айназның әле тумаган баласы, дөньяга аваз салганда ук: «Миңа әти кирәк, мин әтиемне беркемгә дә бирмим!» — дип кычкырадыр кебек тоелды. «Юк, юк, нарасый, әтиеңә тимим, аны синнән тартып алмыйм. Ул синеке, бары синеке», — дип кабатлый-кабатлый, яфрак ярырга бөреләнгән сылу каенны кочаклаган килеш тезләнде дә үрсәләнә-үрсәләнә елады. Канаты каерылган кош сыман өзгәләнгән Алия киләчәктә үзен тагын да көчлерәк яңа сөю, парлы бәхет көтәчәген, ә Айназның төзәтә алмаслык хата кылуын, зур югалтуын, мәхәббәттән башка корган тормышының чәлпәрәмә киләчәген әлегә белми иде...

**Динәрә ГЫЙЛЬФАНОВА,**
*Янил мәктәбенең 11 нче сыйныф укучысы,*
*Кукмара районы*

## Гомерлек үкенеч

**«Күрәчәгең булса, күркә талап үтерер» ди. Интернет аша танышуларны өнәп бетермәгән Алия үзе дә әлеге ысулның корбаны булырмын дип һич тә уйламаган иде.**

Язгы чәчәк кебек гүзәл яшьлегенең сизелмичә үтүенә борчылган Алиягә бүгенге замананың хикмәтләре кызык тоела. Чыннан да, кирәк-ярагыңны сатып алу, озын чиратларда торып түләүләреңне түләү өчен өеңнән чыгып торасы да юк. Кешедән калышмаска тырышып үткәрелгән туйлар, акчасы күп кешеләрнең чит илләрдә ял итүләре турындагы мәгълүматлар белән беррәттән нинди генә яңалыклар, мөмкинлекләр юк компьютерда. Алия дә эче пошканда аның янында төннәр буе утырганын сизми дә кала. Үзе кебек гаилә корырга азапланып йөргән яки өйләнеп тә парлы тормыштан бәхет таба алмыйча аерылган егетләрдән килгән SMSлардан да арыды. Интернеттан яхшы кияү табып булмасына шулкадәр ышанып, егетләрнең әле бер, әле икенче җиреннән гаеп эзләде. Берсенең буе кыска, икенчесенең чәче коела башлаган, өченчесенең мыегы килешсез, кичә танышырга тәкъдим ясаганының кесәсе сай кебек күренә.

Алия бу көннәрдә төшендә күргән татлы кичерешләре белән тәэсирләнеп, канатланып йөрде. Озын буйлы, түгәрәк йөзле чибәр егет белән зәп-зәңгәр диңгездә икәүдән-икәү көймәдә йөзделәр. Егетнең чем-кара күзләре өнендә күргән кебек күз алдында тордылар, аңа дип атап сөйләгән матур сүзләре колагында чыңладылар. Төштә күргән күңелгә ятышлы егет минем булачак тормыш иптәшемдер дип уйлады. Гадәттәгечә эштән арып кайтып фоторәсемнәр карап утырганда, бер сурәт аны таң калдырды, күңелен әсир итте. Бу — ул төшендә күргән егет ләбаса. Серле елмайган, йөзендә ниндидер сагыш сизелгән билгесез кешене җентекләп тикшергәннән соң, аның кем булуын белергә ашыкты. Егет Алмаз исемле, 33 яшьлек икән. Иң мөһиме, өйләнмәгән һәм ул да Казанда яши, Алиянең таләпләренә туры килә торган ир заты. Ул гомерендә беренче тапкыр үзе башлап Алмазга танышырга тәкъдим ясап хат язды. Озак та үтми, кыз күңеленә хуш килерлек җавап алды. Ул көнне алар бик озак аралаштылар. Күк йөзендә очкан кошлар кебек кыска хатлар ике арада назга сусаган җаннарның күңелләренә сары май булып ята бирде. Озакламый Алия белән Алмаз аралашулардан туган ләззәтле хисләрнең гашыйк булу икәнен аңладылар. Бер-берсенә шулкадәр нык якынайганнан соң, Алмаз үзендә мәхәббәте хакына очрашырга көч тапты. Алар, һәр гашыйк пар кебек, Бауман урамында күрешергә сүз куештылар.

Икесе дә чиксез дулкынлану белән, сәгать телләренең кичке алтыны сугуын көттеләр. Алия егетне атаклы галимнәр йолдызлыгы янында кулына чәчәк бәйләме тоткан килеш каршы алыр, бер-беребезнең җан җылыбызны тоеп, кичке шәһәр урамнарында йөрербез дип хыялланды. Машинасыннан төшүгә, ышанычлы адымнар белән тәүге очрашу урынына атлады. Бәхетле мәхәббәткә зур өметләр баглаган Алия Алмазны ерактан ук күзләде. Ул урында кемнедер көтүче бер кеше дә күренмәгәч, беренче күрешүгә үк соңга кала бит бу дип уйлады. Йөзләрендә нур балкыган гашыйкларның җитәкләшеп узып китүләренә сокланып карап торганда, үзенә таба килүче ике егеткә күзе төште. Имән кебек нык, сөйкемле ир затының коляскада утыруына, ә кыскарак, чандыр яшь егетнең аны этеп баруына игътибар итте ул. Алар нәрсәдер хакында сөйләшә-сөйләшә, елмаеп Алия янына килеп туктадылар. Ерактан күзләп китергән әлеге имгәкнең аның сөйгәне икәнен аңлаудан югалып калган Алия, «Сез мине, Алмазны, көтмисезме?» — дигән сүзләрен дә әллә кайдан, томан эченнән ишеткән кебек булды. Әйләнә-тирәсендәге бернәрсәне күрмәс, сизмәстәй булып катып калды. Менә сиңа ир булырга тиешле кеше диген ә! Аларның аралашулары көтелгәнчә түгел, салкын булды. Сүзгә-сүз ялгана алмау, югалып калуның сәбәбе дә нәкъ әнә шул каһәр суккан коляскада иде. Гарип булуын күргәч, Алиянең йөзендәге елмаюының эреп юкка чыгуын, ул кичергән хис-тойгыларны шунда ук аңлады Алмаз. Аерылышканда һәр икесе дә киләчәкләре юклыгына инанган иделәр. Яратса да, Алия Алмазны кабул итә алмады. Юл һәлакәтенә очрап аякларын җуйган Алмазның бердәнбер гомерлек яры, балаларының әтисе булуын теләмәде. Ул булачак тормыш иптәшенең үзе белән янәшә атлавын, аны кулларына күтәреп ЗАГСның баскычларыннан алып менүен көтте.

Алия мәхәббәтеннән баш тартып, киләчәктә үзе теләгән кешене очратуына өметләнеп яшәсә дә, төшендә күреп, интернет аша гашыйк булган Алмазны оныта алмады. Яраткан, кадерле кешесеннән башка тормыш кора алмаячагын аңлагач, язмышның тайгак юлларында ташлап калдырган Алмазны янә эзләп тапты. Тик соңга калуын аңлау аның йөрәген парә-парә телгәләде. Бәхетсез тормышында Алмазның юлына мәрхәмәтле, үзен аңлаучы, яратучы хатын-кыз очравын, малай белән кыз үстерүләрен белгәч, бик үкенде Алия. Тормышта хыялларыңа ирешер, бәхетле булыр өчен Ходайдан бирелгән язмышыңны узып алга да чапма, артта да калма икән...

**Илфат ӘХМӘДУЛЛИН,**
*Ядегәр мәктәбе директоры,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Кукмара районы*

## Мәңгелек сер

**14 февраль. Гашыйклар көне. Туй мәҗлесе тәмамланып, яшьләр өчен кунакханәдә алып куелган бүлмәгә кайтып керүгә, Илүсәнең телефонына SMS хәбәр килеп төште: «Мин сине һаман да яратам!»**

Яралы йөрәгендә Данияр дип язылган тирән эзләрне мәңгелеккә сызып ташлар өчен генә кияүгә чыккан Илүсә әлеге SMSны укыгач, тагын да күңелсезләнде. Кеше гомерендә бер генә мәртәбә була торган истәлекле, иң бәхетле булырга тиешле туй көне дә аның хәсрәтен юа алмады. Май кояшы кебек балкып торучы, шат холыклы кызның йөзендәге ямансулыкны кунаклар да сизенделәр. Бүгеннән тормыш иптәше булган Равилне яратмавын үзе бер генә кешегә әйтмәсә дә, сагышлы күзләре, кияү егетенә булган битарафлыгы бу хакта ачык сөйләделәр. «Мин аны ничек булса да онытырга тиеш! Әниемнең үтенечен аяк астына салып ташларга хакым юк!» — дигән гыйбарәне берөзлексез башында әйләндерде. Үзе теләмәсә дә, Илүсә өчен язмыш ачы сынау әзерләгән шул.

Уч төбе кадәрле генә йөрәген шулкадәр нык билэп алган мәхәббәт хисеннән

башы әйләнеп, үзен күкнең җиденче катында сизеп йөргән вакытта Сания апа Илүсәне янәшәсенә утыртты да, кулларын кысып, салмак кына:

— Кызым, кадерлем! Күңелемә тынгылык бирмәгән, җан көйдергеч хәсрәтемне тыңласаң һәм мине аңласаң иде, — дип сүз башлады. Әтисе Рәис белән яратышып өйләнешүләрен; тәүге мәхәббәт җимешләре булып Илүсәнең дөньяга аваз салуын; сөеп-сөелеп яшәгәндә, елан кебек шуышып килеп кергән хыянәтнең бәхетләрен җимерүен; иренең сөяркәсе яныннан кайтканын төннәр буе көтеп утыруларын; үзенең югалган йөзеген көндәшенең кулында күргәч, йөрәгенең әрнүләрен; төшке аш вакытында бергә каядыр китүләрен карап калганда гарьләнүләрен күз яшьләрен тыя алмыйча сөйләде. Илүсә әлеге коточкыч хәлләрне башына сыйдыра алмыйча, әнисен кызганып:

— Әнием, кем соң ул хатын? Мин аны беләмме? — дип сорады. Сания апа бер бөртек кызының йөрәген яралыйсын, аның гүзәл дөньясын җимерәсен белгәнгә, кыюсыз гына:

— Ул — Даниярның әнисе Тәнзилә, — диде. Илүсә, әнисе әйткән сүзләргә ышанмагандай:

— Нәрсә дисең? Әнисеме?! — дип кычкырып җибәрүен сизми дә калды. Ул кечкенә вакытта менә ни өчен өзгәләнә-өзгәләнә елаган икән әнисе. Шул мизгелдә ике кадерле кешесенең кычкыра-кычкыра талашулары, үзенең читтән генә куркудан дерелдәп карап торулары күз алдыннан йөгереп үтте.

— Әйе, аның аркасында күпме җәфа чиккәнемне үзем генә беләм. Очрашуларыгызны дәвам итеп, гаилә корырга уйласагыз, безнең саф хисләребезне, җылы мөнәсәбәтебезне урлаган шул карак белән туганлашыйкмы? Кодагыйлар булып бер табында чәй эчикме? — Әнисе, өстенә эссе су койган чебешкә охшап калган кызының алдына тезләнеп:

— Мине газап утларында яндырган шул хыянәтченең малае белән араңны өз, зинһар! — дип үтенде.

Илүсә телефонын сүндереп, бүлмәсенә кереп бикләнде дә төне буе күз яше түкте. Аның әтисенең якасына ябышып, Даниярның әнисенең битенә сугып: «Оятсызлар сез!» — дип әйтәсе килде. Сөюләренә киртә булган әлеге ике адәм затының Илүсә белән Даниярга гомер бүләк итүләре исә уеннан кире кайтырга мәҗбүр итте.

— Беркайчан да ташламам дип антлар иткән, үзен фәрештәләргә тиң күреп яраткан бердәнберемә аерылышу турында ничек аңлатыйм соң хәзер? Синең әниең кайчандыр безгә кайгы алып килгән, кеше гаиләсен җимерүче азгын хатынның малае белән очрашмавымны үтенде газиз әнием, дисенме? Әгәр дә дөреслекне әйтсә, үрнәк булырдай ана нинди сурәттә килеп баса үз баласының каршына? Данияр аны гафу итә, кичерә алырмы, бу авырлыкны ул ничек күтәрер? Юк, Илүсә беркайчан да аңа бу турыда әйтмәс. Нинди генә булса да, Тәнзилә апа аны якты дөньяга тудырган ана бит. Ул Даниярның яраткан кызын югалту газабыннан әнисенә карата нәфрәтләнүен теләми. Шуңа күрә бу аның мәңгелек сере булып калачак.

Илүсә соңгы очрашуга гадәттәгечә канатланып түгел, күңел әрнүләреннән нишләргә, күз яшьләрен тыярга ихтыяр көчен каян алырга белмичә барды. «Минем башка егетем бар», — дип ялганлаганда, нинди хисләр кичергәнен әйтеп-аңлату мөмкин түгел иде. Икесе дә аерылышуны авыр кичерделәр, төшләрендә бер-берсен эзләп, таба алмыйча тилмерделәр. Нишлисең бит, әти-әниләренең хаталары өчен балалары кыйммәт түләгән кешеләр җир йөзендә бер алар гына түгел. Илүсә бер-берсен онытырга ярдәм итүен, Даниярга бәхетле тормыш бирүен Аллаһы Тәгаләдән ялвара-ялвара сорады.

**Рәзинә ӘХМӘДУЛЛИНА,**
*Янил урта мәктәбенең татар теле һәм*
*әдәбияты укытучысы,*
*Кукмара районы*

# «Танымыш» дәресе

①



*Әхәт Гаффар*

②



*Җәвит Шакиров*

③



*Нури Арсланов*

④



*Нәбирә Гыйматдинова*

⑤



*Ленар Шәех*

*Үткән «Танымыш»ка дөрес җавапларны Фәнис Думави һәм Наилә Вилданова җибәргән. Икесенә дә «бишле» куябыз. Наиләгә исә – «плюс» белән, чөнки ул 4нче сандагы «Танымыш»ка да дүрт җавап биргән, дүртесе дә дөрес: Ркаил Зәйдулла, Җәүдәт Сөләйманов, Фирүзә Җамалетдинова, Ләйсәнә Садретдинова (2-5нче шаржлар. Беренчесен генә танып җиткермәгән ул). Матбугат ветераны Саимә Ибраһимовага да симез «бишле» куярга була. Соңгы санга дүрт дөрес җавап бирсә, 4нче санга җавапларының бишесе дә дөрес, хәтта Наилә танымаган Алмаз Хәмзинны да таныган ул. Илсөя Һадиева дүртәр дөрес җавап җибәргән. «Симез» «дүртле» дә шәп!*

①



②



③



④



⑤



*Шаржларның искеләренең дә, яңаларының да авторы шул ук:* **Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН.**

# Подписка өчен ipad һәм башка бүләкләр!



АҖ «ТАТМЕДИА»
газеталарына,
журналларына язылыгыз
һәм бәйгедә катнашыгыз!

**Бәйгедә катнашыр өчен өч һәм аннан да күбрәк басмага язылу кирәк. Акциядә катнашучы басмаларның исемлеген www.tatmedia.ru сайтыннан карый аласыз.**

**«Бәйге» билгесе белән язылган басмаларыгызның квитанция күчермәләрен Казан ш., Декабристлар ур., 2 яки podpiska@tatmedia.ru адресына җибәрегез. Элемтәгә керү өчен телефоныгызны күрсәтегез!**

**Тулы мәгълүмат һәм бәйгенең кагыйдәләре - www.tatmedia.ru сайтында.**

**Акцияне «ТАТМЕДИА» АҖ оештыра.**
Акция 2015 елның 15 апреленнән алып 30 июньгә кадәр дәвам итә.
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222 09 84 (1261)

16+ Реклама

# МӘКАЛЬ ӨМӘСЕ

*XXI гасыр мәкальләрен – авторлы мәкальләрне җыю дәвам итә. Шәпләрен китап итеп бастырып чыгарачакбыз.*

- Йокың симергән саен, рухың ябыга барыр.
- Миңа кирәк – мин тырыш, сина кирәк – тик торыш.
- Рухы чистаның юлы чиста.
- Таш тишәр өчен тамчыга чүкеч кирәкми.
- Чыпчык та үзенә күрә сандугач.

**Индус СИРМАТОВ**

- Ир белән хатын – тормыш көймәсенең ике ишкәге.
- Ялгыз башның җаны тыныч, эче буш.
- Әтәч, кукрайма, тавыктан башка синең кирәгең юк.

**Мансур ШАМБАЗОВ.**
*Түбән Кама*

- Ялкауның ялы бетмәс, телендә зары бетмәс.
- Премиясе булса, лауреатлар табыла ул.
- Тауның биеклеге менгәндә беленә.
- Хатын-кыз бизәнә-бизәнә матурлыгын җуя.
- Тәртип булмаган илдә геройлар күп була.
- Туры сүзе ахмак булса да хак.
- Монсыз күңел – мәнсез күңел.
- Җәллад булса, балта табыла ул.
- Тәкәләр сөзешми, патшалар сугышмый яши алмый.
- Гильотинаны башсыз кеше уйлап тапкан.
- Ялкау эт ятып өрер.
- Гомер буе ике кесәсендә ике йодрык йөртте...
- Бер туры өчен җиде куштан якаларын өзешкән.

**Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН**

*Сәрхушләр турында*

- Хәмерле тост – шайтанга бер дога!
- Аек таулар актарыр, исерек эчкәне белән мактаныр.
- Руль тоткан сәрхушнең юлдашы – Газраил.
- Хәмерле баш – мәкерле баш.
- Сәрхуш ата нәселне вата.

**Фаварис ГАЛИЕВ.**
*Балтач районы Смәел авылы*

## Мәкаль иясен эзлибез!

Бер авторыбыз мәкальләрен исемен куймыйча гына язып җибәргән. Бәйләнешкә чыксын иде ул. «Пароль» мәкаль: «Чөгендер суы как түгел, тәхетсез хан хан түгел».

# Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### БӨЕК ҖИҢҮГӘ — 70 ЕЛ

Республикабызда Бөек Җиңүнең 70 еллыгы зурлап билгеләп үтелде.

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында ТР Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миннехановның сугыш ветераннары һәм тыл хезмәтчәннәре белән традицион очрашуы булды. Анда 500гә якын сугыш ветераны һәм тыл хезмәтчәне катнашты.

Ирек мәйданында Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган тантанада ТР Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов ТР Дәүләт Советы, хөкүмәт, шәхсән үз исеменнән халкыбызны Бөек Җиңүнең 70 еллык юбилее белән котлады. Быел парадта беренче тапкыр хәрби техника катнашты. Аннары ретро автомобильләр колоннасы узды.

Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган тантаналарда ТР Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Премьер-министр Илдар Халиков катнашты.

### ОЧРАШУ

Татарстан Республикасы Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миннеханов «Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында республикабызның гаммәви мәгълүмат чаралары җитәкчеләре һәм федераль басмаларның үз хәбәрчеләре белән очрашты. Очрашуны ТР матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов алып барды.

Башта Р.Миннеханов очрашуда катнашучыларны элекке көнне ТРда билгеләп үтелгән Матбугат көне белән котлады, журналистларга рәхмәт әйтте. Сәгать ярым барган бу очрашуда гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләре Рөстәм Миңнехановка икътисадка, социаль сәясәткә, шул исәптән ТРның 2030 елга кадәрге социаль-икътисади үсеш стратегиясенә, авыл хуҗалыгына, кадрлар әзерләүгә, спортка, шәхсән үзенә кагылышлы күп кенә сораулар бирделәр.

### КАБУЛ ИТҮ

ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин ТР Матбугат көне уңае белән Котлавын ирештерде. Бәйрәм көнне ул республика гаммәви мәгълүмат чаралары җитәкчеләрен, журналистларны кабул итте. Бу очрашуда Ф.Мөхәммәтшин илдәге икътисади-сәяси вазгыять турында сөйләде, журналистларның сорауларына җавап бирде, бер төркем каләм әһелләренә ТР Дәүләт Советының Рәхмәт хатын тапшырды.

### ТАНТАНА

Казандагы «Корстон» үзәгендә «Бәллүр каләм» XVIII республика бәйгесенә йомгак ясалды. Бәйгенең колачы елданел киңәя бара. Быел аңа 2 меңнән артык гариза кергән. «Бәллүр каләм»нең быелгы яңалыгы шунда: 11 номинациядән тыш «Татарстанда мәдәният елы» һәм «Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгы» дип исемләнгәннәре өстәлгән. Болар — махсус номинацияләр. Аларның беренчесендә «Казан утлары» журналы җиңүче булды. Тантанада журналыбызның баш мөхәррире Илфак Ибраһимовка диплом тапшырылды.

«Бәллүр каләм» республика бәйгесенә йомгак ясау тантанасында ТР Премьер-министры Илдар Халиков катнашты.

### КОРЫЛТАЙ

Казанда Бөтендөнья журналистлар федерациясе тәкъдиме белән төрки дөнья журналистларының II корылтае булды. Беренчесе 2014 елда Төркиянең Искешәһәр каласында узган иде. Корылтайга Төркия, Азәрбайҗан, Төркмәнстан, Казакъстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Гыйрак, Сүрия, Молдова, Румыния, Болгария, Греция, Германия, Венгрия, АКШ, Англия, Канададан 60лап каләм иясе килде. Әлеге чара кысаларында гаммәви мәгълүмат чараларының төрки дөнья илләрендәге ролен күрсәтүгә, үзара тәҗрибә уртаклашуга багышланган семинарлар, «түгәрәк өстәл»ләр оештырылды.

### «ТАТМЕДИА»ДА ЯҢА КИТАПХАНӘ

Журналистлар, редакция хезмәткәрләре ТР Матбугаты көнендә зур бүләккә ия булды. «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең редакцияләр корпусында яңа китапханә ачылды. Дөрес, ул монда элек тә бар иде. Соңгы елларда эшләмәде. Аның фондында биш меңләп китап, журнал, газета исәпләнә. Монда XIX гасыр ахыры — XX гасыр башында чыккан сирәк басмаларны да очратырга була. Китапханә ачылу уңа-

еннан уткәрелгән әдәби салонда Татарстан Язучылар, Журналистлар берлекләреннән вәкилләр, редакторлар, җәмәгать эшлеклеләре катнашты.

## ЕЛ КИТАБЫ

Татарстан Милли китапханәсе ел саен иң күп укылучы китапларны ачыклый. Күптән түгел бирелдә «Ел китабы» бәйгесенә йомгак ясалды.

Милли китапханә, ТР Мәдәният министрлыгы, «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы тарафыннан оештырылган бәйгедә 219 китап катнашкан. 2013 елда басылып чыгып, 2014 ел дәвамында иң күп укылган китапны билгеләүдә республиканың 1541 китапханәсе катнашкан.

Чәчмә әсәрләр арасында җиңүчеләр болай ачыкланды:

I урын — Зифа Кадыйрова, «Бәхеткә юл кайдан»;

II урын — Нәбирә Гыйматдинова, «Үзем генә беләм»;

III урын — Гөлсинә Галимуллина, «Күгәрчен оя корганда». Факил Сафинның «Гөлҗиһан» китабы кызыксындыру бүләгенә лаек булды.

Тезмә әсәрләр номинациясендә җиңүчеләр:

I урын — Габдулла Тукай, «Актык тамчы яшь» (төзүчесе — Л.Шәехов);

II урын — Кол Гали, «Кыйссаи Йосыф» (төзүчесе — В.Камалиева);

III урын — Флёра Гыйззәтуллина, «Яңу дәверләрендә». Кызыксындыру бүләген Ләис Зөлкарнәйнең «Мәңгелектән исә җил» китабы алды.

Балалар әдәбияты номинациясендә җиңүчеләр:

I урын — Хәкимҗан Халиков, «Сакчы күркә»;

II урын — Нур Әхмәдиев, «Мырауҗанның туган көне»;

III урын — Шәүкәт Галиев, «Шәвәли шуклыгы». Алмаз Гыймадиевның «Телефонлы кәҗә» китабына — кызыксындыру бүләге.

Рус телендәге әдәби әсәр номинациясендә I урынны Равил Фәтхетдиновның «Бегущий от ада, или Господин уголовник», II урынны «Кот-воркот, Котофей Котофеевич — Мырау батыр» (төзүчесе — Л.Гыйззәтуллина), III урынны Әлфия Ситдыйкованың «Радуга Сабантуя» китаплары яулады. Альбина Әпсәләмова «Живая вода» китабы өчен кызыксындыру бүләген алды.

Раиф Мәрданов белән Ирек Һадиев төзегән «Татар китабы» басмасы «Татар телендәге публицистика һәм фәнни-популяр әдәбият» номинациясендә беренче булды. Шулай ук Равил Фәхретдиновның «Татар тарихы — История татар» китабы — II, Әнвәр Хәйринең «Әхмәд ибне Фадланның 921-922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе» III урынны яулады. Юныс Әхмәтҗановның «Татар халык ашлары» китабы кызыксындыру бүләгенә ия булды.

## ӘДӘБИ КИЧӘ

Әдәбият елы уңаеннан Мордовиянең Ләмберә районы үзәгендә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов, берлекнең идарә әгъзасы Мөдәррис Вәлиев мәктәп укучылары белән очраштылар. Очрашуда район җитәкчеләре, укытучылар, китапханә хезмәткәрләре дә катнашты.

## ЮБИЛЕЙ

Язучы-публицист, журналыбызның актив авторы Фирдәвес Хуҗинга 60 яшь тулды. Бу уңайдан аның туган ягында — Алабуга районы Илмәт авылында иҗат кичәсе уткәрелде. Шундый ук кичә Алабуга Мәдәният йортында да булды. Бәйрәмдарны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов, Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, язучылар Зиннур Мансуров, Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Рәшит Бәшәр, Әлфия Ситдыйкова котлады.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» — ТҮБӘН КАМАДА

«Казан утлары» журналының иҗат төркеме Туфан Миңнуллин исемендәге Түбән Кама дәүләт драма театрында әдәби кичә уткәрде. Журналның баш мөхәррире Илфак Ибраһимов басманың туган телебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калуда, милли мәдәниятебезне үстерүдәге роле, мәсләге, редакциянең киләчәккә эш-планнары турында сөйләде. Кичәдә Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, Татарстанның халык язучысы Марсель Галиев, журналның баш мөхәррир урынбасары Рамил Ханнанов, Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, бүлек мөхәррирләре Айгөл Әхмәтгалиева, Фәнил Гыйләҗев чыгыш ясады.

Шул ук көнне Түбән Камада мәктәп укучыларының әдәби бәйгесенә йомгак ясалды. Җиңүчеләргә Разил Вәлиев премияләре бирелде. Быел бу бүләк 17нче тапкыр тапшырылды. Әлеге чараларда Түбән Кама муниципаль районы башлыгы урынбасары Эльвира Долотказина, шәһәр башлыгы киңәшчесе Фирдәвес Ханов, Бөтендөнья татар конгрессының Түбән Кама бүлеге җитәкчесе Рөстәм Ганиев, Түбән Кама педагогия колледжы директоры Фәйрүзә Манихова катнашты.

## ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

Татарстан Республикасы дәүләт үсешенә лаеклы өлеш керткәне, актив җәмәгать эшчәнлеге өчен ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары **Ратникова Римма Атлас кызы** ТРның «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: роман А.ХАСАНОВА «Где гнездится счастье»;
литературно-документальная повесть Ш.ХАНИФОВА «Остаться человеком»;
поэма М.МИРЗЫ; стихи М.ГАЛИЕВА, Л.ШАГИРЗЯН.
«100-я страница»: Ф.САФИН. «Ещё не прошёл угар войны».
«Искусство»: беседа И.Ибрагимова с ректором Казанской государственной консерватории Р.Абдуллиным.
«Память»: А.ШАМОВА. «Ваши судьбы связаны с огнём войны»;
Л.ХАМИДУЛЛИН, Б.ХАМИДУЛЛИН. «Тяжёлый путь к победе».
«Наши юбиляры»: статья Ф.ХАТИПОВА «Литературно-теоретический мир учёного»;
статья Р.СВЕРИГИНА, посвящённая 100-летию со дня рождения Г.Халита.
«Книжное обозрение»: рецензии Р.ГАТАШ, Ф.МУСЛИМОВОЙ.
«Слово читателя»: А.КАШАПОВА. «Тёплые лучи «Казан утлары».
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
«Белый парус»: Г.КУТУЙ. Повесть «Приключения Рустема» (прод.);
стихи Р.ГАБДРАХМАНОВОЙ, А.САЛАХОВОЙ; рассказы А.АБДРАХМАНОВОЙ, Д.ГИЛЬФАНОВОЙ, И.АХМАДУЛЛИНА, Р.АХМАДУЛЛИНОЙ; «Узнавайка».
Из фотоархива журнала. Рубрику ведёт Р.ФАЙЗУЛЛИН.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Сабантуй». Художник – И.Муртазин; Ленинский сад Казани.

# IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: novel by A.HASANOV «Where happiness breeds»;
literary and documentary story by SH.HANIFOV «Stay human»;
poem by M.MIRZA; verses by M.GALIEV, L.SHAGIRZYAN.
«100th page: F.SAFIN. «Frenzy of war has not passed yet».
«Art»: conversation of I.Ibragimov with the rector of the Kazan State Conservatory R.Abdullin.
«Memory»: A.SHAMOVA. «Your fates are linked with the fire of war»; L.HAMIDULLIN, B.HAMIDULLIN. «Heavy road to victory».
«Our heroes of the day»: Article by F.HATIPOV «Literary-theoretical world of the scientist»; article by R.SVERIGIN dedicated to the 100th anniversary of G.Halit.
«Book review»: reviews by R.GATASH, F.MUSLIMOVA.
«Reader's word»: A.KASHAPOVA. «Warm rays «Kazan Utlary».
«Pages of humor»: section is led by M.GALIEV.
«White Sail»: G.KUTUY. Story «Rustem's adventures» (cont.); poems by R.GABDRAHMANOVA, A.SALAHOVA; stories by A.ABDRAHMANOVA, D.GILFANOVA, I.AHMADULLIN, R.AHMADULLINA;
«Find it out».
From photo archives of the magazine. Section is led by R.FAYZULLIN.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Sabantuy». Artist I.Murtazin; Leninsky garden of Kazan.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Сабантуй» картинасы. *Рәссам — **Илдус Мортазин**.*

*Тышлыкның дуртенче битендә:* Казандагы Ленин бакчасы.



*БДБ илләре җитәкчеләренең Казанда үткән саммиты. 2005 ел.*

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

2015
Парклар һәм
Скверлар елы



Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал